ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2008



# “КАЗАН УТЛАРЫ” 2009 ЕЛДА

## Журналыбызга тәкъдим ителгән кайбер әсәрләр:

**Нур Әхмәдиев**. (Мөнирстан. *Роман)*, **Рәмзия Габделхакова**.(Тау артында кояш бар. *Роман)*, **Альберт Хәсәнов**. (Данәгөл. *Роман)*, **Сәгыйдулла Хафизов.** (Сәрви–Сәрвиназ.*Повесть)*, **Фәнзаман Баттал**. (Сатирик хикәяләр) һ.б.

**Әхсән Баян, Шәүкәт Галиев, Фәнис Яруллин, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллин, Зиннур Мансуров, Газинур Морат** һ. б. шигырьләре һәм поэмалары.

Күренекле галимнәребездән **Миркасыйм Госманов, Адлер Тимергалин, Әгъдәс Борһанов**ларның тарихи–публицистик язмалары, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр **Хатыйп Миңнегулов, Тәлгат Галиуллин, Рафаэль Мостафин, Фәрит Хатыйпов, Марсель Бакиров, Рифат Сверигин, Дания Заһидуллина, Фәрит Бәширов, Илшат Вәлиулла**ларның мәкаләләре дөнья күрәчәк.

Журналда драматургларның яңа пьесалары, сәнгать белгечләренең күренекле шәхесләребез турындагы язмалары, иҗтимагый–мәдәни тормышыбыз хроникасы, юмор–сатира әсәрләре дә урын алачак.

Шулай ук **Нурихан Фәттах, Әхмәт Рәшит** истәлекләре, **Гомәр Бәширов** көндәлекләренең дәвамы, “Авылларыбыз тарихы”, “Татар энциклопедиясе” битләреннән һ. б. кызыклы язмалар белән таныша аласыз.

***Бу санда киләсе елда басылачак әсәрләр хакында тәфсилле алхәбәрләр бирелгән.***

# Казан утлары
# Qazan utları

2008

11
(1033)

<u>ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:</u>

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

<u>НАШИРЕ:</u>

*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*



*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**


---


✉: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир—292-38-60.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.*
*Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.*
✆: **Факс**—*(843) 541-38-77.*
💻: **E-mail:** *kazanutlari@telebit.ru.*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


Бу санда


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Салисә ГӘРӘЕВА. Аккош канатыдай ак болыт... *Шигырьләр.* ... 5
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Кош булып очар идем... *Роман.* ... 11
Радик ФӘИЗОВ. Ат карагы. *Хикәя.* ... 87

**ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВКӘ 80 ЯШЬ**

Шәүкәт ГАЛИЕВ. Мәңгелек утны да мизгел кабыза... *Багышлаулар.* ... 49
Нил ЮЗЕЕВ. Балаларга шатлык өләшүче ... 120

**ДРАМА ӘСӘРЕ**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Дивана. *Ике пәрдәле драма* ... 59

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Резеда ГОБӘЕВА. Югалмабыз. *Шигырьләр.* ... 82
Людмила АЛАНЛЫ. Без эзләгән Бәхет. *Шигырьләр.* ... 84

**ӘДӘБИ МИРАС**

Шамил АНАК. Көзге сары яфраклар. *Медитацияләр.* ... 93
Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. "Нәһҗел-Фәрадис" турында ... 170

**ХӘТЕР**

Нурихан ФӘТТАХ. Беренче шигырь күк балачак. ... 98
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр.* ... 173
Гомәр БӘШИРОВ. Күңел дәфтәре. ... 145

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Тәфкил ВАФИН. Мәкруһлар ... 109

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәнзаман БАТТАЛ. Безне беләләрме? ... 124
Марат ШӘЕХОВ. Латыйфи романнары. ... 130
Ләйлә МИНҺАҖЕВА. Шигърияттебездә Истанбул образы. ... 140

**СӘНГАТЬ**

Канәфи Нәфыйковка 70 яшь. ... 162

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 165

Безнең күргәзмә. ... 163
Заһидулла Яруллинның тууына 120 ел. ... 162
Алхәбәрләр ... 31–186
Госман ГОМӘР. Шәхесләр һәм шәрехләр. ... 179
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 188

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": Роман Р. МУХАМАДИЕВА "Взлететь бы птицей...",
рассказ Р. ФАИЗОВА "Конокрад", стихи С. ГАРАЕВОЙ.
"Драматургия": Т. МИННУЛЛИН. "Сумасшедший". Драма.
"Творчество молодых": стихи Р. ГУБАЕВОЙ, Л. АЛАНЛЫ.
"Литературное наследие": Ш. АНАК. Медитации; статья Х. МИННЕГУЛОВА.
"Память": Н. ФАТТАХ. "Детство — как первый стих" (продолж.), А. РАШИТ.
"У каждого своя судьба"—воспоминания. Г. БАШИРОВ. "Дневнековые записи".
"Публицистика": Т. ВАФИН. "Отпавшие", Ф. БАТТАЛ. "Знают ли нас?"
"К 80 летию Ш. Галеева": стихи Ш. ГАЛЕЕВА, статья Н. ЮЗЕЕВА.
"Литературная критика": М. ШАИХОВ. "Романы Ф. Латыфи"; Л. МИНГАЗОВА.
"Образ Истанбула в поэзии".
"Искусство": к 70 летию К. Нафикова.
"Наука": Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень" (продолж.).
Наш календарь.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Древние тюрки. Клятва Хана. Картина К. НАФИКОВА;
писатель Захид ФАЙЗИ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": novel by R. MUHAMADIEV "Fly up like a bird...",
story by R. FAIZOV "Horse-rider", S. GARAEVA. "Dramatic art":
T. MINNULLIN. "Madman". Drama.
"Youth's creativity": verses by R. GUBAEVA, L. ALANLY.
"Literary heritage": SH. ANAK. Meditations; article by H. MINNEGULOV.
"Memory": N.FATTAH. "Childhood as first verse" (continuation), A. RASHIT. "Every has his destiny" — memoirs. G. BASHIROV. "Ancient records.
"Publicism": T.VAFIN. "Fallen away", F.BATTAL. "Are we known?"
"To 80th anniversary of Sh. Galeev": verses by Sh. GALEEV, article by N. YUZEEV.
"Literary critics": M. SHAIHOV.
"Novels by F.Latyfi": L. MINGAZOVA.
"Istanbul image in poetry".
"Art": to 70th anniversary of K. NAFIKOV. "Science": F. GARIPOVA. "History of our villages" (continuation).
Our calendar.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Ancient Turkishes.
Khan's oath. Picture by K. NAFIKOV; writer Zahid FAYZI.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.10.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–1438 Тираж 4788.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Салисә
Гәрәева

# АККОШ КАНАТЫДАЙ АК БОЛЫТ...

## Ватан

Тау битләре, киртләч кыялары,
Миасс үзәннәре түреннән
Мин Казанга кайттым—Ураллардан
Алтын бишек булып күренгән!
Анда калды зәнгәр күзле күлләр,
Корыч кайнап торган мартеннар;
Өмет белән Хыял гына кайтты
Казаныма минем артымнан.
Мәңге эштән яргаланган куллы,
Тыйнак, сабыр, моңлы татарым,
Миңа бәхет вәгъдә итмәдең син,
Тының белән тартып кайтарып!
Мин барына риза-бәхил, Илем,
Туфрагыңда шыткан орлыгың.
...Яши-яши тирән аңладым мин
Ватан дигән сүзнең зурлыгын!..

## Татар туганнарым

Кай ягында йөрмә җир шарының,
Таулар калка, ага елгалар,
Һәм кайдан да дөнья юлларыннан
Татар туганнарым чыгалар...

Язмыш җиле каерып алып киткән
Туганнарны безнең Иделдән;
Күргән халкым—чукынудан качкан,
Җирсезлектән, ачтан тилмергән;

Сугышлардан, янаулардан туйган,
Гаҗиз булган янгын көленнән;
Телен, динен, җанын саклар өчен
Ерак киткән туган җиреннән!..

Кайда да ул хаклык эзләп йөргән,
Чисталыкка, Моңга табынган,
Һәр гасырда аның батырлары,
Шагыйрьләре, даны табылган!..

Ул яшәгән җирен гөлгә күмгән,
Эшләп тапкан хәләл икмәген;
Мин үзем дә шул халыкның кызы—
Бәхетемне күктән көтмәдем!

Кай ягында йөрмә Җир шарының—
Таулар калка, ага елгалар,
Һәм кайдан да юлга нурлы йөзле
Татар туганнарым чыгалар!..

## Вәхи

Утта яндым, суда баттым,
Сикердем кыялардан,
Юктыр, миндәй, язмышыннан
Шулкадәр кыен алган!

Күкләрдә очтым, болытка
Ятып йөздем майларда.
Канатлы шигъри аргамак
Илтте әллә кайларга!

Киек каз юлларын кичтем,
Сары айга атланып.
Еладым, кайткач илемә,
Чирәмнәргә капланып.

Ишеттем Күкләрдән вәхи;
—Тәкъдирең шундый, бала!
Хезмәт. Газап. Ләззәт өчен,
Шигъри юллар тезмәк өчен
Яратты сине Алла.
Тәкъдирең шундый, бала!

## И ул көйләр...

И ул көйләр, күктән иңгән көйләр!
Минем өчен генә түгелгән!
Тирбәлгәндә шул көй дулкынында
Бөтен гомер үтә күңелдән.

Кояш тулы, чәчәк тулы алан,
Урманнарның яшел сулышы!
Чак беленгән сукмак буйлап барам,
Абагалар белән сугышып.

Килеп чыгам тын күл ярларына,
Төнбоеклар анда сарыдан.
Пар аккошлар күккә күтәрелә
Күл өстеннән. Ап-ак бары да!

Мәхәббәтем иңә хәтеремә,—
Пар канатлар чыкты диярсең!
Мондый илдә, мондый гүзәллектә
Янып-шашып ярлар сөярсең!

И ул көйләр! Һаман яңрап тора,
Әллә кая дәшә Күкләрдән.
Яшәү дәрте, яшьлек мәхәббәте
Гарешләргә мине күтәргән...

Сихри моңнар ява Күкләрдән!..

## Болыт йөри

Болыт йөри. Йә сибәләп китә,
Йә, яшенләп, коя яңгырын.
Еракларга, йомылып, агып китә,
Күләгәсен җирдә калдырып.

Йә тарала таулар түбәсеннән,
Ак канатлы кошка әйләнеп.
Ашыкмыйча коя алларыма
Җыеп бетермәслек сәйләнен!

Болытлары кайгы булып килә,
Күксел кара шәлен ябынып.
Тыя алмаслык айгыр булып килә,
Ялы гына кала чалынып...

Гөл таҗына кунган чык энҗесе—
Явар яңгырларның дымы ул.
Болыт йөри. Моңлы йөрәгемнең
Күккә ашкан кайнар тыны ул.

## Рәхмәт хисе

Тын кырларда башак серләшүе...
Бытбылдыклар тынган. Җил дә юк.
Шундый авыр бодай башаклары!...
Мондый тынлык башка җирдә юк.

Туган кырлар! Сезнең җилегез дә
Итагатьле, сабыр, әдәпле.
Басуларга чыктым, истә тотып
Борынгыдан калган гадәтне.

Тирбәлегез! Мин дә, буем бөгеп,
Башыгыздан сыйпап сөярмен:
—И, туган җир! Икмәк—суың өчен ,
Мәңге бурычлы мин!—диярмен.

Бар булганым белән яшим синдә.
Үткәннәрем—артта, хәтердә.
Бар йөрәгем, кальбем, җаным-тәнем
Тели сиңа рәхмәт әйтергә!..

## Кичер мине, тәңрем

Гөнаһларым күптер, бихисаптыр—
Иман камил алар барлыкка!
Кичереп мине, сал бер рәхмәтеңне,—
Гөнаһларны, Тәңрем, ярлыка!
Җирдә шыткан үлән кыягыдай
Гади кеше—инсан, хатынмын,
Сүзсез аңлыйм ата-ана уен,
Мәхәббәт, ир, бала хакын мин.
Чистарасым килә җаным белән!
Сәламәт ит,Тәңрем, тәнемне!
Оныт берүк яшьлек елларымда:
Мәңгелек мин, дигәннәремне.
Тәкәбберлек хастыр кешеләргә,
Мактану да эчтә яшидер,—
Гармун уйнау, җырлау, биюләр дә
Вәсвәсәдер—шайтан эшедер!..
Гайбәткә дә искәрмәстән генә
Кушыламдыр, бәлки, сүз җөпләп.
Гамьсез-нисез, гади бер кыз булып
Яшәгәнмен шулай ничекләр?!
Айга карыйм—Айда таплар күрәм,—
Бәлки,Ул да гөнаһ кылгандыр:
Илаһи көч Күккә ашырганчы
Гөнаһлы бер хатын булгандыр?!

## Без—сер

Без—кайтаваз, яңрау, тау иңрәве.
Без—сер. Язның зәңгәр тыны без.
Таулар тишеп аккан чишмәләрнең
Кабатланмас көмеш чыңы без!
Зәңгәр томан белән эретелгән
Серле күл без җәйге таңнарда.
Иң саф җанлы, сирәк ир-егеткә
Җаныбызны язган аңларга!
Салкын Акыл түгел—уй иярмәс
Фикер чуалган бер йомгак без—
Хатын-кызлар!
Гел үз юлын эзләп,
Табалмаган юлчы сымак без!
Көлдә калган утлы куз шикелле
Без янарга әзер җилдән дә!
Юл яздыру безгә берни түгел,
Арттан Язмыш куып килгәндә...
Яшен яшьнәп, яңгыр яуган чакта,
Күк күкрәве шартлап сынганда—
Сәер чакта мин хатын-кыз булам,
Бар Табигать уйга чумганда,
Һәм яратам сине, көтәм сине,
Тормыш бирер өчен balaңа!
Эндәш миңа, кайтавазың итеп
Башкалардан аер, арала, -
Кайтавазың итеп кара да!..

## Китәбез

Яшь агачлар яшел яфракларын
Яшь җилләрдә тора, уйнатып:
Гүя киткәннәрне, көткәннәрне,
Киләчәкне тора уйлатып.

Гомерләре кыска—яздан көзгә
Җитәләр дә, яфрак коялар!
Тамырларны кышка әзерлиләр—
Җимеш өлгерүен тоялар...

Без яшибез—өмет итәбез.
Көтмәгәндә... бакый китәбез.

## Дусларым

Якты дөньларны ташлап киткән
Сайлап алган соңгы дуслар да.
Сезнең рухка хәер өләшергә
Калдым ахыры салкын кышларга.

Бар дөньяга игълан итәр идем
Исем-атыгызны яңратып:
Чөнки һәркөн бер дә онытмыйча
Искә алам сезне, яратып.

Йолдыз булып җиргә карагыз.
Җәннәт түрен безгә юрагыз!

## Нинди хозур җир

Нинди хозур кояш тулы дөнья!
Сулар ага, яфрак пышылдый!
Бу авазлар—Җиргә мәдхия ул,
Син дә безнең сүзгә кушыл!—ди.

Бөҗәкләрнең хәрәкәттә чагы.
Сандугачлар бала ашата.
Кырмыскалар дәррәү йөк ташыйлар.
Дым суыра җирдән башаклар...

Дөнья тере, дөнья хәрәкәттә –
Авазлары хуш та, тыйнак та!
Шул мәңгелек чорлар агышында
Без, кешеләр, бары кунакта!

Чал Вакытның бу—туктаган мәле
Күләгәдә черем итәргә.
...Җил дә базмый гүя чәчәкләргә,
Яфракларга тиеп үтәргә!..

## Йөрәгемдә скрипка елый

Йөрәгемдә скрипка елый,
Галәмнәрдән көчләр иңә дә!
Үз җаныммы? Минем җанымнанмы?—
Кемдер әллә ниләр инәлә!..

Күңелемдә чишмә тамагында
Сулкылдаган моңдай өннәр бар!
Айдан—сагыш, йолдызлардан—тылсым
Чыңлап—сызлап иңгән төннәр бар!

Ә кайчакта гобой инәлүе
Дәшә кебек офык артына:
Борынгыдан килгән чакырулар
Дулкынына җаным тартыла!..

Кыйтгаларны кичеп, яңа чикләр
Аръягына килә чыгасым:
Әллә нинди шомлы сере белән
Сискәндерә мине бу гасыр!

Йолдызлы моң эчеп, давылларда
Сөңге аткан яшен эзеннән,
Әй, очасым килә Галәмнәргә –
Алга ыргып үзем үземнән,

Сөңге аткан яшен эзеннән!...

## Нида

Туган җирнең зәңгәр күкләрендә
Аккош канатыдай ак болыт.
Йөзеп бара ачык зәңгәрлектә,
Пегас дигән шигъри ат булып.

Миннән китеп бара шигъри атым,
Тезгененнән тотар әмәл юк!
...Күктән аваз килә: Шигърияттә
Ихлас булсаң гына Әҗәл юк!
Ихлас булсаң гына Әҗәл юк!..

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

*Бу айда танылган шагыйрә, журналыбызның күптәнге авторы Салисә Гәрәеваның юбилей бәйрәме. Шигърияттә Урал ягы аһәңнәрен, туган җир моңнарын, хатын-кыз язмышының гаҗәеп үзенчәлекле тасвирларын тудырган шагыйрәне күпсанлы укучыларыбыз исеменнән котлыйбыз, яңа иҗади куанычлар телибез.*



Ринат
Мөхәммәдиев

# КОШ БУЛЫП ОЧАР ИДЕМ...

РОМАН

## 1

Ул җәйне Нәгыш тавы итәгендә җир җиләге сыдырылып унган иде. Савытларын хуш исле җиләк белән тутыргач, малайлар чишмә читендәге яшел чирәм өстендә хәл алырга булды. Хәл алу дигәннәре дә шул—йөзтүбән ятып җиләк яфраклары, кыр чәчәкләре исеннән бертын хозурлангач та, мәтәлчек ата-ата уйнарга керештеләр, көрәштеләр һәм туйганчы аунадылар.

Кояш кыздыра. Төш вакыты якынлашып килә икән инде. Ерак түгел генә, Таулар авылы тарафыннан, көтүче чыбыркысы шартлаганы ишетелеп алды. Анарга җавап итеп, "нигә рәнҗетәсең инде" дигәндәй, сузып-сузып кемнеңдер сыеры мөгрәп куйды.

—Малайлар,—дип дәште шунда чалкан ятып карашларын галәмгә текәгән Рафаэль,—бу күк нигә шулай серле икән? Зәп-зәңгәр... Һәм шундый биек...Моның бер-бер чите бармы икән?.. Булса, ул зәңгәр күкнең аргы тарафларында ниләр бар икән...

—Тапкансың баш ватарлык нәрсә,—дип, ятып чишмәдән су эчкән җиреннән башын калкытты Фәрваз.—Нәрсә булсын, йә Уфа, йә Казан дигән шәһәрдер инде. Ерак булганга гына ул бит шулай зәңгәр булып күренә...

—Һәй надан. Уфа белән Казан күктә була димени?! Минем абый әйтә, җир ул шар кебек икән. Бөтен авыл һәм шәһәрләр шул шар өстендә урнашкан,—дип, күбәләк куып йөргән Нурулла кушылды сүзгә. Авыл малайлары аны, үз итеп, Нурый дип кенә йөртәләр иде.

—Әкият,—дип, өзде аның сүзен Фәрваз.—Шар булса, аның аскы ягында нәрсә була инде синеңчә?

—Һәр тарафында да кешеләр яши, дип әйтә минем абый. Ул белә инде—ул җиденче класста укый. Гел бишлегә генә... Авыллар, шәһәрләр һәм елгалар, диңгезләр уратып алган икән ул Җир шарын. Минем абый шулай дип әйтә, ул ялганламый, дөресен сөйли—ул бөтен нәрсәне белә.

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ (1948)—*язучы, тәнкыйтьче һәм җәмәгать эшлеклесе; "Кенәри—читлек кошы", "Сират күпере", "Утлы таба өстендә", "Алланың кашка тәкәсе" романнары һәм күп кенә повестьлар, хикәяләр авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Мәскәүдә яши.*

Иhahайлап көлеп җибәрде Фәрваз.

—Абыең сиңа кызык итеп кенә сөйләгәндер аны, олылар сөйләгән бөтен әкияткә ышансаң... Шыттыра ул синең абыең. Үз башың белән уйлап кара. Соң ул авыллар һәм шәһәрләр шарның аскы ягында ничек асылынып торырга тиеш? Синең абыең сөйләде дип кенә булмый ул, тәк шту безнең башка да тай типмәгән. Кешеләрнең аяклары өстә, башлары аста була аламы? Соң, малайкай, син дигәнчә булса ул диңгез-елгаларның суы әллә кайчан түгелеп беткән булыр иде инде. Вәт тәк...—дип тә өстәп куйгач, тәмам күңеле булды аның.

Рафаэль аларның сүзенә катышмады. Тыңлап кына ятты. Бер уйласаң, икесе дә дөрес сөйли кебек. Җирнең шар кыяфәтендә булуы турында аның да ишеткәне бар барын, әмма бу калкулык һәм үзәннәрне шар өстендә итеп күз алдына китерүе кыен. Ул бит, әнә, тип тигез, әллә кая—офыкларга тикле сузылган... “Ничек ул шар өстендә кеше яши алсын икән, аны бит әле әйләнә дә дип әйтәләр! Соң алайса, гел нәрсәгәдер тотынып кына йөрергә кала түгелме соң? Кызуырак әйләнеп китсә, очып барып төшүең дә бар...”

Шуңа бу бәхәскә катышмауны кулайрак тапты ул. Аннан, Җир—ул әллә кайда түгел, аяк астында гына. Житәр вакыт, бераз үсә төшкәч ул әле аны үз аяклары белән дә йөреп чыга алачак. Шармы ул, түгелме—ачыкланыр... Ә менә зәңгәр күк... Аның серләрен, анда ниләр барлыгын күргән кеше бармы икән?.. Шунда менсәң иде дә, үз күзләрең белән барысын күрсәң иде ул.

Фәрваз белән Нурый күпме генә бәхәсләшеп тә Җирнең шармы-түгелме икәнлеген ачыклый алмадылар ул көнне. Өч дус, өч авылдаш, тамаклары ачыкканга түзә алмыйча, хуш исле җиләк тулы савытларын кулларына алып өйгә кайтырга чыктылар. Кайтыр юл ерак түгел, аларның туган авылы—Яңа Актау, әнә анда гына, Бәхтияр чокырының аргы ягында нарат һәм каен урманнарына елышып урнашкан.

Ара-тирә генә сүз алышып, әлсерәүдән башларын салындырып җиләктән кайтып килүче яланаяклы, такыр башлы бу өч малай шунда бөтенләй көтелмәгән бер вакыйгага тап булыр дип кем уйлаган. Сигез-тугыз яшьлек малайлар өчен генә түгел, үз заманы, ягъни 1936 елның җәе өчен, бу якларда өлкәннәрнең дә төшенә кермәгән вакыйга иде ул.

Гел уйламаган җирдән, һавада очкан сабан тургае сайравын, үлән арасына качкан чикерткә авазларын бүлеп, Нәгыш тавы аръягыннан гомер ишетелмәгән сәер бер гөрелте янгырый башламасынмы шунда. Ул башта тоныкк кына янгырап ишетелде. Малайлар туктап калдылар. Җиләкләрен арба юлы читенә куеп сораулы карашларын бер-беренә текәделәр. Ә тавыш, тукталу кая, көчәйгәннән көчәя генә бара иде.

—Нинди тавыш бу?—дип, ачкан авызын ябарга онытып катып калган иде Фәрваз.

Аның дуслары да авызларын турсайтып җилкә сикертүдән башка чара тапмады.

—Белмим шул, Каранга дүрт тәгәрмәчле төтен чыгарып йөри торган тимер ат кайткан дип әйтәләр, шуның тавышымы әллә?

—Тимердән булса да, аттан андый тавыш чыга диме. Ат бит ул пошкыра гына, аннан "пурт" итә.

Нуруллага кушылып, дәррәү бер көлешеп алдылар. Нурулла “пурт” шундый, ике уйлап тормый, әйтсә әйтә инде ул. Ә теге гөрелте туктамый, аның саен көчәя бара.

—Ат түгел, ул трактор дип атала, наданнар,—дип, ачыклык кертте Фәрваз.—Минем абый бит Каранга йөреп укый. Ул аны үз күзләре белән күргән, беләсегез килсә.

Ул арада, Нәгыш тау артыннан бер зур кара нәрсә атылып чыкмасынмы. Жир өстеннән түгел, югарыдан, һавадан очып килә тагы үзе. Ә тавышы... Тавышыннан колак томаланырлык. Малайлар, сүз берләшкәндәй, ин элек өчесе бер юлы башларын иделәр һәм шундук йөзтүбән жиргә капландылар.

—Бу шул, үзе, теге трактор дигәннәре. Ул әле оча да икән бит...Абый анысын әйтмәгән иде,—дип, башын калкытты Фәрваз.

—Әкиятеңне сөйләмә, тынынны кысып кына ят. Монда үзең генә түгел, без барын онытма,- дип пышылдады Нурулла.—Бер-бер гыйфрит фәлән яки газраил булуы ихтимал монын, мәчет манарасын кисүчеләрне эзләп килә торгандыр әле. Әби әйткән иде аны...

Рафаэль ни дияргә дә белмәде, нәкъ өсләренә очып килгән тимер кошны күрүдән хәйран калып, чалкан борылып ятып күзәтә иде инде ул аны. Үзе куркыта да, үзе гажәп хикмәтле дә күренеш. Канатларын шул рәвешле киң жәеп очкан тилгәннәрне дә сулыш алмый сәгатьләр буе күзәтеп туймый торган иде ул. Ә бу бит кош түгел, ул шундый зур һәм шундый тавышлы. Өстәвенә шул тикле дә тиз оча тагы үзе. Ә канатлары селкенми дә, талпынмый да...

—Беттек, малайлар, туры безнең өскә килә бу,—дип чырыйлап кычкырып жибәрде шунда Нурый.—Башны калкытмый качып кына ятасы булган да, кем белә бит аны.

—Юк-юк, без түгел, Яммәттән килгән исерек мари зимагурлары кисте ул мәчетне,—дип мыгырданды Фәрваз үзалдына, һәм кулын болгап күрсәтергә кереште.—Әнә, теге якта, урман артында ул авыл.

Фәрвазны ишетмәгәндер ишетүен, ул тавышка ничек ишетәсең. Әмма кулын изәгәннән аңлады булса кирәк, теге тимер кош, нәкъ аларга төбәп түбәнәя башлаган жиреннән, яман үкереп янадан күтәрелергә кереште.

Ниһаять, монарчы тын да алмый күзәтеп яткан Рафаэльгә дә жан керде.

—Малайлар, күрәсезме, анын эчендә кеше утырып бара икән бит. Әнә, ул безгә кул изи, елмая, сәлам юллый,—дип, яткан жиреннән сикереп торып басты ул. Һәм, дөньясын онытып, оча торган тимер кош артыннан йөгерергә кереште. Алдына-артына карамыйча урманга таба йөгерә иде ул. Буразнага абынып егылгач та тынычланмады, ук кебек атылып янадан торып йөгерде.

Тузанга баткан түшен кага-кага шулчак Нурулла да торып басты.

—Малай, бу ычкынды ахыры,—дип дәште ул, башын ике учы белән каплап жиргә елышкан Фәрвазга төртеп.—Жанын чыктымы әллә, исән булсаң тор. Ыштан төбең юешләнгән, әнә.

Нурулла шаяра, димәк хәлләр алай ук хөрти түгел. Як-ягына карангалап алгач, ниһаять, Фәрваз да торырга жөрьәт итте:

—Рафаэльне әйтәм, коты ботына төште ахыры, дип уйлаган идем аны. Менә сиңа кирәк булса, дәшми-тынмый япы-ятты да торып йөгерде диген, ә?.. Хафаза апа белән Миргалим абзыйга ничек аңлатырбыз инде. Малаегыз акылдан шашты, дип әйтеп булмый бит, нәрсә диербез икән?..

—Башыңны катырма,—диде Нурулла, дөнья күргән кешегә охшарга тырышып һәм тач итеп юл читенә төкерде.—Рафаэль югала торган малай түгел. Суда—батмый, утта—янмый ул, бик беләсең килсә.

Очкыч, үзе артыннан йөгергән Рафаэльне сәламләгән сыман, урманга житкәч тагы бер тапкыр чайкала төшеп нык кына гөрелдәп алды да, Киндер күл, Таш күперләр өстеннән очып, Мулла чаты аша, Тугыз Кыз авылына таба китеп югалды.

Рафаэль анын үзен югалтса да тавышы артыннан йөгерде. Беренче таш күперне узды, икенчесен дә "эх" дигән арада артта калдырды. Әлсерәү

һәм сулышына кабу белән хисаплашмастан, Мулла чатына ук барып җитә язды. Әле тагы күпме кирәксә, шул кадәрле йөгергән булыр иде. Тимер канатлы кошны куып җитү ихтималы булса һич туктамас иде. Әмма, ничек көтмәгәндә килеп чыккан булса, шул рәвешле үзе артыннан эз дә калдырмыйча китеп тә югалды ул хикмәтле нәрсә. Тора-бара тавышы да тынды. Йөрәк җилкенүен ничек тыярга белмәгән малай, башка чарасы калмагач, ике уйлап тормастан, каршысында торган иң биек агач—йөзьяшәр карт имән башына үрмәләп менеп китте. Һәм ни арада имәннең иң югаргы ботагына менеп кунаклаганын да сизми калды. Тирә яктагы агачларның очлары гына түгел, әллә кайдагы буа һәм күлләр дә уч төбендәгедәй аермачык күренә иде аннан. Исе-акылы китеп сокланып карап торды ул һәр тарафка: нинди кинлек, нинди хозурлык, нинди манзара... Тик аның күңелен җилкендергән, җилкендереп үзе белән алып киткән әлеге дә баягы теге тылсымлы тимер канатлы кош кына юк. Күпме генә үрелеп-үрелеп ераклардан эзләсә дә офыкта ул аны тапмады, аңардан җилләр искән. Ул юк... Эзе дә юк, тавышы да.

Карт имәннең Мәсәлим бабасы маңгаендагы сырларны хәтерләткән ботагын кочаклап озак утырды ул шулай. Бик монсу һәм үкенечле хисләр биләп алган иде аны. Максатына ирешә алмаудан, әрнеп еларга иде исәбе башта, әмма күзләренә яшь килмәде. Шул мизгелдә кош булып очасы, канатларын җилпеп тагы да югарырак күтәреләсе һәм шул биеклектән туган авылын, аның әйләнә-тирәсен, урман һәм кырларын туйганчы бер күзәтәсе килде аның. Авылдашларына, әти-әнисенә, бергә уйнап йөргән малайларга һәм кызларга, теге тимер канатлы кошка утырып әле генә аларның баш очыннан очып узган кеше сыман, кул болгап сәлам юллыйсы килде. Һәм, әлбәттә, Фәрваз белән Нурый дустына да...

—Фәрва-а-аз... Ну-ры-ый...,—дип аваз салды ул шунда ботак өстеннән бераз калка төшеп.

—Син кайда-а?—дигән аваз ишетелде Кичү буасы тарафыннан. Фәрваз тавышы иде бу, андый әче тавыш башка берәүдә дә юк. Тавышы әче булса да, үзе әйбәт малай Фәрваз. Әнә ич, аның өчен борчылып оран сала урманга.

—Ра-фа-эль, дусты-ым...

Монысы инде Нурулла, ягъни Нурый тавышы. Төнлә йокыдан уятып сорасалар да таный инде ул бу тавышны. Нурый бит аның иң якын һәм ышанычлы дусты. Урманда ташлап өйгә кайтып китә торган малайлар түгел алар.

—Борчылмагыз, мин монда, имән башында,—дип җавап кайтарды ул.

Дуслары аны югалтудан борчыла торгандыр дип, кабалана-кабалана түбән төшәргә кереште шундук. Агач башына менү генә җинел, төшүләре бермә-бер авыр. Ул тырмалып, күлмәк җиңнәрен ертып төшеп җиткәндә, йөзьяшәр имән ябалдашы астында ике дусты—Нурый белән Фәрваз авыз ерып янәшә басып торалар иде инде:

—Йә, нәрсә, куып тоттыңмы...

—Без инде сине очып киткәндер дә кире кайтмас дип курыккан идек...

—Бик очар идем дә канатларым юк шул.

Өчәүләшеп рәхәтләнеп бер көлеп алды алар һәм, су буеннан кайтып килгән үрдәк балалары кебек, бер-бер артлы тезелешеп урман сукмагы буйлап авылга юнәлделәр.

## 2

Яңа Актау гадәти бер авыл гына түгел. Урман куенына кереп елышкан татар авыллары дөньяда болай да бик сирәк. Ул шуларның иң матуры булса кирәк. Артык зур да түгел, нибарысы бер урамлы. Әмма ул урам чакырым ярымга сузылган. Гадәттә, авыл урамының уртабер жиреннән тузанлы юл уза, ә Яңа Актауда һич алай түгел. Күз алдына китерә аласызмы, монда урам уртасыннан чылтырап салкын сулы һәм чишмәле инеш агып ята. Аны Идәш дип атаганнар. Идәш... Исеме генә дә ни тора бит, ә... Нинди жылы һәм күңелгә ятышлы сүз. Аның каян килеп чыгышы һәм ни аңлатканын да өзеп кенә әйтеп бирә алган кешене мин очратмадым. Әмма ул барыбер бик тә якын һәм үз булып, беренче ишетүдән үк хәтергә уелып кала. Исеме жисеменә тиң диләр андый чакта. Идәш—өйдәш, илдәш, иптәш һәм тагы әллә никадәр изге төшенчәләрнең мамык жылысын үзенә туплаган кебек бу исем. Жәйләрен ул инешнең буеннан буена каз-үрдәк көтүе була. Шулкадәр күп ки алар, әгәр дә мәгәр ул каз-үрдәкнең һәммәсе берьюлы канатларын кага башласа, инеш кенә түгел, йортлары, кешеләре белән бергә бөтен авыл, ягъни Яңа Актау үзе, очып китәр кебек тоела.

Алла биргән урманы бар Яңа Актауның. Урман эченнән кайнап чыккан чишмәләре, бөдрә каен, карама һәм тирәкләр күз салып ыспайлансын өчен генә яратылган түгәрәк күлләре бар. Ул да аз тоелган, мөгаен, урам уртасына авылның буеннан буена каен, шомырт һәм миләш агачлары утыртылган. Жәннәт кайда, дип сораучы булса, ул монда—безнең Яңа Актауда дип әйтерлек булсын, дигәннәр, күрәмсең.

Авыл зур юллар чатында түгел, адашып та килеп чыгучы булмас монда. Аның каравы киек жәнлек һәм кош-корт өчен куйган да каплаган урын, бөтен шартлары бар. Бүре, төлке, урман мәчесе бу яклар өчен табигый күренеш. Элгәре заманнарда ара-тирә Урал якларыннан адашып килеп чыккан аюларны очратучылар да аз булмаган. Ә кыр куяннары монда әле дә үзләрен хужа итеп хис итә. Ат арбасына печән төяп болыннан кайтып киләсеңме, урманга утынга юнәләсеңме, кая карама алар, ике колакларын үрә торгызып актаулыларның жыруын тыңлап калалар. Узып барышлый бер-бер печән чүмәләсенә яисә салам эскертенә ялгышып таяк ыргыта калсаң, аннан ким дигәндә бер пар куян атылып чыгасын көт тә тор. Инде ул урман-кырлардагы кошларны саный китсәң, һич очына чыгам димә. Алар сайрап та жибәрсә, дөньяңны онытасың. Ачкан авызыңны ябарга онытып хәйран калачаксың.

Тик шунысы бар, әлегедәй матур табигать кочагында яшәп тә, ял итәргә өйрәнмәгән монда халык. Ял өчен ара калмый, ял сүзе кулланылышта юк иде ул, гомумән. Һәркем, олысы-кечесе монда иртә таңнан кичке караңгыга кадәр эш белән мәшгул. Эшләп арыгач та монда туктап ял итмиләр, хәл генә алалар. Ашау-эчүне дә көн яктысында олы вакыйгага әйләндерми генә—тамак ялгап алу дип йөртәләр. Яңа Актау бу уңайдан Идел-Урал киңлекләрендәге меңнәрләгән татар-башкорт авылларыннан һич аерылып тормый икән ләса...

Шулай да елга бер бәйрәм итеп ала иде халык. Һәм ничек кенә бәйрәм итә иде әле. Хәзер Сабан туе диеп йөртәләр ул бәйрәмне. Ә менә Рафаэльнең балалык һәм үсмер чакларында аны, борынгы бабаларыбыздан калган мирас санап, "Жыен" дип атыйлар иде.

—Укытучы малайлары да көрәшәмени,—дигән төртмәле сүз белән каршы алды Рафаэльне Алмаз.

—Карап карыйк.

—Сөякләреңне жыеп алырга капчык алып килдеңме соң?

—Колхозда капчык күп, әтиең алып килгәндер әле...

—Ярар, теленә салынма, көрәшергә чыксаң көрәш,—дип, үзе башлаган сүз көрәштерүне үзе үк туктату ягын карады Алмаз.

—Сөлгеләрне билгә салдык, егетләр,—дип дәште шунда монарчы бер читтәрәк торган Гыйниятулла абзый.

Билләрдән алышып, башны башка терәп куйгач Алмаз үзе сүз башлады тагы. Телгә салыну, үзенә күрә бер хәйләсе иде бугай аның.

—Йә, ничек, алыштанмы-салыштанмы?

—Алыштан да булыр, салыштан да,—дип җавап кайтарды Рафаэль. Татар халык әкиятләрен ул да яхшы белә ич.

—Үзеңне Таң батыр итеп хис итәсең инде, ә?!.

—Дию пәрие итеп хис итиммени?

Шунда, әле көрәшә дә башламаган Рафаэльне аяк чалып егарга маташа башлады Алмаз. Уңга да боргалап карады үзен, сулга да төртеп карады, әмма алдый алмады. Күтәрергә итеп карады, көче җитмәде, Нурулла шактый ук хәлен алган иде үзенең.

Рафаэль ашыкмады, артык көч түкмичә генә җай чыкканны көтеп йөрде. Алмаз исә моны үзенчә, аның йомшаклыгы дип аңлап, тагы җәтрәк хәрәкәтләнергә керешә. Үзе артыннан да өстерәп карады, этеп тә йөртте, әмма җирдән суырып кына ала алмады. Суырып кына аласы да тотып кына атасы бит, нишләптер, ул дигәнчә барып чыкмый иде.

Шунда, Рафаэльнең җәт кенә чүгә төшеп үзен күтәреп алганын һәм ул аны-моны абайлап өлгергәнче башаркан тотып җиргә ташлаганын сизми дә калды.

Мәйдан дәррәү килеп аягүрә торып кул чаба башламасынмы...

—Кем малае булды бу?

—Безнең авылныкымы?

—Соң, безнең авылныкы булмаска, Миргалим абыйның олы малае ич.

—Кайсы Миргалим?

—Укытучы Смаков Миргалим малае...

—Менә ничек көрәшергә кирәк...—ди-ди, баш чайкады, тел шартлатты күпне күргән агайлар.

Персидәтелнең уң ягында утырган бригадир Садыйк кына ярарга тырышып: "Җәмәгать, дөрес булмады бит, яңадан көрәшсеннәр, яңадан..." дип, сүз башлап караган иде дә, аны тыңлаучы булмады. Персидәтел үзе үк җиңеннән тартып аны кире урынына утыртырга мәҗбүр булды:

—Буза куптарма, утыр Садыйк. Бер ни әйтеп булмый, дөрес екты. Дөреслеккә каршы барып булмый, Садыйк...

Рафаэльнең иңбашына чиккән сөлге китереп салдылар. Гыйниятулла абзый аның кулын югары күтәреп, үз тиңнәре арасында җиңүче дип игълан итте. Мәйдан читенә чыккач та һәр очраган кеше мактады, җилкәсеннән какты үзенең. Фәрваз белән Нурулла исә үзләре җиңгәннән дә болайрак куандылар, бер урында басып тора алмый сикергәли-сикергәли тантана иттеләр.

—Малай, Алмаз пеләмәнни айгыр өстеннән мәтәлеп төшкәндә дә болай кычкырмагандыр, өнен алдың бит. Мин сине ул тикле дә көчле дип уйламый идем, малай,—дип, исләре китеп тәбрикләде дустын Фәрваз.

—Һәй, син Рафаэльне белмисең икән бит, ачуын чыгарсаң—аңарда җен көчләре бар. Беләсең килсә, үзем карап тордым, капка өстеннән ике потлы гер ыргытып уйный ул,—дип шыттырырга керешә Нурулла.

Рафаэль көлде генә. Чын дусларга ничек шаяртса да килешә.

Ерак түгел генә батырны күзәтеп торган күрше авыл малайлары, моны ишетеп, бер-берсенә карана-карана телсез-өнсез калдылар. Шуны сизеп алган Нурулла исә тагы да бүрттерүен дәвам итте.

—Әле кайчан гына Таулардан печән урларга килгән алты малайны бергә тотып ярды да, печән урынына үзләрен ат арбасына төяп кайтарып җибәрде,—диде ул, тегеләр ишетсенгә тагы да кычкырыбрак. Берочтан җәт кенә дустына күз кысып куйды.

—Әйе, әйе, без бит синең белән бер читтә, кабак орлыгы ашап, көлеп карап тордык,—дип кыстырды Фәрваз да.

Шул минуттан теге малайларның эзе суынды. Аларны мәйданда башкача күрүче-очратучы булмады.

Рафаэльнең берсеннән-икенчесе кечкенәрәк ике энесе бар. Алар да абыйлары янына килеп сырпаланырга кереште. Күрсеннәр, хәтерләп калсыннар, алар бит хәзер гади малай-шалай гына түгел, алар мәйдан тоткан батырның энекәшләре. Әнә ич аларның нинди яклаучысы бар...

Килеп чыгулары әйбәт булды әле, Рафаэль бүләк итеп бирелгән чигүле сөлгене төреп тоттырды.

—Барыгыз, апайларым, әнкәйгә йә булмаса Әсма апага илтеп бирегез.

Нур белән Римнең башлары күккә тигән иде. Абыйлары батыр калу гына бер хәл, менә хәзер шул батыр абыйлары көрәшеп алган сөлгене күтәреп баралар бит...

### 3

Шундый матур һәм бәхетле башланган балачак, кызганыч, озын гомерле булмады. 1941 нче елның иң матур көннәрендә, басуда игеннәр өлгереп килгән, болында печән өсте башланырга торган, тау битләрендә җир җиләге һәм каен җиләге кызарып пешкән ямьле җәй уртасында өзелеп калды ул балачак. Яңа Актауда җир җимертеп эшләрдәй ир-ат заты бетте. Барысы да илбасарларга каршы сугышка яисә Уралдагы хәрби заводларга хезмәт фронтына китеп барды.

Олыгаймас жиреңнән олыгаерсың, басуда өлгергән игеннәрне җыеп алу, мал-туарга печән, кышка утын хәзерләү кебек барча мәшәкать әниләр һәм яшүсмерләр җилкәсендә торып калды. Әтиләре Чиләбедәге танк заводына эшкә киткәч, Смаковлар гаиләсендә дөнья көтүнең бар михнәт-мәшәкатьләре әниләре Хафаза апа белән ундүрт яшьлек Рафаэль өстендә иде хәзер. Әсма апалары сугыш алдыннан ук Уфада эшли башлаган иде. Рим белән Нур, кул арасына керергә тырышсалар да әле малай-шалай гына. Тамара белән әле яңа тәпи йөрергә өйрәнеп маташкан төпчек малай Ринатның үзләренә караучы кирәк. Шулар өстенә әле мәктәптә укуны да ташларга ярамый, Туган илне саклау өчен белемле яшьләр кирәк диләр әнә. Яңа Актауда башлангыч мәктәп кенә булу сәбәпле, аларга хәзер тугыз чакырым ераклыкта урнашкан Каран авылына йөреп укырга туры килә. Анда бару-кайту өчен машина юк, атлар колхоз эшенә дә житми. Яхшы атларны шулай ук фронтка озатып бетерделәр. Җәяүле кеше өчен якын ара түгел тугыз чакырым.

Авыл кешесенең ашаганы ипи белән бәрәңге иде. Алары да булган чакта гына. Бер кыерчык ипи белән бармак башы кадәрле ике бәрәңге эләксә түбән күккә тия инде. Ачлы-туклы яшәүгә дә, фронттан кайгылы хәбәрләр килеп торуга да, көн-төн эштән арына алмауга да карамастан, укуга зыян китермәскә тырыша иде авыл балалары. Җиденче класста укыган Рафаэль исә, соңыннан калып, бишенче класс малайларына хәрби дәрес бирүче укытучыны да алыштыра иде әле бик еш кына. Кыска җинле күлмәк өстеннән биленә әллә каян гына табып алган, таушалып беткән иске солдат каешы буып куйгач үзен чын командир кебек хис итә иде ул. Малайларны тигез рәткә тезеп "айт-два"га шап-шоп атларга өйрәткәндә, соңгы арада болай да буйга шактый ук калкынып киткән егетнең нинди дәрт белән

очынып йөрүен күрсәгез икән сез!

—Ватанны саклар өчен таза малайлар кирәк. Физкультура һәм башлангыч хәрби әзерлек дәресләре иң мөһим дәресләр. Туган илен яраткан һәр укучы бу дәресләргә аеруча җаваплы килергә тиешле. Хәрби әзерлек дәресләренә керми калу—Ватанга хыянәткә тиң,—дип тә сөйләп җибәрә иде ул аларга. Койган да куйган солдат, менә дигән укытучы инде читтән карап торсаң.

—Абый, солдат каешыңны тагып карыйк әле...

—Абый безнең дә синең кебек оста итеп “айт-два”га йөрисебез килә, иртәгә дә керегез әле,—дип тинтерәтә иде аны малайлар.

Чөнки хәрби әзерлекне алып барган укытучы Вәлиәхмәт абыйлары, сугыштан контузия алып кайткангадыр инде, алай бик ачылып китеп сөйләшми, аралашмый иде үзләре белән. Өстәвенә бер аякка нык кына аксый да иде әле. Рафаэль исә аларга үз тиңнәре кебек карый. Каешын да салып тоттыра, биргән бер сорауларына да җавап табарга тырыша. Бу аралашудан ул үзе дә бәхетле, мавыгуын малайларга да йоктыра белә иде.

Шул рәвешле, бер-ике ел дигәндә, Каран мәктәбендә шактый ук дәрәҗәле һәм мәртәбәле укучы буларак танылды Рафаэль. Укытучылар да хөрмәт итә иде үзен, укучылар да тартыла иде аңарга. Борынын чөймәсә дә, үз дәрәҗәсен белеп, төз басып, туры атлап йөри торган асыл егетләр затыннан иде.

Көз һәм кыш айларында, көннәр кыскара, караңгы бик тиз төшә, авылга һәр көн кайтып йөреп булмый. Рафаэль әнисенең сеңлесе Мөсфирә апаларында торып укый. Атнага бер генә кайткан чаклары да була иде туган авылга.

Яңа Актауга кайту өчен ике чакырымлап урман эченнән барасы бар. Шуңа алар бергә-бергә җыелышып кайтырга чыга торганнар иде. Авылдашлары арасында Рафаэль үзенә күрә башлап йөрүче санала. Чөнки, аның кыю йөрәкле, куркуның ни икәнлеген дә белми, дигән даны бар. Чынлыкта алай ук түгел иде, әлбәттә, урман аша узган чакларында, бигерәк тә караңгы төшкәч, шүрләми түгел, күңеленә шом керә иде аның да. Ләкин, башкаларның ышанычын аклар өчен генә булса да сер бирмәскә тырыша торган иде.

Көннәрнең берендә Каран мәктәбеннән Яңа Актауга үзеннән бер класска югарырак укыган авылдашы Асия исемле кыз белән кайтырга туры килде аңарга. Сабакташларыннан әлеге дә баягы шул хәрби дәресләр аркасында аерылып калган иде. Ә Асия мәктәптә комсомол активисты.

Караннан чыгып Иске Актауга җиткәнче үк кичке эңгер-меңгер башланды. Ноябрь ахырлары җитеп килсә дә кар ятмаган иде әле, төннәрнең иң караңгы чагы. Аяк асты да яман тайгак—төнлә чыерата, көндезләрен җепшетә. Үзле кара балчык шундый итеп ябыша ки, берәр калыпка зуррак булса, аяк киемеңне суырып кына ала.

Башта үзара сөйләшми генә кайттылар. Рафаэль бишмәт изүләрен ача төшеп олы адымнар белән алдан атлады, ә Асия, калышмаска тырышып, яшь болан баласыдай аның артыннан теркелдәде. Урманга җиткәнче түзде, сер бирмәде, ул да авылда эшләп үскән кыз иде ич. Әмма тора-бара арый башлады, күрәмсең, адымнары акрынайа төште.

—Ул тикле ашыкма инде, Рафаэль, мин бүтән йөгерә алмыйм,—дип әйтергә мәҗбүр булды кыз.—Әйдә, бераз акрынрак кайтыйк. Ерак калмады бит инде.

Егет бик рәхәтләнеп риза булды, әлбәттә. Яшьлек дуамаллыгы белән генә бара иде ул да. Иртәдән бирле авызына ризык капканы юк, ашказанында чуашлар утын кисә. Анысы бер булса, икенчедән, аның үзенең дә Асия белән сөйләшәсе, һич югында үзенә бер-бер сүз катасы килеп кайта иде бит. Асия, авылда гына түгел, тирә якта тиңе булмаган бер матур кыз. Өстәвенә эшчән

һәм акыллы да. Каран мәктәбендә тугызынчы-унынчы класс малайлары авыз суларын корытып йөри иде аның артыннан. Үзе якын җибәрми ул аларны. Шул кыз, әнә, күпме гомер инде аның артыннан йөгереп кайта. Ә Рафаэльнен анарга, бер-бер җылы сүз әйтү түгел, борылып та карамый. Әллә бар, әллә юк иде ул аның өчен, исе дә китми, янәсе...

—Мин шулай тиз йөрергә яратам инде,—дип, үзе дә абайламастан, мактанып алды иң элек. Тагы нәрсәдер әйтәсе килгән иде дә сүзен таба алмый торды.

—Артыннан җитешерлек түгел, син бит, әнә нинди, озын буйлы таза егет,—дип, салпы ягына салам кыстырырга өлгерде Асия. Ә бәлки, ихлас күнелдән әйтүе булгандыр.

—Юк инде, озын дип, миннән озын егетләр дә бар бит...

—Була да, алар бит армиягә, сугышка китеп баралар.

—Анысы шулай,—дип, килешергә мәҗбүр булды Рафаэль. Үзенең дә тизрәк үсеп, Ватанны саклаучылар сафына басасы килгәнлеген әйтергә теләде. Әмма шуны гади генә анлатырлык сүзләр тел очына килми аптыратты. Әллә нәрсә генә булды әле бу—гомергә сүз сорап кеше кесәсенә керүне белмәгән Рафаэль, күнелендә булганнарны анлату өчен сүз таба алмый изаланды.

Ә Асия, әнә, аз гына да дулкынланмый, нинди матур итеп, гади генә сүзләр белән сөйләшеп бара:

—Сине Рафаэль, юл буенча кызыклы хәлләр сөйләп күнелне күтәрә, аның белән кайтканда юлның ераклыгы сизелми дә кала дип әйтәләр. Ә минем белән сөйләшергә дә теләмисен...

—Юк, Асия, алай түгел. Син бит... Син... Синең белән...

—Ә син каушама. Без бит авылдашлар. Бер урамда уйнап үскән...

Шунда башлаган сүзен әйтеп бетерә алмады кыз, аягы таеп китеп егыла язды. Ярый әле Рафаэль тотып калды үзен.

Кызның кайнар сулышын, йомарланган май кебек тыгыз тәнен тоеп калды ул шул мизгелдә. Әмма, гаепле кеше сыман, кулларын тартып алды җәтерәк.

—Аяк асты тайгак шул,—дип кенә әйтеп калды.

Ә Асия исә үзен, читкә тайпылып өлгергәнче, җитәкләп үк алды.

—Юл да тайгак. Урман да карангы. Шомландыра. Ярыймы, Рафаэль?..

Аздан гына "Ничек кенә ярый әле", дип әйтеп ташламады. Асия белән шул рәвешле җитәкләшеп кайту төшенә дә кермәгән хыял иде бит аның өчен. Әмма сер бирергә ярамый иде.

—Абау, Асия, кулың шундый салкын. Өшегән икәнсең бит.

—Юк, өшемәдем. Кулым салкын, әмма йөрәгем кайнар минем,—диде кыз, чаялана төшеп.

Бу ни дигән сүз булды икән тагы, дип уйлап куйды Рафаэль. Әмма кайнарлык турында, йөрәкләр турында сөйләшергә әзер түгел иде шул әле ул. Байтак кына ни әйтергә белми, унайсызлык кичереп һәм оялып, уйланып барды алар.

—Ярый әле син очрадың, Рафаэль, югыйсә авылга кайта алмый кала идем,—дип, сүз башларга омтылды Асия.

—Нәрсәсе бар инде аның, юл таныш ич, тотасың да кайтып китәсең.

—Куркыта ич. Урманда әллә нинди качкыннар бар дип сөйлиләр.

—Ә мин курыкмыйм. Алар үзләре курыксын миннән.

—Берүзең генә кайтудан да курыкмас идеңме?

—Һи, нәрсәсе бар инде аның. Рәхәтләнеп җырлый-җырлый кайтам мин үзем генә булганда. Юлның ераклыгы сизелми дә кала.

—Ә бүген нигә җырламыйсың?

—Мин ялгызым гына җырларга яратам.

—Мина да берәрне җырлап күрсәт әле, Рафаэль,—дип, кыз анының кулын кысып куйды шунда.

Уңайсызланып китте егет, әмма, сер бирмәде.

—Бүген түгел, башка бер юлы җырлармын, яме, Асия.

—Ә ни өчен бүген түгел?

—Җыр капчыгым онытылып калган,—дигән булды ул, шаяртып.

—Ярар, нишлисең бит, тыңлыйсым килгәнгә генә әйткән идем. Ә нинди җырлар яратасың син?

—Җырның ертыгы юк, ди безнең әни. Барысын да яратам.

—Шулай да...—дип, кызыксынуын дәвам итте кыз анының саен.

—Ну..., туган авыл турындагы җырларны, туган ил турындагыларын... Ә сиңа нинди җырлар кирәк, Асия?

Бераз тынып барды кыз. Ничек җавап бирергә белмичә уйлануы иде булса кирәк.

—Минме... Мин мәхәббәт турындагы җырларны бик тә яратам. Аларны мин бер дәфтәргә дә язып барам әле.

—Минем дә бар җыр дәфтәрем,—дип әйтеп ташлады Рафаэль.—Әле күптән түгел генә башлап җибәрдем.

—Ә мин инде өченче дәфтәргә күчтем.

—Шул тикле җыр таптыңмы?

—Күңелгә ятышлы, матур җырлар аз түгел, Рафаэль. Безнең татар-башкорт халкы моңнан яралгандыр кебек тоела миңа.

—Асия,—дип, тирән сулыш алып куйды егет. Үзе дә ачык кына аңламаган хис һәм тойгылар өермәсе биләп алган иде аны.—Син шул тикле матур сөйләшәсең, Асия. Синең белән янәшә бару, синең авыздан чыккан сүзләрне тыңлау рәхәт миңа.

—Син дә әйбәт егет, Рафаэль,—дип, янә дә бер тапкыр кулын кыса төште ул анын.

Рафаэль, уңайсызланудан, тартынып куйды. Сүзне ничек дәвам итәргә белмичә азапланды бер ара.

—Башкалардан бер аермам да юк, гади бер авыл малае инде шунда...

—Гади булсаң да курку белмәс бит син... Тыйнак та.

—Ничек бар—шулай инде. Авыл малайлары бары да бер иш була торгандыр.

—Юк, Рафаэль, син бүтәннәр кебек түгел. Башкалар, кызлар белән икәүдән-икәү генә калса төрлечә төртмәле сүзләр сөйләшә, кулларын, авызларын суза башлый. Ә син андый түгел.

—Ә кызлар бит шундый кыю егетләрне ярата диләр.

—Егет кешегә җебегән булу килешми, әлбәттә,—дип, Асия да авызын сузгандай итте. Шул сузуы белән үтерә язды Рафаэльне. Һәм, әллә юри, әллә чынлап, башлаган фикерен тәмамламыйча ярты юлда өзеп торды.

Киеренке тынлык урнашты бер мәлгә. Асия тукталып калды. Рафаэльнең дә тукталмый чарасы юк иде, Асиядән кулын тартып алып бер ялгызы китеп бара яисә ташлап йөгерә алмый бит инде. Урман эче. Төн. Күзгә төртсәң, күренмәслек дөм караңгы. Әйләнә тирәдә һичкем юк...

—Арыдым, Рафаэль, туктап аз гына хәл алыйк булмаса,—дип пышылдады Асия, әлеге шомлы тынлыкны бүлдерүдән куркып.

Ягымлы сүзләргә анын җылы сулышы килеп кушылды. Житәкләшкән кулны ычкындыру кая, кыз аңарга тагы да елыша гына төште.

—Тундыңмы әллә,—дип сораудан башка чарасы юк иде егетнең.

Кызның үзенә текәлгән якты карашын, зур булып ачылган күзләрен тоемлады шунда. Әмма үзләренә туры карарга кыюлыгы җитмәде.

—Тунмадым, Рафаэль, ут булып янам,—диде Асия, тагы да ягымлырак пышылдауга күчеп.—Иреннәрем генә күшекте...

—Ә мин иреннәрем тунса, уч төбе белән каплыйм да жылы сулыш кына өрәм,—дип әйтеп ташламасынмы шунда Рафаэль. Алдын-артын уйлап тормады шул.

—Киттек,—диде Асия, тавышын күтәрә төшеп. Һәм, житәкләшкән кулын аерып, кузгалып та китте. Ни өчендер озаклап ял итеп торасы килмәде тагы.

Инде хәзер Асия алдан бара иде. Каян ул тикле көч һәм егәр килгәндер үзенә, уйнаклап, йөгереп диярлек ашыга башлады ул. Аның артыннан калышмаска тырышкан Рафаэль озын-озын адымнар белән дә чак житешә иде үзенә.

Шул рәвешле жил-жил кайта торгач, ничек урманны аркылы чыкканнарын да сизми калдылар. Ниһаять, адымнарын акырынайта төште алдан йөгергән кыз.

—Менә урманны да чыктык, мине куып тота алмадың,—диде һәм, үзалдына нидер уйлап, рәхәтләнеп көлеп алды Асия.

—Синдә жен көчләре бар икән бит, Асия, шундый йөгерттең үземне, чак ташлап качмадың,—дип, Рафаэль дә анарга кушылып шаярырга омтылды.

—Юк инде, жен урманда калды. Мин хәзер Асия генә,—дип, канәгать һәм серле итеп кеткелдәвен дәвам итте ул.

Юлдашының күнел күтәренкелеге егеткә дә күчте, ул кинәт кенә кызны куып житеп, аның аркасына жиңелчә кагылды да, алга таба йөгереп китте.

—Урмандагы теге жен куа чыккан, әйдә, калышма, куып житеп кара мине.

Асия, курыкканга сабышып, чырык-чырык көлә-көлә аның артыннан йөгерде.

—Йөгер, тизрәк йөгер, юкса жен куып тота үзеңне...

Егет аны ташлап качмады билгеле, бераз йөгергәч адымнарын акырынайта төште. Ә кыз исә, шундук куып житте һәм кочаклап ук алды. Икесе дә рәхәтләнеп көлделәр бер туйганчы.

—Менә, Мәсәй чирәмен дә узып барабыз, авылга күп калмады,—диде кыз, тагы бертын барганнан соң.

—Ә син, Асия, беләсеңме соң, ни өчен бу урынны Мәсәй чирәмлеге дип йөртәләр,—дип, күтәреп алды Рафаэль.

—Белмим шул, бер-бер кеше исеме белән бәйле булгангадыр.

—Ә мин беләм,—диде егет, бер горурлык белән.—Мәсәй, Мәсәлим—минем бабам исеме. Патша заманында волостной старшина булган ул. Хәзергечә әйтсәк, иң зур нәчәлник инде. Аның монда үз печәнлеге булган. “Мәсәй чирәме” әнә шуннан калган исем, бик беләсең килсә.

—Менә ничек...

... Шул рәвешле шаяра-көлә, тугыз-ун чакырым ара узып, кай арада авылга—Яңа Актауга кайтып житкәннәрен сизми дә калды алар. Бу ерак көзге караңгы юл, тайгак һәм пычрак юл очсыз-кырыйсыздыр төсле тоела иде башка вакытларда. Әллә ничек кенә килеп чыкты әле бүген, туйганчы бер сөйләшә дә алмый калдылар. Тагы туры килерме аларга шулай икәүдән-икәү генә калып юлга чыгарга, белеп булмый. Рафаэльнең Асиягә әллә ниләр әйтәсе килә иде дә бит, кыюлыгы житмәдеме, әйтә алмады. Бераз соңрак әйтермен әле дип кичектереп килде. Инде авыл башына килеп житкәч тә чыкмады жае, бөтен өмет капка төпләренә калган иде. Кызлар белән егетләр арасындагы иң мөһим сүзләрнең авылда, кагыйдә буларак, капка төбендә әйтелүен ул өлкәннәрдән ишетеп белә.

Капка төпләренә житеп килгәндә, инде бөтен кыюлыгын жыеп сүзне башлыйм дигәндә, ипле генә сөйләшеп кайткан Асия, кинәт, йөгәннән

ычкынган тай кебек торып чапмасынмы! Капкалары ябылганда "Тәмле төшләр күреп йокла, йәме, сау бул, Рафаэль" дигән сүзләре генә ишетелеп калды аның.

Кая ашыкты, нигә шулай йөгереп кереп качты инде ул, һич анламассың. Әйткән сүзләре дә мыскыл итү кебегрәк яңгырады. Әллә ничек кенә килеп чыкты әле бу...

## 4

Сугыш вакыты булу сәбәпле өлкән сыйныфларда укучыларның җәйге каникуллары ай-ай ярымга алдан башланып, шулай ук бер-ике айга кичегебрәк тәмамланды ул елларда. Каникул дисәләр дә, ул—җәйге ял түгел, көн-төн эш һәм авыр хезмәттән гыйбарәт иде. Рафаэль, әнисе Хафаза апа кебегүк, бер караңгыдан икенчесенә кадәр колхоз эшендә. Ашарыңа бармы, өең ягылганмы—анысында һичкемнең эше юк, син бер эш көнен дә калдырырга тиеш түгел. Рафаэль колхоз малларына басудан салам-печән ташый иде. Атлар ябык, аларның да ашарына җитми. Вакыт-вакыт чанага яисә арбага төялгән саламны, ат белән янәшә басып, икәүләп тә өстерәргә туры килә. Әмма яшьлек җүләрлеге һәм сугыш чорындагы рух күтәренкелеге белән әллә нинди авырлыкларга да түзәсең икән. Бер кыерчык ипи һәм бер бәрәңге дә тәтесә, дөнья тәмам түгәрәкләнә, ундүрт-унбиш яшьлек үсмер икәнлегең онытыла, гайрәт иясе ир-ат итеп хис итә башлыйсың үзеңне.

Сугыш чорында, үсмерләр генә түгел, сабый балалар да тиз олыгайды. Әнисе белән абыйсы колхоз эшенә киткәч, ихатадагы бөтен җаваплылык уникенче яше белән баручы Рим җилкәсендә кала иде. Шуның өстенә әле ул бөтен гаиләне аяк киеме белән дә тәэмин итүче—чабата үрә. Нур белән Тамара җиләк, карлыган җыя. Кышка чикләвек, миләш, шомырт, балан һәм төрле-төрле шифалы үлән һәм яфраклар хәзерләү белән мәшгуль. Иртәдән кичкәчә урманда була торганнар иде, шуңа аларны "Урман балалары" дип тә йөретәләр иде. Төпчек малай Ринат та кул арасына керә башлады инде, аның да үзенә йөкләнгән бурычлары бар. Тавык-чеби ашату, вакытында аларның суын алыштыру, сәндерәдән тавык йомыркаларын җыеп төшү. Бакчага кергән карак кәҗәләрне, күрше тавыкларын куып чыгару—болар һәммәсе Ринат җаваплылыгында.

1943нче елның җәй урталарында Яңа Актауга районның ягулыклар өчен җаваплы иң зур түрәсе—райтоп нәчәлниге" килеп төште. Бригадир Фәхрислам Сәмигуллин, ягъни Фәрсәй карт, каравыл өе каршысына авылның иң таза һәм егәрле егетләрен генә чакыртып китерде.

Райтоп нәчәлниге Хатыйп исемле икән. Гәүдәгә әллә ни зур булмаса да, бар җире таза, сәламәт күренә иде үзе, сугышка ни сәбәпле бармый калгандыр, анысын алла үзе генә белә. Аягында чем кара хром итек, өстендә соры гәләфи чалбар һәм китель. Ул аларның һәркайсы белән кул биреп исәнләшеп, танышып чыкты иң әүвәл. Малайлар аның белән исәнләшкәндә үзләренең исем-фамилиясен һәм ничә яшьтә булуын әйтергә тиешләр иде.

"Нурый Хәкимовның, уналтынчы яше". "Фәрваз Бакиев, унбиштә". "Смаков Рафаэльгә, уналтынчы китте". "Риҗал Хәмитовка, унбиш". "Ләбиб Гыймаловның ундүрте тулып килә инде."

Ләбиб белән танышканда уйга калып торды райтоп нәчәлниге. Бер бригадир Фәрсәй картка, бер малайга сынап карап торды.

—Булдыра алырмы, ундүрте дә тулмаган икән бит әле...

—Әйттем бит инде, тиздән унбишенче китә инде, абый,—дип, гозерләп сорагандай түрәнең күзләренә текәлде Ләбиб.—Яшьтә генә мени хикмәт, аның каравы, күрәсезме, минем мускул да бар инде.

—Ул тырыш малай, булдырыр. Әнисе дә бик үтенеп сораган иде,—дип, сүзгә Фәрсәй карт үзе дә кысылгач, нәчәлник ризалашкандай булды.

—Белмим шул. Алайса, эшләп карасын...

—Җәмәгать,—дип сүзне Фәрсәй карт башлады,—дәүләт сезгә бик җаваплы эш йөкли. Сугыш вакыты икәнлекне онытмагыз. Ә хәзер сүзне, райтоп нәчәлниге Хатыйп иптәшкә бирәбез.

Янә бер кат күз йөртеп, каршысында басып торган егетләрне барлап чыкты нәчәлник кеше. Барысы да урындамы, ул сөйләячәк җитди сүзләрне тыңларга әзерләрме, янәсе. Һәм шунда кинәт җанланып китте ул, уң йодрыгын югары күтәреп болгый-болгый, хром итегенең аяк очларында гына калып күтәрелә-күтәрелә сөйләп китмәсенме мин сиңа әйтим. Коеп куйган трибун инде менә...

—Ватаныбыз өстенә кара козгыннар булып ябырылган фашист илбасарларын җиңү өчен ягулык кирәк, ягулык җитми, иптәшләр. Алар, әнә, Идел буена килеп җитте. Әмма шуннан ары китмәсләр. Безнең иптәш Сталин җитәкчелегендәге Кызыл Армия аларны һичшиксез тар-мар итәчәк. Берлиннарына тикле куып барып, үз өннәрендә тончыктырачакбыз без аларны. Утын ул әнә шуның өчен кирәк. Утын булса—ягулык була. Утын булса—паровозлар йөри. Утын булса—җылылык була. Утын булса... Утын булса,—дип кабатлый-кабатлый ниндидер сүз таба алмый интекте ул шунда. Һәм фашистларның башына утын тумраны белән суккандай берөзлексез йодырыгы белән кизәнеп торды.—Утын булса—завод-фабрикалар эшли. Вәт тәк, менә шулай, иптәшләр.

Нәчәлник кеше тукталып хәл алып торган арада бригадир Фәрсәй карт та бер-ике сүз кыстырып өлгерде:

—Аңладыгызмы инде, егетләр, әнә нинди олы бурыч тора сезнең алда?!.

—Аңладык. Аңладык...—дип әйтми чаралары юк. Нәчәлник сөйләгәннәрне тыңлаганда тәннәрендә бала йоннарына кадәр үрә торып баскан иде. Үзләрен фронтка китүчеләр сыман хис итә иде инде халык.

—Озын сүзнең кыскасы шул, егетләр,—диде нәчәлник, ниһаять, бармак очларыннан җиргә төшеп,—фронт өчен, Мәскәү һәм Лилинград өчен утын кирәк. Бүгеннән башлап шушы зур эшкә алынасыз. Еракка да барып торасы түгел, урман, әнә, авылыгыз каршында гына. Килештекме?

—Килештек,—диде малайлар бертавыштан.

Бригадирга карап дәште нәчәлник:

—Иптәш Сәмигуллин бит әле...

—Әйе, Фәхрислам Сәмигуллин.

—Ә сезгә, иптәш Сәмигуллин, шуны әйтәм. Егетләрнең тамагы тук, пычкылары кайралган, развуты ясалган булсын. Алар бүгеннән дәүләт эшендә санала. Тәк шту, вәт тәк, менә шулай, иптәш Сәмигуллин!

—Аңладым, иптәш райтуп нәчәлниге. Пычкыларын Гарифуллин Гыйниятулла абзыйдан каратырмын. Бу эшнең ул рәтен белә, бик хөрмәтле кеше, империалистик сугыш ветераны. Вәт тәк, менә шулай, тәк шту, иптәш райтуп нәчәлниге...

—Аңлагач бик әйбәт, бүгеннән үк эшкә тотынасыз. Егетләргә ярдәмгә Яммәттән мари хатыннары да кушылачак. Утын эшен алар яхшы белә, урманда үскән кешеләр. Кирәксә, Тугыз кыз авылыннан да ярдәмчеләр чакыртырбыз. Сөйләштек, килештек. Инде, әйдәгез, эшкә тотыныйк, егетләр.

Хром итекләрен бер-берсенә кагып алды нәчәлник һәм иелеп гәләфи чалбарын кабартыбрак куйды. Китәргә җыенуы иде. Әмма искәртергә кирәк тапты.

—Ярты сәгатьтән бәләкәй таш күпер янында көтеп торам үзегезне.

Аякларыгызга кияргә онытмагыз, урман кисүчегә яланаяк йөрү килешми,— диде ул, каршысында яланаяк басып торган Ләбипкә ым кагып. Һәм шаярткан атлы булды.—Тиздән ундүрт тула бит инде, аннан унбишенче китәчәк сиңа да...

—Киям, нәчәлник абый, киям, әтидән калган күн итек бар безнең, зур булса да шуны киярмен,—диде Ләбиб, кабалана төшеп. Күп уйлап торсаң, урман кисүчеләр исемлегеннән төшереп калдырулары да бар.

Ярты сәгатькә сузып та тормадылар. Унбиш-егерме минут дигәндә малайлар өс-башларын әтмәлләп бәләкәй таш күпер янына җыелып та беттеләр.

Райтоп нәчәлниге мактап бетерә алмады үзләрен.

—Бу тикле булган, өлгер егетләрне күргәнем юк иде. Ай күрде, кояш алды дигәндәй, кай арада җыелып та беттегез. Вәт молодцы, вәт молодцы... Урман кискәндә дә шундый өлгер булырсызмы икән... Булырсыз, мин ышанам сезгә, булырсыз. Шулай бит, Ләбиб иптәш,—дип, иң кече малайны аркасыннан да кагып канатландырып алды ул. Һәм көлеп куйды.—Ундүрт тулмадымы соң әле?..

Шаяртуга күнеле булган Ләбиб авызын җырып елмаеп куйды.

—Үзем дә көтә-көтә көтек булдым бугай инде, тулмады шул әле, абый.

Шул рәвешле, райтоп нәчәлниге белән бер-ике сүз алмашкан арада, бригадир Фәрсәй карт та килеп житте. Аңарга Гарифуллин Гыйниятулла бабай да ияргән иде.

Бәләкәй таш күперне чыккач та урман юлыннан сулга борылды алар. Әмма ерак китмәделәр, салкын сулы чишмә кайнап торган уязлык читендәге каенлыкта туктап калдылар.

—Бу каеннарга инде йөз яшь булыр, шулай бит, Гыйниятулла абзый,— дип, иң элек аксакалга мөрәҗәгать итте райтоп нәчәлниге.

—Каен йөз ел яшидерме-юкмы, ул кадәресен әйтә алмыйм. Әмма бик борынгы агачлар инде болар. Без малай чакта ук бар иде инде алар,—дип, ипле генә сүзгә кереште Гыйниятулла абзый.—Яшь иделәр кәнишне. Ул чакта шул кәүсәләре беләк юанлыгы булгандыр кебек хәтердә калган.

—Ничәнче белән барасыз инде?

—Тиздән житмеш тула, боерган булса. Авылда ир-атлардан иң карты мин инде хәзер. Алланың биргәненә шөкер...

—Егетләр,—дип, тавышын күтәрде нәчәлник.—Диләнке менә шушында булачак.

—Диләнке...—дип, сораулы карашын Фәрвазга төбәде Нурый.—Ни дигән сүз икән ул, малай?

—Белмим шул. Утын әзерли торган урмандыр, күрәсең.

Рафаэльне исә башка сорау борчый иде. Колач житмәслек булып үскән бу каеннарны кистерәсе килми иде аның. Авыл әйләнәсендәге иң матур урыннарның берсе иде бит карт каеннар арасы. Монда җиләк, бөрлегән күп була торган иде. Җилле көнне килеп тынлап торган чаклары бар, ул каеннарның шаулавы да гаҗәеп тирән бер мәгънәгә ия иде бит. Ул каеннарны кискәчтен урман шәрәләнеп, ятим калыр төсле иде.

—Бу каеннарны кисәргә кызганыч инде,—дип әйтеп куйды ул, бар булган кыюлыгын җыеп.—Башка бер-бер урында булмыймы соң ул утынны әзерләп?..

—Кайсыгыз булды бу? Кем авызыннан чыкты бу сүзләр,—дип, кинәт кенә бер читтәрәк җыелышып торган малайларга табан борылды райтоп мөдире Хатыйп.

Егетләрнең күнеленә шом керде. Кермәслекме соң, нәчәлник кеше әнә нинди кырыс караш ташлады үзләренә. Кем икәнлеген белсә, куып

кайтарырга да күп сорамас. Авызларына су капкандай катып калды алар.

—Мин ул,—диде Рафаэль, ни язса шул булыр дигәндәй, тәвәккәлләп.—Каеннарны җәлләгәнгә генә әйттем, иптәш райтоп нәчәлниге абый.

—Каеннарны җәлли икән берәү,—дип, дәртләнеп янә кулларын болгый-болгый, хром итегенең очларында гына калып, очып китәргә җыенгандай канатланып сөйләп җибәрмәсенме нәчәлник.—Фронттан әнә безнең районга гына да ай саен илле-алтмыш "батырларча һәлак булды" һәм "хәбәрсез югалды" дигән хатлар килеп тора. Ил тоткасы булган ирләрне чалгы белән чапкандай кыралар. Меңәрләгән, миллионлаган каһарманнар Ватан өчен башын салды. Каеннар турында уйлый торган вакытмыни, иптәшләр. Ватан өчен утын кирәк! Фронт өчен утын кирәк! Утын—ул, бик беләсегез килсә, стратегик ягулык, иптәшләр... Тәк шту, вәт тәк, менә шулай, иптәш урман кисүчеләр!

Райтоп нәчәлниге шактый озак сөйләде. Ялкынлы итеп, ышандырып, тыңлаучыларны, бигрәк тә малайларны, киеренке бер халгә куеп сөйли белә иде ул. Тын да алмый тыңладылар үзен. Яңа Актау якларына бу тикле дә ялкынланып сөйләүченең килеп чыкканы булмагандыр әле анарчы. Ул сөйләгән арада бригадир Фәрсәй ике мәртәбә махра төреп тартты инде. Әмма үзе һич кенә дә эчкерле кеше түгел икән тагы. Ялкынлы сүзләрен тәмамлаганда Рафаэль турында бөтенләй оныткан да иде бугай. Сүзләрен искә төшереп, кабат-кабат каныгып тормады үзенә.

Шунда Рафаэльне, бармак изәп, бер читтәрәк карт каенга сөялеп торган Гыйниятулла бабай үзе янына чакырып алды. Үз итеп аркасыннан кочаклап алды иң элек.

—Улым,—диде, башкалар да ишетерлек итеп.—Бу каеннар өчен борчылма инде син. Аларның да шул, минем кебек, калса биш-алты ел гомерләре калгандыр. Бу дөньяда һичкем дә бернәрсә дә мәңгелек түгел, болай ичмаса алар кемгәдер файда китерәчәк, кемнедер җылытачак. Черел корып егылганга караганда файдалары күбрәк булачак аларның.

Гыйниятулла бабайны байтактан күреп белүенә дә карамастан, аның белән болай якын торып, кинәшен ишеткәне юк иде әле Рафаэльнең. Башта ул аның гомер буе эшләүдән сөялләнеп, бирчәеп беткән зур кулларына карап торды, аннан маңгаендагы тирән буразналарны хәтерләткән җыерчыкларга төште күзе. Баксаң, Гыйниятулла бабайның үзен әлеге карт каеннар белән чагыштыруы һич очраклы түгел икән бит, аның маңгай җыерчыклары чын-чынлап үзе сөялеп торган каен каерысына бик тә охшаш иделәр.

Яшь чакларында Гыйниятулла бабайны бик гайрәтле кеше булган дип сөйлиләр иде авылда. Ул Беренче империалистик сугышның башыннан ахырынача катнашып, берничә ел Германиядә пленда да булып кайткан. Немецларның телен генә түгел, үзләрен дә, илләрен дә яхшы белгән бердәнбер кеше иде әйләнә-тирәдә. Үзе пленда булып кайтса да, немецлар турында булсын, Германия турында булсын аның ялгышып та яман сүз сөйләгәне булмагандыр . Хатыны белән сигез бала үстергәннәр. Дүрт бала сугышка кадәр туган, дүртесе ул пленнан кайткач. Исемнәре бик кызыклы иде үзләренең: сугышка кадәр туганнары—Сөнгатулла, Сибгатулла, Мөхәмәтҗан һәм Сөембикә, ә сугыштан соңгылары—Алмес, Альберт, Радик һәм Фрида.

Малайлары олысы-кечесе барысы да сугышка китте. Инде икесенең үлем хәбәрен алган иде. Шуңарга бик аз сүзле, ягъни гел сөйләшмәскә әйләнгән иде ул соңгы араларда. Бер-бер артлы ике улларының үлем хәбәрен алу кайгысын күтәрә алмыйча гомер иткән хатыны да дөнья куйган иде.

Әмма аның болай кинәт кенә үзгәреп китүе һәм үз-үзенә бикләнүенең тагы бер яшерен сере бар икән. Сугыштан ике аягын да югалтып кайткан фельдшер Гималов Гали абыйга чишкән ул үзенең бу серен. Имеш, пленда

чакта Гыйниятулла бабай бер немец маржасы белән очрашып йөргән булган. Шул хатыннан бер малайлары туып, аңарга Алмес дип немецча исем кушкан булганнар. Шуның хөрмәтенә пленнан соң туган беренче малаена да шул ук исемне куштырган ул. Алмес исемле улының үлем хәбәрен алгач төш күргән бу: имештер, аның Германиядә калган улы Алмес Советлар илен яклап хезмәт иткән Алмесны атып үтергән. Дөрестерме-юкмы, менә шул төш корт булып кимерә икән Гыйниятулла бабайның бәгырьләрен...

Райтоп нәчәлниге әллә ни озакка тоткарланмады, Фәхрислам абзыйга тагы нинди дә киңәшләр бирде дә, малайларның һәммәсе белән олылап кул биреп хушлашып чыккачтын атына атланып китеп барды.

—Мин, көн дә булмаса да, әледән-әле кагылып узармын. Ә мари хатыннары иртәгесен килерләр ярдәмгә,—дип кычкырды ул инде агачлар артында күмелә дигәндә.

Менә, ниһаять, авылдашлар үзләре генә торып калды.

—Каеннар бик юан икән,—дип, арлы-бирле йөренгәли башлады бригадир Фәрсәй абзый.—Пычкыларны бик кысар микән инде.

—Развудлары әйбәт алынган. Егетләр—җилле,—дип, йөткеренде Гыйниятулла бабай, малайларның күңелен күтәрергә омтылып.—Мондый егетләр булганда Алып батырларың бер читтә торсын.

Мактау кемгә ошамый инде, малайларны канатландырып җибәрде шул сүз. Алар пычкы һәм балталарга үрелделәр.

—Сабыр итегез,—диде бригадир Фәрсәй карт.—Иң элек эшне ничек оештыру хакында киңәшергә кирәк. Арагыздан берегезне старший итеп сайлыйк иң әүвәл. Кемне?..

Малайлар бер-беренә каранып алдылар. Әмма баш ватып, бәхәс корып тормадылар.

—Рафаэль инде безнең командир, Рафаэль...—диделәр бертавыштан.

—Ә ул үзе ничек уйлый? Бөтен җаваплылыкны үз өстенә алырга әзерме?..

—Безгә нәрсәгә инде ул, старшийлар сайлап тормыйк, барыбыз да бер тигез тырышып эшләрбез, Фәхрислам абый,—дип әйтүче Рафаэль үзе генә булды.

—Юк, җегетләр, “Син дә мулла, мин дә мулла—атка печән кем сала...”, дигән сыман килеп чыгар, юкса. Һәр эшнең башында бер җаваплы кеше булырга тиешле. Армиядә ул командир була, ә менә калхузда персидәтел яисә бригадир ягъни мәсәлән...

—Ярый алайса,—дип, ризалашырга мәҗбүр булды Рафаэль.

—Менә шулай диген аны. Бер мәсьәләне хәл иттек, димәк. Инде тагы бер соравым бар,—дип, малайларны күз йөгертеп узды Фәрсәй карт.—Урман кискәнегез бармы соң сезнең?

Малайлар бер мәлгә тынып калдылар. Кем башлар сүзне дигәндәй, бер-беренә карангалап тордылар. Андый чакта, билгеле инде, беренче булып үз өстенә җаваплылык алган кеше әйтергә тиеш сүзен.

—Без бит, Фәхрислам абый, үзең беләсең, авылда үскән малайлар. Урман авыл кырыенда гына. Утын кисмәгән, корыган агач аудармаган малай юк инде ул,—дип әйтеп салды Рафаэль.

—Утын кисү бер хәл, урман кисү башка нәрсә, шулай бит, Гыйниятулла абзый,—дип, карт каенга сөялеп йокымсырап утырган аксакалга мөрәҗәгать итте бригадир.

Тегесе, күзләрен ачып тормый гына, баш кагып җөпләгәндәй итте.

—Иң элек агачны кайсы якка аудару уңайрак икәнлеген ачыклагыз. Моны агачның кай тарафка авышлыгын, ботаклары кайсы якта күбрәк булуын күреп кенә билгеләргә була. Кисә башлаганчы, киңәшеп бер фикергә килә торган булыгыз. Аннан аударасы яктан агачны бер ун сантиметр кисеп,

шул киселгән жирен балта белән кыйгачлап алырга кирәк. Шуннан соң инде, икенче ягыннан, бераз югарырак алып, ныклап кисәргә тотыныгыз. Кисеп чыгарганда, күсәкләр алып, агачны аударасы якка этеп торыгыз, өстегезгә ава күрмәсен. Утынны берәр метрлы итеп кисеп өерсез. Чыбык-чабыкларын икенче тарафка жыеп барыгыз, алары үзебезнең авыл кешеләре өчен ярап куяр. Аңладыгызмы инде?

—Аңладык...

—Тәк шту, вәт тәк, менә шулай,—дип, елмаеп куйды Фәрсәй карт. Бу аның, шаярган атлы булып, райтоп нәчәлниген кабатлавы иде бит.

Малайларга да кызык булып китте. Бер туйганчы көлеп алды алар да.

Беренче агачны Фәрсәй карт, пычкының икенче башын Рафаэльгә тоттырып, үзе кисеп күрсәтте. Калган малайлар, кулларына балта алып, агачны этеп аудару өчен кәшәкәле күсәкләр хәстәрли торды. Гыйниятулла абзый черем итә иде кебек, авыр сыкрау авазы чыгарып беренче каен ауган чакта гына күзләрен ачып алды.

Эш гөрләп торды. Малайлар, үз-үзләрен аямыйча, алны-ялны белмичә, жен урынына эшләделәр. Иртәгәсен аларга күрше авылдан килгән мари хатыннары да ярдәмгә кушылды. Йөзьяшәр каеннар кими барган саен урман эчендәге якты ачыклык зурайганнан зурая барды. Агачлары киселгән ул ачыклыкның дилянка дип аталганлыгын малайлар һәммәсе дә яхшы белә иде инде. Киселгән утынны тигез итеп әрдәнәләргә өеп бардылар. Ә чыбык-чабыгын, арба тарта алган вак-төяк малай-шалай, ялап алган кебек, арлырның артыннан ук авылга ташып бетереп барды.

Мари хатыннары да эшкә каты куллы икән, сүз әйтерлек түгел. Тик менә телләрен генә бик аңлап бетереп булмады башта. Ә тора-бара, ияләшә төшеп, үзләре пыр туздырып татарча сөйләшә, алар белән шаярыша да башладылар әле хәтта. Аларның һәммәсенә кушамат та табып бетерделәр. Үз итеп, аларга “матур малай”, “татар малай”, “якши малай” дип кенә эндәшә иделәр. Ә Рафаэльне исә, үз иптәшләре кебек үк, “камандир” дип атап йөрттеләр.

Көнгә ике тапкыр туктап тамак ялгап алалар иде. Мари хатыннары башта бер читкәрәк китеп аерым ашадылар. Әмма, бераз үзләшә төшкәч, малайларны да үз табыннарына чакырдылар. Уртак табын һәр ике тараф өчен дә кулай булып чыкты. Мари авылында икмәк кытлыгы бик зур икән, аның каравы, татар авылында гомер күренмәгән, тозлы кыяр, кәбестә, гөмбә кебек тәмле ризыклары мулдан иде. Малайлар үз ипиләрен бүлеп, аның зуррак өлешен хатыннар алдына куйды. Мари хатыннарының ул ипине шикәр кебек кенә вак-вак кисәкләргә бүлеп, бер валчыгын калдырмыйча кадерләп кабуларын күрсәң икән. Аның каравы, Яна Актауда күренмәгән ризык—гөмбә, тозлы кәбестәгә рәхәтләнде малайлар.

Бер-берләрен кысташып шаяра-көлешә ашауга житәме соң инде. Әллә нинди кызык һәм мәзәк хәлләр дә сөйләп жибәрә торган иде алар. Үзләре уйлап чыгарып түгел, булган хәлләрне сөйлиләр:

“Шулай бер көнне кичкырын аларның авылына жигүле ат арбасына утырып ике татар килеп чыккан. Таулар авылыннан булырга тиеш, бик шустрый татарлар икән.

—Утын кирәкме, мари абзый,—дип сораган болар, капка төбендә махурка көерәтеп утырган өстерлектән. Алар авылында да урман караучы, ягъни лесникны өстерлек дип йөртәләр икән.

—Юк, кирәкми,—дип, кул гына селкегән бу тегеләргә. Күрмисезмени, янәсе, әнә ич, капка төбенә тау кадәр итеп кисеп, ярып, өеп куелган.

Туктап та тормаган тегеләр. “Ярар, алай булгач”, дигәннәр дә атларын чаптырып китеп тә барганнар.

Ә иртәгәсен йокыдан торгач, лесник үз күзләренә үзе ышанмый телсез

калып торган. Капка төбенә тау кадәр итеп ярып өеп куелган имән утыныннан жилләр искән...

—Ялгыштым. Ялгыштым... Сорадылар югыйсә, утын кирәкми, дип, үзем әйттем шул, ди-ди сукранган икән өстерлек абзый".

Шаян сүз һәм мәзәк хәлләр дигәндә башкалардан калышырга күнекмәгән Нурулла да жавап йөзеннән сөйләп жибәрде:

"Бер мулла булган безнең күрше авылда. Көннәрдән бер көнне сазлыкта бата башлаган бу.

—Коткарыгыз,—дип кычкырган тавышына ярты авыл жыелган.

—Мулла абзый, бир кулыңны,—дип дәшәләр, тартып чыгарырга теләп кул сузалар икән үзенә.

Ә теге һаман да кулын бирми. Ә үзе батканнан бата бара икән. Башы гына торып калган сазлык өстендә.

—Мулла абзый, бир инде кулыңны, батып үләсең ич,—дип, арлы-бирле йөгеренә, ничек ярдәм итәргә белмичә өзгәләнә икән авыл халкы.

—Һәй наданнар,—дип шунда мәчет ягыннан мәзин йөгереп килеп житкән.—Мулла кешегә "бир" дип әйтәләр мени инде. Мә, хәзрәт, тот,—дип, кулын сузуы булган, теге моны эләктереп тә алган. Шул рәвешле, сазлыктан тартып чыгарганнар хәзрәтне..."

Мари хатыннары егылып-егылып көлде. Нурулла сөйләсә сөйләп күрсәтә инде ул.

Мари авылы Яммәттә дә ир-ат заты калмаган, барысы да фронтка китеп беткән икән. Хатыннар кайчак урман кисүче малайлар белән сөйләшеп утырган жирдән, ирләрен искә алып, аларның фронттан килгән хатларын укый-укый елашып та ала торганнар иде. Ә сугыш алдыннан гына унжидесе тулмас борын кияүгә чыккан Лиза исә, көннәрнең берендә иренең үлем хәбәрен алгач, елый-елый шешенеп бетте һәм гел сөйләшмәс булып калды. Сугыш вакытында берәүгә дә жиңел булмагандыр. Әмма әле яңа гына гаилә корып яши башладык дигәндә унтугыз-егерме яшеннән тол калган хатыннардан да кызганычрак язмышлар булмагандыр.

Юк, берәүгә дә жиңел түгел иде. Малайлар бит үз әниләренең дә нинди шартларда бала тәрбияләвен, ирләр эше дип тормыйча, көн-төн колхоз эшендә, аннан кайткач өйдә төн йокыларын калдырып кием-салым ямау, ашарга әзерләү, каралты-кура һәм мал-туар карау белән мәш килгәннәрен күреп торалар. Шулай да күрше мари авылыннан килеп урман кисүче ул хатыннар аеруча кызганыч иде аларга. Ник дисәң, алар бермә-бер гадирәк, эчкерсез һәм хәтта, табигать балалары буларак, беркатлырак та кебек иде.

Татар хатыннары еласа да качып еларга тырыша, күзен яулык чите белән булса да капларга жай таба. Ә болар исә, бахырлар, инде егет булып өлгергән малайларның күкрәгенә капланып та елап жибәрәләр. Лиза хәтта, Нурый шыттырмаган булса, аны берничә мәртәбә иреннәннән дә үбеп алган икән. "Син минем Микулайга охшаган. Шуны сагынганга, шуны юксынганга үбәем",—дип әйтеп әйтә икән.

—Охшаса охшагандыр инде, әмма иреннәре кайнар, чукынчыкның,—дип, сер итеп кенә, Нурый үзе сөйләде Рафаэльгә.—Эшләр зурга китмәгәе. Лиза үпкәндә, малай, тез буыннары чатнап-чатнап куйды.

Рафаэльгә кызык иде билгеле. Дустын күбрәк сөйләштерәсе, аннан күбрәк сораштырасы килде аның, әмма уңайсызланды.

Утсыз төтен чыкмый дигәндәй, Лиза тора-бара эшкә бар булган матур киемнәрен киеп килә торган булып китте. Нурулланың кая киткәнен, кайчан килгәнен күзәтеп кенә йөри, тәмам ияләште үзенә. Бер-бер авыр агачны күтәрешергә кирәк булса да ярдәмгә Нурулланы чакыра, урман эчендәге чишмәгә суга барасы булса да үзенә юлдаш итеп сайлап ала иде

ул аны. Нуруллага исә бу бик ошый. Иптәш малайларына күз кысып серле караш ташлап ала да, елмая төшеп, Лиза артыннан китеп бара. Ә кире әйләнеп кайткан чакта, күрсәгез икән сез аны, май ашаган мәчегә әверелә тәмам. Авыз колакка житкән була.

Бу тарих күпме дәвам иткән һәм ни белән тәмамланган булыр иде икән, белгән юк. Көннәрдән бер көнне алар янына эшнең ничек баруын тикшерү уе белән райтоп нәчәлниге Хатыйп үзе килеп чыкты. Әллә бераз төшереп тә алган, кәефе шәп иде аның. Малайларны гел мактап бетерә алмады. Мари хатыннарына да житте мактау сүзләре.

Шунда берчиттәрәк Нурулла белән янәшә каенга сөялеп торган Лизага күзе төште аның. Һәм сөйли башлаган сүзен онытып, ыспай әтәч кебек хром итекләренен бармак очына гына тып-тып басып, анын каршысына килеп басты. Лизанын ике йомарлам май кебек тырпаеп торган күкрәкләренә текәлеп карап торды башта. Егерме яшьлек тол хатын кочаклап торган каенны ошаттымы, карашын махсус түбәнгәрәк текәп, шул каенны беркат әйләнеп чыкты аннан.

—Карале, мин сине күргәнем юк иде кебек, син яңа кешеме әллә монда?—дип дәште ул анарга, янә каршысына килеп баскач, баштан-аяк үзен тикшереп.

Лиза уңайсызланып куйды, ике бит алмасы кызарып чыкты шундук.

—Яңа кеше түгел, мин беренче көннән башлап эшлим, туарищ райтуп нәчәлниге,—диде ул, тегенең ач карашыннан үзен кая куярга белмичә, читенсенеп.

—Чуа-то мин сине хәтерләмим. Күргән булсам онытмас идем,—дигән булды ул. Тагыниләрдер әйтергә уйлаган иде дә, башкалар каршында әйтергә кыймады тагы үзе.

Лиза башын түбән иеп китеп барам дигәндә, кулыннан тотып туктатты аны Хатыйп.

—Бар энем, иптәшләрең янына бар, эшеңдә бул,- дип, Нурулланы читкә таба куып жибәрде.

Нәчәлник әйткәч, тыңламый булмый, китәргә мәжбүр булды Нурулла. Бер читтәрәк торган карт каен янында Лиза белән генә торып калды райтоп нәчәлниге. Икәүдән-икәү генә калгач, ул сөйләшә белә инде.

—Исемен?—диде ул анарга, күзләрен майландырып.

—Лиза.

—Матур икән исемен.

—Безнен авылда Лизалар күп инде ул...

—Белемен?

—Жиде класс.

—Яхшы. Бик яхшы...

—Жиде классның нәрсәсе яхшы булсын инде.

—Миңа синең белемең кирәк түгел. Үзең яхшы! Үзең...—диде ул, һич тартынмыйча иреннәрен ялый-ялый.

—Башкалар кебек инде...

—Менә шул, Лиза, син бүгеннән башлап минем кантурда эшли башларсың.

—Ничек алай, мин урман эшендә бит, туарищ райтуп нәчәлниге.

—Монда кем нәчәлник?—дип тавышын күтәргән булды Хатыйп.

—Син...

—Сугыш вакытында нәчәлник сүзе—закун. Тәк шту, вәт тәк, менә шулай, матурым. Аңладыңмы?!

—Аңлавын аңладым да бит, туарищ райтуп нәчәлниге. Урман кискән кешеләргә утын була, диделәр. Ә кыш көне утынсыз нишләрбез?

—Утының да булыр, чуртың да булыр. Күп сөйләшеп торма,

анладынмы?!.—дип, башкалар күрмәгәндә, үзенә генә серле итеп күз кысып алырга да өлгерде шул арада.—Мин сине кошовкада гына утыртып йөрермен, анладынмы?!

Лиза ни дияргә дә белмәде. Район тикле районнан килгән нәчәлниккә каршы сүз әйтеп булмый бит инде, буйсынырга мәҗбүр булды.

Шулай итеп райтоп нәчәлниге Хатыйп, һичкемгә берни аңлатып тормастан, ялгызы гына утырып килгән тарантаска Лизаны утыртып китеп тә барды.

Киткән чакта Нуруллага таба каерылып-каерылып караса да авыз ачып сүз әйтә алмады Лиза. Нурулланың да әллә ниләр әйтәсе, Хатыйпның аты каршысына чыгып басасы, аларны туктатасы килде, әмма булдыра алмады. Бугазына килеп тыгылган авыр төерне кая куярга белмәүдән, читкә тайпылды, башка чара калмады.

Менә шулай, Лиза китеп барды. Ә Нурулла калды.

Көн артыннан көн үтә торды, әмма Лиза кире алар янына әйләнеп кайтмады. Үзләре белән эшләүче мари хатыннары Нуруллага сер итеп кенә сөйләделәр: Лизаны эштән җигелгән тарантаска утыртып кына кайтарып куялар икән хәзер. Танымаслык булып, тагы да матурайган, диләр үзен. Кыска итәк киеп биек үкчәле туфлиләрдә генә йөри икән. Иреннәрен кып-кызыл итеп буяп, исеннән башларың әйләнеп китәрдәй тәмле хушбуйлар сибеп җибәрә ди.

—Мине сораштырамы соң? Мине искә ала микән?- дип кызыксынмый булдыра алмады Нурулла.

—Гел сораштырып кына тора. Привитлар да әйтергә куша,—диделәр, малайның күңелен күреп.

Малай шунарга чын күңелдән куанды. Димәк, Лиза аны онытмаган, аны хәтерли икән бит. Ә бәлки әле сагына да торгандыр. Сагынуны һәм яратуны аны урман кисүче хатыннар аша тапшырып булмый бит инде. Төннәр буе күзен дә йоммый Лизаны уйлап чыккан чаклары да бар иде аның.

Малайлар октябрь башына кадәр утын кисте ул җәйне. Иписез көннәре дә булды, аяк киемнәре туздым, алны-ялны белми барыбер эшләделәр. Уч төпләре картайган каен каерысы кебек сөялләнеп-муртаеп бетте. Әмма арадан ник берсе арыдым яисә талчыктым дип сүз әйтсен яисә ялгышып кына булса да зарланып алсын икән. Сугыш вакыты ич, һәркем ил язмышын үз язмышыннан алгарак куеп эшләргә һәм яшәргә тырышты.

Шунысы кызганыч, авылның куанычы булып ел тәүлеге буенча юлга чыгучыларны шаулап озатып калган һәм каршы алган каенлык шәрәләнде. Карап торсаң, түзәм димә, күзләреңә кайнар тамчылар килеп тыгыла. Аның каравы, Мәскәү һәм Ленинград калалары өчен менә дигән утын булды. Шунысы тынычландыра иде күңелне, бу утын илбасарларны тар-мар итүгә алардан өлеш булып керәчәк бит.

—Сугыштан соң монда яшь агачлар утыртырбыз,—дип кенә юаттылар аларны.

## 5

Инде эшне тәмамлап, Каран мәктәбенә төшәргә җыенып йөргән көнне урам яктан сызгырган аваз җәлеп итте Рафаэльне. Капка төбендә аны Нурулла көтә иде.

—Бик җитди йомыш бар, малай,—дип, читкәрәк алып китте ул аны. Һәм үтә яшерен сер сөйләгән сыман пышылдауга күчте.—Райтоп нәчәлниге үзенең малаен өйләндерә икән. Безне туйга чакыра.

—Нинди туй ул, сугыш вакытында, шаяртма әле,—дип, кул гына селтәмәкче иде Рафаэль.

Әмма дусты шаяртмый, чынлап сөйли иде кебек.

—Эшләр болай тора, дустым Рафаэль,—дип, олыларча килештереп сөйләп китте Нурулла.—Бүлдермичә генә тыңла, йәме. Теге, безнең белән утын кисә башлаган Лизаны хәтерлисеңме?

—Яхшы хәтерлим. Шуннан...

—Шуннан, утырган да шуган. Лиза үтенеп сорагач, теге чакта мин анарга татарча җыр җырлап күрсәткән идем. Ул яратып тыңлаган иде. Лиза бит хәзер райтуп нәчәлниге белән эшли. Үзенә күрә ул да нәчәлник бит инде хәзер, иреннәрен кызартып, ислемайлар сибеп йөри икән эшкә. Вәт тәк, малай, бер дә шухрый-мухрый түгел! Нәчәлниге Лизадан бер-бер баянчы йә булмаса җырчы табарга иде, дип сораган. Ә Лиза ике уйлап тормаган: "Теге урман кисүче Яна Актау малайлары үзләре җырчы, үзләре музыкант та бит—менә дигән ансамбль",—дип әйтеп ташлаган. Вәт шуна мине райтоп нәчәлниге үзенә чакыртып алды да инде.

—Кайда чакыртты, кайчан?—дип, колагы ишеткәннәргә ышанырга белми аптырап торды Рафаэль.—Син малай, дуслардан яшереп әллә кайларда йөрисең икән...

—Райтоп нәчәлнигенең үзен күрмәдем, кәнишне. Бөтенесен Лиза аңлатып бирде. Лиза бит безнең авылдан ерак түгел генә Иске Барак лесхозында эшли икән. Үзенең аерым кабинеты бар мин сина әйтим, өстәле-урындыгы бар. Чәй эчим дисәң, самавырларына кадәр кайнап тора. Бер кырыйда шыгыр-шыгыр килеп торган күн диван. Лиза кыска итәктән генә, биек үкчәле туфлиләре белән тып-тып басып, менә болай итеп арлы-бирле болганып йөгереп йөри, малай. Райтоп нәчәлниге атнага бер, йә булмаса ике мәртәбә генә килеп китә икән. Башка вакытларны—Лиза үзе нәчәлник.

—Ярар, син миңа, дустым, Лиза турында түгел, туй турында сөйлә инде,—дип бүлдерде аны Рафаэль.—Кем туе соң ул? Райтоп нәчәлнигенең малае Лизага өйләнәмени?..

—Һе, Лизаны мин беркемгә дә бирмим,—дип әйтеп ташламасынмы Нурулла. Аннан аңлатуын дәвам итте.—Райтоп нәчәлнигенең сугышка яраксыз бер кылый малае бар икән. Шунарга Көязебаш авылыннан унҗиде яшьлек бер кызны димләгәннәр. Кызның әтисе сугышта һәлак булган, әнисе авырып урын өстендә ята икән. Берсеннән икенчесе кечкенәрәк биш сеңлесе бар икән. Түрә кеше белән туганлашкач, шуларның тамагы булса да тук булыр бәлки дип ризалашкан диләр кызны. Качып кына урман эчендәге биш-алты өйлек Иске Барак лесхозында туй итәргә җыеналар икән. Туй булгач, җырсыз булмый—шуна, үз кешеләр итеп, безне чакыралар.

—Аңлашылды,—дип әйтеп куйды Рафаэль коры гына.—Башкалар үз-үзләрен кызганмыйча фронтта кан коя. Ватан өчен гомерләрен бирергә әзерләр. Ә боларның кешедән качып кына туй итеп яту икән исәпләре. Мин андый эшкә катнашмыйм, Нурый дус.

Моңарчы ашкынып торган Нурулла, кәефе кырылудан, коелып төште. Ни дип әйтергә, дустын ничек юмаларга белми торды бермәл. Ләкин шундук үз-үзен кулга алып өлгерде.

—Өйләнү, гаилә кору—ул җинаять түгел, Рафаэль. Син алай кырт кистереп куйма әле, малай. Кылый булса да, ул бит кеше баласы. Атасының да улын өйләндерергә тырышуы гаеп эш түгел. Сугыш вакыты булмаса ул унҗиде яшьлек кыз шундый егеткә әллә чыкмаган да булыр иде. Гаилә ул, бик беләсең килсә, дустым, безнең илнең киләчәге. Шулай дип язганнарын гәҗиттән укыганым бар. Тәк шту, вәт тәк, менә шулай...—дип йомгаклап куйды ул сүзен, райтоп нәчәлниген искә төшереп.

Нурулла гел йомшартып җибәрде бит әле Рафаэльнең күңелен.

—Туйда җырларга без бит җырчы түгел, син ул ягын бер дә белмисеңме?

Лизаны күргәч тә синең башың әйләнгән, алдын-артын уйламыйсың.

—Ник уйламаска, бик уйлыйм,—дип, тагы да тәвәккәлрәк сөйләшүгә күчте Нурулла.—Беренчедән, без бишебез дә җырлый беләбез. Урман кискәндә аз җырламадык. Икенчедән, Фәрваз әтисеннән калган гармунда шыгырдата белә. Син өздереп мандолинада уйныйсың. Рижалның камыш курае бар. Ләбиб кул чәбәкләп торыр, кирәксә әле ул мәтәлчек ата-ата бии дә белә. Ә мин бер пар агач кашык алып килермен дә шуларны сугып уйнармын. Харап шәп чыгачак бу безнең.

—Кеше көлдермәбез, бәлки,—дип тә карады Рафаэль. Әмма Нурулланы уеннан кире кайтара алмады.

—Туй булгач—кеше көлергә, кәеф күтәрергә тиеш. Туй бер генә була.

—Лиза тәмам башыңны әйләндергән икән,—дип, башын чайкаудан һәм ризалашудан башка чарасы калмаган иде Рафаэлнең. Әмма мәсьәләнең икенче бер четерекле ягы да бар, ул хакта да онытып булмый. Кием ягы.—Ә синең туйга киярлек киемең бармы соң? Миндә юк. Башкаларда да шул ук хәл дип беләм...

—Без—урман кисүчеләр. Ансамбльнең дә исеме шундый ук булачак—“Урман кисүчеләр”. Димәк, киемнәребез дә урман кисүченеке була. Тәк шту, вәт тәк, менә шулай. Килештекме?..

—Килештек.

Күңелләре күтәрелеп китеп, чәпелдәтеп кул биреште ике дус—килештеләр. Сабыйлык дип әйтү килешмәс, малайлык чыгып бетмәгән иде шул әле үзләреннән.

Туй, билгеләнгән көнне, билгеләнгән сәгатьтә бернинди шау-шусыз башланып китте. Кыз ягыннан сиксәнне узган әбисеннән башка туйга килер кеше табылмаган. Егет ягыннан да районда калган иң якын туганнар гына чакырылган иде. Башка һичкемнең, хәтта якын күршеләрнең дә бу хакта хәбәре юк. Сугыш вакытында туй итә дигән сүз чыгару кирәк түгел иде шул райтоп нәчәлниге өчен. Сүз чыга-нитә калса, моның ни белән бетәсен ул яхшы белә. Эшсез калу гына түгел, башсыз калуың да бик ихтимал.

Урман хуҗалыгының бинасы болын кадәрле, җылы һәм иркен. Бинаның тәрәзәләре калын пәрдә белән томаланган. Түрдә, бер-берсенә кыюсыз гына әледән-әле күз төшергәләп, кияү белән кәләш утыра. Алар шушы көнгә кадәр таныш та булмаганнар ахырысы, әледән-әле бер-беренә сынаулы караш ташлап алалар.

Райтоп нәчәлниге малае, ташка үлчим, тумыштан ук кылый икән, бер күзе әшрикъка караганда, икенчесе мәшрыйкъка борыла. Алай да сер бирми тагы үзе, муенны текә тота, күбесенчә түшәмгә карап утыра. Шулай караганда килешәрәк төшә бугай аңарга. Матур итеп киенгән. Дулкынланудандыр инде, әледән-әле сузып-сузып борынын тарта. Буйга кешедән ким җире юк, ике аягы һәм ике кулы үз урынында—менә диген кияү егете инде киендереп-ясандырып куйгач.

Ә кыз... Күрсәң күзеңне ала алмаслык дәрәҗәдә матур һәм сөйкемле иде кыз. Яшь болан баласыдай сылу, яңа ачылган роза чәчәгедәй гүзәл, җиләк яфрагына кунган таң чыгыдай саф иде ул бер үк вакытта. Исеме дә җисеменә тин—Зәйнәп. Күренеп тора, Зәйнәп үз язмышын үзе хәл иткән, балавыз сыгып яисә балтасы суга төшкән кешедәй мескенгә сабышып утырмый. Язмыштан узмышлар юк шул. Кияү егетнең күңеленә ачкыч табарга теләгәндәй, әледән-әле аңарга үзенең ягымлы һәм җылы карашын юнәлтеп ала иде.

Шул җылы карашны тоюданмы, кияү егеткә җан инде. Кызның матурлыгына сокланып, шатлыгыннан елмаеп ук җибәрде ул бераздан. Ә елмаю кемгә килешми соң...

Туйда иң бәхетле кеше райтоп нәчәлнигенең хатыны булгандыр. Ул тутый кош каурыйларыннан бер дә кайтыш булмаган матур яулык һәм күлмәкләргә төренгән. Шактый ук озын буйлы һәм юан да икән тагы, бүлсән, ике түгел, өч райтоп нәчәлниге чыгар иде үзеннән. Аның йөзендәге бәхет нурлары бөтен бинаны нурландырып торырга житәрлек булгандыр. Барыннан да бигрәк, булачак килененнән канәгать иде ул. Әнә ич, нинди кыз тапкан анарга әтисе. Чибәр кызлар яисә хатыннарга күзе чос инде аның элек-электән. Шул сыйфаты белән аның да теңкәсенә төшкән, көнләштереп җанын телгәләгән чаклары аз булмагандыр, нишлисең бит, һәр рәхәтнең үзенә күрә михнәте була инде аның.

Туйдагы бар кеше һәм һәрнәрсә куаныч чыганагы булып тоела иде нәчәлник хатынына. Тик менә, теге, кыска итәкле, түгәрәк ботлы мари кызы гына эчен пошырды. Ул каян килеп эләккән дә һәм ни өчен үзен әллә кемгә куеп йөри соң әле монда—аларның туенда.

Мари кызы дигәне, Лиза иде, әлбәттә. Лизаның юк-юк дигәндә дә аның ире Хатыйпка арка яктан килеп, нидер сорашкан атлы булып, тырпаеп торган күкрәкләре белән ышкылып китүен сизми идеме әллә ул. Ә ир- ат затына шул житә кала, барысы да бер иш инде аларның, әнә ич, Лиза артыннан ач кәҗә тәкәседәй карап кала. Икенче бер уйласаң, “Карамагае тагы” дип тә тынычландырды ул үз-үзен. Нәчәлник кешегә хатын-кызның күзе чос була инде ул, бер бүген генә түгел, гомер-гомергә шулай килгән.

Бәхетенә каршы, Лизаның кайда һәм кем булып, кем янында эшләвен ачык кына белеп бетерми иде нәчәлник хатыны. Барысын да белсә, басып торган җиреннән мәтәлчек атып егылган булыр иде дә бит. Белми торсын әле...

Өстәлләр, үз заманы өчен ярыйсы гына мул булса да, туй—туй сыман җанланып китә алмый торды озак кына. Өстәлдә аракы, көмешкә күренмәсә дә ир-ат заты үз җаен тапкан иде ахры, чаршау артына бер-бер артлы иппле генә кереп китәләр дә, ялт итеп иреннәрен ялый-ялый кире чыгалар. Шул арада борыннарына кызыл шәфәкъ нурлары кунарга өлгерә, бер дә юктан гына түгел иде бу. Кунаклардан бигрәк, райтоп нәчәлнигенең үзенә хуш килде бу юл, шырт иткән саен ул шул чаршау артына керә дә югала, керә дә югала иде.

Аңлашылса кирәк, туй мәҗлесенең бар авырлыгы кияү-балакайның әнисе җилкәсенә төшеп калды. Болай да санаулы гына кунакларның вак төркемнәргә тарала баруын күреп, ул үзе үк җыр башлап карады:

И аланда инде, и аланда,
Мәкнең чәчәккәе бар анда;
Бергә җыелышкач җырлашыек,
Җыелышып булмас болай ялан да...

Әмма җырны эләктереп алучы, җырга кушылучы табылмады. Аның үзе нечкә, үзе әче, үзе бер үк вакытта чәрелдек тә булган тавышына кушылырга җөрьәт итмәделәр бугай. Ә ул ни тавышы, ни моңы булмаса да үзен җырчы саный иде. Бер аңарга гына хас түгел, түрә хатыннарының күбесендә була торган шаукым инде ул. Тагы да әчерәк, тагы да чәрелдәбрәк җырлавын дәвам итте кияү-балакайның әнисе.

Челтерәп аккан чишмәгез,
Ялтырап каткан бозыгыз;
Арыслан кук безнең егетебез,
Ничек икән сезнең кызыгыз...

Жырлады жырлавын. Әмма шушы жыры белән туй өстәле артында утырган унжиде яшьлек кәләшне, ягъни үзенең киленен шактый уңайсыз хәлдә калдыруын кичегебрәк аңлады. Бу жыр бит—җавап сорый, ә кыз ягыннан җавап бирер кеше юк. Бер почмакта дисбе тартып утырган сиксән яшьлек әбисе исә, колакка каты иде булса кирәк, башын да калкытмады. Җырламагайлары тагы, әллә бар иде алар бу карчык өчен, әллә юк.

Нәкъ шул мәлдә чираттагы мәртәбә чаршау артыннан тирләп-пешеп чыгып килүче райтоп нәчәлниге Хатыйп, үз хатыны җырыннан дәртләнеп китеп, кычкырып такмаклап җибәрмәсенме:

Агыйдел күпере,
минем хатын бөкере...

Хатыйпның җыры тәмамланмый ярты юлда өзелеп калды. Ни өчен дисәң, тешләрен кысып, йодрыкларын йомарлап алган хатыны килеп тә җиткән иде инде янына.

—Кем бөкре... Әйт әле, кем бөкре? Өйгә генә кайтыйк, күрсәтермен әле мин сиңа кемнең бөкере, кемнең туры икәнлеген. Туры җирләреңне бөкрәйтермен, бөкреләрен турайтырмын!

—Чеметмә әле, ботны кара яндырып чыгарасың ич,—дип, бер читкә тайпылып куйды райтоп нәчәлниге.—Җырның җыртыгы җук инде аның. Үзең җырлаганга гына җырладым ич...

Һәм шунда, нидер искә төшереп, кулын кулга сугып шапылдатып куйды ул.

—Онытыла язган ич. Безнең туйга бер дигән артистлар да чакырылган иде бит әле... Лиза... Лиза, бар әле җәт кенә артист егетләребезне чакырып керт.

Лиза исә, шул боерыкны көтеп кенә торган диярсең, түгәрәкләнеп торган арт санын килешле генә уйнатып өйалдына таба чыгып йөгерде.

Нәчәлник хатыны кыска итәкле чукынчыкның һәр адымын һәм хәрәкәтен энә күзеннән үткәрә, кем өчен шулай боргаланганын аңламады түгел, аңлады, әлбәттә. Шуңа бит инде, әле Лиза кире борылып кергәндә дә җыерылган борын үз хәленә кире кайтырга җыенмый иде.

Әмма кунакларның бар игътибарын ишектән кереп килүчеләр җәлеп итте. Бер кыяфәтләре белән генә дә гаҗәпкә калдырырлык иде шул алар. Иң алдан ялтырап торган ике куллы пычкы тотып Рафаэль килеп керде. Аның артыннан кыска итеп киселгән утын түмәренә чабылган балталарын аркаларына салган Нурулла, Фәрваз, Риҗал һәм Ләбиб ияргән. Күтләрендә ямаулы чалбар, өсләрендә кояшта-җилдә уңып беткән эш күлмәге. Кайсы эшләпә киеп алган, кайсы фуражка, кайсы түбәтәйдән. Ә Нурулла исә, каян тапкан диген—мари картларының да бик сирәкләрендә генә очрый торган сары камыш эшләпә чәпәп куйган башына. Яңа гына акшарланган зур мич каршындагы буш урынга барып басты урманчы егетләр. Кайсы берсе үзләре күтәреп кергән утын түмәренә утырды. Мич артыннан җәт кенә гармун, мандолина һәм тагы әллә ниләр тартып чыгардылар. Һәм, кунаклар аны-моны абайлап өлгергәнче, матур итеп уйнап та җибәрделәр. Тынлап торсаң, гел килешле генә көй чыгаралар иде тагы үзләре. Рафаэль мандолина чиертеп җибәрде. Фәрваз бер рәтле иске гармун тартырга кереште. Әллә уйнавы шулай гына, әллә бакалары батып калган иде гармунының, шыгыр-шыгыр китерде дөньясын. Риҗал курай сайрата, Ләбиб кубыз гыжылдата. Нури исә, үзе кашык суга, үзе дирижерлык итә, үзе басып торган җирдән бии-бии башлап җырларга кереште.

Без үзебез Актауныкы,
Йөремәйбез мактанып.
Без урамнан үткән чакта
Кызлар кала сокланып.

Ай илләре, илләре.
Илләрендә—күлләре.
Шул илләрдә кызлар жырлай
Сандугачтай телләре.

Кунакларга жыр ошап китте. Алар башта шым калып тынлап кына утырган булса, ул да түгел, малайларга кушылып кул чәбәкли-чәбәкли өстәл астындагы аякларын тыпырдатырга керештеләр.

Урам аша чыккан чакта
Әллә абындыгызмы.
Сарыларга салышкансыз,
Әллә сагындыгызмы...
Ай илләре, илләре...

Кунаклар кыюланганнан кыюлана барды. Инде берәм-берәм жырга да кушылып китә башладылар. Нурулланы исә бу хәл тагы да дәртләндерә төште, урман кисүче малайлар белән генә түгел, инде туй мәжлесендәге бөтен кунаклар белән идарә итүне үз кулына алып бара иде ул. Үзе жырлый, үзе бии, үзе кашык суга. Ул сикерүгә, ул сугуга агач кашык түзә торганмы соң, кителеп-кителеп идәнгә коелып бетте инде алар. Әнисеннән сорамый гына алынган, өйләрендәге соңгы ике кашык иде югыйсә. Ничек жавап бирер, белгән юк. Әлегә исә, кашык кайгысымыни, кашык түгел, идән сынып, түшәм жимерелсә дә тукталырлык хәлдә түгел иде ул, туй мәжлесенең кендегенә әверелеп китте бит, әнә. Сикерә-бии, уйный-жырлый иде безнең Нурый. Бер читтә үзен Лиза күзәткәнлекне дә онытмый иде, әлбәттә :

Алай да яна йөрәк,
Болай да яна йөрәк.
Яна йөрәк, яна йөрәк,
Яна пожарник кирәк.

Ай илләре, илләре.
Илләрендә—күлләре,
Шул илләрдә кызлар жырлай,
Сандугачтай үзләре...

Кияүгә дә жан керде тора-бара. Ул кызның касыгына төртә-төртә кылый күзе белән егетләргә таба ымлап каш сикертә, аякларын өстәл аратасына бәреп тупырдата башлаган иде. Яшьләрнең бу дәртле жыры шул кадәр биләп алган иде кунакларны, утын түмәрләре кебек утырган абзый һәм апалар да түзмәде, урыннарыннан сикереп-сикереп тордылар. Яшь киленнең дә йөзенә көләчлек кунды, тигез ритмга башын чайкый-чайкый үзалдына жырлый башлаган иде инде ул да. Чаршау артында ир-ат заты калмады, алар анда керү юлын онытып торды байтак кына. Парлашып-парлашып биючеләр дә бар иде инде. Иң хикмәтлесе шул, " ай илләрен..." такмаклаганда райтоп нәчәлнигенең хатыны, жыр-бию дәрте белән онытылып китеп, мари кызы Лиза белән култыклашып бии һәм әйләнә башлаганын да абайламый калды.

Жыр тәмамланып, биюдә-уенда булган кунаклар үз урыннарына утырыша башлагач та, инде чаршау артына йөри-йөри шактый ук йөзе килгән райтоп нәчәлниге Хатыйп, хуҗа буларак, сүз башлады:

—Кунаклар,—дип, кулын югары күтәрде ул.—Минем бүген иң бәхетле көнем. Сез шул бәхетне бүлешергә, уртаклашырга килдегез. Рәхмәт сезгә! Бүген минем сөекле улым Миргазиян өйләнә. Зәйнәп белән алар яңа гаилә коралар. Ә гаилә ул, кадерле иптәшләр, социалистик ватаныбыз СССРның нигез ташы. Туган илебезне сакларга әзер булырлык уллар һәм кызлар үстерүләрен телик без аларның. "Урра!" иптәшләр. Тәк шту, вәт тәк, менә шулай, улым Миргазиян. Бүгенгесе көннән эшкә керешәсең...

Хатыйпка ияреп "ур-ра" кычкыручы булмады булуын. Шулай да, үзе хакындагы сүздән артык дәртләнеп киткән идеме, әтисе нотык сөйләгәндә кияү егет Миргазиян берничә мәртәбә калкынып-калкынып куйды һәм әтисенә охшатып йодрыгын югары чөйде.

—Нәрсә, улым, бер-бер сүз әйтеп җибәрәсеңме әллә?—диде моны күреп торган әтисе.

Малай, нишлим икән дигән сыман, әнисенең күзләренә текәлде.

—Җә, җә, сүзең бармы әллә? Сөйлә, җә, әйт, матурым,—дип, дәртләндереп җибәрде үзен әнисе.

Рөхсәт булгач, урыныннан сикереп диярлек торып басты Миргазиян. Әмма ни сәбәптәндер, сүзен генә башлый алмый азапланды. Ни әйтим икән диеп, бер әнисенә, бер әтисенә алмаш-тилмәш карап торды. Әнисе, башын кагып, яшь кәләшкә таба ымлады, аңарга бер-бер сүз әйт, улым, дигән сүзе иде бу. Әмма малайга тиз генә барып житмәде.

—Инде улым, әти-әни күзенә карап кына яши алмассын,—дип, киеренкелекне киметергә теләп сүз башлады әтисе.—Бездән качып эшли торган эшләрең дә булыр инде моннан ары.

Малай дөрес аңладымы-түгелме, әйтеп булмый. Әмма теле ачылды үзенең.

—Анысын булдырабыз аның, әти,—дип, авызын киң җәеп бәхетле елмаеп җибәрде ул шунда. Һәм кәләшенә борылып кылый күзен сикертеп куйды.—Шулай бит, иеме, Зәйнәп. Ниятенә генә кермәгән әле, ниятенә дә бер кереп китсәк...

Зәйнәп коелып төште һәм нык кына уйга калды. Кая һәм кемгә килеп эләктем мин, дип уйлады булса кирәк ул шул мизгелдә. Кияү егет авызын тагы да ныграк җыра төшеп дәвам итте.

—Әти сиңа рәхмәт. Миңа әйбәт хатын тапкансың. Ошый да башлады инде ул миңа. Ватан каршында да бурычлы булып калмабыз. Бүген үк эшкә тотынабыз, шулай бит иеме...—диде дә тотлыгып калды ул. Кәләшенең исемен хәтерли алмый иза чикте.

—Зәйнәп... Зәйнәп,—дип пышылдадылар аңарга. Уңнан да, сулдан да пышылдадылар. Әмма теләсә кем әйткән сүзгә игътибар итмәде ул, үз әнисе арка тарафтан килеп җитеп кабатлаганнан соң гына кәләшенең Зәйнәп атлы булуына инанды.

—Әйе,—диде ул, кош тоткандай бәхеткә ия булып.—Зәйнәп. Минем хатын—Зәйнәп.

—Утыр!—диде, ниһаять, түземлеген җуя төшкән әнисе. Һәм җилкәсенә басып малаен урындыгына таба кысты. Ә үзе, берни булмагандай, кунакларга мөрәҗәгать итте.—Әллә, хөрмәтле кунаклар, безнең киленебез Зәйнәпкә багышлап бер-бер җыр җырлап алыйкмы...

"Урман кисүчеләр" бу унайдан алдан ук кисәтеп куелган иделәр, озак көттермичә җыр башлап җибәрделәр—"Ал Зәйнәбем" не.

Бакчадагы гөлләремнең
Тамырлары бер генә шул, Зәйнәбем;

—дип, калын һәм көр тавыш белән Рафаэль жырларга кереште иң элек. Башкалардан аермалы буларак ул бу жырны яхшы белә, аны үзе генә калган чакларында жырлап туймый торган иде. Рафаэльне тиз арада дуслары күтәреп алды. Жыр урман шаулавыдай бөтен мәжлесне жилкендереп жибәрде, дулкын шавы сыман йөрәкләрне дәртләндереп узды.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен жәйләрең!

Жыр матур яңгырады. Шуңа да ул күп кенә нәрсәләрне онытырды, табынга янадан бәйрәм рухын кайтарды кебек. Әмма килен булып төшкән Зәйнәп кенә, үзенә багышлап жырлаган жырның сүзләрен ишетер, аңлар хәлдә түгел иде булса кирәк. Нишлисең бит, язмыш! Ә язмыштан узмыш юк диләр... Бер телем икмәккә тилмереп авыру әниләре янында калган сеңелләре турында гына уйларга тырышты ул шул мизгелдә. Үзе хакында уйламады.

Ә жыр агыла. Жыр тагын да бөтен табынны бер итеп күтәреп алган иде инде.

Күз тияр дип, йөзләреңә
Туйганчы карамадым шул, Зәйнәбем.

Ал Зәйнәбем, гөл Зәйнәбем,
Рәхәт үтсен жәйләрең!

Кыскасы шул, туй шәп узды. Яшь килен белән кияү-балакайны, алдан килешеп куйганча, күрше йортка озатып куйдылар. Райтоп нәчәлниге хатыны шул китүдән кире әйләнеп кайтмады, чаршау артын сакларга калды булса кирәк. Улына йә булмаса килененә ярдәм-фәлән кирәк булырга да ихтимал иде ич...

Ә райтоп нәчәлниге Хатыйп исә, ялгызы гына калгач, икенче өйдәге башка чаршау артыннан чыкмас булды. Һәм бу эш, билгеле инде, аның исереп йомшаруы белән тәмамланды. Ул инде кичәдән оялыр хәлдә түгел иде, берөзлексез Лизаны кымтырыкларга маташты. Тегесе исә, ачуланмады, карышмады, әмма үзен бигүк тоткаларга да ирек куймады, шома балык кебек шуа да чыга, шуа да чыга иде райтоп нәчәлниге кочагыннан. Ахыр чиктә, чираттагы мәртәбә чаршау артыннан чыгып килгән Хатыйпны ике таза егет, аңлашылса кирәк, боларның берсе Нурулла иде билгеле, жигелгән ат арбасына чыгарып салдылар. Ат китте. Туй таралды. Урман кисүче музыкантлар Яна Актауга таба юл тотты. Араларында Нурулланың булмавына да бигүк исләре китмәде кебек. Туйдан соң бинада тәртип ясау, жыештыру һәм фәлән-фәсмәтәннәр өчен ярдәмгә дип, аны Лиза үзе белән алып калган булып чыкты.

Ни хәл итмәк кирәк, туйлар узды. Туйлар тиз арада онытылды да инде хәтта. Әмма районда Яна Актау авылында оешкан жыр һәм музыка ансамбле—"Урман кисүчеләр" хакында сүз көннән-көн үсә һәм арта гына торды. Күрше-тирә авылларга чакырдылар аларны иң элек, авыр эш һәм кайгы-хәсрәттән башканы белмәгән хатын-кызларның һәм сугыштан кайткан инвалидларның күңелен юатты алар үз жырлары белән. Клубларда гына түгел, ачык һавада һәм ындыр табакларында да рәхәтләнеп уйный-жырлый иде алар. Үзләре мәктәпкә йөргән Каран авылында исә һәр тантаналы вакыйга аларның чыгышы белән башлана һәм тәмамлана торган булып китте. Дан дигән нәрсә, ул жепшек кар сыман, бер хәрәкәткә килсә

бик тиз үсүчән була, боларның да даны еракларга китте тора-бара. Тимер юл станциясендә вакытлыча урнашкан күчмә госпитальга чакыртып алдылар үзләрен бераздан. Фронттан Урал һәм Себер тарафларына китеп баручы яралылар "афәрин" дип кычкыра-кычкыра кул чапты аларга. Татар һәм башкорт җырларын яратып тыңладылар. Русча җыр да сорадылар. Дөресен әйтергә кирәк, русчалары бик чамалы иде анысы, шулай да "Катюша" белән "Подмосковные вечера"ны ярыйсы гына ерып чыктылар. Шул рәвешле, шаярудан гына башланган эш шактый дәвамлы һәм нәтиҗәле дә булып чыкты бит әле. Әздән генә артист булып китмәде Яңа Актау малайлары...

## 6

1944 нче елның язында Рафаэль тугызынчы классны тәмамлады. Уку аңарга бик җиңел бирелә иде, барлык фәннәрдән дә бишле генә. Ә шулай да күңел тынычсыз, илдә уку кайгысы түгел, синең ничәле билгеләреңә укуыңда һичкемнең гаме юк. Илдә менә өч ел инде сугыш дәвам итә. Фашистларны атна-ун көн эчендә тар-мар итәбез дип фронтка чыгып киткән авылдашларның инде яртысыннан күбесе сугыш кырларында ятып калды. Ай саен авылга кайгылы хәбәр килеп тора. Шундый чакта унҗидене тутырып килгән сау-сәламәт авыл егетләре ничек, әле урта мәктәпне тәмамларга тагы бер ел калды дигән сылтау белән, үзләренә повестка килгәнне көтеп кул кушырып утырсыннар икән.

Рафаэльнең, әнисеннән яшереп кенә, район хәрби комиссариатына гариза җибәрүенә инде ярты елдан артык вакыт узды. Ә җавап һаман да килми. Әллә хаты барып җитмәде, әллә башка берәр сәбәп, һич белгән юк. Беркөнне бу серен ахирәт дусты Нуруллага сөйләргә булды ул. Баксаң, Нурулла үзе дә шундый ук хат юллаган булган икән. Аның хаты да җавапсыз калган.

Озак уйлап тормадылар, көннәрнең берендә таң белән алар икәүләшеп район үзәгенә—Бүздәккә юл тоттылар. Басу капкасын чыгып күп тә китмәделәр, авыл ягыннан килгән тавышка кире борылып карасалар, артларыннан тирләп-пешеп Фәрваз йөгереп килә иде. Сулышына капкан, ә үзе ачулы. Килгән шәптән дусларына үпкәсен белдерергә керешә ул:

—Мине ташлап кая китеп барасыз. Дуслар шулай эшли мени! Әллә белми, сизенми, дисезме?.. Минем сездән кай җирем ким дип уйладыгыз...

Дөрес сүзгә җавап табу җиңел түгел, алар дәшмәделәр, гаепләрен таныи бер-береңә карап куйдылар бары.

Тарткалаша-тарткалаша булса да хәрби комиссарның үзенә үк барып керде алар. Теге исә, нигә килгәннәрен дә сорап тормады, каян белгән диген, сүзне үзе башлады:

—Нәрсә, фронтка җибәрүне сорап килдегезме?—диде ул, кергән шәптән.

—Әйе,—дими чаралары юк, шуннан ары, ни әйтергә белми, бер-береңә карангалап торды алар.

Сүз әйтмичә дә булмый, җүнле-башлы сөйләшә дә белмәгән кешене кем сугышка тотып җибәрсен ди инде. Рафаэльгә ым какты Нурулла белән Фәрваз.

Ул арада хәрби комиссар үзе ярдәмгә килде.

—Йә, сөйләгез, телегезне йотмагансыздыр ич, кайсы авылдан килдегез. Исем-фамилияләрегез дә бардыр...

—Без Яңа Актауныкы, иптәш хәрби комиссар,—дип аңлатырга керешә Рафаэль.

—Ә-ә, беләм-беләм, Яңа Актау бик матур авыл. Шундый матур табигать кочагына урнашкан авылны ташлап китәргә җыенасызмы...

Хәрби комиссарның бу сүзләре аларның күңелләренә сары май булып ятты. Дулкынлану, курку, калтырау шундук юкка да чыкты. Баксаң, бер дә куркыныч яисә кырыс кеше түгел икән ич. Алар кебек үк матур итеп татарча сөйләшә. Хәтта аларның туган авылы Яңа Актауны да белә икән бит әле.

—Әйе, туган авылыбыз матур анысы,—дип дәвам итте Рафаэль.—Әмма без гаризалар да язып карадык, җавап килмәде. Менә үзебез килдек. Иптәш комиссар, алыгыз безне армиягә, безнең дә туган илне саклаучылар сафында буласыбыз килә.

—Әйе, әйе,—дип хуплады, күтәреп алды шунда Нурулла.—Без инде мылтыктан атарга да өйрәндек, "шагом марш"ка да атлый беләбез.

—Ә син нигә дәшмисең, син ничек уйлыйсың?—дип, бер почмакта посыбрак утырган Фәрвазга баш какты комиссар, елмая төшеп.

—Минме,—дип, сискәнеп урыныннан ук сикереп торды Фәрваз.—Мин, иптәш комиссар, разведкага барып немец генералларын капчыкка салып алып кайтыр идем. "Тел" буларак, хәрби серләрен сөйләтер өчен...

Комиссарга кызык булып китте.

—Тагы, тагы нинди батырлыкларга сәләтле инде син?

—Тагымы,—Фәрваз үзен ирештерәләр дип уйламый иде әле.—Тагы мин, иптәш комиссар, Александр Матросов кебек дошманның атып торган пулеметына капланып, дусларымны үлемнән коткарып калырга әзер.

—Ә үлемнән курыкмыйсыңмы? Син бит әле шундый яшь, сез бит әле яши дә башламагансыз. Кызлар сөясегез, гаилә корып балалар үстерәсегез бар. Үлем куркытмыймы?..

—Куркыта инде анысы,—дип куйды Фәрваз, эчкерсез сөйләшүгә ияреп китеп.—Әмма Ватан өчен үләргә дә була.

—Менә шул, егетләр,—дип, сәгатенә карап алды хәрби комиссар,—сугыш—ул уен түгел, иң элек шуны аңлагыз. Ә инде Ватанны сакларга атлыгып торуыгыз, шул хакта сорап килүегез—икеләтә мактаулы һәм ихтирамга лаек эш. Гаризаларыгызны язып калдырыгыз да, барыгыз, авылыгызга кайтыгыз. Авылда да эшче куллар кирәк. Ул эшегез дә җиңүгә керткән өлешегез булыр. Вакыт җиткәч тә без сезне чакыртырбыз. Менә шул.

Малайлар сөйләшү болай тәмамланыр дип көтмәгән иде, әлбәттә. Чираттагы мәртәбә, үзара киңәш иткән сыман, бер-берләренә карашып алдылар.

—Юк, иптәш комиссар,—дип, кыюланып китте Рафаэль,—без сезнең янга янадан авылга кайтып китү өчен килмәдек. Сездән чакыру килгәнне көтеп ятсак, сугыш беткәнче без авылда булачакбыз. Ә без бүген үк, менә хәзер үк фронтка җибәрүегезне сорап килдек. Без кемнән ким!..

Комиссар, тагы да җитдиләнә төшеп, урыныннан торып басты. Киемнәрен тарта төшеп хәстәрләде, каешын турылады. Аның артыннан, алдан сүз берләшкәндәй, малайлар да сикереп торды. Рафаэльнең каршысына килеп басты комиссар, аның кыска итеп алынган чәченнән сыйпап куйды:

—Исем, фамилияң...

—Рафаэль Смаков, әтием Миргалим исемле.

—Ә-ә, менә ничек,—дип, тагы да ачылып китте хәрби комиссар.—Син Миргалим абый малае буласыңмыни?

—Әйе, мин Миргалим Смаковның иң олы малае булам. Сез минем әтине беләсезме?—дип, шаккатты, гаҗәпләнеп калды малай.

—Беләм. Яхшы беләм. Миргалим абый минем иң яраткан укытучым иде. Богады мәктәбендә тарихтан укытты ул безне. Туган илне яратырга, дөньяны танырга өйрәтте. Бик күп нәрсәгә өйрәндем мин анардан. Ул чын укытучы... Ә кайда ул хәзер, исәнме әле?

—Әти Чиләбедә. Танклар ясый торган заводта эшли. Сугыш башланганнан бирле кайтканы юк. Хатлары килеп тора.

—Заводта эшлиме?..—дип, гажәпләнде комиссар, башын чайкап куйды.—Аның сәламәтлеге беләнме... Сугыш вакыты шул.

Егетләрнең барысына да кул биреп чыкты ул һәм, үзенең бик ашыгыч эшләре булуын аңлатып, чыгу юлына китте. Малайлар ишек төбендә утырган кече лейтенант янында гариза язып калдылар.

## 7

1944нче ел җәендә алар тагын утын кисте. Әмма урманга барышлый һәр көн иртән почта ташучы капкасын урап узалар иде. Почтальон булып эшләүче Хәдичә апаларын йөдәтеп бетерделәр:

"Миңа повестка юкмы әле?.. Миңа повестка килмәдеме?"—дигән сорауларына, " Юк, килмәде",—дигән җавабы әзер иде хат ташучының.

Әмма һаман бер үк төрле җавап ишетүдән арып бетте инде алар. Шуңарга: "Хәдичә апа, әллә югалдымы икән ул чакыру. Эзләтеп карагыз әле..." дип тә тинтерәтә башлады алар хат ташучыны. Аның да түземлеге бетеп, малайларны ачуланып ташлыйсы килгән вакытлары булгандыр. Шулай да хат ташучы Хәдичә апалары сабыр кеше иде, каты бәрелмәскә тырышты: "Тәмам туйдырдыгыз инде, иртән дә бер сорау, кичен дә. Почтага мин атнага ике мәртәбә генә барам, наныйлар. Каран якын ара түгел, шул тикле җиргә көн дә чыгып йөгерә алмыйм, җәяүләп бару-кайту байтакка җыела. Килсә, беркая да китмәс, үзем өегезгә китерермен...",—дип юата иде.

Инде тәмам өметләр өзелеп, унынчы класска йөри башлаган көннәрдә авылга повестка килеп төшмәсенме. Рафаэльгә... Ә Нурулла белән Фәрваз аңардан берничә айга яшьрәк иделәр, шуңа алар бераз көтеп торсын дигәннәрдер.

Рафаэль тиз арада унынчы класс өчен имтиханнарын тапшырып, урта мәктәпне тәмамлау турында аттестат алырга да өлгерде әле.

1944 нче елның елак һәм пычрак көзендә, ягъни 17 октябре таңында, җилкәсенә арыш капчыгыннан кисеп тегелгән биштәр элеп, юлга чыкты ул. Басу капкасын чыкканчы аны елый-елый әнисе һәм ике энесе—Рим белән Нур озата барды.

—Житте, башкача бармыйсыз, үзем генә китәм. Тизрәк барып җитәргә кирәк, юкса соңлавым бар,—диде Рафаэль.—Солдат кешегә кичегеп йөрү ярамый.

—Улым, исән-сау гына йөр. Юлында яхшы кешеләр генә очрап торсын. Хуш, сау бул,—диде төн буена черем дә итми улының кием-салымын юып-хәстәрләп, тишек-тошык җирләрен астарлап чыккан Хафаза апа. Күңеле нечкәреп улының такыр итеп кырылган чигә чәчләрен бармак очы белән сыйпап алды ул шул чакны. Үз балаларын гаять дәрәҗәдә кайгыртып яшәсә дә Хафаза апа күңелендәге хис һәм тойгыларны аларга бик күрсәтергә яратмый иде. Гомумән, безнең татар-башкортларда әти-әни белән үбешү, аерылышкан һәм күрешкән мизгелләрдә кочаклашып елаулар кабул ителмәгән бит ул.

Рафаэль иң элек әнисен, аннан энеләрен аркаларыннан какты да, кискен борылып җәт-җәт китеп барды. Шул мәлдә бугазына килеп тыгылган күз яшьләре тышка бәреп чыгудан, әнисе каршында үзенең йомшаклык күрсәтүеннән курыкты ул барыннан да элек. Кире борылып карыйсы бик килсә дә, ул байтак кына ара борылмаска мәҗбүр итеп барды үзен. Әмма урманга житеп килгәндә, түзмәде, тукталып, хушлашырга теләгәндәй, авылга таба борылып карап торды. Басу капкасын кочаклап сыгылып төшкән әнисенә игътибар итте иң элек: "Әни елый..." дигән уй китереп

сукты чигәсенә. Аннан үзе артыннан йөгереп килгән Нур белән Римгә төште карашы. Пычрак саз ерып йөгерәләр иде алар абыйлары артыннан. Әнә, Нур аягы таеп китеп йөзтүбән пычракка килеп төште. Әмма шундук торып тагын Рим артыннан йөгерде.

Энекәшләрен көтеп торырга мәҗбүр булды ул. Юл капчыгын ачып, аларга үзенә дип тыгылган ярты ипидән ике зур-зур кыерчык сындырып бирде. Һәм тагы бер мәртәбә аркаларыннан сөйде.

—Барыгыз, кайтыгыз инде. Әни еламасын, әнине тынычландырыгыз. Сез хәзер өйдә иң олы малайлар булып каласыз, әнигә ярдәм итегез, карагыз аны,—дип кычкырды артларыннан.

—Ярар, бөтен эшне үзебез эшләрбез,—дип җавап кайтарды Рим.—Безгә фуражкага кадый торган йолдыз алып кайтырга онытма, яме абый...

Бүздәктән аларны товар вагонына төяп шул ук кичне Уфага озаттылар. Әле яңа унҗиделәрен тутырган кырыкка якын малай, арыш саламы түшәлгән суык вагонның почмакларына каз бәбкәләредәй төркем-төркем җыелып, укмашып-укмашып утырдылар. Төрле мәктәп, төрле авыллардан җыелганга әле алар бер-берләрен белми, рәтле-башлы танышыр аралары да булмады. Вагон эчендә, үзара сөйләшкәнгә караганда, йөткергән авазлар ешрак кабатлана иде. Күпчелек малайлар өчен бу туган авыллары һәм районнан беренче тапкыр аерылу булгандыр әле. Һәм нинди аерылу бит, тагы атна ун көн дигәндә аларның күбесе фронтка, алгы сызыкка барып житәчәк. Анда ни көткәнен кем белә—яшәүме, үлемме... Ул хакта уйламыйм дисәң дә, уйламый торып булмый. Әнә шуңа күрә дә алар һәркайсы үзалдына уйга бирелеп, тыныч кына монсуланып бара.

Рафаэльнең бөтен уйлары туган авылына барып тоташа иде. Беразга күзен йомдымы—аермачык булып күз алдына авыл килеп баса. Армиягә китәм дип ничек кенә ашкынды югыйсә, шушы көнне күпме зарыгып көтте, хыялланып күпме йокысыз төннәр кичерде. Ә инде шул хыяллары тормышка ашып килгәндә, күз алдыннан туган авылы, туганнары, Яңа Актауның урман-болыннары китми аптырата. Нурулла белән Фәрваз ни эшләп, ниләр уйлап йөриләр икән хәзер? Мөгаен, аны юксына торганнардыр, ә бәлки бераз көнләшү хисе дә кытыклый торгандыр әле үзләрен. Ни дисәң дә Рафаэль армиягә киткән көн ич. Бу хәбәрне, бәлки, Асия дә ишеткәндер инде. Әллә ничек кенә булды, аның белән дә кешечә хушлаша алмадылар. Яратышып йөрделәр дип әйтерлек булмаса да, үзара бер-беренә тартылулары хак иде ләбаса. Асия ун классны тәмамлагач та Сәбәй авылында кибетче булып эшли башлаган иде. Авылга әллә нигә бер генә кайта инде хәзер. Асия матур кыз, кибетче дә булып эшли башлагач, артыннан йөрүче егетләр буа буарлыктыр инде хәзер. Рафаэлне ике ятып бер искә дә алмый торгандыр әле. Ярар, үткән эшкә салават. Нигә монсу уйларга бирелеп бара соң әле ул?.. Туган авыл, анда калган газиз кешеләр хакында бик уйламаска иде дә бит, әмма уйламыйм дисәң дә уйландыра икән шул...

Телеграф баганасы очраган саен туктала-туктала, шалтор-шолтыр барган поезд Уфа вокзалына икенче көнне иртән генә барып житте. Аларны республика хәрби комиссариатына җәяүләп алып киттеләр. Иске бишмәт һәм ямаулы телогрейкалардан гына киенгән булсалар да, урам уртасыннан тигез рәтләргә тезелеп атлап барганда, алар артыннан һәр кеше борылып карап кала. Шул карашлар исә төне буе товар вагонында күз дә йоммый туңып, бөрешеп килгән егетләргә беркадәр җан өрә, дәрт иңдерә иде кебек.

Хәрби комиссариатта эшне аларның сәламәтлеген тикшерүдән башладылар. Ак халатлы марҗа кызлары каршында анадан тума чишенеп

йөрү уңайсыз иде билгеле, ни хәл итәсең, солдат тәртибенә буйсынырга мәҗбүр булдылар. Һәммәсенең дә чәчләрен пәке белән кырып алдылар аннан соң. Татар-башкорт авылларыннан килгән малайларда чәч болай да озын булмый инде ул, әмма тәртип шундый булгач, аларны гына аермадылар.

Һәм, ниһаять, төш вакыты якынлашып килгәндә үзләрен беренче тапкыр җылы аш белән сыйладылар. Әниләре пешергән токмачлы аш булмаса да, егетләрнең эчләренә җылы керде, тел ачкычлары әйләнеп кайтты үзләренә. Үзара таныша һәм уен-көлке сөйләшә, шаярыша да башладылар тора-бара.

Шул ук көнне булачак солдатларның һәркайсыннан нинди частьта хезмәт итәргә теләүләре белән дә кызыксындылар. Сугыш вакыты өчен бу гайре табигый тоелырга мөмкин, әмма инде 1944 нче ел ахыры якынлашканны искә алсаң, бер дә гаҗәп хәл түгел. Рафаэль үзенең күптәнге хыялы—очучы булырга теләвен сөйләде. Бер ул гына түгел, һәр ике малайның берсе очучы булырга хыяллана иде, әлбәттә. Әллә үз теләген искә алып, әллә башка бер сәбәп белән, аны чынлап та Чкалов шәһәрендәге хәрби очу училищесына юлладылар.

Уку йортында исә, кемдә нинди теләк бар, дип сорап тормадылар. Фронтка тиздән яңа тип самолетлар җибәреләчәк. Очучылар җитәрлек, ә менә махсус белемле хәрби штурманнар бөтенләй юк икән. Рафаэльне бу хәбәр куандырмады билгеле. Бер уңайлы вакыт табып, барлы-юклы русчасы белән рота командирына мөрәҗәгать итте ул:

—Иптәш капитан, мин очучы булырга хыялланган идем.

Капитанның исе китмәде. Соравына күрә җавабы дигән сыман, коры гына:

—Хыяллан, курсант. Хыялланудан тыймыйбыз,—диде.

—Хәрби очучы буларак мин күбрәк файда китерер идем. Иптәш капитан...

—Разговорчики... Әбиеннең мич башында утырмыйсың курсант.

—Очучы буласы килә иде шул.

Шунда гына капитан егетнең хәленә кереп, аңлатырга кирәк санады.

—Сугыш дәвам итә. Ә без барыбыз да солдатлар. Сугыш вакытында, “хыял” һәм “теләк” дигән төшенчәләр юк. “Ватан өчен кирәк” дигән сүз генә бар. Аңлашылдымы, курсант! Фамилияң ничек?

—Курсант Смаков. Аңладым, иптәш капитан.

—Тагы мин сиңа шуны да әйтә алам. Штурман—ул самолетта иң зур кеше. Ул самолетның хуҗасы. Летчик—ул шофер. Ә штурман—навигатор, ул акыл белән, баш белән эш итүче интеллигент та бик беләсең килсә, курсант Смаков. Штурманлыкка без иң сәламәт һәм яхшы билгеләренә генә укыган егетләрне алабыз, бик беләсең килсә. Вот так, курсант Смаков.

Шуның белән сүз бетте. Күңелдә очучы булырга дигән хыял сүнмәсә дә башкача ул хакта сүз кузгатуның урынсыз икәнлеген аңлады Рафаэль. Һәм үз язмышы белән килешеп, штурман һөнәренең серләрен өйрәнүгә бөтен тырышлыгын куйды. Авылга дусларына язган хатларында исә әледән-әле капитаннан ишеткән сүзләрне кабатлады: “Штурман—самолетның хуҗасы. Летчик—ул шофер. Ә штурман—навигатор, ул акыл белән, баш белән эш итүче интеллигент...”

Бу сүзләр, бәлки, кемгәдер мактану булып тоелгандыр. Ә Рафаэль исә ул сүзләрне кабатлый-кабатлый бер очтан үз-үзен тынычландыра иде. Чөнки бала чактан ук килгән иң олы хыялы—очучы булу, летчик булып зәңгәр киңлекләрне иңләү онытылмады, киресенчә, ул көннән-көн арта гына бара иде. Штурманлыкка укуны да ул шушы олы хыялына ирешү юлында чираттагы этап буларак кабул итте. Әмма ул юл кешегә сөйләсәң,

кеше ышанмаслык дәрәҗәдә борылмалы һәм катлаулы булып чыкты аның өчен.

Егет Җиңү көнен Чкалов шәһәрендә хәрби штурманнар хәзерләү уку йортында каршылады. Алай гына булса бер хәл, 1946 елның маенда СССР оборона министрының Чкаловтагы штурманнар мәктәбен ябу турындагы әмере килеп төшә. Бу яңалык курсантларга аяз көнне яшен суккандагыдай тәэсир ясый. Ясамаслык та түгел, инде укуны менә-менә тәмамлыйбыз да хәрби авиация частьларына хезмәткә китәбез, ин яна самолетларда оча башлыйбыз дип хыялланып йөргән көннәре иде бит. Кемгә кирәк булган да, кем уйлап тапкан алар өчен мондый җәзаны... Рафаэль исә үз-үзен кая куярга белми йөрде байтак кына. Дусларына һәм әти-әнисенә хат язуын туктатып торды хәтта. Чөнки, ул бу хәбәрне һичкемгә җиткерергә теләми иде. Ул хакта язган тәкъдирдә дә ышанмаслар иде кебек аның сүзләренә. Булдыра алмаган, шуңарга куганнар икән, дигән яман сүз чыгудан курыкты.

Курсантларның күбесе, хәрби хезмәткә чакырылган солдатлар сыйфатында, төрле хәрби частьларга җибәрелә. Ә бик яхшы билгеләренә генә укыганнарын хәрби училищеларга тәкъдим итәләр. Шулар арасында Рафаэль Смаков Серпухов шәһәрендәге хәрби авиацияга механиклар хәзерләү мәктәбенә барып юлыга.

Серпуховка китәргә тиешле өч курсантны үзләренең командиры капитан Буданов шәхсән озатып кала.

—Беләм, сезгә авыр. Ләкин, безгә—сезне укыткан офицерларга—тагы да авыррак, шуны аңлагыз,—ди ул, егетләрнең кулларын кысып.—Әмма армиядә министр приказы үтәлергә тиеш. Аның урынлы-урынсыз булуы шик астына куелмый.

—Аңлыйбыз. Советлар Союзына хезмәт итәбез,—дип җавап кайтарды солдатлар.

—Ләкин сез, башкаларга караганда бәхетлерәк санарга тиеш үзегезне—авиацияда каласыз. Беләм, сез очар өчен туган бөркетләр. Мин кулымнан килгәнчә ярдәм итәргә тырыштым үзегезгә. Калганы үзегездән тора,—диде Буданов. Бу сүзләрне әйткәндә ул Рафаэльга карап куйды. Күрәсен, аның белән сөйләшүләрен онытмаган иде капитан.

Серпуховта алар 1947 елның августына кадәр, ягъни 15 ай дәвамына яна профессия үзләштерделәр. Һәм шул ук елның августында сержант Смаковны әле сугыш ыгы-зыгысыннан арынып бетмәгән Румынияга җибәрделәр. Анда ул хәрби самолетларны очышка әзерләүче өлкән механик буларак хезмәтен дәвам итте. Бу гаять киеренке һәм авыр еллар була. Румыннар Совет солдатларын, үзләренә азатлык китерүче буларак түгел, басып алучылар кебек кабул итә. Шуңа әле бер, әле икенче урында, партизан отрядлары сыман оешып, алар Совет гаскәрләренә каршы ачыктан-ачык көрәшүләрен дәвам иттерәләр. Рафаэльгә дә 1947 нче елның декабрь ахырларына кадәр кулына корал алып канкойгыч сугыш вакыйгаларында катнашырга туры килә. Әмма румыннарга каршы барган бу сугышны искә алу ул заманда катгый тыела. Баш күтәрүчеләрне тар-мар иткәч тә ике арада шактый киеренке мөнәсәбәтләр дәвам итә. Тимер чыбыклар белән уратып алынган хәрби частьтан аз гына читкә тайпылдыңмы, син инде үзенне куркыныч астына куйдым дип сана. Кыйнап китү генә түгел, үтереп ташларга да күп сорамый монда җирле халык. Сугыштан соңгы бөтен җимереклек һәм хәерчелекне, әйтерсең лә, аларга безнең солдатлар алып килгән.

Шуңа күрә монда хезмәт итүчеләргә хәрби часть биләмәсеннән читкә аяк басу катгый рәвештә тыелган иде. Ул гынамы, туган ил белән теләсә нинди элемтә һәм, хәтта, хат алышу да тыюлы. Клуб юк, китапханә юк, телевизор һәм радио турында хыяллану кая инде ул. Бик ачыкканда яисә

эчен пошканда кагылып чыгар өчен кибет һәм буфет итше нәрсә дә юк. Хатын-кыз заты да, күренсә, шул ике кат чәнечкеле тимер чыбык койманың аргы тарафында гына, анда да әллә нигә бер күренеп китәргә мөмкин. Еллар дәвамына бер үк төрле тормыш—эш, аш һәм йокы. Һәр туган яңа көн саен шулай, яңа көн һичнинди яңалык вәгъдә итми монда. Кая карама, шул бер үк таныш йөзләр—очучылар, механиклар һәм солдатлар. Очучылар өчен тимер чыбык койма артында яшәүнең авырлыклары, бәлки, ул кадәр үк тоелмый да торгандыр. Чөнки алар, самолетта гына булса да иркен дөнья, зәңгәр киңлекләрне урап кайту бәхетенә ия. Ә механик—ул җирдә, ул көнозын тимер-томыр арасында казынудан башканы белми.

"Самолет" дисәләр, Рафаэль борылып карый, әйтерсең лә ул аның үз исеме, аңарга шулай диеп дәшәләр сыман тоела иде. Самолет—ул Рафаэльнең иң авырткан һәм йомшак җире. Рафаэльнең күңелен берөзлексез нәрсә тынгысызлый, ни җилкендерә икән дисәгез, җавап бер—ул әлеге дә баягы шул хәрби самолетлар... Алар каты гүләү авазы чыгарып җирдән күтәрелеп киткәндә вакыт-вакыт бик тә кыен булып китә иде аның өчен. Балачактан бирле очучы булырга хыялланып, зәңгәр киңлекләрне канатлы кош сыман иңләү хыялы белән саташып үскән авыл малае бит ул. Инде менә ничәнче ел бар укыганы, бар өйрәнгәне—самолет. Штурман һөнәрен үзләштерде иң элек, әмма диплом алыр көннәре якынлашып килгәндә, үч иткәндәй, уку йортлары ябылды. Күпме тырышлык һәм хыял җилгә очты. Урамга чыгарып җибәргәндәй иттеләр, дүрт ягың кыйбла дигәннән артык булды анысы. Инде, Ходай кушып, ниһаять, укып һөнәр алды. Хәзер менә авиациядә өлкән механик булып хезмәт итә. Самолетның ул һәр винтын, һәр шөребенә кадәр белә. Ә барыбер әле күккә күтәрелгәне юк. Бүген дә иртәдән кичкә кадәр көннен-көн буена шул самолетларны очышка әзерләү белән мәшгуль булды, бар механизмын, бөтен приборларын карап, көйләп чыкты ул аларның. Ә зәңгәр күккә ул түгел, башкалар күтәрелә. Самолетның зур тизлек алып бетон юлдан ыжгырып килгәнен, кинәт кенә җирдән аерылып кош сыман югары күтәрелеп киткәнен күргән саен йөрәге сулкылдап-сулкылдап куя иде аның. Кош булып канатлары булса, түзмәс, артларыннан калмый үзе очып китәр кебек иде. Башкалар, әнә, оча, ә ул җирдән карап кала. Кем уйлап чыгарган да, кем юллаган аңарга шундый язмыш сынауларын. Махсус уйласаң да шулай килеп чыкмас.

Әмма шундый кичереш һәм хыяллар җанын эчтән көн-төн кимерүгә дә карамастан, ул бу хакта ачылып китеп теләсә кемгә сөйләмәскә тырыша иде. Кайбер летчикларның, барлы-юклы сәбәп табып, очудан читләшергә тырышуын күргәндә эче поша, җен ачулары чыга. Ә инде летчиклар үз һөнәрләрен яратып, бер-берләре белән фикер алышырга керешсә, дөньясын онытып тыңлый, ул аларның яннарыннан китми. Үз һөнәрен яхшы белгәнгәдер, очучылар аны үзләре дә аерым бер җылылык белән якын күрә торган иде. "Самолетны өлкән сержант Смаков очуга хәзерләде" дигән сүз, ул летчиклар телендә гарантия буларак кабул ителә, иң югары бәя буларак яңгырый башлады.

Күрәсең, читтән генә күзәтеп, сынап йөргәнме, көннәрдән бер көнне эскадрилия командиры данлыклы очучы капитан Вобликов аңарга сорау белән мөрәҗәгать итте.

—Рафаэль, мин байтактан сине күзәтеп йөрим. Үзенә бер сорау бирергә ярыймы?

—Тыңлыйм, Александр Иванович. Бер түгел, ун соравыгызга да җавап бирергә әзермен.

—Яшерми генә әйт әле, син летчик булырга хыяллана идеңме әллә?

Көтелмәгән сорау иде бу. Чөнки, ул бу хакта һичкемгә сүз катмаска тырыша иде бит. Белсәләр, үзенә тагы да кыенрак булыр кебек тоела торган

иде. Башка бүтән берәү сораса да ул сер бирмәгән булыр иде әле. Ә сугыш ветераны, берничә орден кавалеры, данлыклы летчик-испытатель капитан Вобликовка ялганлый алмады.

—Иптәш капитан, хыяллана идем генә түгел, бүген дә хыялланам. Балачактан бирле хыялланам. Әмма, хыял гына үземнән оча да китә, оча да китә, һич кенә дә тоттырмый...

Үзенең эчкерсез сүзләреннән унайсызланып куйдымы, беркадәр тартына төшеп елмаеп җибәрде ул шунда. Аның куе кара кашлары артыннан карап торган чем кара күзләрендә ниндидер тамчылар мөлдерәп чагылып киткәндәй булды. Кызыклы һәм киеренке халәт иде бу—әзмәвердәй яшь һәм таза ир-атның иреннәре елмаерга итә, күзләре кайнар яшькә буылган. Табигатьнең дә була андый чагы—кояш та балкый, янгыр да ява берүк вакытта, кояшлы янгыр ява диләр халык телендә.

—Ә нигә очучылар мәктәбенә бармадың? Сәламәтлек рөхсәт итмәдеме, кирә алмадыңмы...—дип, кызыксынуын дәвам итте капитан.

—Хәрби комиссариатта гаризамны "авиациядә хезмәт итәргә телим", дип язган идем. Штурманлыкка укыдым башта, аннан механик булдым. Летчик булырга телим, дигән сүзләремә колак салмадылар, иптәш капитан. "Син солдат, Ватан кая кушса—шунда барасың" дип томаладылар авызны.

—Анысы дөрес. Солдатка алынган егетләрнең яртысы очучы булырга тели, ә калган яртысы танкист булу турында хыяллана. Ә сугышның төп авырлыгы пехота җилкәсенә төшә. Хакыйкатьтән качып булмый, сугыш чорының никадәрле генә кырыс булмасын, үз кагыйдәләре бар шул аның.

—Инде Җинү көне килгәнгә дә байтак гомер, иптәш капитан. Ә мин һаман да җирдә үрмәләвемне дәвам итәм.

—Үрмәләр өчен яратылган оча алмый, диләр. Әмма, бу сиңа карамый, син—очар өчен туган бөркет, сержант Смаков. Теләгең сүрелмәсә, син һичшиксез очарсың әле. Әйтте диярсең, безнең хыялга да кермәгән зур тизлектәге яна самолетларда очачаксың...

Бу сүзләрнең, аның күңелен күтәрү өчен генә әйтелгәнен аңласа да, Рафаэльгә аларны ишетү рәхәт иде, әлбәттә.

—Әмма, ничек тормышка ашырырга икән шул хыялларны, әйтсәгез, өйрәтсәгез икән, Александр Иванович?

—Син кайчаннан хәрби хезмәттә?—дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды капитан Вобликов.—Хезмәтең тәмамланырга күпме калды икән соң?

—Белүемчә, мин биш ел хезмәт итәргә тиешле. Әле дүртенче елым гына дәвам итә.

Ак бәс кунган чигә чәчләрен кашып алды капитан. Чын күңелдән, урынлы киңәш белән генә булса да, ярдәм итәргә тели иде ул егеткә.

—Инде күп калмаган икән. Бер ярым ел сизелми дә узып китә ул.

—Ә аннан соң?..—дип, капитанга текәлде Рафаэль.

—Хезмәтеңне тәмамлагач, син иректә кош сыман буласың. Кайда укырга керәсең, ни эшлисең килсә—үз ихтыярың.

—Ә хәзер үк, бүгеннән үк җибәрмәсләрме?..—дип, тәкатьсезләнеп, капитаннан унай җавап көтте ул.—Мин бит армиядан качмыйм, киресенчә, гомеремне хәрби авиациягә багышларга әзер.

Бу юлы бераз көттерә төшеп җавап кайтарды капитан. Күпме генә ярдәм итәргә теләсә дә, бу аның кулыннан килә торган эш түгел иде шул. Летчикларга кытлык юк бүген, ә менә яхшы квалификацияле механиклар санаулы гына. Гомумән, авиациядә механиклардан да кадерлерәк һөнәр иясе булганы юк һәм булмас та.

—Күпкә түзгәнне азга түзәрсең, мин сиңа, сержант, сабыр итәргә киңәш

итәр идем. Ә инде вакыты җиткәч, мин шикләнмим, син һичшиксез максатыңа ирешәчәксең. Синең кебек егетләрне табарга кирәк әле,—дип, очындырып куйды тагы сүзенең ахырында.

Әлеге сөйләшүдән соң күп тә үтмәде, Үзәктән аларның частен Румыниядән чыгару турындагы приказ килеп төште. Капитан Вобликов белән өлкән сержант Смаков тәмам дуслашып киткәннәр иде инде. Өлкән механикны данлыклы очучы үзеннән калдырмады. Алар Союзга кайткач та хезмәтләрен бергә Воронеж өлкәсендә дәвам иттерделәр.

1949 елның июнендә, ниһаять, Рафаэльнең солдат хезмәте тәмамланды. Аны үзе хезмәт иткән полктан җибәрергә теләмәделәр, әлбәттә, авиамеханик буларак хезмәтен дәвам итәргә үгетләп тә, юмалап та карадылар. Барып чыкмады. Һәм шуннан соң гына өлкән сержант Рафаэль Смаковка Борисоглебск авиация училищесына керү өчен менә дигән характеристика биреп, үзенә хәерле юллар теләп, озатып калдылар.

Рафаэльнең биш ел инде авылда булганы, туганнары һәм әти-әнисен күргәне юк. Бик сагынган, өзелеп сагынган иде ул туып-үскән якларын. Әмма аның авылдан чыгып киткәндә очучы булам дип, очучы булырга хыялланып әйткән сүзләрен дә онытмаганнардыр әле. Шул хыялын тормышка ашырмый торып ничек кайтып керә алсын инде ул туган авылына, егет горурлыгы рөхсәт итми иде.

Солдат киеменнән, солдат биштәре аскан көйгә ул туп-турыдан Воронеж өлкәсенең көнчыгыш тарафында урнашкан Борисоглебск шәһәренә юл тотты. Һәм үзенекен итте, биш елга кичегеп булса да, хәрби очучылар әзерли торган уку йортына керү бәхетенә иреште. Кесәсендә бер тиен акчасыз калган чаклары булса да, ачлы-туклы йөрергә туры килсә дә, иң бәхетле кеше иде ул шул көннәрдә. Ниһаять, ул очучы булачак. Атлап түгел, очып йөри иде ул гүя, иңнәренә пар канат үсеп чыккан диярсең... Ничә еллар үзен әйдәп торган хыялы тормышка ашты бит аның. Аның хәлен, аңласа да, чын бәхетнең ни икәнлеген белгән, татып караган кеше генә аңлаган булыр иде.

Борисоглебсктагы бу авиаучилище легендар очучы Чкалов исемен йөртә иде. Аларны әле беренче үрнәкләре заводларда гына булган яңа буын реактив самолетлар белән идарә итү өчен әзерләделәр. Вакыт-вакыт, укучылар гына түгел, укытучыларның үзләре өчен дә бигүк аңлашылып җитмәгән, яңалык булган мәгълүматлар өстендә баш ватарга туры килә иде. Әмма самолетларның төзелеше һәм техник үзенчәлекләрен бөтен нечкәлекләренәчә өйрәнгән Рафаэль Смаков өчен, башкалар белән чагыштырганда, күпкә җиңелрәк бирелде ул дәресләр. Укучылар арасында ул авторитетлы өлкән дус булса, укытучылар исә аны үз тиңе, фикердәшләре сыман кабул итә, аның белән хәтта киңәш-табыш итә торганнар иде.

1950нче елның 16 августы аның өчен һичшиксез иң бәхетле һәм истәлекле көннәрнең берсе. Балачактан бирле килгән хыялы тормышка ашкан көн бу, ул шул көнне беренче тапкыр самолетта зәңгәр күккә күтәрелде, җиргә кошлар да очып менеп җитә алмаслык биеклектән карап сокланды. Дөрес, самолетта ул очучы-инструктор янәшәсенә генә утырган иде һәм ул сәяхәт, күп булса, ун-унбиш минут дәвам иткәндер. Әмма тәэсирләрне сөйләп кенә аңлатырлык түгел иде. Шул ук көнне шәһәрдәге бердән-бер фотоательены табып истәлеккә рәсемгә төште ул. Һәм рәсемнең артына: "Бүген беренче мәртәбә самолетта һавага күтәрелеп, шәһәр өстеннән аның матур табигатен күзәтеп төштем. Бу көн минем летная практиканың башлануын белдереп, аның киләчәгенә юл күрсәткән көн дип санала. г.Борисоглебск.16.08.50г. Рафаэль Смаков", диеп язып куйды. Фоторәсем шул ук көнне Яңа Актауга әти-әнигә адресланып, почта ящигына салынды.

Имтиханнарны ул иң беренче булып һәм гел яхшы билгеләренә генә

биреп барды. Сабакташлары арасыннан беренче буларак мөстәкыйль рәвештә һавага күтәрелү бәхете дә анарга язган булып чыкты. Бу инде сиңа инструктор янәшәсендә сәяхәт кылып төшү генә түгел. Шул мизгелдәге кичереш һәм күнел күтәренкелеген, белмим, гади сүзләр белән генә аңлату мөмкинме икән...

Реактив самолет кабинасына кереп штурвал артына утыргач та, бер мәл, үзен биләп алган хисләр өермәсен йөгәнли алмый торды ул. Өнемме, әллә төшемдә генәме бу, дигән сорау туып юкка чыкты. Әмма болар бик кыска вакыт аралыгына сыйган кичерешләр иде. "Сынатма. Синең һәр хәрәкәтең, бар кылган гамәлеңне тәҗрибәле белгечләр, асс инструкторлар карап, бәяләп тора. Әйдә, Рафаэль, күрсәт үзеңнең нигә сәләтле булуыңны..." дип әмер бирде ул үз-үзенә. Һәм реактив двигательга тиешле басым биреп бер үкертеп алгач, тимер рычагны үзенә таба тартты. Кош сыман, хәер, кош сыман гынамы соң, аткан ук тизлеге белән, бераз тимер-бетон өстеннән йөгереп баргач та, югарыга ыргылды самолет. Һәм, каршы искән җилне бар дип тә белмичә, күз ачып йомган арада тиешле биеклеккә менеп җитте. Приборларны барлап күз йөгертеп алды ин элек. Реакторга булган басымны киметә төште. Самолет, көчәнүеннән туктап, тыныч ритм белән эшләү режимына күчте. Шунда гына үзен биләп торган киеренкелектән арына төшеп, иркен сулыш алды ул. Һәм, башын бер тарафка янтайта төшеп, түбәнгә күз ташлады. Аэродром инде әллә кая, артта калган. Аста иген басулары, зур булмаган калкулыклар һәм урман полосалары. Без яшәгән, ыгы-зыгы килеп яткан җир өстенең матурлыгын күрер өчен менә нинди биеклеккә менәргә кирәк икән. Очсыз-кырыйсыз зур һәм иркен ләса ул. Шунда сыеша алмый бит кайберәүләр. Кеше белән кеше тарткалаша, булган саен нидер җитми үзләренә, ниләрдер бүлешәләр, илләр тарткалаша—сугыша. Кесәләре калынайа барган саен кайберәүләргә җир тарая башлыймы соң әллә... Андый ыгы-зыгының башында торган тар җанлы кешеләрне, җитәкчеләрне дә шул җөмләдән, ялгызларын гына самолет кабинасына утыртып зәңгәр күккә очыртып җибәрергә кирәк икән. Яман ниятләрен онытып, бик тиз әйләнеп кайтырлар иде иманга.

Романтик уй һәм хисләр бишегендә тибрәлеп тиешеннән артык ераклыкка китә язган иде ул. Тиз арада кире борылып һава аланына таба юл тотты. Анда, инструкторларның баш очында, үзенең осталыгын күрсәтеп, төрле борылышлар ясарга тиеш иде бит әле ул, сугыш шартларына охшатып һөҗүм һәм дошманнан саклану маневрларын күрсәтергә. Очучы өчен, бигрәк тә тәҗрибәсез очучы, иң авыры һәм катлаулысы шунда. Очу маршрутын һәм программасын тулысынча үтәп чыгу өчен тәгәл вакыт бирелә—40 минут. Артык та түгел, ким дә түгел, син шул вакыт аралыгына сыешырга тиешсең. Бары шуннан соң гына, алдан билгеләнгән маршрут белән, кире тимер-бетон юлга төшереп утыртты ул ажгырып торган тимер кошын. Очучы аэродромнан шасси аерылып самолет күтәрелә башлаган чакта бер киеренке мизгел кичерсә, икенче тапкыр ул киеренкелек аны тәгәрмәчләр җиргә тиеп йөгереп киткән чакта биләп ала икән. Самолетын тиешле сызыкка китереп туктаткач та, күңеле ашкынуданмы, кабаланган сыман җиргә сикереп төште Рафаэль. Тиз-тиз адымнар белән бераз читтәрәк торган офицерлар янына килеп рапорт бирергә кереште.

Башлаган сүзен сөйләп бетергәнне көтмәделәр.

—Йә, ничек, куркытмадымы?—дип, үз итеп, җилкәсеннән кагып бүлдерде аны инструктор.

—Куркалар димени...Тәүлекләр буе җиргә төшми очар идем, иптәш майор!

—Тәбриклим, өлкән сержант Смаков. Очышны син тәҗрибәле летчикларны көнләштерерлек итеп үтәп чыктың. Бүгеннән башлап үзеңне

очучы-истребитель дип саный аласың...

Бик югары бәя иде бу. Шул көнне үк, кич җиткәнне дә көтмичә, тагы хат язарга утырды ул. Әти-әнисенә язды иң элек. Уфада укытучы булып эшләгән Асма апасына язды. Энекәшләре Рим белән Нурның һәр икесенә аерым хатлар язды. Авылда әти-әнисе янында булган сеңлесе Тамарага һәм 12 яшьлек энекәше Ринатка да—һәммәсенә аерым хат. Нурулла белән Фәрвазга тагын... Әлбәттә, кызып киткән шәптән бер-бер кызга да бик язасы килә иде дә бит, кызганыч, йөргән кызы юк, белгән адреслары юк. Язган хатларында ул сәлам һәм хәл-әхвәл белешүдән соң ук очу темасына күчә иде, әлбәттә. “Мин хәзер мөстәкыйль рәвештә яңа реактив истребитель самолетта оча башладым инде. Аларның маркаларын яза алмыйм, хәрби сер. Күз иярмәс тизлектә оча торган самолетлар бу. Совет армиясенең горурлыгы санала алар. Аларда очуның ни кадәр җаваплы һәм шул ук вакытта рәхәт тә икәнлеген белсәгез икән. Очкан чакта үзеңне чын-чынлап канатлы кош сыман хис итәсең инде...” дип, тезеп-тезеп китә иде ул язган хатларында. Әлеге хатларны Рафаэль, тизрәк барып җитсеннәр өчен, шул ук көнне үзләренең частеннан җиде чакрым ераклыкта урнашкан район үзәгенә илтеп, почтага тапшырып кайта. Җәяү бара, җәяү кайта, ерак ара диеп тормый. Ә үзләрендә булган почтага тапшырса, алар әле, ким дигәндә, дүрт-биш көнгә соңарып китәчәкләр иде. Ничә еллар зарыгып көтелгән шундый яңалыкны, көне-сәгате белән үк булмаса да, тизрәк туганнарына җиткерәсе килә бит аның.

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## Алхәбәр. “Казан утлары” — 2009

### МӨНИРСТАН

РОМАН

Танылган шагыйрь һәм прозаик **Нур ӘХМӘДИЕВнең** яңа әсәре эзлекле мавыктыргыч сюжетка корылган. Төп геройның кичерешләре 40–50нче еллардагы Ил тарихыннан аерылгысыз. Сугыштан имгәнеп кайткан Мөнирнең язмышы маҗаралы вакыйгаларга бай. Конфликтлар киеренкелеге Гайниягә карата булган мәхәббәт кичерешләре белән үрелеп бара. Башкаларны яклаганы өчен һаман саен төрмәгә эләгеп тә тигез мәхәббәт хакында хыялланудан ваз кичмәгән Мөнир укучыларның күз алдында көчле кеше булып гәүдәләнә.

***Роман киләсе елның 1нче саныннан басыла башлый.***

*Шәүкәт Галиевка 80 яшь*



Шәүкәт
Галиев

# МӘҢГЕЛЕК УТНЫ ДА МИЗГЕЛ КАБЫЗА...

**Саумы, Казан!**

*Саумы, Казан!*
*Иҗат башкалабыз,*
*Чакыруың белән киләмен,*
*Киләчәкнең үренә күтәрелгән*
*Юлларымны синдә күрәм мин!*
1948 ел, 26 ноябрь.

*Ике "түгәрәк датам" бергә туры килде. Бу юлларны нәкъ 60 ел элек, 1948 елның 12 санында беренче шигырьләрем шушы журналда күренгәч язып куйган идем. Әдәбиятка—киләчәккә юлларны "Казан утлары" (ул чакта "Совет әдәбияты") ачкан иде! Татарстанның Яшь язучыларының Беренче республика конференциясенә дә олы журналыбыз китерде: Г. Тукайга багышлап шигырьләр, поэмалар язган Сибгат Хәким редакциядә эшли иде, безнең шигырьләрне дә ул сайлап алган. Ватан сугышыннан кайткан яраткан шагыйрем гомерлек остазым булды. Бүгенгене кайгырт, үткәннәрне онытма, дип өйрәтте Сибгат агабыз. Журналыбызның шул традициясенә кушылам, берничә багышлавымны тәкъдим итәм.*

*Яшә, Казан, иҗат башкалабыз!*
*Рәхмәт, сүнмәс "Казан утлары"!*

**Автор**

## Багышлаулар

*Беренче Президентыбыз*
*Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә*[1]

**Мөстәкыйльлек безнең байрагыбыз,**
**Ирекле ил туды дөньяга—**
**Нигезе нык-тирән тарихларда,**
**Татарстан булыр өр-яңа!**
**Иманыбыз камил, ышаныч нык,**
**Максатыбыз, алга дәшәсең:**
**Елдан-елга үсеп, күтәрелеп**
**Республикам мәңге яшәсен!**

*Август. 1995*

[1] Акрошигырь. Юлларда беренче хәрефләрдән исем укыла.

## Кол Галигә

Сигез гасыр элек җырларыңны
Яраткан да халык, ятлаган,
Шуннан бирле аны онытмаган,
Күңелендә көйләп саклаган.

Каерылган күпме канатларның
Каурыеннан каләм очладың?
Көнләгәнсең әле: шул кошлардай
Ник иректә бераз очмадым...

Кушаматың нигә «Кол» икән дә,
Кемнәр сиңа богау кидерде?
Мәхәббәтең—җырның канатлары
Сине азат көнгә китерде.

Күңел белән күрәм мин барыбер
Кулларыңны бәйсез кул итеп;
Галине дә мөмкин кол итәргә,
Чын шагыйрьне булмый кол итеп!

*1962*

***

Бөек Кол Галидән килә
Шигърият шәҗәрәбез.
Мәңге бакый югалмасын
Хиссият дәрәҗәбез!

*21 ноябрь, 1996*

## Тукайга

Тормышыңда бәйрәмнәр аз булган—
Тартыш белән тулган көннәрең.
Шуңа, ахры, искә алынмыйча
Үткән синең туган көннәрең...

Бәйрәмнәрең алда икән әле,
Кара, шагыйрь, бүген текәлеп—
Халкың килде сиңа, мәхәббәтен
Ал чәчәкләр итеп күтәреп.

Син күрмәгән яңа буын килде,
Котлап бүген туган көнеңне,
Киләчәккә барган улларыңнан
Ишетәсең «Туган тел»еңне.

Буын арты буын алмашыныр,
Гасыр арты узар гасырлар.
Шигъриятең өчен рәхмәт әйтеп,
Язлар сиңа гөлләр ташырлар.

Халык моңы—синең моңың булды,
Халык күңеле—синең күңелең.
Ил гомере, халык гомере кебек
Озын булсын, шагыйрь, гомерең!

*1965*

## Без—Тукай оныклары

Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без—«Туган тел»дән туганнар,—
Без—Тукай оныклары!

*1982*

## Тукай рәсеме

Сынап тора сизгер күңел
Безне ерак көннәрдән,
Гүя шагыйрь беркайчан да
Елмаймаган, көлмәгән.

Күзләрендә бәгырьләрне
Үксетерлек моң тулы,
Милләт язмышын сагышлап
Сискәндергән шом тулы.

Елмаймый борчулы күзләр,
Мәэюс карый сызланып,
Үткәннәрдән карый Тукай
Киләчәкне кызганып.

Заманнарның хәвефләре,
Сынаулары азмы соң...
Тукай рухы борчылмаслык
Булсын милләт язмышы!

*Апрель, 1995*

## Туган телем—Тукай теле

Әнкәм сөеп-сөеп әйткән,
Әткәм чөеп-чөеп әйткән,
Апам биеп-биеп әйткән—
Матур сүзләр җанымдадыр!

Әбкәм сыйпап-сыйпап әйткән,
Бабам сыйлап-сыйлап әйткән,
Абзам сынап-сынап әйткән—
Зирәк сүзләр аңымдадыр!

Бәет көйләп-көйләп әйткән,
Кыйсса сөйләп-сөйләп әйткән,
Такмак иләп-иләп әйткән—
Гыйбрәт сүзләр намымдадыр!

Язда уйнап-уйнап үскән,
Җәйдә буйлап-буйлап үскән,
Көздә уйлап-уйлап үскән—
Туган телем канымдадыр!

Телгә тимә—аңга тимә,
Телгә тимә—канга тимә,
Телгә тимә—намга тимә,
Тимә, тимә—җанга тимә!

*1988*

## Чулпы чыңы

*«Китап сатып алыр өчен, әни Һади абыйга үзенең чәченә үреп йөри торган тәңкәләрен берәм-берәм бирә торган иде».*

Хәнифә Такташева истәлекләреннән

(Әнием Бибихәлимәгә багышлыйм)

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңлавы...
Елтыр күзле малай бишектә.
Биләүләрдә яткан чактан ук
Шушы җырны Һади ишеткән.

Таныш көйләр һаман чыңлаган,
Таныш чыңнар бер дә тынмаган.
Йөрәгенә моңын сеңдереп
Тыңлаган да Һади тыңлаган.

Сөйләшәләр нидер тәңкәләр,
Серләшәләр нидер тәңкәләр.
Тәңкәләрнең телен кем белгән,
Бала күңелен белә әнкәләр.

...Уеннарын ташлап беркөнне
Чабып керә Һади ишектән:
—Бик кызыклы китап саталар,
Алыйк әле, әнкәй, ничек тә!

Шәмсениса апа ни дисен,
Юк акчаны кайдан аласы?
Зәңгәр күзен төбәп, ялварып,
Өметләнеп тора баласы.

Чылтыр-чылтыр чулпы чыңлавы
Тынып кала ана кулында.
Ана кулы—калын толымда,
Толымдагы тәңкә—улында...

Ничәнче кат Һади шатлана,
Ничәнче кат Һади очына—
Ничәнче кат инде әнкәсе
Көмеш тәңкә сала учына.

Күзен алмый ана улыннан,
Күзен алмый улы китаптан.
Тәэсирләнеп йөри ничә көн—
Күңелендә яңа көй тапкан...

Аһәңендә чорлар чыңлавы,
Бик борынгы җыр-моң яңара,
Мәйданнарга чыга даһилар
Гасыр белән бергә янарга...

*1960*

## Муса Җәлилнең кызы Чулпанга килеп җитмәгән хаты

*«...җиңгәч, мин өйгә кайтырмын. Синең туган көнеңне бәйрәм итәрбез. Мин сиңа бик яхшы бүләк бирергә җыенган идем, кайткач бирермен».*

Муса Җәлилнең фронтка барганда кызы Чулпанга язган хатыннан. 28 февраль, 1942 ел

Кичер, балам, кичер эткәнне,
Мин сүземдә тора алмадым,
Туган көндә була алмадым...
Тик бурычлы булып калмадым—
Җиңү булды сиңа бүләгем,
Мин тыныч көн сиңа теләдем—
Кадерен бел, балам, кадерен!..

Көткәнсеңдер нәни чагыңда,
Үскәч инде үзең аңладың,
Вакытында кайта алмадым,
Тик барыбер читтә калмадым—
Азат илем сиңа бүләгем,
Мин бит сиңа бәхет теләдем—
Кадерен бел, балам, кадерен!..

Сагынуларым калды мәңгегә—
Җырга барсын сала алмадым...
Белеп киттем, якты дөньяда
Мәхәббәтем исән калганын—
Газиз әнкәң сиңа бүләгем,
Мин бит сиңа шатлык теләдем—
Кадерен бел, балам, кадерен!..

*1968*

## Алиш кайтты

*Туган авылы Көектә 2001 елда һәйкәл куелды*

Улларымны югалттым, дип,
Яшәдең янып-көеп,
Көзге яфраклар өстеннән
Абдуллаң кайтты, Көек!

Һәйкәл итеп каршылады
Илем батыр баласын—
Үткәннәрдә калмады ул,
Мәңгелеккә барасы!

*Сентябрь 2001*

## Кыя һәм Кеше

(Баллада)

*Хәсән Туфанга*

Диңгез ярында
Алар икесе;
Торалар бергә—
Кыя һәм Кеше.

Кыя мәңгелек,
Какшамас, нык таш.
Тамыры белән
Тауларга тоташ.

Ә Кеше япь-яшь,
Үзе бик чандыр.
Күзләре уйчан,
Нигә уйчандыр...

Өермәләрне
Сизми дә Кыя.
Кеше җилдән дә
Чайкалып куя...

Давыллы еллар
Екмасмы аны?
Көрәш диңгезе
Йотмасмы аны?

Эндәшә Кыя:
—Егет-егетем,
Пос син ышыкка,
Тыңла үгетем!

Беләм, карышып
Файда юклыгын...
Эх, булса синдә
Кыя ныклыгы!

Мин бит—мәңгелек,
Какшамас, нык таш.
Тамырым белән
Тауларга тоташ.

Ул көннәрдән соң
Күп еллар үткән.
Давыларда Кеше
Күп юллар үткән.

Кырык давылда
Айкалган Кеше,
Кырык батып та,
Сау калган Кеше.

Чәче—ак дулкын,
Үзе гел чандыр...
Бу якларда ул
Булган кайчандыр.

Бүген дә алар
Тагын икесе:
Торалар бергә—
Кыя һәм Кеше.

Күптәнге бәхәс
Инде чишелгән—
Кыя яртылаш
Иңгән, ишелгән...

Сизә карышып
Файда юклыгын:
—Эх, булса миндә
Кеше ныклыгы!..

Сораган Кыя:
—Әйт, Кеше, сөйлә,
Мондый көч сиңа
Кайлардан килә?

Һәм Кеше әйткән:
—Кыя, кыя-таш,
Йөрәгем минем
Халыкка тоташ!

*1962*

## Сибгат Хәким белән хушлашканда

Энеләргә күз-колак бул, диеп,
Сине Җәлил, Кәрим җибәргән—
Үлемнәрне кичеп илгә кайттың
Аталарча сөйдең иңнәрдән.

Без әтисез моңлы балаларның
Җан-рухына терәк идең син,
Шагыйрьләре үлеп ятим калган
Халкыбызга кирәк идең син.

Уттан чыксаң да син утта булдың—
Һәр көнеңне янып озаттың.
Януларың, моңың, җырың белән
Татарның син гомерен озайттың.

Соңгы сүзең безгә дә шул булды:
«Бирешмәгез, диде, эшләгез!"
Васыятең киләчәккә бара—
Изге эздән синең төшмәбез.

Бер тынычлан инде, шагыйрь абый,
Борчуларың безгә калсыннар...
Ә җырларың саф безнеңчә мәңге
Ил күңелен көйләп барсыннар.

*1986*

## Югалган шагыйрь

*Китапларның да язмышы була.*
Борынгы мәкаль

Ерак төбәктә, тын бер авылда
Яшь бер мөгаллим күзләрен йомды;
Кулыннан төште каурый каләме,
Яшь бер шагыйрьнең йөрәге тынды.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Сөйгән ярында җырлары калды,—
Яулыкка төреп сандыкка салды,
Качып укырга кулына алды.

Үтте күп гомер, саргайды кәгазь,
Саргайды кыз да, дөньядан кичте.
Көмеш чулпылар, җыр дәфтәрләре
Истәлек булып кызына күчте.

Яшәде кызы баш күтәрмичә,
Мәшәкать, шөгыль азмы тормышта?
Борыннан килгән шәҗәрә белән
Шагыйрь йөрәге ятты тырыста.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Ничәмә тапкыр калды янгыннан;
Туып та үсеп һәм дөнья куып,
Ничәмә буын үтте яныннан.

Укый белмәгән бер оныкк аны,
Әбидән калган дога дип белеп,
Әвернәләр һәм каба кырына
Кыстырып куйды чормага менеп.

Юк, ул чак шагыйрь үлмәде әле!
Килер ул телгә, ал гына, укы.
Җырлар күптәнге, әмма бүген дә
Таныш аңдагы мәхәббәт уты.

Кешегә дигән күпме сөенеч
Онытылып ята, ята күмелеп;
Пәрәвезләрдән аны аралап
Аласы гына юкса үрелеп...

...Чынмы, ялганмы—хәбәр таралган:
Әгәр дә өйдән табалар икән
«Комган хәрефле» иске бер китап,
Тотып төрмәгә ябалар икән!..

Шүрләгән хуҗа, шагыйрьне дә ул
Тиз генә йолкып төшкән чормадан
Һәм китапларның барысын бергә
Киндерә белән кат-кат чорнаган.

Шагыйрь яраткан якты бер төндә
Айның батканын сагалап торган,
Авыр таш бәйләп чоңгылга аткан,—
Җырларны шулай суга батырган.

Куыклар гына чыккан бик озак,
Элмәктәй бөҗра уйнаган күлдә.
Ерак төбәктә, өч йөз яшендә,
Ил белми калган зур шагыйрь үлгән...

*1966*

## Тирән тамырлар

*Галимҗан Ибраһимовка*

Йөз еллар үткәннәр—
Имән сау,
Сәмумнар өткәннәр—
Имән сау,
Яшеннәр теткәннәр—
Имән сау,
Тираннар беткәннәр—
Имән сау,
Ни хикмәт, могҗиза—
Имән сау?!
Имәннәр бездән дә
Калырлар,
Тагын күп буынны
Танырлар,
Кояшка үрелә
Барырлар!
Ни хикмәт, могҗиза?!
—Тамырлар!
Тамырлар—
Нык,
Тирән тамырлар!

*1967*

## Олы Бакырчыда очраштык

*А. С. Пушкинның тууына 200 ел тулу уңаеннан*

Болдинода—синең мәшһүр көзең,
Миндә менә Бакырчы җәе.
Пушкин елы быел—шигърияткә
Килеп кенә тора бит җае.

Бик исемдә утыз җиденче ел...
Үлгәннәргә «почет» булганмы—
Бәйрәм итеп шаулаганнар иде
Вафатыңа йөз ел тулганны.

Урман арасында ерак авыл,
Без икенче генә сыйныфта.
Ул чак әле синең даһилыгың
Аңыбызга бетмәс сыеп та...

Күңел тарткан, үз иткәнбез икән,
Саф татарча иде язганың:
Тукай теле якынайткан сине...
Икегезне бергә кызгану...

...Шигырьләрең һаман телгә килә,
Татарча һәм русча ятладым.
Тукайны да, шигъриятне дә син
Яңа Дантеслардан сакладың.

Ике йөз ел тулды бу көннәрдә—
Бусы инде туу бәйрәмең,
Яратуыбызны яңарттың син—
Бөтен татар җирен әйләндең.

Күргән идем Олы Бакырчымда,
Үзгәрмәгән, шул ук сурәтең.
Уртак дога итеп кабатлыйбыз
Син зурлаган Коръән сүрәсен.

*Июнь, 1999*

## Варислар вәгъдәсе[2]

Очраштык без мәктәпләрдә[3],
Бастык бердәм сафларга—
Милләтебезне якларга,
Туган телне сакларга.

Сүз бирәмен:
Вәгъдә—иман.
Иманым камил—
Тугры калырмын гомергә
Шушы сафка мин!

Тарихлар кичкән бабайлар,
Авыр юллар үткәннәр,
Бетмәбез, дәвам килер дип,
Алар безне көткәннәр.

Без гасырларга сузылган
Озын сафлар башында—
Бурычлы да, җаваплы да
Һәрчак алар каршында.

Югалтмыйк рухи мирасны,
Бөек асыл затларны—
Килер татар бәхетенең
Чәчәк атар чаклары.

---

2 Рамил Курамшин музыкасы.

3 «Гимназиягә килдек без» дип тә алырга мөмкин.

**Ышаныгыз, әти-әни,**
**Ышансын милләттәшләр—**
**Улларыгыз, кызларыгыз**
**Офтанырлык итмәсләр.**

**Сүз бирәмен:**
**Вәгъдә—иман.**
**Иманым камил—**
**Тугры калырмын гомергә**
**Шушы сафка мин!**

*Апрель, 1999*

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

*Бу айда Татарстанның халык шагыйре, журналыбыз белән 60 ел дәвамында актив хезмәттәшлек иткән, күп еллар буе редколлегия әгъзасы булган каләмдәшебез Шәүкәт ага Галиевкә 80 яшь тула. Аны күпсанлы укучыларыбыз исеменнән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, яңа иҗат бәхетләре телибез!*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

## ТАУ АРТЫНДА КОЯШ БАР

"...Авыл халкы киң күңелле, ул күп нәрсәне аңлый, кичерә. Бел, кызым, авыл халкы бары каракларны һәм ялкауларны гына яратмый". Кайчандыр әни шулай дигән иде. Мин карак та түгел, ялкау да түгел кебек... Әллә каракмы? Мин бит әтиемнең тынычлыгын урлаганмын. Бәлки минем аркада үлгәндер ул... Аның үлеменә мин гаепле булсам? Ничек яшәргә? Бу гаеп, бу гөнаһлар белән ничек яшәргә?! Ай, башым, бичара башкаем, шартлый бит инде хәзер. Нишләргә? Әллә, караңгы төшү белән беркемгә дә күренмичә, авылдан чыгып качаргамы? Теленнән кач, моннан кач... Мәңгелек качак булып гомер кичерергәме? Үз илендә урын тапмаган кеше кая сыя?.."

Әлеге өзек **Рәмзия ГАБДЕЛХАКОВАНЫҢ "Тау артында кояш бар"** исемле романыннан алынды. Әсәрнең төп каһарманы Нәргизәне аяусыз язмыш җилләре ватанынннан аера, бихисап сынауларга дучар итә...

***Кызыклы сюжетка корылган бу әсәрне киләсе елгы саннарыбыздан укый аласыз.***



Туфан Миңнуллин

# ДИВАНА

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМА

**Катнашучылар:**

Вил — психик авыру белән чирләүче
Хәнифә — Вилнең әнисе
Нургазиз — авыл карты
Зәйнәпбану — Нургазизнең карчыгы
Айсылу — авыл кызы
Ким — Вилнең иң өлкән абыйсы
Диана — Вилнең курсташы

## I пәрдә

*Рәшәткә белән уратып алынган алма бакчасы. Бакча уртасында куыш (шалаш). Ул Ленинның Разливтагы мәгълүм шалашына охшатып ясалган. Куыш алдында ике агач төбә. Сәхнәдә Нургазиз һәм Хәнифә.*

Нургазиз. Булды бугай бу, Хәнифә сенел. Менә рәсемдә дә шулай ясалган. Менә монда куыш, монда бер агач төбе, монда икенчесе. Монысында менә Ленин утыра, монысына куеп яза. Язу өстәле инде, ягъни мәсәлән. Йоклавын да шушы куышта йоклар микән?

Хәнифә. Кем белгән инде аны, кем белә.

Нургазиз. Монда эликтыр тартырга да кирәктер инде. Төнлә караңгыда утырмас. Ленинның да лампасы булгандыр.

Хәнифә. Рәхмәт инде сиңа, Нургазиз абый.

Нургазиз. Нигә рәхмәт? Күршеләр ич без. Ул малайны үзем дә бик яратам. Тәртипле. Нургазиз бабай дип кенә тора. Бүтәннәр бәрелеп китәләр, исәнләшә дә белмиләр.

Хәнифә. Тәртиплесен тәртипле дә, нишләп китте бит әнә.

Нургазиз. Борчылма, тереләчәк. Күп укыганныкы ул. Башына шул уку бәргән. Кирәгеннән артыкны белсәң дә зыянга бит ул, Хәнифә сенел. Чамалап кына укырга кирәк, үзенә кирәк кадәрле генә. Ленин үзе дә бит әнә укыган да укыган, укыган да укыган. Башына шуңа күрә кан сауган. Менә улыгызның да укуын туктатып торырга иде.

Хәнифә. Ничек туктатасың, Ленинның бөтен язган китапларын җыйган. Укый да яза. Хәерлегә генә булсын.

Туфан МИҢНУЛЛИН (1935) — *Татарстанның халык язучысы, драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе; Станиславский (Россия) һәм Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты. Күпсанлы пьесалар, китаплар (шул исәптән ун томлы "Сайланма әсәрләр") авторы. Казанда яши.*

Нургазиз. Шулай инде. Кем белә инде анысы, бәлки, укый-укый Ленин кебегрәк кеше булыр. Бәлки анардан да уздырып китәр. Әтисе дә башлы кеше иде бит. Колхозны ал да гөл итеп тотты. Ул да китте председательлектән, колхоз да таркалды.

Хәнифә. Хәзер бөтен нәрсә таркала инде.

Нургазиз. Кем белә, бәлкем, Вил кебекләр җыяр. Тереләчәк улын. Әнә Торна авылында бер кыз да акылдан шашкан булган. Көпә-көндез урамда шыр ялангач йөргән. Хәзер терелгән ди. Кияүгә чыгарга җыена ди. Вилегез сезнең акылдан шашмаган ич. Бераз киткән генә, җиңеләйгән. Тереләчәк. Казанга укырга китеп ялгышты ул. Анда бит бер генә дә нормальный кеше юк. Трамвайга утырсаң төшеп каласы килә. Бер-берсенә акыралар. Менә авылда Вилегез бер-ике ай дигәндә кеше булачак. Шулай шул, кирәгеннән артыкны укырга да, белергә дә ярамый. Күп белгәннәрне элек-электән үтергәннәр. Бер бик башлы кеше булган борын заманда. Бруна дигән. Шул әйткән, Җир Кояш тирәсендә әйләнә дигән. Шунын өчен аны утта яндырып үтергәннәр. Хәзер дә үтерәләр. Фактически Ленинны да бит үтерәләр. Сталин башына җиткән анын. Миннән өстен булмасын дип.

Хәнифә. Син үзең дә күп укыйсың бит, Нургазиз абый.

Нургазиз. Нәрсә ул минем уку. Мин бит үземә ошаганнарны гына укыйм. Мин баш өчен укымыйм, күңел өчен укыйм. Баш өчен күп укырга ярамый. Баш ул кечкенә, күп укыганны сыйдыра алмый. Кан тамырлары бик нечкә бит башта, түзә алмыйлар—шартлыйлар. Ә күңел киң ул, анда бөтен дөнья китабын укысаң да сыя, укыган саен күңел киңәя генә бара. Әкият күп укырга кирәк, Хәнифә сеңел. Әкиятне кешеләр күңел өчен язганнар.

Ким *(Керә. Куышны күреп)*. Нәрсә бу?

Нургазиз. Башта исәнләш, Ким энем.

Ким. Нихәл. Нәрсә бу?

Нургазиз. Вилгә бу, Ким Нурәхмәтович. Син Владимир Ильич Ленин дигән кешене укып беләсендер. Әллә оныттың дамы? Шул кеше патша заманында патшадан качып, Разлив дигән бер болында шалаш корып яшәгән. Шунда ничек итеп ривалютсия ясау турында китап язган. Беләсеңме шуны?

Ким. Йә, шуннан?

Нургазиз. Шуннан шул. Ривалютсия булган. Менә синең бертуган энекәшең дә Владимир Ильич Ленин кебек, шалашта яшәп, китап язырга җыена.

Ким. Сүтеп ташлагыз хәзер үк.

Хәнифә. Улым, нитмә әле син. Нишләтик. Ленин кебек буласы килә. Ленин булып уйный.

Ким. Җүләр сүзенә карасаң, кем буласы килмәс. Кеше көлдермәгез. Болай да инде бөтен бала-чага сезнең капка төбендә.

Нургазиз. Сезнең капка төбендә димә, Ким Нурәхмәтович. Безнең капка төбендә диген. Хәзер каттиҗда яшәсәң дә бу синең туган нигезең.

Ким. Күп белмә, картлач. Син котыртып йөрисендер әле. Җыен юк-барны син уйлап чыгарасың. Әкият укып.

Хәнифә. Ким!..

Нургазиз. Белмичә сөйлисең, Ким Нурәхмәтович. Ташла шул начар гадәтеңне. Әтиең синең белмичә бер сүз дә әйтми иде. Менә рәсем. Менә Ленин утыра, менә шалаш. Аны миңа Вил үзе күрсәтте. Шуңарга охшатып эшлибез, диде.

Ким. Әкият. Яткан ди Ленин куышта. Сезнең уше дуракларны ышандырыр өчен язалар да. Чит илләрдә гуляйт итеп кенә йөргән ул. Сезнең уше дураклар анын ялганына ияреп яшәдегез дә рәтле пенсия дә ала алмыйсыз.

Нургазиз. Булганы җиткән безгә, Ким Нурәхмәтович. Без ул хәтле нәфесле халык түгел. Сугышка да бардык, сугыштык та, фашистны да җиңдек. Син бертуган энекәшеңнән шалаш күпсенәсең.

Хәнифә. Бәлки ярдәме тияр. Шунда яшәп карасын. Бер уй башына керсә, чыгарып булмый бит, нишләтәсең. Үзем дә аптыраганнан инде. *(Күз яшен сөртә).*

Ким. Йә, йә, булды. Җебемә.

Хәнифә. Нишләтим инде аны хәзер...

Ким. Алып кайтмаска иде. Психлар больницасында андыйларның урыны. Анда врачлар.

Хәнифә. Акылдан шашмаган ич ул, җүләрләр йортында яткырырга.

Ким. Үзеңә читен.

**Хәнифә.** Түзәсең инде. Ул да бит бала минем өчен. Синең кебек үк.

**Ким.** Төпчек дип унбиш яшенә хәтле тезеңдә утырттың. Нормальный кешеләр кырык биш яшьтә бала тапмыйлар.

**Нургазиз.** Надан син, Ким Нурәхмәтович. Томана.

**Ким.** Син тик тор. Өен бар, өеңдә генә утыр.

**Хәнифә.** Ким улым. Нәрсә инде син. Гомер буе керешеп яшәгән күрше абыеңа.

**Ким.** Вил дә аның әкиятләрен тыңлап шулай булды.

**Нургазиз.** Сиңа да сөйли идем. Тыңламый идең.

**Ким.** Бик кирәкләре бар. Сүзем шул—сүтеп ташлагыз бу карга оясын. *(Кочагына Ленин томнары күтәргән Вилне күреп).* Нихәл? Нигә исәнләшмисең?

**Вил.** Ә мин сезнең белән исәнләшергә теләмим. Чөнки сез карак, сез—кеше талаучы.

**Ким.** Син кем инде?

**Вил.** Сез минем белән син дип сөйләшмәгез. Сезгә кешеләр арасында яшәргә ярамый. Сез бүреләр белән бергә яшәргә тиеш.

**Хәнифә.** Вил, улым, бертуган абыеңа андый сүзләр әйтмә.

**Вил** *(Кимга).* Мин Ленинның 15 нче томын тапмадым. Син урладыңмы? Урлап саттыңмы? Сез—урлап сатучылар. Сез илне урлап саттыгыз.

**Ким.** Мин киттем, әнкәй *(Китә).*

**Вил** *(аның артыннан кычкырып кала).* Качып котыла алмассыз. Вакыт җиле сезне качкан җирләрегездән җилдереп чыгарачак.

**Хәнифә.** Улым, тынычлан, улым. Абыең ул синең. Синең кебек үк минем улым бит ул.

**Вил.** Ул синең улың түгел. Ул—явыз, ул—тиран, ул—бирән. Илне без алардан чистартачакбыз. Алар үз корсакларын туйдыру өчен генә яшәүчеләр. Аларга кешеләр кирәк түгел. Чөнки алар җанварлар. Илдә хәерчелек. Халык эчә, наркомания, спид... Халык кырыла. Аларның уенда ул юк. Алар—явызлар. Алар—карак. *(Кинәт тынып калып, тыңлана).*

**Хәнифә.** Ни булды, улым?

**Вил.** Җырлыйлар.

**Хәнифә.** Ишетелми кебек.

**Вил.** Җырлыйлар...

**Нургазиз.** Вил улым, син теләгәнчә булды бугай бу шалаш.

**Вил.** Әйе, әйе... Мин канәгать. *(Төпләрнең берсенә утырып).* Хәзер, әнкәй, миңа пальто кирәк булачак.

**Хәнифә.** Анысы ни өчен? Көн кызу бит, улым.

**Вил** *(Нургазизгә).* Бирегез әле, күрше бабай, картинаны. *(Рәсемне кулына алгач).* Менә күрәсеңме, әнкәй, Ленинның иңендә—пальто. Мин язганда пальто минем иңемдә булырга тиеш.

**Хәнифә.** Хәзер, улым, хәзер. *(Китә).*

**Нургазиз.** Төнлә дә монда куна-сыңмы, Вил улым?

**Вил.** Ленин кайтып-китеп йөрмәгән.

**Нургазиз.** Эликтр тартырга да кирәк булыр диюем.

**Вил.** Кирәкми. Разливта электр булмаган.

**Нургазиз** *(Ленин томнарыннан берсен алып).* Шушындый китапларны 55 дисеңме, Вил улым? Барысын да укып чыктыңмы?

**Вил.** Икешәр тапкыр. Кайберләрен өч тапкыр.

**Нургазиз.** Үзең ничәне язарга җыенасың соң?

**Вил.** Үземнең дөреслегемне, хаклыгымны аңлатыр өчен ничә том кирәк булса, шул хәтле язачакмын!

**Нургазиз.** Беркөн дә сөйләштек. Гел үземнең дөреслек дисең син, Вил Нурәхмәтович. Дөреслек дигән нәрсә синеке, минеке булмыйдыр. Дөреслек бит инде ул Ходай тәгалә кебектер. Синең үз Аллаң, минем үз Аллам була алмый ич инде. Барыбызга да бер Алла.

**Вил.** Ялгышасыз, һәр кешенең үзенә генә хас яшәү принцибы, фикерләү үзенчәлеге, үз дөреслеге була. Әлбәттә, әгәр дә бу сыйфатлар бөтен кешеләргә дә уртак булса, дөнья искиткеч гармонияле булыр иде. Ни кызганыч, ул сыйфатлар антагонистик булалар—һәр кеше үз дөреслеген абсолют хакыйкать дип саный, бүтәннәрнең дөреслеген танырга теләми. Гармония югала, көрәш башлана. Берәүләр өчен үзенчә фикер йөртүчеләр яки дошман, яки надан, яки дивана. Аңладыгызмы?

**Нургазиз.** Бик тә аңлашыла. Эки-

ятләрдә дә бит үги ана үзенчә, үги кыз үзенчә хаклы. Шуңа күрә үги ана үги кызны яратмый. Менә алар икесе бер төсле уйласалар, ничек матур яшәрләр иде.

Вил. Владимир Ильич Ленин шул гармонияне эзләгән.

Нургазиз. Әһе... Тик менә гармония дигән сүзенне төшенеп бетмим кебек.

Вил. Гармония ул бөтен нәрсәнең бер-берсе белән килешкәнлеге, җайлашканлыгы.

Нургазиз. Менә хәзер аңлашылды. Алай булгач гармун да шуны аңлата инде. Анда да бит бер тел артыннан икенчесе килә. Бер тавыш артыннан аңа ошашлырак, аңа ятышлырак тавыш чыга. Сандугач сайраганга ала карга кушыла алмый бит инде, әйеме, Вил Нурәхмәтович?

Вил. Син—гений, син—даһи, күрше бабай.

Нургазиз. Бар инде анысы бераз. *(Зәйнәпбанунын «Нургазиз!» дигән тавышы ишетелгәч).* Менә Зәйнәпбану әбиең генә шуны аңламый.

Зәйнәпбану *(кереп).* Тагын шушында. Йөрмә кешегә мишәйт итеп. Исәнме, Вәли улым.

Вил. Сезгә күпме әйтергә була. Мин Вәли түгел. Мин—Вил. Аңладыгызмы—Вил. Владимир Ильич Ленинны беләсезме?

Зәйнәпбану. Белмәскә. Мин риваләтсиянең ун еллыгы көнне туган бала. Ничә ел коммунист булып тордым. Кәнсәләргә җыеп укыталар да иде. Менә бу бабаң гына йөрмәде. Әкиятне мин өйдә ятып та укыйм дия иде. Менә шушылар таратты ул Сысысырны. Чык өйдә, каз бәбкәләренә кычыткан турыйсы бар. Сау булып тор, Вәли улым.

Нургазиз. Күпме әйтәләр сиңа Вәли түгел, Вил ул, Вил, Вил... Вы.И.Лы.

Зәйнәпбану. Өйрәтмә, беләм. Онытыла. Әйдә, чык. *(Шалашны карап).* Шушыны ясадыгызмыни көн буе? Кирәк инде, кирәк, алма өлгерә. Бала-чагадан сакламасаң, сындырып бетерерләр.

Нургазиз. Бакча саклар өчен түгел ул. Вил улыбыз шунда язып утырачак. Үзең коммунист, үзең Разливның ни икәнен белмисең.

Зәйнәпбану. Өйрәтмә. Барысын да белергә мин синең кебек әкият укып ятмадым. Гомерем сыер имчәге тартып, сыер астында үтте. Менә Вәли улым әйтә... Тьфү, телем коргыры, гомер буе күршедә яшәп, өйрәнә алмадым: Вил инде, Вил. Менә Вил улым әйтә—барысына да Ленин язганнарны бозучылар гаепле ди. Ленин булса да крестиянгә шул абзар да сыер асты инде.

Вил. Алай булмаячак. Кеше азат булачак. Ленин башлаган бөек эшләрне без дәвам итәчәкбез. *(Китаплар арасыннан берсен алып).* Менә, укыгыз. Нәрсә яза Ленин: «Бер адым алга, ике адым артка» ди. Нәрсә аңлата ул? Укыганыгыз бармы ул хезмәтне?

Зәйнәпбану. Биш класс белем белән каян мондый китаплар укырга инде.

Вил. Алайса, тыңлагыз. Владимир Ильич Ленин-Ульянов «Бер адым алга, ике адым артка» дип аталган хезмәтендә большевиклар партиясенең тактик һәм стратегик бурычларын билгели. Үз вакытында бу хезмәт архиактуаль булган. Бүген безгә икенче төрле юнәлеш алырга кирәк—ике адым алга, бер адым артка. Нигә алаймы? Бүген безнең көтеп торырга вакытыбыз юк: алга, бары тик алга гына. Ләкин чигенеп алмыйча да ярамый. Туктап уйланырга да кирәк.

Нургазиз *(Зәйнәпбануга).* Аңладыңмы инде?..

Зәйнәпбану. Өйрәтмә. Аңламаска теге. Уйланырга ди. Син уйлыйсынмы? Иртән чыгып киттең, гамендә дә юк. Гамендә дигәннән, Лининны маузалидан алдырабыз дип сөйләнәләр, булыр микән шундый эш?

Вил. Проблема гәүдәдә түгел, акылда. Аны алып ыргытып булмый. Без Ленин эшен дәвам итәчәкбез. «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг яңача яңгыраячак.

Нургазиз. Карале, Вил Нурәхмәтович. Пролетарий хәерче дигән сүзне аңлата диләр. Хәерчеләр берләшеп нишли ала инде. Ленинның ул сүзе ялгыш булмады микән. Мин әллә кайчан язылган бер китапны укып чыктым. Шунда язылган: «Ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас» диелгән. Дөрес бит.

Зәйнәпбану. Чык әйдә, тузга язмаганнарны сөйли башладың. Әнә алигарыклар җыелса, күрсәтерләр ко-

мынны. Авыл кешесенә элек тә булмаган, хәзер дә юк, булмаячак та. Чык әйдә, әйләндермә кеше башын, болай да әйләнгән. Сау булып тор, кем улым. *(Чыгып китә).*

Н у р г а з и з . Менә шунын белән илле җиде ел яшәдем инде, Вил Нурәхмәтович.

В и л . Юк, без башка юл белән китәрбез... *(Туктап калып, тынлана).* Җырлыйлар.

Н у р г а з и з . Ярый, чыгып керим инде мин. Йә тавыш чыгарыр. Мин керермен әле, ярыймы, Вил Нурәхмәтович. Син миңа язганнарынны укырсың.

В и л . Керегез, Нургазиз бабай. Мин Сезне бик тә хөрмәт итәм. *(Нургазиз чыгып киткәч).* Аның бәхетле булырга хакы юкмы? Ни өчен илгә, халыкка бөтен көчләрен биреп яшәүчеләр һаман интегергә, ә илне талаучылар баерга тиеш? Юк, без башка юл белән китәрбез. Безнең каршыда торган киртәләр биек булса да нигезе инде какшады—төртсәң аварга тора. Без шундый партия төзербез, ул халык үзе төзегән партия булыр. Безнең бурыч кешеләрне бәхетле итү. Илдә бер генә кеше бәхетсез булса да ил бәхетле була алмый. Илдә коррупция, наркомания, спид, алкоголизм. Кешелекнең тамырын корыта торган бу чирләрдән илне без арындырачакбыз. Кешеләрнең бәхетле булырга хаклары бар. Безнең архибурычыбыз һәртөрле гаделсезлектән илне коткару. Дөньяны үзгәртергә кирәк. *(Рәшәткә янына бер төркем балалар килеп, Вилнен Ленин образына кереп сөйләгәнен кызыксынып күзәтәләр. Вил аларга мөрәҗәгать иткәндәй сүзен дәвам итә).* Кешелек дөньясы болай яшәргә тиеш түгел. Бу изге эшкә бөек фикер иясе Владимир Ильич Ленин алынган. Ләкин башлаган эшен ахырына җиткерергә аның гомере җитмәгән. Аның эшен дәвам иттерергә намуслы кешеләр булмаган. Власть башына наданнар, деспотлар, тираннар килгән. Аларны демократия күзлеге кигән авантюристлар алыштырган. Алар берсен-берсе алыштыра, власть бүлешә, ә халык һаман да хәерче. Владимир Ильичны алдаганнар, мине алдый алмаслар. Мин Россияне коррупциядән коткару законын ачтым. *(Балалар ягына барабара).* Сез яңа, ирекле заманда яшәүче буын. *(Балалар куркышып качалар).* Ә-ә... Сез куркасыз. Сезне туганда ук куркытып тудырганнар. *(Җыр сузып, шалашы янына кайта).*

> Это есть наш последний
> Решительный бой:
> С Интернационалом
> Воскреснет род людской.

*(Балалар тагын рәшәткә янына килеп такмаклыйлар: «Тиле-тиле-тилгән, чебеш эзләп килгән. Тиле-тиле тилгән, чебеш эзләп килгән». Хәнифә чыгып балаларны куа).*

В и л . Тимә аларга, әнкәй. Алар егерме беренче гасырны бәхетле итәчәк буын.

Х ә н и ф ә . Ашыйсың килгәндер, улым. Кереп ашап чык.

В и л . Кешенең гомере, әнкәй, ашап һәм ашарга эзләп үтә.

Х ә н и ф ә . Ач йөреп тә булмый бит, улым.

В и л . Кеше күп ашаган саен ач була. Күп ашаган саен комсызлана. *(Малайларнын берсе—зуррагы рәшәткә янына килеп: «Хәнифә түти, Вил безнен белән барсынмы?»).*

Х ә н и ф ә . Нинди Вил булсын ул сиңа. Вил абый диген.

М а л а й . Вил абый безнең белән барсынмы?

Х ә н и ф ә . Кая барырга җыенасыз?

М а л а й . Кәҗә тавына. Бөркет оясы күрсәтәбез.

Х ә н и ф ә . Баралмый ул. Ул әле ашамаган.

В и л . Мин барам.

Х ә н и ф ә . Йөрмә, улым. Алар әле сабыйлар гына.

В и л . Олылар белән миңа кызык түгел, әнкәй. Алар изелә-изелә аңгырайганнар. Аларны изүчеләрнең акылын май баскан. Болар әле сафлар. Боларны бирәннәр кулына бирмәскә кирәк. Киттек, яшь дусларым. *(Рәшәткә аша сикереп чыга да «Интернационал» җырлап атлый. Аңа балалар ияра. Хәнифә тәп башына утырып кала. Айсылу үтеп бара. Хәнифәне күреп туктый).*

А й с ы л у . Исәнмесез, Хәнифә апа.

Х ә н и ф ә . Исәнме, Айсылу. Кая барышын болай?

А й с ы л у . Ерак чишмәгә суга барып кайтам әле. Аның ташы утырмый.

Нәрсә, Вилнең чирләве дөресмени? Манкалы малайлар белән чабышып йөри.

Хәнифә. Балаларны ярата шул. Тегеләре дә моны үз итәләр.

Айсылу. Элек тә әллә ничек иде инде ул. Казан врачлары караганмы соң?

Хәнифә. Караганнар инде. Авыру түгел ул дигәннәр, бераз ял итәргә генә кирәк дигәннәр.

Айсылу. Келәнче авылында бик оста өшкерүче карчык бар диләр. Шул үзең дә белмәгән авыруынны таба ди. Өшкереп җибәрә ди. Яңа туган кебек буласын ди.

Хәнифә. Үзең ни хәлләрдә соң, Айсылу?

Айсылу. Безнең шул инде—алда гөл, артта кычыткан. Кушаяклап чабып җәяү йөрибез. Качып котылып булмады бит. Кияүгә чыгарга кешесе дә юк. Җыен исерек, исерек булмаганы шумашушный. Картаеп та барыла инде, егерме тулды. Ун елдан утыз була. Аннан кырык, илле... Монда нәрсә корып куйдыгыз соң әле?

Хәнифә. Вил ясады. Җиләстә ял итәр өчен ди.

Айсылу. Өйгә сыймый башлады-мыни? Сезнекеләр шундый инде. Ким абый, сыймагач, каттиж дигән өй салып чыкты. Вил—шалаш. *(Көлә).* Кереп карасам, ярыймы?

Хәнифә. Кер әйдә, кер.

Айсылу *(кереп тикшерена. Куыш авызыннан башын тыгып).* Рәхәт икән монда. Җүләр дигән булалар. Итәрсең җүләр. Без ул җүләр, бер капчык писүк өчен шушы кызуда чөгендер утап йөрибез. Их, шушы куышта рәхәтләнеп ятып йокларга. Миңа өйләнмәс микән Вил? Әби әйтә, дәртең кузгалган, кияүгә чыгарга кирәк ди. *(Ул бик еш үз сүзеннән үзе көлеп сөйләшә).* Үземнең дә элек исем дә китми иде, хәзер егетләр күрсәм, кытыгым килә башлый. Соңга калып өлгерден ди әби.

Хәнифә. Чибәрләнден шул.

Айсылу. Элек тә чибәр идем мин. Безнең нәсел чибәр нәсел ди әби. Бу китапларның барысын да Вил укыймы?

Хәнифә. Укый.

Айсылу. Бигрәк күп. Нургазиз бабай әйтә, җүләр түгел ул ди. Вил үзе дә мин җүләр түгел дип әйтә ди. Кем инде үзен җүләр ди. Исерек тә бит мин исерек диме. Өшкерүчегә алып барып карагыз, Хәнифә апа. Карап торырга чын кеше кебек. Синең киленең булсаң ярар иде ул, әйеме, Хәнифә апа. Их Ким абыйның егет чагына туры килмәгәнмен шул. Бай хатыны гына булып яшәр идем. Туйдым тирес актарып. Чыннан чибәр бит мин, әйеме. Телевизордан күрсәткән булалар. Чибәрләр конкурсы дигән булалар. Җыен салам сыйрак. Әрәм булып ятабыз монда.

Хәнифә. Насыйбы табылыр әле, Айсылу.

Айсылу. Кем табыла. Җыен... Җитмәсә чәйнәгән булалар. Шалтай-балтай, тиле-миле дигән булалар. Иха-ха да миха-ха дип йөри диләр. Миндәге акыл бераүдә дә юк, беләсең килсә. Казанда минем яшьтәшләр әллә нишләшеп беткән диләр. Шалтай-балтай булсам да миңа әле бераүнең дә кагылганы юк. Кагылырга җыенучылар—муре. Берсен дә якын җибәрмим. Керпе Садыйк малае кыз түгел дип сөйләп йөри ди. Врачлардан ысправка алып кайтып, кылый күзенә чәпеп куям әле заразының. Кызык кына бу кешеләр, Хәнифә апа, үзләренекен күрмиләр, кеше ботарасын тикшерәләр. Әй, рәхәтләндем, синең белән сөйләшәм, Хәнифә апа. Ачуланма инде. Тукта, тагын бер кереп чыгыйм әле шалашына. *(Кереп чыккач).* Гел китап та гел китап инде. Менә мин укый алмыйм инде. Үтер, укый алмыйм. Укый гына башлыйм да йокыга китәм. Әле ярый, телевизор бар, бөтенесен күрсәтәләр. Ярый, сау бул, Хәнифә апа.

Хәнифә. Көлмәген бигрәк матур.

Айсылу. Эһе. Былтыр бәрәнге иләмсез унды бит. Бер баз башланмыйча язга чыкты. Шуны олы бер КамАЗга төяп җибәрдек. Рәхәтләндек акчасына, әбигә дә, әнигә дә, үземә дә Казаннан ике күлмәк алып кайттым. Киң итәклеләрен. Берсен хәзер кидем, берсен сабан туена. Чалбар кимә ди әби. Егетләрнең күзе иң беренче кызлар итәгенә төшә ди. Егетләр кызлар итәге җиленнән тилерәләр ди. Дөресме, Хәнифә апа?

Хәнифә. Әбиен әйткәч дөрестер инде.

Айсылу. Аның бер дә белмәгәне юк.

Хәнифә. Бүген син җырладыңмы ул, Айсылу?

Айсылу. Кайчан?

Хәнифә. Баягынак.

Айсылу. Мин гел җырлап йөрим инде ул.

Хәнифә. Мин ишетмәдем, Вил ишеткән, ахрысы.

Айсылу. Нәрсә ди?

Хәнифә. Жырлыйлар ди.

Айсылу. Шул миндер инде, миннән башка кем жырласын авылда.

Хәнифә *(Айсылуны киткән жиреннән туктатып).* Айсылу... Кил әле, Айсылу. Ни... Сина безнең Вил ошыймы?

Айсылу. Нәрсәме?

Хәнифә. Ошыймы?

Айсылу. Ник алай дип сорыйсың, Хәнифә апа?

Хәнифә. Килеп йөр син безгә.

Айсылу. Нәрсәгә?

Хәнифә. Вил янына. Сөйләшеп утырырсыз.

Айсылу. Кит әле, нәрсә сөйләшим мин аның белән.

Хәнифә. Сөйләшкәч сүз табыла ул.

Айсылу. Юк инде. Шумашушныйлардан куркам да.

Хәнифә. Куркыныч түгел ул. Сабый бала кебек. Савыгырга ярдәм ит. Дөньяны үзгәртәм дип саташа. Бәлки синең белән сөйләшкәч...

Айсылу. Мин үзем дә, Хәнифә апа, дөньяны үзгәртсәң иде дип саташам. Мин иң бәхетле хатын булыр идем. Тупырдап торган балалар тудырыр идем.Ату бер чирләшкә табалар да больнистан больниска чабалар. *(Ким кергәнне күреп).* Исәнмесез, Ким абый.

Ким. Исәнме... Әнкәй, бар әле алып кайт тегене. Мине тынламый. Су буенда ялангач йөри. Көләләр.

Айсылу. Йөрсә ни. Казанда су буенда барысы да ялангач йөри.

Ким. Син тик тор. Бар әле, әнкәй.

Хәнифә. И ходаем! *(Чыгып китә).*

Ким. *(Айсылуга).* Ә син нишләп йөрисең монда?

Айсылу. Ярамыймыни?

Ким. Көпә-көндез, киенеп-ясанып...

Айсылу. Бүген бит ял көне, Ким абый.

Ким. Авылда бит ял көне юк.

Айсылу. Ә мин үземә үзем ял ясадым. Хәнифә апа әйтә, безгә килеп йөр ди.

Ким. Нигә?

Айсылу. Вил белән сөйләшеп утырырга ди.

Ким. Шуннан?

Айсылу. Без бит Вил белән тугызынчыга хәтле бер класста укыган идек.

Ким. Шуннан?

Айсылу. Кызык син. Шуннан, шуннан... Утырган да шуган.

Ким. Ярый, бар.

Айсылу. Сау булыгыз, Ким абый. *(Китә).*

Ким *(аның артыннан карап торганнан сон).* Кил әле монда.

Айсылу *(килеп).* Нәрсә, Ким абый?

Ким. Кил бүген Ахун чокырына.

Айсылу. Нәрсәгә, Ким абый?

Ким. Килгәч әйтермен.

Айсылу. Кайчан?

Ким. Егетләр белән кайчан күрешәләр сон?

Айсылу. Син егет түгел ич.

Ким. Очрашкач егет булырмын.

Айсылу *(көлеп).* Ай-яй, беләм мин нигә Ахун чокырына чакырганыңны.

Ким. Белгәч бик әйбәт.

Айсылу. Мин әле кыз кеше, Ким абый.

Ким. Анысы тагын да әйбәтрәк.

Айсылу. Харап итеп ташлар идең бугай.

Ким. Өйләнсәм, кияүгә чыгасынмы сон?

Айсылу. Хатының бар ич инде.

Ким. Хатынны бит аны аерырга да була.

Айсылу. Ай-яй, хитри-митри син, Ким абый. Өйләнмәгән булсаң ие ул. Менә шундый куышта ятыр идек тә йоклар идек.

Ким. Куыш ошыймыни?

Айсылу. Эчендә шундый рәхәт. Кереп чыктым, чыгасы килми.

Ким. Әйдә, бергә карап чыгыйк.

Айсылу. Мин карап чыктым инде.

Ким. Кем белән?

Айсылу. Кем белән булсын, үзем генә.

Ким. Хәзер икәү карыйк.

Айсылу. Ай-яй, хитри-митри. Нишлисенне белми дип беләсенме әллә?

Ким. Белгәч бик әйбәт.

Айсылу. Бик әйбәт түгел шул.

Ким. Бигрәк чибәр инде үзең.

Айсылу. Чибәр булмасам Ахун

чокырына чакырмас идең. Сау бул, Ким абый.

Ким. Китмә инде. *(Айсылуның кулыннан тотып куышка алып кермәкче була. Айсылу кулын тартып алып, көлә-көлә чыгып йөгерә).*

Ким. Кил Ахун чокырына! *(Ленин томнарын карый, актара. Рәшәткә буенда Вил белән Хәнифә күренәләр).*

Вил. Кагылмагыз Ленин хезмәтләренә! *(Йөгереп кереп Ленин томын Ким кулыннан тартып ала).* Сез аңа лаек түгел. Торыгыз аннан. Сезнең анда утырырга хакыгыз юк.

Ким. Йә, кызма инде. Укып карыйм, бәлки мин дә синең кебек булырмын. Югыйсә, гел мине сүгәсең.

Вил. Сез минем кебек була алмыйсыз.

Ким. Ленин китапларын укысам дамы?

Вил. Юк! Ленинны баш белән укырга кирәк, корсак белән түгел. *(Бакчага кергән Хәнифәгә).* Әнкәй, әйтегез аңа, китсен бездән.

Хәнифә. Алай итмә инде, улым. Абыең бит ул. Бертуган абыең.

Вил. Дөньядагы бөтен кешеләр дә берсенә берсе туган. Ләкин һәрберсе аерым-аерым яши. Китсен. Аның үз өе бар.

Ким. Ачуланма инде, энекәш. Мин бит сине яратам.

Вил. Мин хатын-кыз түгел яратырга. Сез яратырга сәләтле дә түгел. Бер кешене яратыр өчен бөтен кешеләрне дә яратырга кирәк. Сез үзегезне генә яратасыз. Хәтта үзегезне дә яратмыйсыз, үзегезнең корсагыгызны гына яратасыз.

Ким. Корсаксыз да яшәп булмый бит, энекәш. Синең дә бит корсагың бар, синең дә бит ашыйсың килә.

Вил. Килми минем ашыйсым. Ашыйсым килсә дә мин ашыйсым килгәнгә генә ашыйм. Ә сез корсак тутырыр өчен ашыйсыз. Ләкин сезнең корсагыгыз беркайчан да тулмый. Килгән саен: әни, ашарга бармы, дип сорыйсың.

Ким. Ярый, мин начар инде, начар. Син дә инде бала-чага янында шыр ялангач йөрмә. Кешеләр көлә.

Вил. Көлүчеләр үзләренең шәрә икәнлекләрен белмиләр. Чүпрәккә төренгәч, алар үзләрен ялангач түгел дип уйлыйлар. Сез шәрәләр. Катлы-катлы туннарга төренсәгез дә мин сезне үтәли күрәм.

Ким. Ленин да кешеләрне үтәли күргәнме?

Вил. Күргән.

Ким. Кайсы китабында язган инде күрәм дип. Укып күрсәт.

Вил *(томнарны ачып укып-укып күрсәтә).* Менә, менә карагыз. «Мы говорим: наша цель—достижение социалистического общественного устройства, которое устранив деление человечества на классы, устранив всяческую эксплуатацию человека человеком и одной нации другими нациями». *(т.32, 78 б).* «Мы хотим добровольного союза наций—такого союза, который не допускал бы никакого насилия одной нации над другой, -такого союза, который был бы основаны на полнейшем доверии, на ясном создании братского единства, на вполне добровольном согласии. *(т.40, 43 б).* «Чтобы управлять, надо иметь армию закаленных революционеров-коммунистов, она есть, она называется партией» *(т.42, 2546).* «Масса должна иметь право сменять их, масса должна иметь право знать и проверять каждый малый шаг их деятельности» *(т.38, 157 б).* «Коммунизм один только в состоянии дать демократию действительно полную и чем она полнее, тем скорее она станет ненужной, отомрет само собой»... «Только коммунизм создает полную ненадобность государства, ибо некого подавлять» *(т.33, 90 б).* «Мы ставим целью равенства как уничтожение классов» *(т.38, 353 б).*

Ким. Алай икән. Бу томнарның әтидән калганлыгын беләсең инде син. Аларны әтинең ачып та карамаганлыгын беләсеңме? Аларны бер генә райком секретарының да укымаганын беләсеңме?

Вил. Алар наданнар.

Ким. Син укыган. Бот буе малайлар белән уйнап йөрисең.

Хәнифә *(Кимга).* Бар инде, улым, кайт. Вилнең ял итәсе бар.

Ким. Энекәш белән сөйләшүе кызык бит, әнкәй. Тагын ниләр язган инде Ленин?

Вил. Мин сезнең белән сөйләшергә теләмим.

Ким. Ленин бит кешеләр белән сөйләшкән.

Вил. Кешеләр белән сөйләшкән. Сезнең кебекләр белән түгел.

Ким. Мин кеше түгелмени?

Хәнифә. Ким, житте сина.

Ким. Кызык бит, әнкәй.

Вил. Әнкәй, әйтегез ана, мина эшләргә комачауламасын. *(Төп өстенә утырып китапка «чума»).*

Хәнифә *(Кимга).* Ярый инде, бар.

Ким. Ашарга бирәр нәрсә бармы? *(Вилгә ишарәләп).* Урамга чыгарма. Минем турыда әллә ниләр сөйләп йөри.

Хәнифә. Ачуланма инде, нишләтәсең.

Ким. Ачу чыга шул. Көне-төне чабасын. Рәхмәт әйткән кеше юк. Бөтенесе таларга гына тора.

Хәнифә. Бик нитмә инде. Әтиегез дә чапты-чапты да... Вил белән жаена торыбрак сөйләш. Врач әйтте бит—нервысын чыгарырга ярамый диде. Үртәмә. *(Чыгып китәләр. Вил укый, яза).*

## II күренеш

*Вакыт кичкә авышкан. Вил һаман да селкенмичә утыра. Малайлар рәшәткә ярыгыннан тын гына күзәтәләр. Алар янына Нургазиз килә.*

Нургазиз *(әкрен тавыш белән).* Көш! Китегез моннан.

1нче малай. Без карап кына торабыз.

Нургазиз. Кино түгел ул сезгә, барыгыз.

2нче малай. Ә ул нәрсә яза?

Нургазиз. Сезне бәхетле итәсе килә аның. *(Малайлар авызларын учлары белән томалап хихылдап алалар. Нургазиз аларнын башларыннан сыйпый-сыйпый озата).* Барыгыз. Әниләрегез югалткандыр. *(Малайлар киткәч, рәшәткәгә таянып, Вилгә карап тора. Айсылу үтеп бара).*

Айсылу. Исәнме, Нургазиз бабай.

Нургазиз. Тс... с... с... Шаулама. Күрмисенмени? Кеше эшли.

Айсылу. Китап уку эшмени.

Нургазиз. Кемгә—эш, кемгә—мәзәк.

Айсылу. Күп укырга ярамыйдыр ана, шунын аркасында бит инде ычкынган.

Нургазиз. Ычкынмаган ул, күпне сөйләмә.

Айсылу. Нәрсә укый икән?

Нургазиз. Ленин дигән кешене беләсенме? Шул кешенең "империя крититсизм" дигән китабын укыдыңмы?

Айсылу. Кит әле, жүләр мәллә мин андый китап укырга. Син укыдынмы сон?

Нургазиз. Мин укымасам да беләм. Минем өчен дә, синең өчен дә укый ул.

Айсылу. Минем үземнеке үземә житкән. Сигез класс бетердем.

Нургазиз. Сигез белән ерак китеп булмый шул хәзер.

Айсылу. Ә нигә кайтарганнар алайса?

Нургазиз. Бер хикмәте бардыр. Сталин заманында бик күп укыган, бик күп белгәннәрне сары йортларга япканнар.

Айсылу. Нәрсә соң ул сары йорт?

Нургазиз. Нәрсә булсын, жүләрләр йорты.

Айсылу. Вилне бит япмаганнар.

Нургазиз. Япмасалар. Казаннан ераккарак жибәргәннәрдер. Бәлки әле кем белә, зур кеше ясамакчылардыр. Бераз карап йөрсен мондагы хәлләрне, нәрсәнен ничек икәнен белсен, аннары зур урынга утыртабыз дигәннәрдер.

Айсылу. Шумашушный түгел дисеңмени?

Нургазиз. Сумашушный—синен белән без ул.

Айсылу. Мин нишләгән ул кадәрле?

Нургазиз. Ярый, бар, юлында бул.

Айсылу. Мина Хәнифә апа әйтә Вил янына килеп йөр ди.

Нургазиз. Ни нәрсәгә ди?

Айсылу. Син килеп йөрсәң терелә ул ди.

Нургазиз. Терелер дә. Хатын-кыз сихерче бит ул. Терелтә дә акылдан да яздыра. Ярый, әйдә, комачауламыйк, эшләсен. *(Китәләр. Хәнифә кереп Вилнен иннәренә пальто сала. Кереп китә. Рәшәткә янына Айсылу килә дә рәшәткә аша бакчага керә. Вилнен язганын укыр-*

*га тырыша. Тигезлеген югалтып егыла яза. Вилгә тотынып кала. Вил куркуыннан сикереп тора, Айсылуга карап тора. Айсылу да куркуыннан чигенә).*

Вил. Син?..

Айсылу. Мин... Исәнме, Вил. Кайчан кайттың, Вил? *(Вил эндәшмәгәч).* Әллә танымыйсыңмы, Вил?

Вил. Таныйм. Син—Айсылу.

Айсылу. Айсылу, Айсылу! Без бит тугызынчы класска чаклы бергә укыдык, син алдагы партада идең, мин иң арттa.

Вил. Таныйм.

Айсылу. Ничек инде танымыйсың? Бер авылдан. Каникулларга да кайтасың.

Вил. Мин сине күрми идем.

Айсылу. Ничек күрәсең. Без кем дә син кем. Син Казанда укыйсың, без монда...

Вил. Бөтен кешеләр дә тигез булырга тиеш. Кешеләр тигез булмаган җәмгыять—кешелек җәмгыяте түгел.

Айсылу *(төп өстендә яткан кәгазьләргә карап).* Ә син нәрсә язасың?

Вил. Аларны син анламыйсың. Аларны бик күпләр анламый. Бүгенге кеше үзеннән башка кешене анларга теләми. Кеше үз-үзенә бикләнде.

Айсылу. Син бу китапларның барысын да укыдыңмы? *(Бер томны кулына алып).* В. И. Ленин. 201нче том.

Вил. Куй урынына. Син аны анламыйсың.

Айсылу. Ишеткәнем бар инде Ленин турында.

Вил. Ишетү генә аз. Анларга кирәк. Сәясәттәге спекулянтлар бөек философ Ленинның хезмәтләрен күрмәмешкә салыналар. Анардан үзләре кебек спекулянт ясамакчы булалар. Анардан гаеп эзлиләр. Аны сүгүчеләрнең берсе дә Ленинны укымаган. Ул бит сөрсеп беткән дөньяны янартырга алынган даһи. Анлыйсыңмы?

Айсылу. Әһе.

Вил. Син беләсеңме, кеше туганда азат, иректә булып туа. Ләкин тууга аны чүпрәккә урап куялар. Кешенең иреген буалар.

Айсылу. Урамасаң, салкын тия ич ана.

Вил. Син мине анламыйсың.

Айсылу. Аны гына анламаска. Әллә Ленин да шулай язганмы?

Вил. Ленин ул философ.

Айсылу. Ә бу куышны ник ясадың? Шундый матур. *(Кереп чыкмакчы була).*

Вил. Ярамый.

Айсылу. Мин инде аны көндез карап чыктым.

Вил. Кем рөхсәт итте?

Айсылу. Хәнифә апа. Вил, чибәрме мин? *(Вил карап торгач, унайсызлана).* Карап торма инде алай.

Вил. Син чибәр. Әйе, син чибәр.

Айсылу. Син дә чибәр.

Вил. Дөньяда бөтен нәрсәне дә чагыштырып карарга кирәк. Дөньяда бөтен нәрсә дә чагыштырмача. Син Эйнштейнны беләсеңме? Юк, белмисең. Аның чагыштырмачалык теориясе бар. Теория относительности. Ул дөньяны бөтенләй икенче яктан өйрәтүче теория.

Айсылу. Ярый, мин китим инде, Вил. *(Көйләп кайтыр якка атлый).*

Кайтам инде, кайтам инде
Туган ягыма...

Вил. Тукта. *(Айсылу янына килеп).* Син матур җырлыйсың.

Айсылу. Хәнифә апа да әйтте, минем җырны тыңлыйсың икән...

Вил. Аларны да син җырлыйсыңмы?

Айсылу. Мин булмый кем булсын.

Вил. Син бик матур җырлыйсың.

Айсылу. Үзебезгә ярый инде.

Вил. Син кайтма.

Айсылу. Нишлим монда?

Вил. Син җырла.

Айсылу. Язуың кала бит.

Вил. Җырла.

Айсылу. Син нинди җыр яратасың?

Вил. Бөтен җырларны да.

Айсылу. Кил алайса. Мин монда басам, син монда утыр. Кул чап.

Вил. Нигә?

Айсылу. Артистларны кул чабып каршы алалар.

Вил. Син артист түгел.

Айсылу. Җырлагач артист инде. Кул чапмасаң, җырламыйм.

Вил. Мин кул чабам. *(Кул чаба).*

Айсылу. «Урманнарда йөрдем»не җырлыйммы?

Вил. Җырла. *(Кул чаба).*

Айсылу:

Урманнарда йөрдем бер ялгызым
Баласын жуйган болан эзеннән.
Башларым әйләнеп китте кинәт,
Башканы сөям дигән сүзеннән.

*(Вилнең жылаганын күреп).* Ник жылыйсың?

Вил. Баласын жуйган... Болан...

Айсылу. Жыр гына бит ул. Жылама. *(Бу күренешне карап торган Хәнифә Вил белән Айсылу янына килә).*

Хәнифә. Вил улым, табыла аның баласы. Ерак китмәгән ул.

Айсылу. Кайтам инде мин, Хәнифә апа.

Хәнифә *(Айсылуны озата барып).* Рәхмәт сиңа, Айсылу.

Айсылу *(шыпырт).* Күзләрен күрдем мин аның, Хәнифә апа. Әллә нинди. Төбе юк күл кебек. Сау бул, Хәнифә апа.

Хәнифә. Сау бул. *(Вил янына килә).*

Вил. Ул матур жырлый.

Хәнифә. Матур. Үзе дә чибәр. Минем улым матурларны гына ярата шул ул.

Вил. Без бергә укыганбыз.

Хәнифә. Әйе, әйе, бергә. Ничә ел бергә. Беренче класстан алып бергә.

Вил. Мин аны начар хәтерлим.

Хәнифә. Син бит, улым... Син укыдың да укыдың. Әллә укудан бераз ял итәсеңме? Язуыңны да куеп торсаң...

Вил. Минем өчен кем укыр, кем язар. Әнкәй, нигә мине авыру диләр? Мин бит чирле түгел.

Хәнифә. Түгел, улым, түгел.

Вил. Мине ленинизм тәгълиматларын яклаган өчен эзәрлеклиләр, әнкәй. Мин беләм, минем арттан күзәтәләр.

Хәнифә. Беркем дә күзәтми, улым, син арыгансың гына.

Вил. Эзәрлеклиләр, әнкәй. Чөнки минем әйткәннәрем күпләргә ошамый. Син минем язганны берәүгә дә әйтмә, ярыймы, әнкәй. Жир өстендә кешеләрне төрле катлауларга бүлеп бетерделәр. Шуның нәтижәсендә явыз кешеләр килеп чыкты. Жиргә синең кебек кешеләр кирәк. Әгәр дә бөтен кешеләр синең кебек булса, жир өстендә коммунистик жәмгыять төзеп булыр иде. Коммунизмны утопия диләр. Кеше утопия белән яшәргә тиеш. Коммунизм идеясен Хрущев кебек наданнар пычраттылар. Егерме елдан коммунизм төзибез дип халыкны аллар өчен изге сүзне калерсезләделәр. Коммунизмны егерме, утыз, кырык еллан да төзеп булмый. Бәлки ул төзелмәс тә. Ләкин ул бар. Еракта, бик еракта. Кеше аның барлыгына ышанырга тиеш. Күктә—галәмдә миллион ел барып та барып житә алмаслык йолдызлар бар. Анарга кешеләр бер кайчан да барып житмәячәкләр. Әмма ул йолдыз бар. Менә шул йолдызны күрү турында хыялланырга тиешләр кешеләр. Ожмахны да берәүнең дә күргәне юк. Тик аны юк дип кем әйтә ала. Юк дип әйткән кеше—кеше түгел ул. Ул бүгенге белән генә яшәүче жан иясе. Чебен ул. Кайда татлы шунда куна, кайда пычрак шунда жыела.

Хәнифә. Боларны син, улым, үзең уйлап чыгарасыңмы?

Вил. Мин уйлап чыгармыйм. Мин ул законнарны ачам гына. Наданнар миннән көләләр. Ленин язганнарны аңламаучы наданнар аны үзләре дәрәжәсенә төшереп аңа әллә нинди гаепләр тагалар. Ленинны аңлар өчен Ленин дәрәжәсенә күтәрелергә кирәк. Мең тәнкәгә хәтле акча саный белүне алар зур белемгә санаилар.

Хәнифә. Улым ишетәсеңме?

Вил. Нәрсәне?

Хәнифә. Айсылу жырлый.

Вил. Юк, моны син жырлыйсың, әнкәй. Синең жаның жырлый. Кешенең үз жаны жырласа гына бүтәннәр жырын ишетә. Син әйт, кешеләрнең зарын кем ишетә? Кешенең жылау авазын тоя алганнар ишетә. Жирдә шундый жәмгыять төзергә кирәк—кешеләр берберсенең жырлаганын да, жылаганын да ишетергә сәләтле булсыннар. Күңелләре саңгырау булмасын кешеләрнең.

Хәнифә. Шулар турында язасыңмы, улым?

Вил. Мин шул жәмгыятьнең моделен төзим.

Хәнифә. Абыеңны да син бик ачуланма инде.

Вил. Мин аны ачуланмыйм. Мин андыйларны фаш итәм. Алар корсакларын кыйммәтле костюмнар астына яшерәләр. Мин ачып күрсәтәм. Ленин кебек. Ленин андыйларның битлеген салдырган. Шуңа күрә капкорсаклар аны яратмыйлар. *(Нургазиз белән Зәйнәпбану күренәләр).*

Нургазиз. Керергә ярыйдыр бит, күршеләр.

Хәнифә. Әйдәгез, әйдә.

Нургазиз. Менә Вил улыбыз белән сөйләшеп утырырга дип кердек әле. Телевизордан карар нәрсә юк, радиодан тыңлар әйбер юк. Тыңлый гына башлыйсың, аны алыгыз, моны алыгыз дип дару мактый башлыйлар. Дару алырлык пинсе бирмиләр. Шул даруны алыгыз диләр. Ничек соң, Вил Нурәхмәтович, җайлымы урының? Укып-язып буламы?

Хәнифә. Була, була. Бик матур сөйләшеп утырабыз әле.

Нургазиз. Без дә матур гына сөйләшеп утырган җирдән...

Зәйнәпбану. Җә, җә... Кеше башын әйләндермә.

Нургазиз. Баш ул әйләнер өчен, Зәйнәпбану. Шуның өчен ана муен дип аталган күчәр куелган.

Вил. Русның кучер дигән сүзе татарның күчәр дигән сүзеннән алынган, күчереп йөртүче. Күчәр дә күчереп йөртә, кучер да күчереп йөртә.

Нургазиз. *(Зәйнәпбануга)* Менә күрәсеңме, безнең Вил барысын да белә. Вил, улым, бу җир пае белән ни булып бетәр икән? Авылны тагын болгата башладылар бит.

Вил. Ленинны укырга кирәк.

Нургазиз. Язып калдырганмы?

Вил. Җир һәм кеше. Ул проблеманы читләтеп үтеп булмый. Шунысын онытырга ярамый, кеше ул үзе җирнең продукты. Җир булмаса, кеше булыр идеме? Парадокс—җирнең продукты кеше үзен җирнең хуҗасы дип атый. Алай була аламы?

Нургазиз. Бәрәңге дә җирнең продукциясе бит. Бәрәңге ничек инде мин җирнең хуҗасы дип әйтә алсын.

Зәйнәпбану. Кысылмый гына утыр әле син.

Нургазиз. Син үзең ирләр сөйләшкәнне тыңлап кына утыр. Болай була инде алайса... Колхоз диделәр, асатсия диделәр. Хәзер агрофирма дигән сүз уйлап чыгардылар, ә җир һаман да җир дип атала. Болай булып чыга. Ни генә кыландырсалар да берни дә барып чыкмый инде. Җирне көчләргә ярамый. Болай бит ул—хатын-кызны көчләгән өчен статья бар, җирне көчләгән өчен юк.

Вил. Сез юридик терминнарны бутыйсыз. Җир ул матди нәрсә булса да әхлакый категория. Сез уйлап карагыз, алогизм: кешене—җирнең продуктын сатарга ярамый, җирне сатарга ярый. Кем мондый вәхшилекне уйлап чыгарды? Капитализм. *(Койма яныннан үтеп баручы Ким, туктап, әңгәмәне тыңлап тора).*

Нургазиз. Капитализмы дигәннән, нигә дип үлгәнне терелтеп интегәләр икән. Социализмы ярамагач бүтән төрлерәген уйлап чыгарырга иде инде. Ленинның да башы җитеп бетмәгән, Вил Нурәхмәтович.

Зәйнәпбану. Туктале шул Нурәхмәтович диюеңнән. Әйт үзебезчә итеп Вәли улым диген.

Вил. Вәли түгел, Вил.

Нургазиз. Надан башы белән кысыла бит тәки. Син менә әйт әле, Вил Нурәхмәтович, нигә бу хатын-кыз дигән нәрсә өйрәтергә оста икән?

Вил. Хатын-кызлар ирләр белән бер хокукта булырга тиеш. Ленин хезмәтләрендә бу һәрвакыт ачык әйтелә. Ләкин хатын-кызга чын хокук әле бирелмәде. Без хатын-кызның җәмгыятьтәге чын урынын билгеләячәкбез.

Нургазиз. Мин әле Линин турында әйтүем иде. Башы җитеп беткән ривалютсия ясарга. Менә мәңге дә җимереп булмый торган сациализм төзергә башы җитмәгән.

Вил. Аның эшен дәвам иттерүчеләр булмаган.

Нургазиз. Барые, Вил Нурәхмәтович. Әтиең Нурәхмәт бик маһир кеше иде. Сезгә дә бит исемнәрнең ниндиен кушты. Берегез Ким, икенчегез Вил. Нәрсәдер монда ни инде. Кайсыдыр җирен уйлап бетермәгән Ленин. Хикмәте аның шунда ул авылда тумаган. Авылда туса, крәстияннең ничек яшәгәнен күреп үссә, бүтән төрле, Ельцин дә җимерә алмаслык социализмы уйлап чыгарырие.

Вил. Син, бабай, Ленинга тел тидермә.

Нургазиз. Юк, юк, Вил улым, болай гына әйтүем. Җимерелде бит.

Вил. Җимерелгәнне төзәтеп була. Без Ленин тәгълиматларына таянып бүтән юл белән китәрбез. Яшәсен янартылган Ленинизм. *(Бакчага кереп килгән Кимгә күрсәтеп).* Без боларны класс буларак юк итмичә көрәштән туктамаячакбыз. Әнкәй, нигә ул һаман безгә килә? Нигә син аны һаман да кертәсең?

Ким. Йә, йә, кызма. Сөйләшегез,

мин тынлап утырыйм.

**Вил.** Тынлама, чыгып кит. Сез без сөйләгәнне аңлаучылар түгел. Чыгып кит.

**Ким.** Кызма диләр.

**Вил.** Син миңа кычкырма.

**Ким.** Кычкырмыйм, әйтәм генә.

**Нургазиз.** Ким күрше...

**Ким.** Бар әле син чыгып кит моннан, һәм бүтән кереп йөрмә. Гомерең буе акыл сатып кеше булдың. Рәтле эш эшләмәдең.

**Хәнифә.** Ким!..

**Зәйнәпбану.** Син бик тузынма әле, күрше. Аның эшен син эшләдең мәллә? Аллага шөкер, колхозында да эшләдек, өйдә дә эшләдек. Өй ычтинабыз тулы грамыты.

**Ким.** Менә шуларга карап утырыгыз. Барыгыз өегезгә.

**Хәнифә.** Ким, нишләвең? Өйдән кеше куып чыгаралармы?

**Вил.** Син үзең чыгып кит безнең өйдән. Деспот! Тиран!

**Нургазиз.** Ярый, Хәнифә, чыгыйк инде. Сау бул, Вил улым. *(Чыгып китәләр. Аларны Хәнифә озата бара).*

**Ким.** Тыңлап-тыңлап торам да, энекәш, син бит авыру кеше түгел. Дивана түгел бит син, егеткәй.

**Вил.** Ә кем әйтте сиңа дивана дип?

**Ким.** Нигә дип кайттың монда?

**Вил.** Мин кайтмадым. Мине кайтардылар.

**Ким.** Кемнәр?

**Вил.** Синең кебекләр.

**Ким.** Кемнәр инде ул минем кебекләр?

**Вил.** Халыкны талаучылар.

**Ким.** Кемне таладым инде мин?

**Вил.** Каян акча алып салдың ул хан сараен? Нинди акчага сатып алдың ул иномарканы?

**Ким.** Алай икән. Шуның өчен кычкырасыңмыни карак дип. Ә син бизнес дигән нәрсәне беләсеңме?

**Вил.** Россиядә бизнес юк. Талаучылар уйлап чыгарган сүз ул. Ике ел эчендә бер тиен акчасыз кеше миллиардер була алмый.

**Ким.** Кара син, ә. Ниләр беләсең. Кайда инде ул минем миллиардлар?

**Вил.** Син талаучының бәләкәе.

**Ким.** Алай икән. Кара син, ә... Бәлки син хаклыдырсың да...

**Вил.** Мин беркайчан да ялган сөйләмим.

**Ким.** Ленин да дөресен генә сөйләгәнме?

**Вил.** Әйе. Ул сезнең кебекләрне үтәли күргән.

**Ким.** Алайса, болай, энекәш...

**Вил.** Мин каракка энекәш түгел.

**Ким.** Ярый, ярый, энекәш булма. Ләкин тыңла, колагыңа киртләп куй. Әйе, мин талыймдыр. Ләкин син әйткәнчә халыкны түгел. Мал бүлешү бара Россиядә. Ленин бабай төзегән җәмгыятьтә халыкны талап җыелган миллионнарны бүлешү бара. Беләсеңме шуны? Кем малыдыр, анысын шайтан белә. Синнән башка бөтенесе талый. Нәрсә, мин шул чакта карап торыйммы? Таланып беткән Россиядә кемнәрнеңдер хезмәтчесе булып калыйммы? Син миннән кол ясарга җыенасыңмы? Юк, брат, мин дивана түгел, мин үз өлешемне алып калырга телим. Ә инде минем өй, машиналарымны әйтсәң, авыл халкының өлеше юк анда. Миңа кадәр талап бетергәннәр иде инде аны. Мин авыл бетмәсен өчен генә алындым ул эшкә. Мал бүлешкәндә бөтенесе дә намуслы була алмый. Бүлешеп бетерик, аннары намус турында сөйләрбез. Сиңа ияреп Ленинны укырбыз.

**Вил.** Укырга өлгермәячәксез. Без сезне фаш итәчәкбез...

**Ким.** Кем ул сез?

**Вил.** Минем кебек уйлаучылар.

**Ким** *(Вил иңбашына кулын куеп).* Әй, энекәш, энекәш...

**Вил.** Алыгыз кулыгызны.

**Ким.** Эх, син, бездельник. Дөрес кайтарганнар сине авылга. Син, әбиеңнең әбәнәге, башыңны җүләргә салып абыеңның тишек кесәсендә актарынасың. Әгәр дә син Ленин булсаң, патшалар, олигархлар белән көрәш. Ленин бабаң шулар белән алышкан, мужикка акыл сатып маташмаган.

**Вил.** Мин синең белән сөйләшергә теләмим.

**Ким.** Мин дә теләмим. Син монда теләсә нәрсә лыгырдап йөрсәң, муеныңнан борып ыргытырмын. Монда мин эшләгәнне ашап, теләсә нәрсә лыгырдап йөрмә.

**Вил.** Нишләтерсең?

**Ким.** Кайтаручылар алып та китәрләр. Кара син аны. Бездельник. Симу-

лянт. Укыйсы килмичә монда кайткан да...

Вил. Мин кайтмадым, кайтмадым, кайтмадым.

Хәнифә *(Борылып килеп)*. Ким, нигә син аңа тиясең?

Ким. Син гел шул бездельникны яклыйсың.

Хәнифә. Беләсең бит инде аны. Нигә аңа бәйләнәсең?

Ким. Мин аңа бәйләнмим. Ул минем турыда теләсә ни кычкырып йөри.

Вил. Син—карак. Сез караклар.

Ким. Тукта диләр сиңа!

Вил. Син—карак, син—жулик...

Ким. *(Вилнең изүеннән алып)* Туктыйсыңмы, юкмы?

Хәнифә *(Кимнең кулын ычкындырып)*. Нишләвең бу. Бар, кит.

Вил *(калтыранып җылый)*. Син—карак, син—жулик.

Хәнифә *(Вилне кочагына алып)*. Улым, улым. *(Вил бәргәләнә башлый)*.

Ким. Симулянт ул. Мин аны тикшертергә алып барам.

Хәнифә (*бергәләнгән Вилне тынычландырырга тырышып)*. Улым, улым.

## II ПӘРДӘ

### III күренеш

*Төп өстендә Ким утыра. Куыш эченнән Хәнифә чыга.*

Ким. Йә, нәрсә анда?

Хәнифә. Нәрсә булсын, бөгәрләнеп ята. Харап иттең баланы. Инде рәтләнә дип кенә торганда.

Ким. Ачуны китерә бит.

Хәнифә. Минем ачуым килгән саен бөтенегезне дә изүеннән тотып селкесәм? Хәлен белеп торасың...

Ким. Чирләми ул.

Хәнифә. Белмиләр ди докторлар.

Ким. Докторлар... Врачлар алар авыруның сәбәбен эзлиләр. Моның сәбәбен белмиләр. Чөнки моның авыруының сәбәпчесе син. Күпме әйтә килдем, үчти-үчти итеп алдыңда утыртма дидем. Авыру түгел ул, тормышка яраксыз, имгәк.

Хәнифә. Ни сөйлисең? Нишләп яраксыз булсын. Мәктәпне алтын медаль белән бетерде, университетында бишлегә генә укыды.

Ким. Унлыга укыса да юк. Кемгә кирәк аның укуы. Укуыннан ни мәгънә, һәр укуның да нәтиҗәсе булырга тиеш. Ничә ел каникулга кайтып, көрәк тә тотып караганы юк бит. Һаман китап. Аңа бит инде егерме яшь.

Хәнифә. Бөтен кешегә дә тирестә казынырга димәгән. Син дә күтәреп ташымыйсың.

Ким. Ул бит бәрәңге пешереп тә ашый алмый.

Хәнифә. Син пешереп ашаттың мәллә?..

Ким. Син пешереп ашаттың. Бөтен пенсияң аңа китеп барды. Миннән күпме...

Хәнифә. Кызганасыңмыни?

Ким. Кызганмыйм. Аның каравы ул нишли? Минем акчаны рәхмәт тә әйтми ашый. Мине карак ди. Аның Ленины да шул булган—байлар акчасына чит илләрдә типтергән, аннары байларны сибереп түккән. Ярый ла аны ашатучылар, тәхеткә утыртучылар булган. Бертуган абыйсын хурлаучы, теләсә ни сөйләп йөрүче дивана татарны кем ашатыр?

Хәнифә. Күпне беләсең. Акчаң кызганыч булса, бирмә.

Ким. Син нәрсә инде, әнкәй...

Хәнифә. Тимә син аңа, үзеңчә яшә, аңа тимә.

Ким. Телен тыйсын. Эшкә яраксыз имгәкләрнең генә теле озын була.

Хәнифә. Нишлим соң инде сезнен белән...

Ким. Илтеп салырга кирәк больницага. Авыру икән, дәваларлар. Юк икән... Син аны монда яшереп ятасың.

Хәнифә. Сине кемнән яшереп ятам соң?

Ким. Ә мин нишләгән? Алып барып больницага салып кайтам мин аны.

Хәнифә. Салып кына кара. Бигрәк остардың.

Ким. Җир җылынып та бетмәгән. Әнә хәзер салкын җирдә ята ул. Салкын тигәч тә мине гаепләрсез. Куышлар ко-

рып, уен уйнап ятасыз. *(Куыш эченнән Вилнең тавышы ишетелә).*

Хәнифә. Хәзер, улым, хәзер. *(Куышка кереп китә). (Нургазиз белән Зәйнәпбану керәләр).*

Нургазиз. Нииндидер тавыш ишетелдеме? Вил тавышы да кебек.

Ким. Сез нигә өегездә генә утырмыйсыз, ә? Чабасыз да кереп житәсез.

Нургазиз. Тавыш ишетелгәндәй булды. Күршеләр бит.

Ким. Зәйнәпбану апа, әйт бу картка, өендә генә утырсын.

Зәйнәпбану. Картаерсың да утырырсың. Күршеләр хәл белешеп тора инде. Хәнифә кайда соң әле. Тавышы ишетелгәндәй булды. *(Ким урыныннан торып чыгып киткәч).* Бу берәр нәрсә ниткәндер әле. Бөтен кешене өйрәтергә оста. *(Куыштан чыккан Хәнифәгә).* Монда икәнсең әле. Берәр тавыш ишетелгәндәй булды да...

Хәнифә. Юк, болай гына.

Нургазиз. Бу Кимне әйтәм әле, бер дә күрше итми.

Хәнифә. Аның да башы әйләнәдер инде. Вил кәефсезләнеп китте.

Зәйнәпбану. Өйгә кертеп яткырырга кирәк. Салкынча бит.

Хәнифә. Керми, нишләтим. Утырып торыгыз әле, юрган-матраслар алып чыгыйм. *(Китә).*

Зәйнәпбану *(Нургазизгә).* Бар, булыш. Нәрсә торасың. *(Нургазиз киткәч, төпкә утырып дога кыла).* И, Ходаем, бәндәләреңне кодрәтеңнән калдырма. Акыл-зиһеннәрен тулы ит. Имансызларга иман иңдер.

Вил *(куыштан чыгып).* Әнкәй...

Зәйнәпбану. Юк, әнкәң түгел әле бу кем, Вил улым.

Вил. Әнкәй кайда?

Зәйнәпбану. Хәзер килә, килә.

Вил. Нургазиз бабай кайда?

Зәйнәпбану. Ул да килә, хәзер килә.

Вил. Минем башым авырта, әби.

Зәйнәпбану. Үтәр, балакаем, үтәр. Яле, карыйк әле. *(Вилнең маңгаена кулын куеп карап).* Юк, болай кайнар түгел, үтәр, Алла боерса.

Вил. Күрше әби, син Аллага ышанасыңмы?

Зәйнәпбану. Ышанмыйча ярамый, балакаем. Коммунист чакта ышанмаска кушалар иде, хәзер рөхсәт булгач ничек инде ышанмыйсың?

Вил. Ленин ышанмаган.

Зәйнәпбану. Ышанмаган кешене нишләтәсең, һәркайсының үзенә җавап тотасы.

Вил. Бәлки, ул ялгышкандыр.

Зәйнәпбану. Ялгышуы да ихтимал. Ул да адәм баласы бит. (Нургазиз белән Хәнифә керәләр).

Хәнифә *(ашыгыбрак атлап).* Улым торган. Кара, Нургазиз бабасы, ничек итеп күрше әбисе белән чөкердәшәләр!

Вил. Әнкәй, минем башым авырта.

Хәнифә. Хәзер, улым, хәзер. *(Әйберләрен куышка кертеп чыга).* Хәзер, улым.

Нургазиз. Ярый, без чыгыйк, Хәнифә. *(Кулы белән ишарәләп Зәйнәпбануга ияреергә куша. Китәләр).*

Вил. Әнкәй, минем башым авырта.

Хәнифә *(төпкә утырып).* Кил, улым, башыңны куй. *(Вил жиргә чүмәшеп, башын әнисенең алдына куя. Хәнифә аның башын сыйпап).* Хәзер үтә ул, улым, үтә. Менә шулай. Өйгә керәсең мәллә, улым?

Вил. Өйдә йолдызлар юк. Әнкәй, әкият сөйлә. Йолдызлар турында...

Хәнифә. Йолдызлар турында... Йолдызлар турында *(Уйланып торгач).* Тыңла инде алайса.

Галәм дигән дөньяның нәкъ уртасында -
Күптән күп, бик күп йолдызлар арасында
Яшәгән ди матур гына гүзәл бер йолдыз.
Янында йолдызлар булса да булган ул ялгыз.
Бүтән йолдызлар аны күрмиләр икән,
Аның йолдыз икәнен дә белмиләр икән.
Яктырак та янып караган ул йолдыз,
Барыбер үзен күрсәтә алмаган йолдыз.
Күңеле йолдызның сүрелә башлаган,
Һәм ялгыз йолдыз сүнә башлаган.
Миллион елдан соң миллионнар үткән.
Һәм ялгыз йолдыз сүнеп тә беткән.
Шул чакта гына аны күргәннәр -
Янына йолдызлар жыелып килгәннәр.
Гафу үтенеп сәлам биргәннәр.
Кайгы-хәсрәткә батма дигәннәр.
Бу хакта Айга хәбәр иткәннәр,
Кояшның үзенә барып житкәннәр.
Алар гозерен Кояш тыңлаган,
Сүнгән йолдызның хәлен аңлаган.
Мин аны көн дә күрермен дигән,
Яктылыгымны бирермен дигән.
Ай исә төнен килермен дигән,
Йолдыз тирәли йөрермен дигән.
Башка йолдызлар елмаешканнар,
Сүнгән йолдызга ныграк елышканнар.
Сүнгән йолдызга исем биргәннәр,
Жир исемле син булырсың дигәннәр.

Сиңа күңелсез булмасын өчен,
Күңелсезлектән күңелең тулмасын өчен
Сиңа бөек затлар бирәбез дигәннәр.
Шуннан бу җиргә кешеләр ингәннәр.

В и л. Син үзең уйлап чыгардыңмы, әнкәй?

Х ә н и ф ә. Йолдызлар турында кирәк диден, улым.

В и л. Син философ, әнкәй. Димәк, кеше күктән индерелгән? Димәк, кешене йолдызлар җиргә бүләк иткән. Димәк, кайсыдыр йолдызда кешеләр яши? Димәк, кайдадыр тагын бер сүнгән йолдыз бар.

Х ә н и ф ә. Бик күп сораулар бирмә инде син. Мин әкият кенә сөйләдем.

В и л. Син әкият кенә сөйләмәдең, әнкәй. Син галәм һәм тереклек турында лекция сөйләдең. Син Аллага ышанасыңмы, әнкәй?

Х ә н и ф ә. Андый сораулар бирмә инде миңа, улым.

В и л. Ышанасың. Беләм, ышанасың. Алла ул чиста күңеллеләр уйлап чыгарган Гали зат. Кешеләр аны уйлап чыгарган, ләкин ул ни өчендер кешеләргә карата бигүк мәрхәмәтле түгел. Бәхетсезләр күп дөньяда, әнкәй. Уйлап чыгарганнары өчен рәхмәт йөзеннән Алла кешеләргә коммунизм бүләк итсен иде.

Х ә н и ф ә. Оҗмах бар бит инде, улым.

В и л. Аның өчен башта үләргә кирәк бит әле.

Х ә н и ф ә. Андый сүзләр сөйләшмик инде, улым. Башың басылдымы?

В и л. Рәхмәт, әнкәй. Синең кулың кагылса, башым авыртудан туктый. *(Кинәт тыңлап)*. Әнкәй, ишетәсеңме, ул җырлый. Әнкәй, бу әллә мәхәббәт микән? Мин бит аның ни икәнен белмим. Аны серле бөек хис диләр. Ике җенеснең бер-берсенә тартылуында нинди серлелек булсын, нинди бөеклек булсын. Бу бит гап-гади инстинкт. Кешенең яшәве—материалистик төшенчә. Безнең курста бер кыз миңа мәхәббәт турында сөйли, мин аны аңламыйм.

Х ә н и ф ә. Димәк, яратмыйсың.

В и л. Ә нигә мин аны яратырга тиеш? Мин аны хөрмәт итәм. Кешеләрне хөрмәт итәргә кирәк.

Х ә н и ф ә. Исеме ничек соң ул кызның?

В и л. Исеме?.. Диана шикелле. Әйе, Мингалеева Диана... *(Тыңлап)*. Җырлый. Ә нигә ул туктаусыз җырлый?

Х ә н и ф ә. Син ишетсен дип җырлыйдыр.

В и л. Ә ул матур җырлый. Ә ул тагын безгә киләме?

Х ә н и ф ә. Син аны үзең эзләп бар, улым.

В и л. Нигә?

Х ә н и ф ә. Җырлавын яратасың ич.

В и л. Әйе. Ул монда килә. *(Рәшәткә янына бара. Айсылу керә)*.

А й с ы л у. Исәннәрме сез. Хәерле кичләр булсын.

В и л. Мин синең җырыңны тыңладым.

А й с ы л у. Тыңламаска. Авылда миннән башка кем җырласын. *(Куыш янындагы Хәнифәгә)*. Исәнмесез, Хәнифә апа.

Х ә н и ф ә. Исәнме, Айсылу. Кайларга киттең?

А й с ы л у. Гүләйткә чыктым. Алып китимме Вилне? Тукта, башта сезгә кереп утырыйм әле. Сездә монда матур. Алмагачлар, куыш. *(Бакчага кереп Хәнифә янына килә)*. Хәнифә апа, син Ким абыйга әйт әле, бәйләнмәсен миңа. Ату хатынына барып әйтәм. Шалтай-балтай дигәч тә мин пыраститутка түгел. Пыраститутка кирәк булса, шәһәргә барсын.

Х ә н и ф ә. Шаяра гынадыр ул.

А й с ы л у. Беләм мин аның шаяруын. Хатыны белән шаярсын... Күңелле монда, әйеме. Сезгә килен булып төшсәм, монда зуррак куыш ясарбыз. Җәй көне нишләп өйдә йокларга, әйеме. Хитрый ул Вил, белә кайда әйбәтен. Минем белән барасыңмы, Вил?

В и л. Кая?

А й с ы л у. Кая дип... Йөрербез шунда туда-суда. Күрсен әле тегеләр зарази, кылый тәре. Барыбер миңа буласың дигән була.

Х ә н и ф ә. Алайса, мин керим инде, Айсылу.

А й с ы л у. Курыкма. Хәнифә апа, каян алган шунда китереп куям Вилне. *(Хәнифә китkәч)*. Утыр, Вил. Нигә атлы казак кебек басып торасың. Син бераз гына мине сагынасыңмы соң?

В и л. Мин синең җырлаганыңны көтәм.

А й с ы л у. Җырламасам, кирәгем юкмы? Син миңа шундый итеп карап торасың. Эт күргән бозау шикелле. Курыкма, тимим мин сиңа.

Вил. Мин курыкмыйм синнән.

Айсылу. Синең йөргән кызың бармы ул Казанда?

Вил. Ничек йөргән?

Айсылу. Йөргән кызның ни икәнен белмисең мәллә?

Вил. Белмим.

Айсылу. Шушы яшькә җитепме? Шушы кыяфәт беләнме?

Вил. Ә нигә кирәк ул?

Айсылу. Бәтәч. Чынлап әйтәсеңме? Әллә кызлар кочаклап караганың да юкмы? Кочаклашуның ни икәнен дә белмисеңме?

Вил. Нигә белмәскә. Ләкин кочаклашу өчен сәбәп кирәк. Ә минем сәбәбе булганы юк. Минем кочаклашып йөрергә вакытым юк. Вакытым кызганыч. Аннан, кочаклагач, өйләнергә кирәк.

Айсылу. Менә сиңа мә, кодагый, чиле-пешле йомырка. Абыең кымтырыкларга гына тора.

Вил. Ул—бозык. Алар барысы да бозыклар.

Айсылу. Бозыгын бозыктыр да. Бозылмыйча да кочаклашырга була ич. Менә мин бозык түгел, кочаклашасым килә. Их, дип уйлыйм, күңелемә ошаган бер егет кысып кочакласын иде дим. Карап торма миңа алай, кытыгымны китерәсең. Ә син көлә беләсеңме?

Вил. Ә нидән көләргә?

Айсылу. Нидән дип... Кызык табасың да көләсең инде ул. Йәле, елмай әле.

Вил. Ни өчен?

Айсылу. Болай гына...

Вил. Болай гына елмаймыйлар. Елмаер өчен сәбәп кирәк.

Айсылу. Нинди сәбәп? Менә миңа кара да, бу нинди тиле кыз икән дип уйла. Уйла да елмай.

Вил. Син тиле түгел. *(Елмая).*

Айсылу. Ай-яй-яй! Кара син нинди чибәр икән.

Вил. Ирләр чибәр булмый, хатынкызлар гына чибәр була.

Айсылу. Йәле, тагын бер елмай әле. *(Вил елмайгач).* Үләм!.. *(Вилне кочаклап ала).* Синең урында мин булсам, кызларны акылдан шаштырыр идем. Кочакла әле син дә. Мин синең муеныннан кочаклыйм, син минем билемнән. *(Кочаклашалар).* Кара, кулларың көчле синең. Укыган кешенең беләге көпшәк була.

Вил. Мин көн саен зарядка ясыйм. Гантельләр бар минем.

Айсылу. Әйдә, үбешәбез.

Вил. Ничек?

Айсылу. Кил әле монда. Бас әле шушы алмагач янына. Мин моннан үтеп барам ди, әйеме. Мин сине күрмим ди. Син күреп аласың да мине, «Айсылу, кая барасың» дип сорыйсың. Мин әйтәм, «суга барам» дим. Син әйтәсең, «мин сине көтеп торам» дип. «Мин сине бик сагындым» дип әйтәсең дә мине кочагыңа аласың. Аласың да мине үбәсең.

Вил. Ә нигә алай эшләргә?

Айсылу. Әй сиңа аңлатып торганчы. Кил, болай гына үбешәбез. *(Вилне кочаклап үбә).*

Вил. Син шундый чибәр.

Айсылу. Чибәр булмыйча. Әллә ямьсез кызларны үбәр идеңме? Әй, теге кылый заразы карап торсыные. Вил, без хәзер синең белән клубка чыгабыз,ярыймы. Әгәр дә анда керпе Садыйк малае кылый Илбрус булса, миңа килә башласа, каршына чык та «Уйди отсюда» диген. Китмәсә, колак төбенә берне яма.

Вил. Сугышырга ярамый.

Айсылу. Син сугышма, яма гына.

Вил. Кешегә сугарга ярамый. Кешегә сугу—ул шәхесне кимсетү. Бер кеше икенче кешене кимсетергә тиеш түгел. Кешеләр тигез булырга тиеш.

Айсылу. Әгәр дә мине кимсетсәләр, карап торырсыңмы?

Вил. Әгәр дә сине кимсетсәләр, карап тормам. Чөнки сине кимсеткән кешенең кеше дип аталырга хакы юк.

Айсылу. И шушының матур итеп сөйләве. Син мине кулларыңа күтәр әле, Вил.

Вил. Нигә?

Айсылу. Син мине күтәр, ә мин сиңа җырлыйм.

Вил. Яхшы. *(Айсылу Вилнең сузган кулларына очып кунып утыргач).* Җырла.

Айсылу. Җырлыйм, җырламыйммы соң!

Алларың булырмын әле,
Гөлләрең булмасам да;
Ярларың булырмын әле,
Гомергә булмасам да.

Син мине, Вил, алмагачлар арасында күтәреп йөрт.

Алым җәл түгел сина ла,
Гөлем җәл түгел сина.
Алым түгел, гөлем түгел,
Җаным җәл түгел сина.

Әйдә, Вил, киттек клубка. Хәзер төшер инде, болай гына барабыз. Мине подручкым ал. *(Вилне култыклап алып, җырлый-җырлый бакчадан чыгып китәләр).*

Ал биргәннәргә ал бирәм,
Гөл биреп тормыйм әле,
Гөрбияннарга гөрбиян—
Сер биреп тормыйм әле.

*Хәнифә пәйда булып алар артыннан карап кала. Ут сүнә.*

## IV күренеш

Хәнифә. *(Куыш янында җыештырып йөри. Көйли).*

Алым хәл түгел сина,
Гөлем җәл түгел сина...

*(Нургазиз белән Зәйнәпбану керәләр).*

Нургазиз. Нихәлләрдә, Хәнифә. Бу куышның кирәге калмадымыни инде.

Хәнифә. Аллага шөкер, ничәнче көн инде өйдә йоклый.

Нургазиз *(бер томны алып).* Боларның да кирәге калмадымы әллә?

Хәнифә. Бу арада кулына алмый.

Нургазиз. Хатын-кыз кулына эләксәң, атаң-анаңны онытырсың. Бик әтчәйни кыз.

Зәйнәпбану. Харап итеп ташламаса ярый инде.

Нургазиз. Кем?

Зәйнәпбану. Шул ирдавайны әйтәм. Үзенә өйләндереп куяр да.

Нургазиз. Куйса ни. Вилгә аңа шундый хатын кирәк.

Хәнифә. Аны-моны уйлаган юк әле. Сәламәтләнсен иде инде. Алланың биргәненә шөкер, күзгә күренеп үзгәрә.

Нургазиз. Хатын-кыз кулына эләксәң. Колхозның айгыры бар иде. Шуны бер ир-ат та тыя алмый иде. Мал докторы Нурҗамал шуның муеныннан бер генә сыйпый иде, тегесе куян булып кала иде.

Вил *(керә).* Әнкәй, минем гантельләр кайда икән? Исәнмесез, Нургазиз бабай, исәнмесез, күрше әби. *(Кире чыгып китә. Ана Хәнифә иярә).*

Хәнифә. Гаеп итмәгез инде, Нургазиз абый, юындырып, чәй эчертим.

Нургазиз. Төс керә башлады егеткә.

Зәйнәпбану. Элек тә шул иде инде, базда үскән бәрәңге кебек. Көнетөне өйдә китап укып ятып соң...

Нургазиз. Тартып алды әле теге кызый. Сөйләшеп утыруы дөнья рәхәте Вил белән. Авылда сөйләшеп утырырлык кешесе калмады. Әллә нишләде халык.

Зәйнәпбану. Әйдә, әкиятеңне миңа сөйлә. *(Чыгып китәләр. Рәшәткә янына Диана белән Ким киләләр).*

Ким. Менә аның резиденциясе. Танышмы? Ленин шалашы. Әйдә, узыгыз. *(Куыш янына килгәч).* Сез бер курста, димәк.

Диана. Да.

Ким. Татар кызымы?

Диана. Да.

Ким. Татарча белмисеңме?

Диана. Беләм. Бик аз. Ну аңлыйм.

Ким. Хәзер сөйләшер өчен күп сүз кирәкми. Компьютер заманы.

Диана. Наверное. А Виль где? Кайда?

Ким. Хәзер өйгә кучте яшәргә. По моему, приходит в себя.

Диана. Сез татарча... Мин аңлыйм.

Ким. Сез аның белән?...

Диана. Нет, просто сокурсники.

Ким. Бүтәннәр килмәгән, сез килгәнсез.

Диана. Как вам сказать... Он какой-то не такой. Не как все. Мне кажется, врачи ошиблись. Уйлый ул как-то по-своему. Мало общается. Со стороны странно выглядит. Но он чистый. Чистый душой.

Ким. Чистый булу гына аз шул.

Диана. Сегодня это главное качество.

Ким. Тормыш катлаулы.

Диана. Да, катлаулы. Духовная чистота понятие вечное. Для вечности, вчера, сегодня, завтра не существуют.

Ким *(көлеп).* Сез бер-берегезгә

охшагансыз.

Диана. Не очень. Он какой-то отвлеченный. Я—нет. У меня ум практический. Я очень уважаю вашего брата Виля! Надо же в такой глухой деревне... Вы меня извините. Я еле отыскала.

Ким. Машинагыз безнең юлларда йөри торган түгел.

Диана. Да. Но ничего, нашла. Где же он?

Ким. Өйдәдер. Ул өйдә ятарга ярата.

Диана. Мин аны телим күрергә.

Ким. Татарчагыз матур—Вилне күргәнче сезгә бер сорау бирергә ярыймы?

Диана. Почему же...

Ким. Минә сез минем энекәшне бик югары күтәрдегез. Ләкин анардан дөньяга ни файда?

Диана. Анламыйм, какой файда?

Ким. Ул укый да укый... Аның ул кадәр белүе кемгә кирәк? Ул тормышка җайлаша алмый. Не приспособлен. Ул бит ир кеше. Аның өйләнәсе, гаилә асрыйсы бар. Кемгә кирәк ул. Кому он нужен. Минә сез ана кияүгә чыгар идегезме?

Диана. Почему бы нет.

Ким. Хәер, сез барыгыз да бер төсле. Сез күбрәк рассуждать итәргә яратасыз. Высшая материя. Ә яшәргә кирәк. Ниндидер черек буын килә дөньяга.

Диана. А чего такое черек?

Ким. Ничек дип әйтим... Ну аморфное поколение. Әтиләр хисабына укып, акыл сатып...

Диана. Зря вы так думаете.

Ким. Нинди машинага утырып килгәнсез. Үзегез эшләп алдыгызмы?

Диана. А кто же?

Ким. Һәрхәлдә үзегез түгел.

Диана. Ошибаетесь. Я работала в Америке.

Ким. Сезме?

Диана. А кто же?

Ким. Ничего себе.

Диана. Вернулась. Узнала, что Вилик заболел. Вот и килдем. Ну, пойдем к нему.

Ким. Туктагыз. *(Өй ягына барып).* Әнкәй. *(Чыккан Хәнифәгә).* Вил янына килгән. Курсташы ди. Керсенме өйгә?

Хәнифә. Туктале. Өйдә җыештырылмаган, ни... *(Диана янына килеп).* Исәнмесез.

Диана. Исәнмесез.

Ким. Ул безнең әнкәй.

Диана. Еще раз исәнмесез.

Хәнифә. Әйдә өйгә, дисәм... Вилнең үзен генә чыгарыйммы?

Диана. Да, пажалуйста.

Хәнифә. Хәзер, хәзер. Әйдә, Ким. Минем янда гына утыр.

Ким. Мин китәм. Эшем муеннан. Ну, сау булыгыз, Диана. До свидания.

Диана. Сау булыгыз. Рәхмәт сезгә. *(Ким киткәч куыш эчен карый, бакчада йөренә. Вил күренгәч, аны кочаклап алырга барган сыман атлыга да Вил янына җиткәч туктап кала).* Вилик, дорогой.

Вил. Исәнмесез, Диана.

Диана. Нашла же я тебя. Таптым. Ну, как ты?

Вил. Яхшы.

Диана. Вилик, я не о чем не буду спрашивать. Я же в Америке была почти целый год. Приехала, узнала. Ты такой же милый. Ну вот—встретились и не о чем говорить. Я всегда думала о тебе. Хотела писать. Ну ты же...

Вил. Америкада ничек?

Диана. Так—живут. Работала. Эшләдем. Официанткой. Зато я английский выучила. Ну и как авылда?

Вил. Яхшы.

Диана. Ты ничуть не изменился.

Вил. Изменился.

Диана. Ты че такой грустный?

Вил. Мин һәрвакыт шундый.

Диана. Да. Я соскучилась по тебе. Сагындым. Ә син уйладыңмы мине?

Вил. Юктыр...

Диана. Да, конечно, конечно... Все-таки я тебя нашла.

Вил. Рәхмәт. *(Сөйләшер сүзләре бетеп, карашып торалар).*

Диана. Скажи что-нибудь, Вилик.

Вил. Рәхмәт, килүеңә.

Хәнифә *(өйдән чыгып).* Вил улым, алып кер өйгә кунакны.

Диана. Нет, нет, спасибо. Рәхмәт. Мин китәм.

Хәнифә. Ничек инде китәм, чәй эчмичә.

Диана. Я спешу. Ашыгам. Сау булыгыз. Вилик, проводи до машины. Да-а-а... Ты такой же... Я то думала. *(Капкага юнәлә. Аны Вил озата бара. Алар югалгач, Айсылу күренә. Хәнифәне күреп, аның янына атылып килә).*

Айсылу. Хәнифә апа, кем ул?

Айсылу. Бергә укыйлар ди.
Айсылу. Ник килгән?
Хәнифә. Хәл белергәдер. Бергә укыгач.
Айсылу. Нигә бүтәннәр килмәгән, ул килгән?
Хәнифә. Мин каян белим инде. Шушында сөйләшеп тордылар да, китте.
Айсылу. Нәрсә сөйләштеләр?
Хәнифә. Тыңлап тормадым.
Айсылу. Озак сөйләштеләрме?
Хәнифә. Юк ла инде.
Айсылу. Алырга килгәндер әле.
Хәнифә. Нишләп алырга килсен. Праводи да машина диде дә, киттеләр.
Айсылу. Маржамыни?
Хәнифә. Юктыр. Сау булыгыз диде.
Айсылу. Килеп җиткәннәр. Мин терелткәч кенә хужа табылган.
Хәнифә. Син ачуланма инде Вилне. Авырмаймасын...
Айсылу. Әйтмим. Нишләп әйтим. Әйтмим дә бүтәннәргә бирмим дә. Килгән... Йөргән була фуфыраеп. Акылдан шаштырып авылга куып җибәрәләр дә йөриләр. Шалашка кердеме?
Хәнифә. Күрмәдем.
Айсылу. Кереп кенә карасын безнең шалашка, ботын сугып сындырырмын. Праводи машина дигәч, машина белән килгәнмени?
Хәнифә. Шулайдыр күрәсең.
Айсылу. Күрденме рәшәткә буендагы кычытканнарны, Хәнифә апа? Тәки өйрәттем бит чабарга. Көче күп аның, ялкау гына.
Хәнифә. Ялкау түгел ул, Айсылу. Син белгән эшне белми генә.
Айсылу. Ничава. Өйрәтәм әле мин аны «Әпипә»гә биергә. *(Көлә).* Мин сине дә бик яратам бит, Хәнифә апа. Син кеше белән сөйләшә беләсең. Вил сиңа охшаган. Ким абый дурак. Кичә әйтә, йә ничек минем энекәш белән ди. Син түгел инде, мең тапкыр әйбәт диде. Мине шалтай-балтайга саный. Йә ничек дигәнен аңламый дип белә. Вил ул кызлардан да оялчан, үрелми теләсә кая. Теге кыз миннән чибәр түгел, әйеме, Хәнифә апа?
Хәнифә. Кая инде сиңа җитәргә.
Айсылу. Юри генә әйтәсеңдер әле.
Хәнифә. Нишләп юри булсын, алма кисәгем. Кил әле, сөйим әле үзеңне. *(Айсылуны кочагына алып сөя).*
Айсылу. Син моны Вил өчен инде, әйеме, Хәнифә апа? Бер дә борчылма, бик әйбәт ул. Күп укыган булса да, әллә ниләр белсә дә бала кебек. Уйнарга рәхәт. Йомшак куян баласы кебек.
Хәнифә. Син аның белән уйнар өчен йөрмә инде.
Айсылу. Син нәрсә, Хәнифә апа, яратам да ич мин аны. *(Вил килгәнне күреп каршысына йөгерә, кочагына ташлана, ут сүнә).*

## V күренеш

*Куыш янында Хәнифә, Ким, Вил утыралар.*

Ким. Бәлки берәр елга академик ял алырсың.
Вил. Юк, нигә кирәк ул. Мин сәламәт.
Хәнифә. Сәламәтен сәламәт тә...
Вил. Әнкәй, сөйләштек ич инде.
Хәнифә. Икегез дә киреләр, үз сүзләләр. Әтиегезгә охшаган. Бүтәннәр киңәшенә дә колак салгаларга кирәк. *(Кимгә).* Үзең илтеп куясыңдыр ич.
Вил. Кирәкми. Олы юлдан автобус йөри. Ленин томнарын таратма, әнкәй.
Хәнифә. Нишләп таратыйм аларны.
Вил. Әнә абый бит бәйләнә, алып китмәсен.
Ким. Саташма шулар белән, энекәш. Үтте инде аларның вакыты.
Вил. Китапның вакыты үтми. Кешеләр яши белмәгәнгә китап гаепле түгел.
Хәнифә. Бу Айсылу белән нишләрсең икән, бигрәк ияләште.
Вил. Анысы безнең проблема. Әллә кая китмим бит.
Ким. Сезнеке генә түгел. Син укыйсың да укыйсың. Ә ул шыр надан. Тиңнәр түгел сез. Хәзер кызыктыр да, бара тора...
Вил. Айсылуга тимәгез.
Ким. Мәсьәлә тиюдә түгел.
Хәнифә. Ярый, үзләре белерләр, сабый балалар түгел.
Ким. Мин киттем алайса... *(Вилгә).*

Киреләнмә, илтеп куям Казанга.

**Вил.** Кирәкми, дидем.

**Ким.** Ярый, иртәгә карарбыз. *(Китә).*

**Хәнифә.** Айсылу беләме китәсеңне?

**Вил.** Юк әле.

**Хәнифә.** Нишләр икән инде. Бигрәк ияләште шул, бигрәк ияләште.

**Вил.** Айсылуга мин бурычлы, әнкәй. *(Нургазиз белән Зәйнәпбану күренәләр).*

**Нургазиз.** Монда утыралар икән. Вил. *(Кулындагы гәжитен күрсәтеп).* Монда бер нәрсә килеп чыкты бит әле. Шул теге инде—мунсипал. Нәрсә дигән сүз соң ул?

**Вил.** Мунсипал түгел, муниципаль. Латыйн сүзе. Үзидарә җәмгыяте дигәнне аңлата.

**Нургазиз.** Ничек була инде? Авыл советы да хәзер үзидарә. Район да үзидарә. Авыл советы үзидарәнең үзидарәсе буламы?

**Вил.** Муниципаль районның җирле үзидарәсе була.

**Нургазиз.** Әй болгаталар да инде. Таңнан уянасың—үзгәрткән булалар.

**Вил.** Фокусниклар.

**Зәйнәпбану.** Алай ук димә, газ керде бит. Дөнья рәхәте.

**Нургазиз.** Һе мунтисипал... Сүзен каян табалар.

**Зәйнәпбану.** Синең белән мин аңламасын өчен ул. Бәрәңгене дә бит әйтәсең бәрәңге дип, бернәрсәсе дә юк. Картуфел дисәң, икенче нәрсә дип уйлыйсың. Сине Нургазиз дисәң, Нургазиз генә, ә менә мунситипаль икенче төрле—үсеп киткәндәй күренәсең.

**Нургазиз.** Зәйнәпбану булып ул да әйтә алмый, син, Хәнифә, әйтә аласыңмы?

**Хәнифә.** Муниципаль.

**Нургазиз.** Син придсидател хатыны шул, Вилнең әнисе.

**Вил.** Минe һаман да Вәли дип йөртә күрше әби.

**Зәйнәпбану.** Мин аны әйтә белмәгәннән түгел, Вәли улым, әйтергә теләмәгәннән.

**Нургазиз.** Ярый, без тагын чыгып укыйк әле, аңлашылмаган җире чыкса, йөгереп кереп житәрбез. *(Айсылуның җыры ишетелә).*

**Хәнифә.** Берәр җиргә барырга сөйләшкән идегезме?

**Вил.** Юк, әлегә.

**Хәнифә.** Йөртте инде ул сине. Менмәгән тавыгыз, кермәгән урманыгыз калмады бугай. Син аның язмышы турында уйла инде, улым.

**Вил.** Мин уйлыйм, әнкәй. Гаҗәеп бай күңелле ул. Ул табигать баласы. *(Айсылу күренә. Үз бакчасына кергәндәй бакчага керә).*

**Айсылу.** Исәнмесез, Хәнифә апа.

**Хәнифә.** Исәнме, Айсылу кызым.

**Айсылу.** Кызым ук димә әле, киленен булмаган. Киленең булгач мина кызым диярсен, мин әни диярмен. *(Вилгә кулын сузып).* Привет!

**Вил.** Сәлам!

**Айсылу.** Бүген кая барабыз?

**Хәнифә.** Төнгә каршы кая барасыз инде?

**Айсылу.** Көндез эш бар, Хәнифә әни. *(Кычкырып көлә).* Бүген урмандагы Каракүлнең төбен карыйбыз. Мин кесә фонары алдым. Шуны яктыртып төбен карыйбыз. Төпсез диләр, дөрес түгелдер ул.

**Вил.** Без бүген бер кая да бармыйбыз. Бакчабызда гына булабыз.

**Айсылу.** Нигә, Вил?

**Вил.** Шулай кирәк.

**Хәнифә.** Йә, алайса, мин керим. Сау бул, Айсылу.

**Айсылу.** Сау бул, Хәнифә апа... Вил, шулай кирәк, дип әллә ничек итеп әйттең. Нигә шулай кирәк?

**Вил.** Беләсенме, Айсылу... Бүтән җирдә мин сина ияреп йөрим. Монда... Аннан соң, монда мин беренче тапкыр синең җырыңны ишеттем. Өченчедән... Хәтерлисеңме, син мина бер уен өйрәтергә тырышкан идең? Мина менә бу алмагач янына басарга куштың. Син үтеп барганда «Кая барасың, Айсылу?» дип сорарга куштың. Син «Суга барам» дип әйтергә тиеш идең.

**Айсылу.** Аннан үбештекме?

**Вил.** Әйе, әйдә, шул уенны уйныйбыз.

**Айсылу.** Син әйткәч, уйныйбыз инде. Кил, бас шунда... Мин үтеп барам.

**Вил.** Кая барасың, Айсылу.

**Айсылу.** Суга барам.

**Вил.** Мин сине көтеп торам.

**Айсылу.** Нигә көтәсең, Вил?

Вил. Мин сине бик сагындым.

Айсылу. Шуннан мине кочаклап аласын, әйеме?

Вил. Әйе.

Айсылу. Мин дә сине бик сагындым, Вил. *(Вил кочагына керә. Муенына асылынып үбә).* Син яратасыңмы мине, Вил?

Вил. Яратам, әлбәттә.

Айсылу. Мин сине өзелеп-өзелеп-өзелеп яратам диген.

Вил. Мин алай дип, синең кебек әйтә белмим.

Айсылу. Укыган башың беләнме?

Вил. Укуның монда ни катнашы бар?

Айсылу. Укыган кеше матур сүзләр күп белә инде ул.

Вил. Сиңа әйтергә тиешле сүзләрне белү өчен уку кирәкми.

Айсылу. Ни кирәк?

Вил. Син кирәк.

Айсылу. Чынмы, Вил?

Вил. Син, мине үз дөньяңа алып кереп, миңа яна дөнья ачтың.

Айсылу. Чынмы, Вил?

Вил. Мин авылда туып, табигать кочагында үсеп, аның матурлыгын күрмәгәнмен икән, син минем күземне ачтың.

Айсылу. Матур сүзләр белмим дигән була.

Вил. Болар матур сүзләр түгел— чынбарлык. Син табигатьнең үзе кебек гади һәм гүзәл.

Айсылу. Ай, үләм. *(Вилнең әйткән һәр җөмләсеннән аны үбеп ала).*

Вил. Рәхмәт сиңа.

Айсылу. Миңа ник рәхмәт?

Вил. Булганың өчен. Дөньяда синең булганың өчен. Син мине алмагач янында бастырып уйнаттың. Рөхсәт ит, мин дә сине уйнатыйм. Кил әле, монда. Бас әле шушында. Җырла әле теге җырны.

Айсылу. Нигә гел шул җырны җырлатасын?

Вил. Белмим. Ошый ул миңа. Беренче тапкыр син аны миңа җырладың.

Айсылу. Тик син монсуланма, ярыймы? Шуны җырласам, син әллә нишлисең. Мин аны хәзер «ялгызым» дип җырламыйм, ярамый. Сине эзлим дим.

Вил. Җырла.

Айсылу.

Урманнарда йөрдем сине эзләп
Баласын җуйган болан эзеннән.
Башларым әйләнеп китте кинәт
Башканы сөям дигән сүзеннән.

Нигә уйга калдың, Вил?

Вил. Айсылу!

Айсылу. Әү, матурым.

Вил. Мин иртәгә китәм.

Айсылу. Кая?

Вил. Казанга. Укуны дәвам итәргә.

Айсылу. Ничек инде? Әйткәнең юк иде.

Вил. Әйтергә иртәрәк иде.

Айсылу. Кызык икән... Ә мин?

Вил. Син? *(Паузадан соң).* Мин бит сине ташлап китмим.

Айсылу. Нишләтеп китәсең соң?

Вил. Казан ерак ара түгел.

Айсылу. Китмисең.

Вил. Миңа укуны дәвам итәргә кирәк. Үткән сессия имтиханнарын тапшырасы да бар.

Айсылу. Китмисең...

Вил. Китмичә ярамый. Мин өченче курсны тәмамлыйм бит инде.

Айсылу. Ярый, кит алайса... *(Чыгу юлына юнәлә).*

Вил. Айсылу, Айсылу...

Айсылу *(Вилнең кочагына кереп).* Китмә, Вил, китмә... *(Җылап).* Китмә. Харап итәләр анда сине. Китмә, бәгырькәем.

Вил. Айсылу... Йә инде... Хатлар язышырбыз. Кайтып йөрермен, үзең килерсең.

Айсылу *(үксеп).* Китмә!.. Китмә.. *(Ут сүнә).*

## IV күренеш

*Җылы киемнәр кигән Нургазиз, Зәйнәпбану, Хәнифә куышны сүтеп бетереп килаләр.*

Хәнифә. Бәйләнде шул куышка Ким. Торса ни була иде инде.

Нургазиз. Үзсүзле. Сүзен сүз итәргә кирәк. Кар юк бит әле, Хәнифә. Ноябрь бетә бит инде. Салкынайтып җибәрмәсен иде.

Зәйнәпбану. Хәзер инде салкыннан куркасы юк. Газ жылытып тора.

Нургазиз. Ә жир? Жирне газ жылытмый бит. Житмәсә, кышка коры килеш кирә.

Зәйнәпбану. Хат киләме улыннан?

Хәнифә. Хат язмый бит ул. Айсылу—килә, дигән иде. Әле менә ул да әйтә, ун көннән артык килгәне юк ди. *(Шул чак рәшәткә янында чәче-башы тузган Айсылу күренә).*

Айсылу. Хәнифә апа!

Хәнифә *(Айсылу янына килеп).* Ни булды?

Айсылу *(кесәсеннән конверт чыгарып).* Менә хат, Вилдән. Әллә ниләр язып бетергән ул анда. Берни дә аңламадым. Ниндидер революцияләр язган. Язуы да танырлык түгел.

Хәнифә. *(хатны карап).* И, Ходаем...

Айсылу. Хәнифә апа... Нишлим икән.

Хәнифә. Туктале. Сабыр... *(Ким керә).*

Айсылу *(Ким каршына атылып барып).* Ким абый!..

Ким. Кит, буталма әле. Әнкәй, кил әле *(Хәнифәне читкәрәк алып китеп).* Мин Казанда идем. Вилне больницага салып кайттым.

Хәнифә. И, Ходаем! Нигә алып кайтмадың?

Ким. Борчылма. Сөйләштем. Тикшерсеннәр...

Айсылу. Хәнифә апа! Ким абый!.. Нигә миннән качып сөйләшәсез? Беләм ич мин. Әйттем бит аңа! Әйттем бит аңа! Әйттем бит, әйттем бит, әйттем бит, әйттем бит мин аңа.

*Пәрдә*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Галимҗан Ибраһимов

### ДОШМАННАР АРАСЫНДА ДҮРТ АЙ

Олуг язучыбыз 1919 елның май—август айларында, исемен, төс-кыяфәтен үзгәртеп, йөкче рәвешендә Колчак тылында йөргән. Эшләр майтарган ул анда, ни күргән, ни ишеткән—боларны без аның "үз авызыннан" беләчәкбез.—әдипнең шул хактагы "хисап докладының кыскасы" (Г. Ибраһимовның үз билгеләмәсе) басылачак.

"...Боларның берсе мәшһүр провокатор Вәгыйз Нәврүзов, икенчесе аксак ишан Корбангалиевтер.

Вәгыйзне Россиядә чагында ике мәртәбә тотып япкан булсак та, ул ничектер котылып колчакстанга барып чыккан. Хәзер гарби армия штабы янында "Ватан" исемендә татарча гәзитә чыгара... Петропавелда бу явызга очрап һәлак була яздым. Гомер бетмәгән икән, язмыш коткарды..."



Резеда
Гобәева

# ЮГАЛМАБЫЗ

**Безнең милләт куркып яши,
Башта бер уй: югалабыз!..
Юк, туганнар, без бит татар,
Тар сукмактан юл ярабыз.
Өмет булсын—янар учак,
Сукмаклар гел—олы юлга!...
Җыелышыйк! Бердәм булыйк!
Таралышмыйк уңга, сулга.
Киләчәкнең киң дәрьясы...—
Без татарлар юл алабыз.
Еллар гына имин булсын:
Көнелләр киң, югалмабыз!**

## Күкләрдән сорадым

**Бер сиңа китергән юлларда
Мең еллар, мең чакрым, мең адым.
Аяусыз елларны үттем дә,
Мин сине күкләрдән сорадым...**

**Кап-кара төннәрне кичтем дә,
Мин сине төннәрдән урладым...
"Нигә мин синеке соң?"—димә,
Мин сине күкләрдән сорадым...**

***

**Кабат янам,
Димәк, кабат сөям!
Акылыма мең мәртәбә каршы киләм...
Үткәнемнең мең өлештән бер өлешен
Бүгенгемә саклап алып киләм...**

---

Резеда ГОБӘЕВА—*яшь шагыйрә; Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультеты студенты. Шигырьләре көндәлек матбугатта күренеп килә.*

Кабат шашам...
Кабат очам,
Димәк, киңлекләрне кочам...
Син дә миңа каршы барчы,
Без икебез ике очтан...

Кабат дөрлим...
Димәк, үлмим...
Син дә...
Сине саклап калган ул—мин!..

***

Хыяллар!
Ак та соң үзләре,
Тик алар бит мине алдаган:
Бу күкнең иңендә, офыклар чигендә
Бәхетнең эзләре калмаган...

Югалту...
Югалу...
Үкенеч...
Язмышка сылтанган ялгышлар.
Өметне өзмичә, ышанып,
Акланмый үтелгән яз-кышлар...

Күңелгә ышаныч гел җитми,
Таяныч булырдай терәкләр...
Омтылыш!..
Тик җанда
Тормышка ашмаган теләкләр...

Хыяллар!..
Ак та соң үзләре!
Тик аклык ялганга түзәме?..

***

Ә хыялда бар да башкача:
Күк тә зәңгәр, ә чәчәкләр гел ак!..
Ә хыялда бар да саф һәм ихлас ...
Фани дөнья:
яңгыр,
салкын,
гөнаһ...

Их, хыялда гына яшисе дә,
Киң күкләрдә генә очасы!..
Ә яңгырлар тәрәз тырнап елый—
Фанилектән кая качасың?..

Ә хыялда бар да башкача...
Салкын яңгырлардан туйган чакта,
Ак нур эзләп хыялыма кайтам!..

# АЛАНЛЫ ИСЕМЕ БЕЛӘН...

*Людмила Аланлы иseme—шигъриятебездә, бигрәк тә яшьләр поэзиясендә беркадәр билгеле исем. Шунысы бик куанычлы—шагыйрәнең теле чиста тел, читтән кергән алынмалар белән чуарланмаган саф төрки-татар теле. Яшь шагыйрә өчен бу бик әһәмиятле.*

*Людмиланың шигырь формасы, шигырь калыбы да төрле шаукымнарга бирелеп катлауландырылмаган, шигырь юлларының агышы нәкъ үзебезчә, татарча.*

*Шигырьләрнең эчтәлеге, тематикасына килгәндә, яшь шагыйрә әлегә әсәрләрен, нигездә, яшьләргә хас булган мәхәббәткә, аның бәхетле һәм катлаулы минутларына, туган якны, туган өйне, туган табигатьне сагыну-юксынуга багышлый. Болар бер яктан шагыйрәнең киләчәк иҗатына алып баручы бер баскыч булып торсалар, икенче яктан, алар туган илне, туган халкыңны, туган телеңне яратуга, үз илеңнең чын патриоты булуга омтылышлы хисләр кузгаталар.*

*Людмила—югары музыкаль белем алган шагыйрә. Шуңа күрә ул татар шагыйрьләренең шигырьләренә һәм үз әсәрләренә көйләр язучы композитор да.*

*Людмила Аланлы—нефть якларында туып-үскән, шул төбәк табигатен һәм тормышын яхшы белгән, бүгенге көндә Әлмәт шәһәрендә яшәп эшләгән каләмдәшебез.*

**Гәрәй РӘХИМ**



Людмила
Аланлы

## Без эзләгән Бәхет

**Без эзләгән Бәхет ерак микән?**
**Озак еллар микән үтәсе?**
**Барыр юлыбызның таңнарында**
**Күпме икән сынау-киртәсе?**

**Без эзләгән Бәхет нинди икән?**
**Безгә дигән Бәхет ни икән?**
**Ак болытлар төсле куе микән?**
**Галәм кебек гаҗәп киң микән?**

**Без эзләгән Бәхет кайда икән?**
**Күк йөзендә микән, җирдәме?**
**Без эзләгән Бәхет шушы мәллә—**
**Иреннәрдә сусыл... җыр тәме?!**

## Җырлап табышыйк әле

Сандугач сайрый талларда,
Күктә җыр суза тургай.
Яшел үләнгә төренеп
Аланнар тыңлый, тугай...

Хисләрен бер-берләренә
Кошлар шулай аңлата.
Мәхәббәт ул, җырдагы күк—
Ихласлыкны ярата.

Син дә, иркәм, җырлап җибәр,
Тынычланмасмы йөрәк...
Кошлар да җырлап табыша,
Безгә уртак җыр кирәк!

***

Айда булсаң—айдан менеп алыр идем,
Кирәк икән—йолдыз булып янар идем;

Аккош булсаң—күлләреңдә йөзәр идем,
Чәчкә булсаң—янәшәңдә үсәр идем...

Китмә генә, зинһар, китмә бу дөньядан—
Син булмасаң, анда мин дә яши алмам...

## Дустым, уйнат гармуныңны

Дустым, әйдә гармуныңда
Сыздырып алчы!
Оста гармунчылар хәтта
Бер читтә калсын.

Ай да тыңлый безне генә,
Йолдыз күз кыса,
Җырларсың, янында шундый
Гармунчың булса!

Дустым, уйнат гармуныңны,
Бер җырлыйк әле!
Күңелнең әллә кайларга
Җилкенгән мәле!..

## Үз ягымда

Мине тудырган туган җир
Бик тә кадерле, газиз.
Үз ягымда һәркем якын,
Бар да туган, бар да үз.

Кадерле зифа талым да,
Салкын сулы чишмәм дә,
Якын миңа таулар, хәтта
Яңа чыккан чирәм дә.

Әрәмә дә үз бакчамдай—
Иң моңлы кошлар анда!
Тау илләре дә көнләрлек
Саф, чиста безнең һава.

Җилләре дә йомшак аның—
Иркәләп, назлап исә.
Бар матурлык, бар хозурлык
Күңел җырына күчә...

Мине тудырган туган җир
Бик тә кадерле, газиз.
Бал ягылганмени аңа—
Якын шул туган нигез!

## Ходай бүләге ул—Мәхәббәт

Керфекләрең нигә яшерәсең?..
Очкын күрәм алсу йөзеңдә.
Хисләреңнән тамчы хасил булган,
Энҗе балкый серле күзеңдә...

Йөрәгеңне синең Сөю шакый,—
Ак чынбарлык җанга урала...
Тәүге хисләр, тәүге мәхәббәтнең
Ләззәтеннән дөньяң бутала...

Иңеңдәге фәрештәләр хәтта
Җайлый алмый хисең дөньясын...
Син—гашыйксың! Ходай бүләк иткән
Чын Сөюнең серен тоясың...

## Парлы булыйк

Яратам мин сине!
... Кояш яраткандай җирне,
Җиһан яраткандай җилне...
Дулкын сөя диңгез комын,
Акчарлаклар—шаулы җырын...
Былбыл сөя бөдрә талын,
Ярсу елга—яшел ярын...
Җиләк сөя яфракларын,
Һәр җан таба тиңдәш парын...
Бер пар булып, бер җан булып,
Яшик әле без дә, җаным!

## Көмеш әкият

Салмак кына төнлә карлар ява
Акка түшәп урам юлларын...
Шул аклыктан атлап Икәү килә –
Моннан гүзәл нәрсә бар тагын?

Кар ява да, ява... Юлда алар
Ак күбәләк сыман тоела,
Гүя карлар түгел, бар җиһанга
Аклык булып сөю коела...

Гашыйкларның шаян сөйләшүен
Җил дә тыңлап тора тын гына,
Талгын көйгә карлар вальс бии,
Бар җиһанда көмеш нур гына!

Урам тулып парлар йөргән чакта
Юкка мени карлар явалар?
... Юл читендә "сөям" дигән сүзләр
Парлар үткәч кенә калалар...

Кар аклыгы, ихлас сөю хисе
Ни хикмәттер, бергә бәйләнгән...
Икәү килә... Алар мәхәббәте
Көмеш әкияткә әйләнгән...



Радик Фәизов

# АТ КАРАГЫ

ХИКӘЯ

Мин аларны көн дә иртән күрәм, һәм бара торган җиремнән тукталам да, сокланып, күңелем нечкәреп карап калам. Менә. Авыл асты болын юлыннан икәү киләләр. Ат һәм Кеше. Әле чын ат та булып үсеп җитмәгән яшь айгыр һәм яшь егет. Ат озын торыклы, аяклары нечкә, кара яллары дулкынланып төшкән, башы нәфис, зур күзләрендә очкыннар уйный. Озын муйнын дугалап, тасырдап, адымнарын көчкә тыеп килә. Әллә кайдан күренеп тора, җилле чабышкы буласы. Егет шулай ук озын буйлы, билгә кадәр яланөс, кояшта каралган иңнәре киң.

Менә алар көч-куәтләрен тыя алмыйча юргалап китәләр. Егет ат менми, янәшә йөгерә. Тайны яратып сыртыннан, ялларыннан сыйпап-сыйпап ала. Алар шулай янәшә киң болынны бер әйләнеп үтәләр. Аннары инде егет бернинди йөгәнсез, иярсез килеш айгырга менеп атлана, кулларын як-якка җәеп дәртле итеп кычкырып җибәрә. Аннары инде ат та үзенең ашкынуына, ярсу йөрәгенә, җитез аякларына ирек бирә. Бөтен сылу буена сузылып, үләннәргә елышып диярлек, җилдереп чаба башлый. Алар шулай рәхәтләнеп, дәртләре, җегәрләре басылганчы чабалар, болынны берничә кат әйләнәләр. Муллахмәт чишмәсе буена тукталалар да, егет җинел генә җиргә сикерә. Чишмә буенда иртәнге гимнастика ясый. Ә ат янәшә генә утлый, әледән-әле башын күтәреп дустына карый, кайчак хәтта үзе дә ал аяклары белән җиргә сугып-сугып куя.

Аннары алар бергәләп Ашыт суында коеналар, иң тирән яшелчә тугаенда бергәләп йөзәләр. Йөзеп туйгач егет атның яннарын юа, зур агач тарак белән ялларын, койрыгын тарый. Нәни генә ак йолдызлы маңгаеннан сыйпый, муйныннан кочып тора. Ә ат исә үзенең нәфис башын егетнең иңенә сала. Алар шулай итеп бер-беренә тойгыларын белдерәләр. Аннары тагын, нәкъ ике иптәш кебек янәшә атлап үргә, авылга таба юнәләләр.

---

Радик ФӘИЗОВ (1931) — *прозаик һәм публицист; «Бәхет», «Дусларым», «Галәм кызы» һ. б. китаплар авторы. Арчада яши.*

Мин, авыл укытучысы, инде картаеп, калҗаеп беткән бер өлкән адәм, болын буена иркен һавага чыккан җиремнән, аларны яратып карап калам. Бу табигать балаларының яшьлегенә, сылулыгына, алардан ташып торган көч-куәткә сокланам. Аларның гаҗәеп тә, шушы кадәр матур да дуслыгына хәйраннар калам. Чөнки кеше белән атның мондый дуслыгы, кешенең атны үзенә тиң итеп каравы, аны чын күңеленнән яратуы, хәтта ихтирам итүе,—хәзерге заманда сирәк очрый торган күренеш. Мин моны хәтта авылыбызның бер яме кебек кабул итәм. Әле мин генә дә түгел, бөтен авыл халкы белә, күреп тора бу хәлне, аңа сокланып карый.

Егетне мин балачагыннан бирле беләм, ул минем элекке укучым, һәм, әйтәм ки, Рөстәмнең болай авыл җирендә дә иртәнге гимнастикалар ясый торган культуралы, тәртипле, миһербанлы егет булып үсүендә, педагог буларак, минем дә өлешем бардыр.

Безнең авылда иң авыр язмышлы бала булды Рөстәм. Әтисе аның төнлә белән җир сөргәндә кашлак урында тракторы белән әйләнде, бик яшьләй һәлак булды. Әнисе әле бала өч яшьлек чагында ук мари ягындагы ерак бер авылга, ишле балалы тол иргә кияүгә чыкты, үз баласын исә әбисенә калдырып торды. Ә Камәрия әби исә үзе орчык тикле генә, әмма ачы телле, саранлыгы, усаллыгы белән авылда беренчелекне тоткан карчык иде. Кайчак ул үз балаларын да рәхимсез кыйный, тегеләрнең елаганнары бөтен авылга ишетелеп тора иде. Ул балалар үсә барган саен өйдән чыгып таю ягын карадылар, ә ире Әхмәтҗан абзыйны, бик юаш бер бәндәне, гел талап, каһәрләп торды, ул шуңа күрә генә иртә гүргә керде дип сөйләделәр. Менә шундый карчык кулына калды Рөстәм.

Ни хикмәт, Камәрия әби баланың өстен-башын да, тамагын да әйбәт карады тагын. Кем белә, ул, ялгыз карчык, аны үзенчә яраткандыр да. Һәрхәлдә, соңыннан әнисе сорап кайткач, ул Рөстәмне аңа бирмәгән. Ул минем улымның улы, үземдә торып та кала дигән. Ә килене таләп итеп тавыш күтәргәч, аны куып чыгарган. Алай да баланы бик каты кулда тотты, урамда үз иптәшләре белән уйнап йөрү бик сирәк эләкте Рөстәмгә. Ул кечедән гел эшләп үсте, каз көтте, сыер-сарык абзарларын чистартты, болай да чиста ишегалдын себерде, бакчада бәрәңге чүбен утады, төбенә өйде. Карчык аңа кул күтәрүгә барып җитмәде анысы, әмма гел аяк тибеп кычкырып, уклау күрсәтеп кенә торды.

Рөстәм дүртенче сыйныфка кадәр авылда, миндә укыды. Мин инде шундый язмышлы, шундый тәрбиядәге бала бөтен дөньясына ачулы, усал, тискәре холыклы булып үсәр дип көткән идем. Әмма киресе килеп чыкты. Минем алда әйбәт, чиста күңелле, сабыр холыклы бала иде. Анда мин ниндидер эчке ныклык, түземлек сиздем. Тик менә укуы гына бик уртача иде. Бервакыт мин аны дәресләрдән соң ялгызын алып калдым.

—Рөстәм, син бит зиһенле малай. Ә менә начар укыйсың,—дидем.

—Мин дәресләремне хәзерли алмыйм шул, Хатыйп абый. Мәктәптән кайткач өйдә эшләрем күп. Ә кичләрен... Камәрия әби утны сүндереп куя,—диде ул бик уңайсызланып.

—Соң, кичләрен безгә кил алайса. Бездә әзерләрсең дәресләреңне,—дидем.

Ул моңа бик шатланды, кичләрен сумкасын күтәреп безгә килә торган булды. Дәресен әзерләде, телевизор карады. Инде бик картаеп килгән Камәрия әбисе дә моңа ризасызлыгын белдермәде. Кем белә, ул саран өйдә электр утының аз януына шатланган гынадыр бәлки. Безнең үз балаларыбыз инде үскән, һәркайсының үз тормышы. Рөстәм белән кичләрен безгә дә күңелле иде. Минем карчыгым Сания апасы аны җылы кабул итте, тәмле чәйләре белән дә сыйлады. Кыскасы, без аның белән дуслашып киттек.

Укуы да хәйран яхшы якка үзгәрде.

Безнең авыл кечкенә, дүртенче сыйныфтан соң балалар өч чакрымдагы күрше авылга, урта мәктәпкә китәләр. Инде анда, югары сыйныфларда укыганда да, Рөстәм безне онытмады. Кичләрен килде, дәресләрен әзерләде, сөйләшеп, чәйләшеп утырды. Ул инде үсмер булып килә иде һәм мин аны киләсе тормышына әзерли башладым.

—Синең киләчәктә терәгең юк. Сина үз-үзенә терәк булырга туры киләчәк. Югары уку йортларына кереп укый алмассың. Аның өчен ныклы нигез кирәк, әти-әниле булу кирәк,—дип сөйләдем.

Гадәттә балаларның күпчелеге инде үсмер чактан ук, ягъни урта мәктәптә укыганда, үзләренең киләчәк тормышлары турында уйлана, төрле планнар кора башлыйлар, һәм инде үсеп олы тормышка аяк баскач та күбәүләр үзләре сайлаган юлдан китәләр дә.

Андый уй-планнар Рөстәмдә дә бар булып чыкты.

—Әә мин абый, урта мәктәпне бетергәч беркая да китеп йөрмим. Авылда гына калам. Әнә үзебезнең буш нигезгә йорт салып куям. Үземә бер эш табармын, районлагы авыл хуҗалыгы техникумына читтән торып укырга керермен. Мин авыл кешесе булам!—диде ул. Нык итеп әйтте.

***

Урта мәктәпне бетереп чыкканда Рөстәм инде озын буйлы, нык бәдәнле егет булып житеште. Күзләренең карашы игътибарлы, гамьле, ваемлы егет булып. Без колхоз рәисе Наил абыйсы белән киңәштек тә, аңа эш таптык. Баш бухгалтер Гаяз абыйсына ярдәмче хисапчы итеп куйдык. Ул моңа бик куанды:

—Рәхмәт сезгә, абыйлар, бу яхшылыгыгызны онытмам!—диде.

Идарәдә Гаяз абыйсын куандырырлык итеп эшләде, исәп-хисапны төгәл алып барды. Кичләрен дә авылның кайбер егетләре кебек тәмәке кабызып, сыра чөмереп, болагайланып йөрмәде ул. Китапханәдә булды, китапларны, аеруча техник журналларны яратып укыды. Алар, клуб мөдире Банил абыйсы белән бергәләп, шахматчылар түгәрәге оештырдылар. Авылның байтак яшьләре җыелды ул түгәрәккә, кичләрен кискен көрәшләр барды. Кайбер егетләр шунда йөреп кенә эчүләрен дә ташлады. Кайчак мин үзем дә иренмичә клубка менгәләдем. Рөстәм, гомумән, яшьләрне башлап йөрде, театр түгәрәгенә керде, спектакльләрдә уйнады. Халык кул чабарлык итеп.

Көндәлек тормышында да тәртипле, мәгънәле булды ул. Бу вакытта инде аны карап үстергән Камәрия әбисе бик картайды, тузды. Хәзер инде оныгы әбисен тәрбияләде. Үз көчендә вакытта карчык оныгын барча йорт эшләренә, аш-су әзерләргә, керен юарга өйрәтеп житкергән иде. Ныклы әмерләре белән. Рөстәм табигате белән дә бик чиста, пөхтә, мин аның иртәләрен ишегалдында гимнастика ясаганын да еш күрә идем.

Ул арада Рөстәмгә тагын бер кайгы килде. Камәрия әбисе сырхаулап китте, холкына күрә эшне коры тотты, урын өстенә менеп тә тормыйча вафат булды. Хәзер инде яшь егет япа-ялгызы торып калды. Гәрчә карт кешенең вафаты котылгысыз һәм гадәти бер хәл булса да, ул аны авыр кичерде. Кичләрен безгә килә дә:

—Ник мин бу кадәр бәхетсез икән, абый?—дип сорый. Үзенең күзләре яшь белән тулган була иде.

Менә шул вакытта инде ул ат белән, дөресе, тай белән дуслашып китте. Бу тай аның үзенеке түгел, аны аларның ике йорт аша күршесе Кәримулла карт каяндыр сатып алды. Хәзер бит заманалар үзгәрде, авыл кешесен тар кысада гына тоткан совет власте җан тәслим кылды. Хәзер авыл кешеләре

ике, өч, биш баш эре терлек асрый, кайберәүләр ат та тота. Моңа беркем бер сүз әйтми, хуплый гына. Тик менә карчыгы белән икесе генә яшәп яткан Кәримулла абзыйның гына ни өчен ат алуы аңлашылып бетмәде. Ул инде өлкән, үзе ат җигеп йөрерлек түгел. Бу хакта сораганнар да иде, тик анык кына җавап алмадылар. Тәбәнәк кенә, тәмле генә телле Кәримулла абзый бик хәйләкәр, тел төбен яшереп кенә сөйләшә торган адәм.

—Бик очсызга гына бирделәр ул тайны. Бер кирәге чыгар әле,—дигән дә бетергән.

Ат малын гел абзарда гына тотып булмый. Тар урында хәрәкәтсез калса аның аяклары бетә, көн аралаш кына булса да бер йөртеп керергә кирәк. Менә шунда инде Кәримулла абзый күршесе Рөстәмне дәштереп алды.

—Иренмәсәң, шушы тайны гына йөртеп керче, энем. Миңа файдасы, әсиңа савабы булыр,—диде һәм егеткә үзе җиз тәңкәләп ясаган йөгәнне сузды.

Менә шуннан инде яшь егет белән яшь тай аерылмас дуслар булып киттеләр. Рөстәм тайны күрүгә муйныннан кочып алды, аңа йөгән дә кидермәде, әле ныгып та җитмәгән терлеккә менеп тә атланмады. Тик аның сыртына кулын гына куйды да, чөңгереп кенә җибәрде. Акыллы терлек аны шунда ук төшенеп алды. Һәм алар, нәкъ ике иптәш, дус кебек, янәшә атлап киттеләр.

Көн саен үзе эшкә менгәнче иртән, ә кайчак эшеннән соң кичләрен дә алып чыкты Рөстәм тайны тар абзарыннан. Тиз арада исем дә кушып, аны Лачыным дип кенә йөрде. Көче ташып торган, уйнаклап кына килгән яшь айгырга йөгән дә киертмәде, ияр дә салмады. Алар ярыша-узыша янәшә йөгерделәр, егет Лачынына атланганда да йөгәнне кирәк санамады. Томырылып килгән килеш ул кулы белән үрелеп кенә тайның янагына кагылып ала, ә тегесе шул якка борыла. Алар бер-берсен бик яхшы аңлыйлар иде.

Кайчак, аеруча кичләрен, атар болын юлында өчәүләп тә күренәләр. Егет, ат һәм кыз. Рөстәмнең яратып йөргән кызы, фермада сыер сауган Алсу да аларга иярә. Менә иш-ишен таба бит ул, Алсу да тегеләргә тартым озын торыклы, гаҗәеп сылу, сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле кыз. Инде ул аларның өчәүләп килгәнен күрсәң! Егет белән кыз туктаусыз шаяралар, көләләр, йөзләрендә яшьлек сафлыгы, яшьлек матурлыгы балкый. Урталарында муйнын дугалап, тасырдап, күзеннән нур чәчеп ат килә. Егет белән кыз аңа иркәләү сүзләре әйтәләр, йолдызлы маңгаеннан сыйпыйлар. Инде алар болын юлыннан авылга килеп керсәләр, урамдагы бар халык артларыннан карап кала. Кайбер олы җиңгиләр яулыклары чите белән күзләрен сөртеп алалар. Бу атны бөтен авыл ярата, урамнан үткәндә аңа сокланалар, ялларыннан сыйпыйлар, Карт-карчыклар, Рөстәмнең бик нык каршы килүенә һәм уңайсызлануына карамастан, сәдака акчалары биреп китәләр. Халык аңа, үксез бала янәшәсендәге терлеккә, ничектер изге җан итеп карый булса кирәк.

Алып карасаң, безнең авылда әле моңарчы күрелмәгән хәл иде бу. Дөрес, авыл кешесенә ат малы кечедән таныш. Хәзерге өлкәннәр арасында кайчандыр аны җигеп әллә никадәр эшләр башкарганнар да байтак. Аннан килеп, хәзер үз хуҗалыгында ат тотучылар да бар. Әмма бит халык атка асылда тарту көче яисә... сугымлык дип кенә карый. Бездәге кебек яшь егет белән яшь атның мондый да дуслыгы тагын кайда гына бар икән? Хәтта менә мондый хәлләр булгалады. Керә Кәримулла абзый абзар чистартырга, өлкән кеше, оныта ишекнең эчке келәсен төшерергә. Берзаман күрә, юк абзарда Лачын.

Ишекне мыштым гына ачып чыгып тайган. Ә иркенгә чыккан Лачын

кин болынга да, тау астына да чапмый, урам буйлап югары очка менеп китә. Идарәдә исәп-хисап ясап утырган Рөстәмнен кинәт тәрәзәсе карангылана. Караса, Лачын! Башы белән тәрәзәгә кереп китәрдәй булып тора... Ул арада кулына йөгәнен тоткан Кәримулла абзый да менеп житә. Тик ат чын хужасына тоттырмый. Тегесе никадәр ялынса да, ипи сыныклары сузып караса да. Башын чөеп чабып китә дә, Рөстәмнен төшке аш вакыты житкәнче шул тирәдә йөреп тора. Аннары алар урам буйлап бергә төшәләр, Рөстәм Лачынны абзарга алып килә һәм тегесе күндәм генә кереп китә.

Эшләр шулай жай гына барганда авылда хәбәр китте. Авыр вә шомлы хәбәр. Кәримулла абзый тайны иткә дип алган икән дә ул аны быел көз үк чалырга жыена икән! Бөтен авылда таралды, бөтен авыл яратмады бу хәбәрне. Анысы малны итлеккә алуда бернинди гөнаһ юк, безнең татар халкы жылкы ите ашый. Тик менә Лачынны жиргә егып чалырга?! Янып, тасырдап, балкып торган, бөтен авыл белән яраткан яшь айгырны... Монысын, мөгаен, беркем дә күнеленә сыйдыра алмагандыр. Әлбәттә инде, бу хакта Кәримулла абзыйның үзенә әйтүчеләр дә табылды. Абзый исә ниятен яшереп тә тормаган һәм аннан кире кайтмасын да белдергән.

—Ә ни эшкә дип алдым сон мин ул тайны? Жигеп йөри алмыйм, мин карт инде. Ашатып гел абзарымда да тота алмыйм, хәлемнән килми. Үз малым, димәк ки, теләсәм ни эшлим,—дигән.

Абзыкай тиз арада үз ниятен гамәлләре белән дә раслады. Беркөн Рөстәм гадәтенчә иртән Лачынны абзардан алып чыгарга килгәч, ул аны бирмәгән.

—Юк инде, энем, житәр. Мал минеке, абзарында гына торсын, күзгә тикле симереп куйсын,—дигән.

Бу хәлләрдән Рөстәм тагын олы хәсрәттә торып калды. Минем янга киңәш сорап килде. Егетнең тәмам сөмсере коелган, күзләре тулы кайгы иде.

—Ниләр генә эшлим икән соң, абый. Кәримулла абзый анда пычагын кайрый ... Мин бит Лачынның бу дөньяда булмасын күз алдыма да китерә алмыйм. Мин аны киләсе елга район Сабантуена ярышка алып барасы идем. Безнең беренчелекне алуыбыз да бар иде бит. Ниләр генә итеп карыйм икән?—диде ул өзгәләнеп.

—Әллә болай эшлибезме, Рөстәм? Ул тайны Кәримулла карттан сатып аласыңмы? Үз абзарыңа кертеп куярга. Акча житмәсә менә без, Сания апаең белән биреп торырбыз. Сорап кара әле,—дидем мин.

Минем бу киңәшкә егет бик куанды.

—Акчам бар минем. Үземә сатып алам мин Лачынны. Кыйбат сораса да алам!—диде ул һәм бездән иңнәренә канатлар үсеп кайтып китте.

Тик болай да эш барып чыкмады шул. Бирмәгән тар күнелле карт егеткә атны. Тегесе ике бәясен әйтеп караса да.

—Ник чат ябыштың әле шул тайга? Ат заманымы хәзер. Алай акчаң күп икән, әнә машина ал да йөре. Башыңда гакылың булса... Миндә сатар мал юк. Йөрмә монда!—дип егетне тиргәп чыгарган.

Мин уйлыйм ки, бу карт ике бәясенә атны бик бирер иде. Авыл халкы үзен ничек хөкем итәсеннән курыккан ул.

Ул арада көзләр, мал суяр вакытлар якынлашты. Рөстәмнең, әле кайчан гына гел елмаеп, күзләре очкынланып торган егетнең йөзенә кара коелды, ул беркем белән сөйләшмәс булды. Ә Кәримулла абзыйлар йортын урамның теге ягыннан әйләнеп үтте. Ул тайны сорап карт янына тагын берничә тапкырлар барган, тик һаман саен отказ алган.

Шунда, инде көннәр суытып кырпак та төшкәч авылда тагын хәбәр китте. Моңарчы безнең авыл тарихында ишетелмәгән яман хәбәр. Кәримулла

абзыйның атын урлаганнар! Чын ат каракларынча, төнлә белән, абзарның тимер биген игәү белән кисеп, атның тоякларына нидер кидереп. Абзардан чыгып киткән атның эзе дә калмаган... Бөтен авыл купты бу хәлгә. Кәримулла карт шунда ук районга җәвит итте, милиция килде. Китте сорашулар, гоман кылулар.

—Мари урманнары ягыннан килгән болар. Урманнар—әнә генә. Оста караклар эш иткән монда,—диде милиция кешесе бик белдекле төстә.

Тик тиз арада ат карагының кем икәнен дә чамалап булды. Кәримулла картның йорты янына җыелган халык арасыннан бухгалтер Гаязның тавышы ишетелде.

—Ә Рөстәм кайда әле безнең? Бүген иртән эшенә дә менмәде, монда да юк икән,—диде ул гаҗәпләнеп.

Җыйнаулашып Рөстәмнең йортына килделәр. Ә аның йортына зур йозак эленеп тора иде.

—Шул бәдбәхетнең генә эше бу! Атымны урлап качкан. Ташландык. Юньле булса аны әнисе калдырып китмәс иде. Карт белән карчыкны талап китмәсә, беткәндер ана...—дип тиргәнде Кәримулла абзый.

Тик аның ягына чыгып беркем бер сүз әйтмәде.

Кәримулла карт инде ул тиргәнеп кенә дә калмады, артыннан йөрде. Акчалар түкте, күрәзәчеләргә кадәр барды, атын эзләтте. Тик ат та, егет тә, Ашытның тирән тугаена төшеп киткәндәй, юкка чыктылар. Авыл халкы исә төрлесен сөйләде. Кайберәүләр, чынлап та, егет белән ат Ашытның галәмәт тә тирән яшелчә тугаена, чоңгылга кереп батканнардыр дип тә гоман кылдылар. Мин исә Рөстәмнең тиз арада әйләнеп кайтасына өметләндем. Кангырып йөрер-йөрер дә, көннәрдән бер көн Лачынын ияртеп кайтып та керер дип көттем. Шул атны Кәримулла пычагыннан коткару өчен генә авылны, яраткан эшен, сөйгән кызын, туган нигезен дә калдырып каядыр ерак җирләрдә торып каласы, ничектер, минем дә башыма сыймады.

***

Айлар үтте, ел да үтеп китте. Төрле мәшәкатьләр белән, сиздерми генә. Ә егетебез тәки күренмәде, тәмам юкка чыкты. Ул арада аның йөргән кызы Алсу да авылда күренми башлады. Акрынлап авыл халкы хәтерендә бу вакыйга тоныкланды, ул күңелгә бүтән вакыйгалар килеп керде.

Бервакыт мин бер республика газетасында рәсем күрдем. Кайсыдыр район сабантуенда чабышта алдан килгән ат һәм аның җайдагы рәсемен. Атның маңгаенда миңа таныш ак йолдызы бар, ә җайдагы исә Рөстәм иде!



Шамил
Анак
(1928—2007)

# КӨЗГЕ САРЫ ЯФРАКЛАР

МЕДИТАЦИЯЛӘР

## I

***

**Көзге сары яфраклар талгын гына чайкалып**
**суынып барган җир өстенә килеп төшәләр**
**һәм гүяки тын гына көрсенеп куялар...**
**Җирдән китәр вакытым җиткәнне табигать**
**миңа әнә шулай хәбәр итә сыман.**

***

**Әй моңлы сары яфраклар! Соңгы көземнең**
**хатирәсе булып җырларымда калса иде**
**тын сагышлы моңыгыз!**

***

**Иртәләрен гүя кемдер күзгә күренмәгән**
**гаҗәеп инструментның кылларын чиртә**
**һәм дөнья илаһи бер моңга күмелә...**
**Шулай чыңлый миндә яшәү музыкасы.**

***

**Дөнья үзенең бөек өнсезлегендә моңарчы**
**ишетелмәгән гаҗәеп җырларны саклый.**

***

**Йөзъяшәр агачлар шомлы шаулаган бу көзге**
**кичтә мин табигатьнең тиңсез кодрәте**
**турында уйлыйм һәм хәйран калам.**

***

**Без инде бик ерак киттек тәүкараңгылыктан**
**һәм үзебезнең балчык-яратылыштан.**

***

Бу моңсу сары көздә кайчандыр мин сөйгән
йәә мине сөйгән хатын-кызлар төшемә керә:
йөзләрендә өнсез үпкә.
Әнә шулай үкенечле һәм сагышлы сөюләрем
искә төшеп газаплый мине.

***

Тынып калган кичке җир өстенә сиздермичә
эңгер төшкән сыман, инде минем җаныма
көзге тынлык иңә башлады.

***

Зәңгәр эңгер сарган бу моңсу көзге кич—
бер кая да илтмәгән юлдан ялгыз гына
атлаган тол хатынга охшый.
Мин аның авыр адымнарын ишетәм кебек.

***

Әй көзге урман буйларының ялгыз күкесе:
кайсыбызның икән сагыш көчлерәк?

***

Яшәү—өзлексез бер могҗиза. Бу могҗизага
безнең, кагылыш та бар.
Һәм без моңа өзлексез таң калабыз.

***

Көңеле белән кеше гомер буе бала булып кала:
сораулар бирә һәм гаҗәпләнә.

***

Яшәү сере алдында шаулы туй корабыз,
үлем сере алдында каушап тын торабыз.

***

Хәтерли микән калдырып киткән ярларын—
ашыгып аккан елга сулары?

***

Ишетмәгән, күрмәгән һәм уйлый белмәгән
җансыз күләгә генә безнең тугры юлдаш,
безнең белән янәшә атлый гомер буе.

***

Ярый әле, өнсез, тын яткан авыр ташлар
кешеләр арасында үч-кинә барын белми!

***

Кешенең идеалы ни кадәрле югары булса,
шул кадәрле ярсыбрак чәңгелдиләр
капка астыннан көнчел көчекләр.

***

Уйнар сазымның ике кылы шартлап өзелде,
калган бердәнбер кылы сагыш көйләрен
генә көйли.

***

Йөрәгем, сөюеңне беркемнән дә яшермә,
ул бит бөтен галәм өчен!

***

Яшәү быргыларының тантаналы авазларына
бирелеп, без үлем чаңнарының дәһшәтле
чыңлавына колак салмыйбыз.

***

Җирдә Ана гына Алланың бөек вазифасын
үз өстенә алган—кеше тудыра.

***

Изге китабыбыз Коръән Кәримдә әйтелгәнчә,
Оҗмах аналарның аяк астында ята.

***

Күпме генә тапталса да, түбәндә, безнең
табаннар астында кимсетелеп ятса да,—
Җир ул барыбер бөек!

***

Юлчы, тукта, кара: могҗиза түгелмени
табаннарың астында җәелеп яткан
гади бу үлән?

***

Мәңгелекнең, бөеклеге алдында бу дөньяның,
ыгы-зыгылары тузан бөртеге кебек кенә.
Мең еллар тәҗрибәсе шуны сөйли.

II

***

Вакыт сулары белән агып киткән гасырлар,
бөек төрки дәүләтләр, мәшһүр каганнар,
данлы яубәкләренең тарихта күрелмәгән
тиңсез батырлыклары турында уйлыйм да
ачынам: без барысын да онытканбыз!

***

Үткәннәрнең үз сүзләре булган, бүгенге
көннең дә үз сүзләре бар.
Мин исә киләчәкнең сүзләрен эзлим.

***

Дөньяга башлангыч биргән илаһи тәү сүз
хәзер дөнья белән сату итүчеләр базарында
вак акча урынына йөри!

***

Һәр хакимият җимерелмәс ныгытмалар төзи
Һәм иң элек—үз халкына каршы...

***

Күрдек: тиран меңнәрчә җаннарны кыя да,
шул ук санда үзенә һәйкәл куйдыра.

***

Җиңелгән золым үлә, ә җиңелгән яхшылык
чигенә генә.

***

Иң яхшы хакимият—балалар күз яшеннән
башка берниндидә яшь түгелмәгән
хакимият.

***

Кем яшь түгә, ә кем төкерә янгын көленә!

***

Хәтта күк патшасы алла улын да, башына
тигәнәк таҗ кидереп, хачка мендерәләр!

***

Онытылган ялгыз юл өстендә тынлык кошы
канат җәйгән.

***

Кеше, чү, шаулама, сине агачлар, үләннәр
тыңлап тора!

***

Әй сагышлы хатын! Сагышыңны алтын йөзек
итеп, бармагыңа ки—
син ялгызлык белән никахка кердең бүген!

***

Кичләрен чал дала бик борынгы бер телдә
онытылган дастаннарның юлларын көйли,
тик без бу телне аңламыйбыз инде.

***

Үлем түшәгендә ятканнар белән балалар гына
дөреслекне әйтергә курыкмый.

***

Ярсу вакыт агымы берчә болганчык, кара,
берчә кан-кызыл.
Бу төсләргә аны безнең гамәлләр буйый.

***

Туган туганга каршы корал күтәргән чакта
ике як та җиңелә.

***

Бүген төнлә, тулган ай калыккач, агачлар
көчле шаулады һәм дөньяның олы йөрәге
шом белән типте.
Нинди бәла килерен сизде икән табигать?

***

Мин үземдә бихисап олы дөньяларны йөртәм—
бер-берсенә охшаган һәм охшамаган,
яшәгән һәм һәлак булган дөньяларны.

***

Җирдә вакытлы кунаклар, без ни эшлибез
табигатьнең изге храмында—
дога кылабызмы, нәҗеслек эшлибезме?

***

Томан—иртәнге җирнең ефәк туй чыбылдыгы,
аның ышыгында җир яшь кәләш шикелле
сөйгәне кояшны каршыларга әзерләнә.

***

Бу төн—ал тәхеттә утырган борынгы Мисыр
патшабикәсенә охшый: түшендә йолдызлар сәйләне,
маңгаенда тулган ай түгәрәге.

***

Агачлардан сары яфраклар коела тын гына.
Алар үз җырларын җырладылар инде.

*1994*

Нурихан
Фәттах

# БЕРЕНЧЕ ШИГЫРЬ КҮК БАЛАЧАК...

ИСТӘЛЕКЛӘР

## 5. Кучтәвылда, күңел күгендә

Әткәй үлгәч, безнең инәкәй ике бала белән торып калган. Икенең берсе—мин, икенчесе—Тәлгат. Миннән тазарак булса да, ничәнчедер елны Тәлгат тә әткәй артыннан китеп барган. Шуннан соң инәкәй мине күтәргән дә, туган авылы Янтыкка кайткан да киткән. Киткән чакта законлы тәртиптә бүленеп, судлашып йөрмәгән. Ярлы Садырлиманның хәерче йортында бүлешер нәрсәсе дә булмаган.

Шулай итеп, кайтып киткәнбез без Янтык—Яңа Уртавылга. Минем аңлырак балачагым тулысынча шушында узды. Туган як, бала выкыт дигәндә иң элек мин тау-ташлы, урман-сулы Янтыкны күз алдында тотам. Ләкин Кучтәвылда—минем балачак. Анда узган берничә ел җуелмаслык булып хәтергә сеңеп калган. Минем өчен Кучтәвыл бүгенгечә дә, элеккечә дә, бала чакка да, үсмер чакка да катнашы булмаган ниндидер аерым бер сихри дөнья булып тоела.

Әткәй мине бик яраткан, имеш. Нуриханым үсеп, сука башы тотарлык булса, үлсәм дә үкенмәсием дип әйтә торган булган. Инәкәй дә яраткан, башкалар да яраткан. Тик нишләптер мин аларның кул җылысын да, ягымлы күз карашларын да хәтерли алмыйм. Күңел күгендә башкачарак күренешләр, башкачарак төсләр-бизәкләр торып калган. Менә төн. Коеп янгыр ява, әледән-әле нәрсәдер дөбер-шатыр килә дә, ялт-йолт итеп яшен яшьни. Карангы өй почмакларында, идәндә голт итеп куркыныч яктылык балкып китә. Бөтен тирә-як дер селкенеп тора. Мин идәндә йомшак ястыкка чумганмын. Бер якта әткәй, бер якта инәкәй. Куркып мин кемгәдер сыенам.

Жил-давыллар, яшенле янгырлар гомумән онытылмый. Бер җәйне бик каты давылдан соң күршеләрнең юан-юан тупыллары урталай сынып төште, икенче бер күршеләрнең өй түбәләрен куптарып ташлады. Көчле янгырдан соң шунсы кызык була—дөнья тынып калу белән, йөгереп без урамга чыгабыз, бер-беребезне узышып, су чәчрәтеп яшел чирәм өстеннән йөгерәбез, канаудагы суда кимәләр, йомычкалар агызабыз.

Кояшлы көндә без елга буенда чыр-чу киләбез, йомшак туфрак өстендә чокырлар казыйбыз, юллар салабыз. Иске чабатага чирәм йолкып тутырабыз да, өйгә "печән" алып кайтабыз. Бервакытны тилгәннән калган, ләкин куркуыннан аяк сузган бер чебешне бик кадерләп һәм, әлбәттә, бик нык кызганып, кабергә күмдек. Заманына күрә уены да, уенның "сюжеты"да

*Дәвамы. Башы узган санда.*

табылган. Бит балалар күбесенчә олыларны кабатлыйлар .

Елгада су кереп туйгач, яр өстенә менеп чирәмдә уйныйбыз, төшеп калган каз каурыйларын җыябыз. Кайчагында каз каурыеннан аткый ясыйбыз, кемнеке ераграк, кемнеке биегрәк оча дип ярышабыз. Аннары каерылып үскән арыш басуы хәтердә калган. Арыш басуы уртасыннан Күник ягына арба юлы бара. Көн кичкә авышкан. Бик зур кайнар, кызгылт кояш түбәнәя башлаган. Аксыл, җинел болытлар арасыннан туп-туры булып күк читенә саргылт сызыклар сузылган. Юл буйлап без малайлар белән кояшка таба йөгерәбез. Күчтәвыл хатыннары буш бидрәләр күтәреп, иртән иртүк Буә буена карагатка китәләр. Алар анда көне буе йөриләр. Кичкә кайталар. Без шуларны каршыларга барабыз. Алар арасында, билгеле, инәкәй дә бар. Ул булмаса мин каты юлдан аягымны авырттырып барып та тормас идем. Кайтканда алар бидрәләрен көчкә күтәреп кайталар. Бидрәләр туп-тулы. Эре, сусыл кара карагат. Кайчагында шомырт була. Мин әле дә инәкәй алып кайткан шул бидрә тулы карагатның, шомыртның тәмен, исен тоям кебек.

Бервакыт мина куе зәңгәр төстәге гап-гади ситсыдан күлмәк, ыштан һәм кепка тегеп бирделәр. Яңа кием кисәм нишләптер минем авыз ерылырга гына тора. Сөенечемнән кая басканымны белмичә шундук урамга чыгып чаптым. Малайлар янына, мактанырга. Бигрәк тә кепка өчен сөендем бугай. Чөнки ул вакытта кепкасыман баш киеме бик сирәк кешедә була иде. Уен белән мавыгып яңгыр килгәнен сизми калганбыз. Елга буеннан өйгә кайтып җитәм дигәндә генә коеп янгыр ява башлады. Күршеләрнен өй артында басып торам. Безнең өй урам аша гына. Янгыр туктагач, җылый-җылый кайтып кердем. Ни өчен дисәң, бөтен өс пычранган, кепканың козырегы җебеп күзгә салынып төшкән. Козырекны соңыннан да беркем турайтып, тигезләп бирә алмады. Тузганчы шулай киеп йөредем бугай.

Күчтәвылдагы кышкы юлларны, чана шууларны мин бөтенләй хәтерләмим. Ләкин суыгы бик нык истә калган. Тәрәзәләргә бармак калынлыгы боз каткан булыр. Җилле көннәрдә бүрәнә ярыкларыннан, тәрәзә яныннан суык җил өрә. Мондый чакта тыштан тәрәзәгә салам чыпталар бөркәп куялар. Өй эче караңгылана һәм бераз җылынгандай була. Шулай да иң җылы урын—мич башы. Мичкә салам ягалар. Саламны көлтә итеп бәйлиләр дә өйгә кертеп тутыралар. Шуннан көне буе ягалар. Мич дөрләп янганда дөньялар ямьләнеп китә.

Саламның көле күп була. Авыл кешесе көлне йә бакча ягына, йә өй янына гына түгә. Яз көне ул кар суы белән агып китә. Мин Күчтәвылда чакта инде күмәкләшү башланган, авылда колхоз төзелгән була. Колхоз ел да көл җыя. Колхоз дигәннән, безнең әткәй үлгәнче колхозга кермәгән. "Үлсәм ярарые, күрмәсәм ярарые шул калхузны", дип теләгән. " Теләге кабул булды мәрхүмнең", диде инәкәй еш кына. Ләкин исән чагында барыбер тынгылык бирмәгәннәр, башкаларга караганда күбрәк салым салганнар, барлы-юклы малын, ашлыгын алып чыкканнар. Бер елны яна урган бөтен ашлыкны Янавылга илтеп тапшшырганнар—"чәчүлеккә дә калмады" дип сөйләде инәкәй әрнеп. Шуннан соң әткәйне колхозга керергә мәҗбүр итмәкче булып ишегалдындагы келәтне сүтеп алып чыкканнар. Сүтеп алганнар да, елга буена утыртып куйганнар. Тәбәнәк кенә, бәләкәй генә ул келәтнең яр буенда монаеп утыруын мин әле дә хәтерлим. Безнең шул ялгыз келәткә колхоз бер кышны көл җыйдыра. Ләкин күп тә үтми, келәт янып китә. Бу хәл төнлә була. Соңыннан берәрсе ут төрткәндер дигән сүз дә булган бугай. Ләкин агач иданле агач келәткә көл тутыргач, ул ут төртмәсән дә янарга тиеш булгандыр. Ул чакта бөтен авыл салам яга. Салам көле тиз сүнми. Төне

буе балкып янды безнең келәт. Беркем ут сүндерергә бармады. Безнекеләр бары тәрәзәгә капланып догаларын укыдылар да, туктаусыз сукрандылар. “Аллага шөкер, игелеген күрмәделәр”, диде әнкәй сөенеп.

### 6. Мәктәп

Күчтәвылда башлангыч мәктәп бар иде. Мәктәп ниндидер зур гына йортка урнашкан. Беренчедән дүртенчегә кадәр булган балалар бер бүлмәдә утыралар. Аларны бер үк укытучы укыта. Минем үги апалар—Фәүзия белән Нәкыйбә көн дә шунда укырга баралар. Фәүзияне мин түтәй димен, Нәкыйбәне чибәрттәй димен. Көндәме, көн аралашмы безгә “Коммунар” дигән газета килә. Түтәй белән Чибәрттәй укудан кайталар да, төрле аңлашылмаган ят сүзләр сөйлиләр, ижекләп газета укыйлар. Бер көнне болар мине дә үзләре белән ияртеп алып киттеләр. Башта мин шунда алар янында партада утырып тордым. Аннан соң, тәнәфес вакытында, ахрысы, укытучы апа мине үз бүлмәсенә алып керде. Укытучының торган бүлмәсе шул ук мәктәп йортында иде бугай.

Алып керде дә бу өенә, чәй эчәргә утыртты. Зур итеп бер телем ипи кисеп бирде, сөтсез генә кайнар чәй ясады. Укытучы апа кисеп биргән зур телем, тәлинкәдәге кайнар чәй әле дә минем күз алдында тора. Беренче дәресем минем шул булды.

Мәктәптән кайткач, түтәй белән чибәрттәй “Коммунар” уку белән генә шөгыльләнмиләр иде. Алар тагын китап та кычкырып укыйлар, ап-ак дәфтәр битенә нәрсәдер язалар, рәсемнәр ясыйлар. Мин, күрәсең, бик кызыкканмын боларга. Әткәйнең тәрәзә башындагы яшерен бер ярыкка кыстырып куя торган нечкә генә “химический” карандашы бар иде. Ул аны миннән, түтәйләрдән яшереп тоткандыр инде. Аның карандашны кая куйганын карап торганмын да, ничектер итеп алганмын мин моны. Кәгазьне каян тапканмындыр—ансы онытылган. Тәрәзә төбенә капланып рәсем ясыйм. Карандаш очын телгә тидерәм дә сызгалыйм үземчә. Тәрәзәдән карый-карый үзебезнең тайны рәсемгә төшерәм.

Мин инде беркем күрми дип уйлаганмындыр. Ләкин бер заман якында гына, колак төбендә генә олыларның чыш-пыш килүен, көлешүен ишетеп алдым. Куркып артыма борылып карасам, ни күрим, барысы да җыелышып мине күзәтеп торалар. Мин кып-кызыл булдым. Карандашны шундук артыма яшердем. Ләкин олыларның карандашта эшләре юк—мин ясаган рәсемгә карыйлар да көләләр, карыйлар да көләләр. Аларның ник көлгәнен мин соңыннан гына төшендем кебек. Үзебезнең яшь айгырны ничек бар, шул килеш күчереп ясаганмын икән, ягъни гадәттә рәсемгә төшерелми торган әгъзаларын да төшергәнмен икән.

Ул чакта мин социалистик реализм методын тиешенчә үзләштермәгән булганмын, күрәсең. Әгъзасыз, башсыз, йөрәксез итеп тасвирларга, булмаганны булды дип, булганны булмады дип исбатларга без үсеп житкәч кенә өйрәндек.

### 7. Килә–китә

Безнең инәкәй никадәр юаш һәм тешсез булмасын, илдәге үзгәрешләр аңа да тәэсир итми калмаган, билгеле. Аның кыерсытылып яшәве турында авыл советында белеп алганнар. Кемдер аңа аерылырга киңәш иткән. Аннан соң бу вакытта Янтыктан туганнары килеп, аның бик кыен хәлдә яшәвен күргәннәр. Алар да аны аерылып кайтырга өндәгәннәр, ахрысы. Шулай тамыза торгач, котырта торгач, бер елны бу мине алып үзенең

Янтыгына кайтып киткән. "Түзә алмыйча" кайтып китүе аның әле тагын бер-ике мәртәбә булган. Берничә көннән соң әткәй безне барып ала торган булган.

Күчтәвылдан Янтыкка турыдан егерме чакрым чамасы. "Турыдан" дигәне аның Янавылга сугылмыйча дигән сүз. Янавыл—район үзәге. Барлык юллар Янавылда кисешә. Бүә аръягы авылларына барганда, урау булса да турыдан түгел, Янавыл аша йөриләр. Турыдагы юл аулаграк та, ятрак та. Монда Бүә буе болыннары, әрәмәләр аша үтәсең, Бүәне кичәсең дә, икенче якка аяк басасың. Бүәне Иске Уртавыл тегермәне турысыннан чыксаң, юл тагын да турая төшә. Ләкин монда кара урман чыгасы, Очлы тау янынннан үтәсе була. Урманда әле аның качкысы да булырга мөмкин. Элек безне гел шул "качкы" белән куркыталар иде. Гражданнар сугышы вакытында Бүә буе урманнарында тагын "дизәртирләр" булган дип тә сөйлиләр иде.

Бервакыт инәкәй җәй көне Янтыкка кайтып киткән. Иске Уртавыл тегермәне турысында Бүәне чыккан да, икенче якта ял итәргә туктаган. "Яр буена, ташлыкка сине утыртып куйдым, чүпрәкләренне юып кибәргә элдем. Көн ямьле, кояш. Кошлар сайрый..."

Шулай яшь чакларын исенә төшерде дә, күз яшьләрен сөртеп алды. Мин шундук барысын да күз алдына китердем. Сихри таллар, җинелчә генә пышылдап-чылтырап аккан көмештәй саф су. Таллыктагы кошлар чыр-чуы. Болар бит минем мәңгелек сердәшләрем. Сагышланып күз яшьләрен сөрткән чакта, бәлки, инәкәй дә шуларны ук күз алдына китергәндер?

Икенче бер вакытны яз көне ул туган авылына ат җигеп барган. Монысында кунакка гына кайткан, ахрысы. Юл өзеге алдыннан кире Күчтәвылга кайтырга чыккан. Әлеге дә баягы тагын без икәү генә булганбыз. Иске Уртавылга җитәрәк, шундагы бер кечерәк елга аша чыгарга кирәк булган. Чанага мине төреп салган да, йоклаткан да атны алдан җибәргән. Үзе арттан атлап бара икән. Көн матур булган. Язгы кояшта хозурланып бара торгач, бу онытылып киткән, арткарак калган.

Бер заман ат елга ярына килеп җиткән дә, туктап калган. Нәрсә булды икән дип ашыгыбрак килсә, елгада су күтәрелгән ди, шаулап ташу агып ята ди. Ат аны-моны уйлап тормыйча аккан елга аша чыгып китсә, чанага су кереп, чанадагы "мин" агып китәсе булганмын икән ди. Инәкәй үзләренең җирән аты турында сөйләгәндә, гел аны "акыллы" дип, "әдәм акылы бар" дип мактый торган иде. Атның яр кырыенда туктап калуын да ул аның "акыллы" булуы белән аңлатты. "Атның башыннан сөя-сөя, рәхмәт әйтә-әйтә жыладым", диде.

Безнең ат кына акыллы булды микән, атлар гомумән акыллы булалар микән. Шулай да атның акыллылыгы аркасында менә тагын берничә мәртәбә үлемнән исән калырга туры килде. Икенче мәртәбәсе Янтыкта булды. Җәйге эсседә, тырмадан кайтканда, малайлар белән узышып барганда аттан егылып төшеп калдым. Тузан туздырып, дөп-дөп басып минем өстән күпмедер ат узып китте. Шуларның берсе-бер, ялгыш кына да тоягын тидермәде.

Инәкәйнең Күчтәвыл белән Янтык арасында йөргән чакларыннан тагын шул истә калган. Җир өсте ап-ак кар. Бүрәнәләрендә иске обой кәгазьләре торып калган тәбәнәк өйдән туп-турыга—ниндидер абзарлар ягына тирән сукмак сузылган. Минем аякта яңа гына баскан кара киез итек. Сукмактан бик авырлык белән генә атлап мин абзарлар ягына барам. Ишекне ачу белән, каршыда бик зур ак сарык басып тора. Бер-беребезгә караганбыз да, торабыз шаккатып. Шул чакны сарык алгы аягының берсен күтәрде дә, шап итеп тибеп алды.

Инәкәйнең апасы Вазифа бер кышны колхоз фермасында сарык караучы булып эшләгән. Алар, Вәрәш очындагы үз өйләрен калдырып, Буә очындагы фермага күченеп килгән булганнар. Кышны шунда кышлаганнар. Ул чактагы "Очкын" колхозының сарык фермасы авылдан бер чакрым чамасы читкә, Буәгә якынрак бер җиргә урнашкан була. Каршыда гына бик биек булып таулар калкып утыра, тагын да арырак—Буә буенда кара урман белән капланган Очлы тау зәңгәрләнеп күренә. Монда—бөтенләй икенче дөнья, серле, монсу һәм гүзәл дөнья. Иң якын сердәшләремнән берсе Буә һәм Буә болыннары булса, икенчесе Очлы тау, Сакат тавы һәм бал кортлары гүләп торган юкә урманнары булды. Күчтәвылның тәбәнәк тавы белән, балчык ярлы елгасы, каз үләне үскән "болыны" белән чагыштырганда, бу яклар үзе бер әкият.

Әткәй чирләп урынга яткач, авыру кешене борчымасын диптер инде, мине Янтыкка кайтарып куйдылар. Бу вакытта мин нидер сизендем, ахрысы. Минем хәзер гел үземнең авылга—"хәерче" Күчтәвылга, әткәй, инәкәйләр янына кайтасым килә.

Әле дә хәтерлим, кыш көне иде. Тышта буран котыра. Инәкәйнең түтәсе Вазифа, ягъни "яшәби" ул көнне кызу итеп мичкә якты, кунак ашы—орлык бөкәсе пешерде. Бер дә кирәкмәгәнгә ягымлы сүзләр әйтә, кыстый- кыстый бөкә ашата. Шул чакны безнең капка турысына ниндидер атлы кеше килеп туктады. Яшәби тәрәзәдән карап алды да, кунакны каршыларга чыгып китте. Нишләптер алар бик озак керми тордылар. Мин аларның чоланда пышылдап дәшкәннәрен ишетеп калдым.

Күчтәвылдан Сафа дигән кеше килгән: мине алырга җибәргәннәр. Әткәйнең хәле начар икән. Мин инде күптән шомланып, борчылып утыра идем. Үзем дә сизмәстән кинәт кычкырып еларга тотындым. Беренче мәртәбә башка кайгы килде.

Без Күчтәвылга кайтып кергәндә буран тынды. Урамда, безнең капка төбендә ниндидер кешеләр күренә. Минем дус малайлар—Заһир, Назиф, тагын кемнәрдер миңа читтән генә карап калдылар. Алар миңа никтер кызганып карыйлар сыман. Олылар да мине никтер кызганалар, юату сүзләре әйтәләр. Өйдә аяк басар урын юк—барысы да чит кешеләр, олы кешеләр. Әкрен генә сөйләшәләр, күз яшьләрен сөртәләр. Кайберсе чынчынлап җылый. Түр сәкедә—калку урында ... минем әткәй сузылып ята. Хәрәкәтсез, тынсыз, нурсыз. Мин тыела алмыйча кычкырып җыларга тотынам. Кемдер мине тотып ала, юата. Мин тыпырчынам, әткәй янына бармакчы булам. Шул чакны кемдер минем учка ялтырап торган бик зур биш тиенлек бакыр китереп салды. Биш тиенне мин чытырдатып учыма йомдым. Мондый биш тиенне минем тотып карау түгел, якыннан күргәнем дә юк. Кинәт тынычланып, юашланып калдым. Ул арада олылар мәетне баш очларына күтәреп, сүзсез генә өйдән алып чыгып киттеләр.

Биш тиенгә алданып мин, билгеле, дөрес эшләмәгәнмен. Ләкин алданмаган очракта да нәрсә генә эшли алыр идем икән мин ул чагында? Алты-жиде яшьлек сабыйларны гына түгел, аннан ислерәк, акыллырак абзыйларны да бу дөньяда өч тиенлек, биш тиенлек бакыр белән алдыйлар түгелме соң?

## 8. Күчтәвыллар

Туган авылымда мин бик аз яшәп калганын. Сабый чакның истәлекләре дә сабыйларча, өзек-өзек. Әлләни ис китәрлек вакыйгалар да юк. Шулай да әйләнәм-тулганам да мин Күчтәвылны искә төшерәм. Иң күңелле, иң бай

һәм мәгънәле тормыш шунда—өч-дүрт яшьлек, биш-алты яшьлек чакларда булгандыр сыман тоела. Бәлки соныннан минем тарих белән кызыксынуым да Кучтәвылдагы истәлекләрдән аерыла алмавыма кайтып каладыр?

Менә җәйге иртә. Мин битемдә кояш җылысын тоеп уянып китәм. Тышта, тәрәзә башында моңлы итеп, оетып күгәрченнәр гөрли. Чормада, кыек астында аларның оясы бар. Күгәрченне бездә изге саныйлар, күгәрчен гөрләсә сөенәләр. Кайчагында тәрәзә башында чәукәләр чәрелдәшә. Чәукәне бик үк яратмыйлар. Кәрниз тактасы арасында аларның да оясы бар. Без малайлар белән аларның оясыннан күкәйләрен алабыз кайчакта. Олылар күрсә, ачуланалар, кош оясын туздырырга ярамый, үз оян тузар, диләр. Аларның сүзе дөрескә чыкты. Кучтавылдагы оя да, Янтыктагы оя да туздьı. Безнең генә түгел, бөтен илнең, бөтен халыкның оясы туздьı. Барлык тузулар, пыран-заран килүләр безнең чәукә ояларын туздырудан башланганын белгән булсам, курка-курка менеп йөргән булыр идемме соң мин ул тузанлы чормаларга?

Хәер, анда үзе бер дөнья. Иске-москы арасында ниндидер чатыр дигән нәрсә бар. Тимер таягыннан тотып, кечкенә бәжрасын өскә шудырсаң, чатыр кинәя, кабара, бәжраны аска төшерсән—җыела. Хәзер моны зонтик диләр. Каян безнең өй түбәсенә килеп менгәндер ул "чатыр", берни әйтә алмыйм.

Иртән торып тамагыңны туйдыру белән, тизрәк урамга чыгып китәсең, күршеләргә керәсең. Кайчагында кереп булмый—капка бикле була. Дус малаеннның чыкканын көтеп урамда йөреп торасың яисә капка астыннан шуышасың. Күршедә генә безнең мичче Галләм бабай йорты. Беркайчан капкалары бикле булмас. Ике арадагы киртә аша да керергә була. Өй тулы бала-чага. Күбесе малайлар. Кайчагында аны мич чыгарырга чакыралар. Кызык итеп без гел аның тирәсендә буталабыз.

Тимергали абыйлар очында, елга буенда Фатих бабайларның өе. Кайсыдыр ягыннан Фатих бабайлар безгә туган, ахрысы. Аларның да малае бар. Мин аларга да барып чыгам. Кыска кара сакал-мыеклы, озын, чандыр Фатих бабай еш кына сәгать төзәтә. Мин аның янына ук барырга да куркам, сихерләнгән кебек ишек төбендә аның ягына карап утырам да утырам. Ул ниндидер бармак башыдай чүкечләр белән шакы-шокы килеп, безләр, эскәкләр белән, сырлы тәгәрмәчләр, шөрепләр белән булаша.. Сәгатьне борып юри күкесен кычкыртса, синең өчен бөтен бер бәйрәм була. Көне буе шуны уйлап, исең китеп, хыялланып йөрисең. Ничек кычкыра икән дә, кем кычкыра икән ул сәгать эчендә? Аннан соң, бит әле ул "йөри". Ничек "йөри" ул. Һич шуна баш житми.

Якында гына, урам аша, безгә чапырыш, Хәсинә апалар өе. Алар укымышлы абыстай затлары. Аларда һәрвакыт чиста, якты. Идәннәре ап-ак итеп юылган булыр. Алар да кайсыдыр яктан безгә туганнар бугай. Аларның малайлары юк. Шулай да мин аларга керергә бик яратам. Кайчан кермә, Хәсинә апа китап күчерә. Ләкин ул башкалар кебек дәфтәргә язмый. Ап-ак кәгазь кисәкләрен бер-берсенә ябыштырып терки дә, шуннан бик озын тасма барлыкка килә. Ярты дәфтәр киңлектәге тасманы ул гармунсымак итеп җыйган, шуларга җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр, догалар, тагын әллә нәрсәләр теркәп яза. Зур үскәч мин шуны белдем: борынгы Мисырда да нәкъ шундый тасмаларга язганнар "китап"ларны.

Тагын шул. Кышларын бездә туктаусыз җеп җегерлиләр, җеп маналар, киндер сугалар. Мин юри генә, кызык итеп кенә йә коры калтырчаны әйләндерергә тотынам, әвәрнә канатларын этеп җибәрәм. Билгеле, олылар күрмәгәндә. Яисә, исем китеп, инәкәйнең шакы-шокы киндер сукканын

карап торам. Сәгатьнең ничек йөргәнен аңлый алмаган кебек, мин шул кадәр күп жепләрнең буталмыйча, чуалмыйча, киндергә әйләнүен аңлый алмый азапланам. Дөресен әйткәндә, киндер сугу турында махсус мәкаләләр укысам да, әле дә мин киндер ыстанының эшләү принцибын төгәл итеп күз алдына китерә алмыйм. Бик кечкенә чактагы гаҗәпләнү һәм... ансызлык әле булса күңелдән чыгып бетмәгән, ахрысы.

Әткәй минем сука башы тотарлык булуым турында хыялланса да, Күчтәвылда мин иген эшенә кагылышлы берни хәтерли алмыйм. Күчтәвыл халкы гомер-гомергә игенчелек белән бергә вак-төяк кәсеп һәм аз-маз һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Менә шундый кешеләр, күрәсең, миңа күбрәк тәэсир иткәндер.

Күчтәвылның мәчитенә каршы гына, почмакта бер урам икенчесенә килеп төкәшкән җирдә гаҗәеп бер серле йорт бар иде. Йорт хуҗасы—балта остасы, агач остасы. Исеме Хатмулла, ахрысы. Өй кыегына ул малайларның күзен кыздырып, хикмәтле җил тегермәне ясап куйган. Җил тегермәненең канаты зур—бер метр чамасы булыр. Әз генә җил чыгып, канат әйләнә башладымы, канат үзәге беркетелгән озын агач кисәгенең уртасында ике тимерче алмаш-тилмәш чүкеч суга башлыйлар. Тимерчеләрне дә, аларның кулына беркетелгән чүкечне дә Хатмулла агачтан кырып-юнып ясаган. Ерактан караганда алар шундый чын булып күренәләр—аларның шулай чүкеч сукканын күрдеңме, һич аерыла алмыйча карап торасың да торасың.

Карап тору бер нәрсә,—үзеңнең дә шундый ук җил тегермәне ясыйсың, бөтен авыл малайларының исен китәрсең килә башлый. Күчтәвылда чагында мин шундый алмаш-тилмәш чүкеч сугучы кешеләре булган җил тегермәне ясый алмадым, әлбәттә—анысы хыял гына булып калды. Әммә Күчтәвылда чакта ук чүкеч сугарга, мич чыгарырга инде өйрәтә башлаганнар дип әйтә алам. Көннәрдән бер көнне күрше Заһир белән бәләкәй генә кирпечләр суктык та, өй артында, такта чолан янында ук мич чыгардык. Мичкә чүп-чар, йомычка ягып җибәрдек. Мичтә дөрләп "утын" яна, морҗадан ургылып төтен чыга. Кызык! Бер заман бөтен тирә-як төтен белән тулды. Өйдән йөгерешеп кешеләр чыкты һәм... калганы билгеле инде. Утны сүндерделәр, безне тиргәделәр. Шуннан соң мин мичләрне тыштә өй янында түгел, өй эчендә генә чыгардым. Хәер, анысы олыгайгач булды. Үз кулым белән барлыгы дүрт мич чыгардым. Менә дигән тарталар.

## 9. Җегет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз

Үтмәс пычак белән юнып, булыр-булмас агачтан, булыр-булмас калак белән, тимер чыбык белән төрле нәрсә ясауга булган омтылышны миндә беркем дә сүндерә алмады дип әйтсәм, мактану булып тоелмас дип уйлыйм. Бала вакытта пәке, пычак белән, кадак белән кискән, тишкән, уеп алган эзләр-җөйләр кулда әле дә саклана. Янтыкта чагында, мәктәптә укыганда, юкагачтан юнып самолет кыяфәтле җил тегермәне ясадым да, капка баганасына беркетеп куйдым. Җил вакытында бик матур келтердәп утырды ул. Безнең оч малайлары да, күрше Вәрәштән безгә укырга килеп йөрүче малайлар да ярыйсы ук кызыктылар аңа. Аннан соң кәтүккә резин урап, "үзе йөри" торган трактор ясадым. Монысына инде малайларның чын-чынлап исләре китте.

Борчак белән ата торган наганнарны, мылтыкларны, ук-җәяне, һәртөрле очыргыч-аткыйларны, шомакай көпшә ярдәмендә су сиптергечләрне, су тегермәннәрен—һәммәсен-һәммәсен без үзебез эшләдек. Уенчык

чаналар, чын "бәләкәй чаналар", табанына кисәү агачы йә булмаса тимер чыбык куелган тимераяклар, күтәрмәләр ясау—берсе дә калмады. Елга буйларыннан яшь тал чыбыгы алып кайтып, кыш көннәрендә каз оясы, тавык оясы ясауларны инде әйтеп тә торасы юк. Яисә итек ямау, чабата ясау, бау ишү шулай ук безнең өстә булды. Юкә агачын урманнан үзебез барып кистек, көч-хәл белән өстерәп алып кайттык, курасын төшердек, шелесен суйдык. Барысын да үзебез. Еш кына чабатаны базарга илтеп сату да безнең җилкәгә төште.

Монда мин беренче заттан күплеккә күчтем. "Без"дә миннән башка тагын кемнәр булуын әлегә ачыклап тормыйк. Хәзергә "мин" турында гына сөйләшик. Хәер, чабата, ачлык, хәерчелек, мохтаҗлык турында минем язасым да килми. Без аннан гарык. Хәтта истәлектә дә аның бернинди кызыгы юк.

Сугыш елларының берсендә, фашистларны тизрәк җинәргә теләп мин яңа төр автомат уйлап таптым. Бу автомат дары белән түгел, бензин белән атарга тиеш иде. Бу мина бик мөмкин нәрсә булып тоелды. Мин көн-төн уйлана башладым, схемасын сыздым һәм ачышымны Мәскәүгә, "Пионерская правда"га җибәрдем. Җавап-мазар килде микән—хәтерләмим. Бензин белән эшли торган бу автомат кәгазьдә генә калды. Бензин белән эшли торган икенче "автоматны" мин чын мәгънәсендә эшләп, практикада кулланып карадым. Монысы инде сакаллы сабый чагымда булды. 60нчы елларда Казанда, Киров районындагы иске агач йортта торганда өй җылыту системасын, дөресрәге, җылыту казанын бензинга көйләү белән саташа башладым. Үзем "уйлап тапкан" форсунканы тимерчеләрдән эшләтеп алдым да, кирәкле баклар, көпшәләр, басым аппараты җыйдым да, "автомат "ны мичкә куеп, сынап карамакчы булдым һәм... бензин шартлап, чак-чак кына миче-ние белән күккә очмый калдык.

Мондый уйлап табулар-сынап караулар малай чакта аз булмады. Яңавылда сигезенчедәме-тугызынчыдамы укыганда, физикадан пар машинасы темасын үткәч, тоттым да зур гына кансир савытыннан пар машинасы ясый башладым. Физика-математика укытучысы Гали абый, булмастай эш белән җенләнеп йөргәнне күрде дә, ничектер җинелчә генә көлеп куйды. Бары шуннан соң гына сүрелеп калгандай булдым. Матур хыял, шулай итеп, тормышка аша алмады.

Ләкин уйлап табу эшендә һәрвакыт уңышсызлыкка очрадым дисәм, дөрес булмас. Күчтәвылдан Янтыкка кайтып, яшәбиләр белән бергә тора башлагач, аяк очын киртәләп алдык та бәрәңге бакчасы ясадык. Монарчы бәрәңге бакчалары булмаган. Алар бәрәңгене басуга утырткannар. Нилектән шулай булгандыр, әйтә алмыйм. Күрәсең, ул чакта, ягъни 30нчы елларда, колхозлар яңа оешканда, шундый тенденция булгандыр. Аяк очын бакчага әйләндерүне инәкәй башлап җибәрде. Урманнан күтәреп баганалык, читәнлек агач ташыдык, киртә тоттык. Аяк очы таулы җирдә. Түбәндә, тигезлектән чишмә ага. Чишмә киртә артында калды. Яңа бакчага бәрәңге белән бергә суган, кәбестә ише нәрсәләр дә утырттык. Кәбестәгә дә, кишергә дә көн дә су сибәргә кирәк. Су якында гына булса да, читән аша чыгып йөрү кыен. Житмәсә, капка да калдырмаганбыз. Мин чишмәдән бакча эченә канау казырга кирәк дигән уйга килдем. Олылар каршы килмәде. Бакча эченә, су тулып торсын өчен, бер метр чамасы тирәнлектә кое казыдым, читәннең тышкы ягындагы канау өстен, мал төшмәсен өчен чыбык-чабык һәм кәс белән капладым. Ул җәйне без суны "Нурихан коесы"ннан алдык. Яшәбиләр, инәкәйләр, мине масайтып, әлеге коены шулай дип йөрттеләр.

Соңыннан да миңа күп нәрсәне үз кулым белән ясарга туры килде. Бигрәк тә мин балта эшен, юну, кисү эшләрен яратам. Университетны тәмамлап, яңа тормыш башлап җибәргәч, үземә пыялалап китап шкафы ясадым. Берничә елдан соң китап шкафының зуррагын да ясарга туры килде. 50—60 нчы елларда хәзергесе кебек затлы мебель магазиннарда тулып ятмый иде. Тулып ятса да, нишләптер аны бирмиләр иде.

Үз гомеремдә мин ике йорт салдым. Хәер, болай дип әйтү бик үк дөрес тә булмас. Йорт кадәр йортны бер кеше беркайчан берүзе сала алмый. Ләкин бик күп эшне һәм төрле эшне үземә башкарырга туры килде. Кирәк чагында балта белән дә, пычкы белән дә, чүкеч белән дә эшлисең, бүрәнә дә юнасың, такта да кагасың, бетон-цемент, буяу эшенә дә тотынасың.

Миннән, билгеле, чын балта остасы да, чын ташчы да, мичче дә, калайчы да чыкмады. Ләкин үзеңә кирәк булган бар нәрсәне үзең ясау, теләсә нинди эшкә йөрәгең житеп, кулың килешеп тору—үзе бер бәхет. Элегрәк, Казанның Киров районында торган чакта, мин шәһәрнең авыл урамнарында йөрергә ярата идем. Кичләрен электр яктысында барыннан да бигрәк өйләргә, коймаларга карап барам. Кайберләренә карый-карый күзләр авырта. Казанда чын мәгънәсендә сәнгатьчә итеп ясалган иске агач йортлар бар. Ләкин күп кенә авылча урамнар бүген юк—алар урынында таш йортлар калкып утыра. Кызганыч дип тә әйтәсе килми, шулай да агач өйләр миңа якынрак.

Малай чакта минем иң кызыкканым, иң көнләшкән кешеләрем балта осталары иде. Өй бураучылар, такта юнучылар эшенә сәгатьләр буе карап торганым бар. Йорты, каралты-курасы гөлдәй матур булган, чиста, пөхтә булган йорт хуҗаларына хөрмәтем чиксез зур. Минемчә, һәр гаиләнең үз йорты, үз хуҗалыгы һәм ишектән чыгу белән аяк басарлык булса да үз җире булырга тиеш. Үз йорты, үз хуҗалыгы булган кешенең вак-төяк эше һәрвакыт табылып тора һәм аның төрле гайбәткә, аракыга вакыты әзрәк кала яисә бөтенләй калмый. Аннан соң, кеше-туктаусыз үз йортын, үз ихатасын бизәргә, матурларга, яхшыртырга тиеш дип исәплим мин. Таза, матур өй кешенең үзенә генә түгел, күрше-күләмгә, урамга, тирә-якка ямь бирә.

Яшьрәк чакта мин өздереп гармун уйнау турында хыялландым—булмады. Мин әле дә композиторларга кызыгып-көнләшеп яшим. Яшьрәк чакта шулай ук мылтык асып ауга йөрү, фотограф, спортчы һәм сәяхәтче булу турында хыялланганбыз. Ләкин, ни хикмәттер, беркайчан мин паровоз йөртү, очучы-фәлән булу турында хыялланмадым. Шулай ук дингезче буласым килмәде. Төрле хыяллар як-якка таркалган саен, урындыкка һәм язу өстәленә берегә бардым, һәм бүгенге көндә классик мәгънәсендәге өй тавыгына әйләндем. Тик торасы килмәгән кешегә өйдә дә эш табыла. Ашарга пешерү, чәй кайнату, ашагач, табак-савыт юып кую кебек гадирәк эшләрне бик теләп, яратып башкарам. Минем өчен эшнең олысы-кечесе юк. Нәрсәгә тотынсам да җиренә житкереп эшләргә тырышам. Хатын еш кына әйтеп куя: “Америкада булсаң, иң оста табак-савыт юуучы булыр идең”, ди. Ул Драйзерны, Джек Лондонны күп укыган һәм, шуңа күрә, ахрысы, Америкадагы эшчеләр байларның табак-савытларын юуу белән генә шөгыльләнәләр дип исәпли сыман.

## 10. Мулла бабай

Бүгенге көндә бездә муллаларга карата кире фикер урнашкан. Мулла ул комсыз булган, надан булган, оятсыз, әдәпсез һәм ахмак булган. Иң куркынычы, иң әшәкесе шул—мулла ул динче булган, үзенең яман

нәфесләрен канәгатьләндерү өчен, төрлечә халыкны алдау һәм аның аңын томалау белән шөгыльләнгән.

Һәртөрле әдәбият, сәнгать әсәрләрендә, халык иҗатында һәм дәреслекләрдә мулланың чын йөзе менә шулайрак булып күз алдына килә.

Мин белгән чын мулла мондый муллага ошамаган иде. Ул бөтенләй аның киресе, капма-каршысы иде. Күчтәвылның иртәнге кояш нурлары белән өй кыегында гөрләүче күгәрченнәре, яшенле яңгырлары һәм каз бәбкәләре белән бергә "Мулла бабай" да минем хәтер күгендә җуелмас бер сихри тип булып сакланып калган.

Мулла буларак нинди рәк динче булгандыр ул, анысы турында берни дә әйтә алмыйм. Мин бары аның ягымлы, әдәпле һәм тыйнак кеше булуы турында гына әйтә алам. Күз алдында аның матур гына итеп кырылган кара сакал-мыеклы йөзе, һәрвакыт йомшак, ягымлы нур бөрки торган күзләре карап тора. Тавышы шулай ук ягымлы, йомшак. Аннан соң тагын шунысы хәтердә калган—сул кулының мы, уң кулының мы имән бармагы юк. Бик кечкенә чагымда мин тып-тын гына аның янындамы, тез өстендәме утырганымы хәтерлим. Аның миңа иркәләп әйткән ("бәбекәем" дигән) сүзләрен ишеткәндәй булам.

Утызынчы елларда, бөтен илдәге кебек, бәләкәй генә Күчтәвылның да асты өскә килә. Киләчәктә булачак яңа тормыш, бәхетле тормыш коручылар тазарак, хәллерәк кешеләрне чүп үләне сыман, тамырлары белән йолкып ташлыйлар. Авылның һәртөрле ялкавы, хәерчесе, ярлы-ябагае өскә калкып чыга, һәм тырышракларны "дошман" дип, "кулак" дип читкә сөрәләр. Авылдан куылучылар арасында Мулла бабай да була. Хатыны, бала-чагалары белән аны каядыр читкә (салкын якларга) озаталар.

Күпмедер елдан соң, коры таякка калып, хатынын, балаларын ияртеп Мулла бабай кире Күчтәвылга кайтып төшә. Күрәсең, ул вакытта да әле закон, тәртип дигән нәрсә бөтенләй тапталып бетмәгән булгандыр. Күрәсең, Мулла бабайның халыкка каршы, яңа хөкүмәткә каршы дошманлыкларын, явызлыкларын исбат итә алмаганнардыр. Бәлки, алар үзләренә тиешле җәза срогын тутырган булганнардыр.

Кайталар болар Күчтәвылга. Ләкин кайтсалар, өйләрен тартып алганнар, мал-туарлары шулай ук колхоз милкенә күчкән. Бу көз көне, кышка керер алдыннан була. Мулла бабайның ике малае, бер кызы була, ахрысы. Барлыгы биш-алты җан. Кайту белән болар кемгәдер урнашалар. Ләкин ул вакыттагы авыл кешесенең үзенең дә өе әлләни иркен түгел. Ярлы-ябагайның бигрәк тә. Аннан соң ул чакларда сөргеннән кайткан кешене үзендә сыендырырга атлыгып торучылар да бик булмагандыр. Мулла кешене, дошман кешене сыендырган өчен андый кешенең үзен дә бик җиңел генә куштанлыкта гаепләп, җиңел генә озатулары да мөмкин.

Бу вакытта әткәй үлгән була. Өйдә күпмедер дәрәҗәдә инәкәй баш кеше исәпләнә. Менә шунда безнең инәкәй үзенә күрә бер батырлык эшли. Бианасы "әнкәй" белән киңәшә дә, Мулла бабайларны торырга үзебезгә (үзләренә) алып кайта. Кышны Мулла бабайлар бездә үткәрәләр. Язга чыккач, болар авыл читендә, Күник очында, буш җирдә, саман кирпеч сугып, балчык өй сала башлыйлар. Мин аларның ул тәбәнәк, кысынкы балчык өйләрен әле дә хәтерлим. Күпмедер елдан соң алар балчык йорт урынына бүрәнәдән менә дигән йорт салып чыктылар. Мулла бабай өй янына җимеш бакчасы утыртты. Бакчасында берничә төп алмагач, карагат, кура җиләк куаклары бар иде. Күчтәвылга Яңавыл яктан килеп кергәндә Мулла бабайның әлеге бакчасы ерактан ук күренеп, үзенә бер

матурлык биреп тора, урам буйларында биек тупылдан, өянкедән, шомырт агачларыннан башка берни үсмәгән "хәерче" Күчтәвылда Мулла бабайның алма бакчасы иң матур урыннарның берсе булып күренә иде. Ул шул ук бакчасында берничә баш умарта да асрады.

Белгән кадәресе шул: тырыш, булдыклы һәм эшчән кеше иде ул Мулла бабай. Шуның өстәвенә ягымлы, тәртипле, киң күңелле. Яңавылда укып йөргәндә дә, Казанда укыганда да "туган як" дип Күчтәвылның хәлен белеп кайта торган идем. Кайчан гына барсам да, үземнең туган нигезне, әткәйнең бертуган сеңлесе Чибәрттәйләрне (ягъни Тимергали абыйларны) һәм, әлбәттә, Мулла бабайларны күрми китми торган идем. Барган саен Мулла бабай белән дөнья хәлләре турында сөйләшәсең. Сине алар үзләренең балы, җиләге белән сыйлыйлар, үзләренчә кунак итәләр. Мулла бабай да, өйдәге башкалар да ягымлы, кечелекле кешеләр.

Әдәм баласының төрлесе булган кебек, муллалар арасында да наданнар, комсызлар, әдәпсез-оятсыз бәндәләр булгандыр, әлбәттә. Ләкин гомумән барлык муллаларның шундый булуына мин беркайчан ышанмадым. Чөнки минем анда чын мулла, аңлы, белемле мулла образы туып өлгергән иде инде.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

### СТАЛИНГА КИЗӘНГӘН ӘКИЯТ

"Аңа кадәр дә, шуннан соң да 30нчы елларның ул фаҗигале хәлләрен болай калкытып, төгәл һәм мәгънәле итеп үз табигый сурәтендә гәүдәләндергән башка берәр әсәр әдәбиятыбызда билгеле түгел",—әкиятне эзләп табып, журналга тәкъдим иткән Мәсгут Гайнетдин әнә шулай ди. **Идрис ТУКТАР** аны Казан язучыларының 1936 елның март азагында үткән шәһәркүләм җыенында—каләм әһелләренең котын алу, күңелләренә дәһшәт сеңдерү максатында уткәрелгән җыелышта сөйли. Сөйләп кенә калмый, күрәсең, секретариат таләбе буенчадыр, текстын машинкада бастырып, беркетмәгә өсти.

Әкият болай башланып китә: "Бар иде ди, юк иде ди, өе читтә иде ди, ишеге чыпта иде ди. Борын-борын заманда, ерак түгел, монда бер патша булган ди. Ярый. Патша өчен яхшыдан-яхшы эш—кан кою, татлыдан-татлы аш—кан эчү булган. Шуның белән патша үзе дә, аның вәзирләре дә масая торган булганнар. Көннәрнең берендә патша бөтен вәзирләрен, бөтен галимнәрен, бөтен оста эшчеләрен чакырып, фәрман бирә..."

Тәфкил
Вафин

# МӘКРУҺЛАР

*XIX гасыр урталарындагы мөселманнарны көчләп чукындыру гарасаты корбаны—бабам Мөхәммәтсабит рухына багышлыйм.*

## Иман, динебез хакына

Казан ханлыгы яулангannнан соң, патша хөкүмәте җирле халыкка каршы милли-колониаль изү сәясәте үткәрә башлый. Алай гына да түгел, басып алулар-талаулар исәбенә киңәйгән Рәсәй дәүләте урыс булмаган халыкларны, шул исәптән татарларны урыслаштыру һәм милләт буларак юк итү-йоту гамәленә керешә.

Көчләп чукындыру—шовинистик һәм империячел максатның коточкыч һәм гыйбрәтле гәүдәләнеше. Татарларны христиан диненә күчерү сәясәтен гамәлгә ашырганда вәхшилекләре буенча урыс миссионерлары урта гасырларда Европада хөкем сөргән һәм яманаты чыккан инквизицияне дә уздыралар. Инквизиция судлары башлыча аерым еретикларны (динсезләрне) эзәрлекләү һәм җәзалау белән шөгыльләнсә, көчләп чукындыру эшчәнлеге бөтен бер халыкның динен һәм рухи-мәдәни мирасын юк итүгә юнәлдерелә. Аерым алганда, 1742 елда гына да 536 мәчетнең 428е яндырыла яки җимертелә. Алар арасында татарның мәркәзе алынганга кадәр үк төзелгән мәчетләр дә була. Диненә, иманына тугры мөселман бабаларыбызның каршылыгын сындырырга омтылган урыс хакимиятләре коралсыз һәм яклаучысыз халыкка каршы хәтта гаскәр кулланудан да баш тартмыйлар. Буйсынырга теләмәгәннәрне алар камчы белән суктырганнар, төрмәләргә утырткannнар, Себергә сөргәннәр һәм башка төрле җәберләү-мыскыллау алымнары кулланганнар. Казан епархиясе архиепискобы Лука Канашевич (татарлар аны Аксак Каратун дип йөрткәннәр) аеруча кансыз булган.

Ул, мәчетләрне күпләп юк итү белән генә чикләнмичә, чукындыруга каршы торучыларны, бигрәк тә муллаларны, чиркәү подвалларында ач һәм су эчертмичә тотарга боерган; аның кушуы буенча дин әһелләребезне аякларыннан асып куйганнар, кыргыйларча җәзалаганнар.

Дәүләтчелегебезнең юкка чыгу һәлакәте кебек үк, көчләп чукындыру фаҗигасе дә халкыбыз бәгъренә мәңге төзәлмәслек яра салган, хәтеренә кара кан булып утырган. Бу исә хатирәләр, риваятьләр, җырлар һәм бәетләр рәвешендә тышка бәреп чыккан. Патша хакимиятенең эзәрлекләвенә карамастан, милли һәм тарихи-сәяси темага багышланган әлеге әсәрләрнең бер өлеше хәзерге чорга килеп җиткән. Кызганычка каршы, партократия һәм урыс йогынтысы, шовинизм хөкем сөргән дәвердә хәтта дәрәҗәле фәнни-тикшеренү институтларының да аларны дөньяга чыгарырга тәвәккәллекләре җитмәде.

Башка халыклар кебек үк, татар халкының милләт буларак сакланып калырга хокукы бар. Ул шуңа омтыла да. Биш гасыр элек үк көчләп чукындыру, телдән-иманнан яздыру, XIX гасыр уртасында шул ук вәхшилекне яңадан кабатлау юлына

баскан урыс хөкүмәте һөҗүменә дучар булган татар халкы үзенең фаҗигале язмышына аек караш ташларга һәм гыйбрәт алырга тиеш.

Атаклы тарихчыбыз Ризаэддин Фәхреддин динне, иманны эзәрлекләүнең, вөҗданны мәсхәрәләүнең кайбер тетрәткеч мисалларын үзенең «Болгар вә Казан төрекләре» дигән хезмәтендә санап китә. Язмамның асылына турыдан-туры кагылышлы булганлыктан, аларга махсус тукталуны урынлы санадым. Әлеге мәгълүматлар, беркадәр кыскартып, Риза казый китабының "Дүртенче дәвер" дигән бүлекчәсеннән алынды.

"Миссионерларның хакимлек итүләре, рус хөкүмәте тарафыннан мөселманнарның чукындырылуы

Рус кавеменең уртача фикерле һәм яхшы әхлаклы, төзек табигатьле булмаганлыгы мәгълүм. Шуңа күрә һәр эшләре чиктән тыш түбән юллардан йөридер. Бу көнгә кадәр боларга шушы ике юл уртасындагы зур юлдан йөрү насыйп булмады. Моннан соң уңышлы булуы билгеләре күренми. Болар динле булсалар да чамадан тыш кыйланалар, динсез булсалар да һәрбер динсезнең өстеннән таптап китәләр.

Рус падишаһларының бу мәмләкәттә булган мөселманнарны чукындыру өчен тырышулары искитәрлек дәрәҗәдә булды. Бу маҗараны тәфсилләп язу берничә кисәктән торган китап язу белән бер. Безнең моңа көчебез җитми. Болар шушы дәрәҗәдә тырышып та, бу илдә мөселман токымы югалмавы Аллаһы тәгаләнең ярдәме булса кирәк.

Дөрес, әгәр дә русларның мөселманнарны чукындырырга тырышулары беркадәр йомшак һәм уртачарак булса иде, рус халкы бу дәрәҗәдә үрчемәс һәм күбәймәс, ислам халкы да Болгар хөкүмәте вакытына караганда бу мәртәбә дә кимемәс иде. Болар мөселманнарны көчләп чукындыру юлына керделәр һәм шул сәбәптән ифрат дәрәҗәдә күбәйделәр. Бу көндә «керәшен» дип йөртелә торган бер халык көчләп чукындырылган мөселманнардан таралган халыклардыр. Боларны Казан алынганнан соң Иван Грозный шулай бик чиркәнеч ясады.

Русларның бу җинаятьләренә мисал итеп бу урында кайбер вакыйгаларны күрсәтү дә зарар булмас. Ләкин болар—диңгездән бер тамчы кебек кенәдер.

1. Князь Василий, үз кулына төшкән мөселман ир һәм хатыннардан ике йөз әсирне милади белән 1536 елда дингә көчләде, риза булмаганнарны үтерттe.

2. Ярославль шәһәрендә тоткын булып торучы Күчем хан гаиләсен һиҗри белән 1048, милади белән 1638 елда көчләп чукындырдылар.

3. Ханкирмән шәһәрендә хан булып торучы Сәед Борһан бине Алып Арыслан бине Гали хан бине Күчем ханны һиҗри белән 1065, милади белән 1655 елда, бернәрсә дә аңламаган сабый вакытында чукындырдылар.

4. 1731 елда Казан һәм Нижний мөселманнарын чукындыру өчен «Свяжская богородица-монастырь»да рәсми идарә оештырылды.

5. Чукындырылганнарны ислам диненә кире кайтырга өндәүчеләрдән 47 мөселманны 1867 елның 28 гыйнварында Себердәге Турухан якларына сөргенгә җибәрү белән хөкем иттеләр.

6. Берәр төрле эш хакында гаепләнүче һәм дә өсләренә түләүләр төшкән мөселманнар чукынсалар, гаепләреннән коткару, түләүдән азат итү хакында кануннар игълан кылынды. Чукынучы мөселманнар гаскәрлек хезмәтләреннән азат ителәләр иде.

7. Бик күп чакта базарда һәм халык күп җыелып торган җирләрдә поплар җыелып торучылар өстенә үзләренең "изге су"ларын бөркиләр иде дә, шуның белән шул җыелган урында, җыенда булган халык христианлык кабул иткән булып хисаплана иде. Моннан соң шул кешеләрнең: «Минем христиан булганым юк, үз динемнән чыкканым юк!"—дигән дәгъвалары ишетелмидер иде.

8. Русларның талауларыннан, җәфалау һәм газаплауларыннан, үз диннәренә кертер өчен көчләүләреннән йөдәгән мөселманнар бераз булса да тынычлык табу, дөньяларын һәм диннәрен төзәтү һәм саклау өмете белән башкорт сахраларына күчә һәм авыллар корып гомер сөрә башлаганнар иде. Бу эшләре белән мөселманнар шул җирләрдә берләшәләр, Төркестан һәм Фирганә мөселманнары белән

мөнәсәбәткә керүләре ихтимал, аннары чукындырып булмый башлар дип фикер йөртеп, Романовлардан Алексей Михайлович һиҗри белән 1059, милади белән 1649 елда христиан булмаган халыкларның башкорт сахраларында торуларын тыеп фәрман игълан итте.

9. 1713 елда: «Җирләрендә православный крестьяннар булган мөселман җир хуҗалары алты ай эчендә православный мәзһәбкә керергә тиешләр, шуңа риза булмаган мөселманнарның җирләре, йортлары һәм бөтен мөлкәтләре көчләп алыначак»,—дигән фәрман чыкты. Бу фәрман 1729 елның 1 мартында, 1743 елның 28 сентябрендә тагын кабатланды.

10. Чукынырга риза булмаган мөселман алпавытлар үзләренең җирләрен һәм мөлкәтләрен сатып яки залогка салып акчалы булып калмасыннар һәм чукынудан котылмасыннар өчен, 1737 елның 21 октябрендә: «Мөселманнарның русларга җир сатулары тыела»,—дигән фәрман игълан ителде.

11. 1754 елда: «Чукынмаган мөселманнар тарафыннан русларга сатылган яки залогка салынган җирләрнең документлары һәм килешү кәгазьләре игътибарсыз калачак һәм җирләре көчләп алыначак»,—дигән аерым фәрман игълан ителде.

12. 1749 елда Казанда мөселман балаларын көчләп христиан дине мәктәпләрендә укыту юлына басканнар иде. Ләкин бу дәрәҗәдә хурлыкка һәм җәберләргә мөселманнар түзә алмадылар, «файдасы булса, булмаса» дип, шул вакыттагы хөкүмәткә каты сүзләр белән гаризалар бирделәр. Хәтта бу хәл чит мәмләкәтләргә дә иреште, зур гына гауга күтәрелде. Нәтиҗәдә, хөкүмәт мәчетләрне ваттыру һәм җимертү, сабый балаларны христиан диненә көчләп кертү һәм мәктәпләрдә көчләп укыту турындагы законын алмаштырырга мәҗбүр булды.

13. Россиядә булган рус князьләре һәм алпавытларының, дворяннарының күбесе крестьяннарыннан яки җир-суларыннан һәм дөньяда тоткан урыннарыннан аерыласы килмичә чукынган мөселман мирзаларының бер өлеше икәнлекләре мәгълүм. Боларның күбесе үзләренең мөселман вакытларындагы фамилияләрен ташлап, рус фамилияләре алган булсалар да, кайсыберләре әүвәлдәге мөселман вакытларындагы фамилияләре белән калганнар, рус фамилиясен алмаганнар...

14. Көчләп чукындырылган мөселманнар әһле ислам каршында «керәшеннәр» һәм «мәкруһлар» исемнәре белән йөртеләдер. Рус хөкүмәте тарафыннан «Новокрешенская контора» ачылганнан соң чукындырылганнар—«мәкруһлар» дип, аннан элек чукындырылганнар «керәшеннәр» дип аталалар. Бу ике төркем арасында аерма зур. Керәшеннәр үзләренең иске төрек телен саклап килсәләр дә, ислам диненнән һәм мөселманнардан ераклашканнар, христианлыкта торуларына артык пошынмыйлар. Әмма "мәкруһлар" үзләрен чын мөселман саныйлар, әгәр дә аз гына форсат тапсалар, үзләренең мөселманлыкларын күрсәтәләр. Бу уңайдан күреләчәк авырлыкларга түзәргә дә әзерләр. Мәкруһлар турында һиҗри белән 1271, миляди белән 1855 елның 29 маенда императорның: "Ислам диненнән христиан диненә мөрәҗәгать итмәгән мәкруһлар Казанның духовная консисториясе хөкеменә җибәрелсеннәр, бармасалар, балалары ата-аналарыннан полиция көче белән алынып, чукындырылсыннар, христиан диненчә яшәмәгән мәкруһлар чиркәүләргә яңадан христиан руханилары тарафыннан йөртелсеннәр, әгәр дә бу эшкә риза булмасалар, ата-аналары аерылсын, ирле-хатынлы булып тормасыннар!»—дигән указы игълан ителде.

15. Шушы елларда мәкруһлар руслашсыннар, чын христиан булсыннар өчен, ялгыз гаиләләрне рус авылларына таратып утырттылар, руслар белән аралашырга һәм барлык хәлләре русларның күз алдында булып торуга мәҗбүр иттеләр.

16. Мәкруһларның ислам динендә көчле һәм ныклы булуларын муллалар һәм мәчетләр тәэсиреннән күреп, рус хөкүмәте мәчет салу эшләрен христиан руханиларына тапшырды. Болар риза булсалар—мәчет салуга рөхсәт бирелә, әмма алар яраклы күрмәсәләр—рөхсәт бирелми торган булды. Бу закон һиҗри белән 1188, миляди белән 1774 елда гына үзгәрде. Ләкин бу үзгәртү нигездән түгел, бәлки мәкруһлар тормаган һәм, гомумән, христианнарга тәэсир итү куркынычы булмаган урыннарга гына кагыла иде. Әмма христианнардан яки мәкруһлардан бер генә гаилә булса да ул урында мәчет салуга рөхсәт бирү яки бирмәү христиан руханилары ихтыярында иде. Бу закон Икенче Николайның тәхеттән төшкән көненә кадәр дәвам итте.

17. Кыргыз, казакъ кавемнәрен руслаштыру һәм христиан итү теләге белән 1223 һиҗри, 1808 милади елда император тарафыннан: «Фәкыйрь кыргыз һәм казакълар үзләренең балаларын Төркестан, Хива, Бохара халыкларына

сатарга тиеш түгел. Әмма русларга саткан очракта да ярдәм итеЛӘ»,—дигән указ игълан ителде. Шушы указга таянып, сатып алу дигән булып руслар кыргыз һәм казакъ балаларын урлап һәм талап алып кайту юлына бастылар һәм һәммәсен чукындырып тордылар. Шунлыктан бу көндәге русларның ерак әбиләре һәм бабалары мөселман булмаганы бик сирәк һәм аз табылыр.

18. Чукындыру хакында мөселманнарның күргән бәлаләренең иге-чиге юк. Төрмәдә ятучылар, ватаннарыннан сөрелүчеләр, үтерелүчеләрнең исәбен бер Аллаһы тәгалә генә беләдер. Бу турыда иске һәм зур архивлар түгел, бәлки Уфа шәһәрендәге Диния нәзарәте архивында булган эшләр генә дә гакылларны хәйран калдырырлык дәрәҗәдәдер. Көчләп чукындыру турындагы законнар императрица Екатерина тарафыннан юкка чыгарылган һәм алыштырылган булса да, бу юкка чыгару һәм алыштырулар кәгазьдә генә булып, гамәлдә һаман да үтәлеп торды.

19. Кырым ханы Морадгәрәй бине Мөбарәкгәрәй тарафыннан Мәскәү кнәзе Федор Алексеевичка һиҗри белән 1093, милади белән 1682 елның рабигыль-әүвәлендә, ягъни март аенда язылган хатта шундый җөмләләр бар: «Мәмләкәтегездә булган мөселманнарны көчләп һәм кыстап христиан мәзһәбенә кертәсез икән. Мондый эшләр падишаһлар дәрәҗәсенә лаек түгел. Бу бик яман эш. Бездә һәм дә бәхетле солтан кул астында хисапсыз дәрәҗәдә күп христианнар бар, безнең тарафыбыздан алар турында шундый бер эш булганы юк. Сез мөселманнарны дин мәсьәләсендә кыстамагыз, мөселманнар үз диннәрендә тыныч торсыннар».

20. Кырым ханы, Мөхәммәдгәрәй ханның вәзире Сәфәргази Ака тарафыннан Мәскәү кнәзе Алексей Михайлович вәзире исеменә язылган хатта шундый сүзләр бар: «Падишаһыгыз мөселманнарның мәчетләрен һәм мәдрәсәләрен ваттырып, Аллаһы тәгаләнең сүзләре булган изге Коръәннәрне утка яктырды. Тотсакларны йолып алырга биреп, кыйнап христиан итәсез. Андый эшләр белән генә христиан күбәймәс. Бездә дә христианнар күп. Ләкин без аларның диннәренә тыкшынмыйбыз. Кешеләрне көчләп христиан һәм көчләп мөселман итү—лаек эш түгел, Ханкирмән солтанын да көчләп христиан иттегез!» *(Фәхреддинев Р. Болгар вә Казан төрекләре.—Казан, 1993.—53—57 б.).*

Бу мисаллар, Ризаэддин Фәхреддин раслаганча, диңгездә бер тамчы кебек кенә.

Әйтеп киткәнемчә, татарларны көчләп чукындыру 1552 елда гына башланган гамәл түгел. Казан ханлыгын яулап алу нияте белән Мәскәү кенәзләре бер-бер артлы яу белән килгәннәр. 1469 елның язында аларның беренчесе оештырыла, ләкин урыс гаскәре җиңелә һәм ул кире борылырга мәҗбүр була. Шул ук 1469 елның август аенда янә Казанга ябырылалар. Урыслар шәһәрне камап тоталар. Ике арада килешү нәтиҗәсендә камалыш туктатыла. Мәскәүләр кайтып китәләр.

1487 елда Мөхәммәд Әмин Казан ханлыгында бердәмлек булмаудан, Мәскәү кенәзе Иван III ярдәменнән файдаланып, Казан тәхетенә утыра.

1549 елда мәскәүләр тарафыннан Казан ханлыгының җәбәлестаны (Тау ягы) яулап алына.

Әлеге яуларда йөзләрчә мең урыс сугышчысы катнаша. Стрелец итеге, ат тояклары, гади җәяүле урыс яугиренең чабатасы астында татар җире таптала. Тау ягы кала-салалары талана һәм яндырыла. Алар канга батырып узган илле чакрымлык киңлектәге җирдә кара тузан, төтен күтәрелеп кала.

Татар җирләрен яулап алу православие коткысы астында алып барыла. Басып алудан тыш, татарларны чукындыру да максат ителә.

1551 елның май-июнь айларында мәскәүләр Зөя елгасы тамагында Свияжск (Зөя) кальгасын (крепость) төзиләр. Бу эш Казан өчен көтелмәгәндә, аның «борын төбендә» эшләнә: булачак кальганың корылмаларын башта Углич шәһәре янында җыялар; аннан соң аларны сүтеп, тамгалап, Идел буйлап Зөя утравына китерәләр дә егерме сигез көн эчендә корып та куялар.

Шулай итеп, Казан ханлыгының көнбатыш өлеше урыс дәүләте кул астында кала. Казан мөһим икътисади өлкәдән мәхрүм ителә. Казан ханлыгының Тау ягы өлешендә яшәгән мөселман-татарларны, мәҗүсилектәге халыкларны Казан алынганчы ук православиега көчләп кертү башлана, ханлык һәлак булгач, ул котырып дәвам итә. Бу эшкә рус хәрби-күчмә чиркәүләре, руханилары җитәкчелек итә. Әлеге гамәл Казанга каршы һәрбер яу вакытында кабатлана. Юл өстендә утырган татар авыллары—Татар Әҗәлесе, Кармыш, Ачасыр һәм башкалар Мәскәү тарафыннан оештырылган һәр поход саен, ягъни берничә мәртәбә чукындыру гарасатын кичерәләр. Тау ягына, Цивиль өязенә, хәзер Кайбыч районына кергән

татар авыллары—Мәлки, Иске һәм Олы Тәрбит, Янсура һәм башка салалар халкын тулысынча христианлаштыралар.

Яңа чукындырылганнар арасында исламга тугрылык саклаган татарлар авылларыннан куыла, ә православие кабул итүчеләргә, киресенчә, үзләре теләгән урыннарга күчеп утырырга рөхсәт ителә.

Казан яулап алынгач, Идел буенда яшәгән чукындырылган татарлар икегә бүленә. "Иске керәшеннәр" ("старокрещены") XVI—XVII гасырларда формалашалар. Алар урыслар һәм чуашлар арасында яшиләр, шул сәбәпле йолалары урыс йогынтысын кичерә. Телләре татарча булып калган. Казан губернасында XIX гасырның беренче яртысында 30 меңләп иске керәшен яшәве күрсәтелә. Цивиль өязенә кергән керәшен татарлары да исәпкә алына. Мәлки, Тәрбит, Янсура һәм башка авылларда яшәүче керәшеннәр, чуашлар белән аралашып яшәүләре нәтиҗәсендә, чуаш тәэсиренә юлыгалар.

"Яңа керәшеннәр" төркеме XVIII гасырның беренче яртысында—1730 елда Зөя шәһәрендә Яңа чукындырылганнар конторасы (Новокрещенская контора) ачылганнан соң оеша. Алдагы унъеллыкларда бу төркемгә керүчеләрнең (мәкруһларның) саны даими рәвештә кими бара. Аларның күбесе христианлыктан баш тарта. Бу мәкруһлар ислам диненә катгый тугрылык саклыйлар, җомга көннәрдә бәйрәм итәләр, татар киеме кияләр, яшеренеп булса да, мәчеткә йөриләр. Алар һәртөрле авырлыкларга түзәләр, ачыктан-ачык без христиан дип әйтүгә каршылык күрсәтәләр.

Мәкруһларны христианлыкта калдыру өчен хөкүмәт тарафыннан төрле чаралар күрелә, ләкин алар яңа керәшеннәр арасында исламның ныгуына гына сәбәпче булалар. Мәкруһларны мөселманнар арасыннан аерып алып, урыс авылларына күчерүләр 1829, 1835, 1839, 1841 елларда киң җәелдерелә. Ләкин моның әлләни файдасы тими. Киресенчә, мәкруһлар күченеп килгән урыс авылларында татар йогынтысы үзен бик тиз арада сиздерә. Хөкүмәт башка юллар эзли. 1855 елда ул "Высочайше утверждение" белән яшерен комитет ачарга мәҗбүр була. Бу указда: "Якын җирдәге православие руханиена мөрәҗәгать итмәгән мәкруһ татар Казан консисториясенә бирелергә тиеш, йә булмаса ул христианлыкка кайтарылсын. Чукындырылмаган балалар ата-аналарыннан полиция тарафыннан тартып алынып чукындырылсын. Христиан никахы белән өйләнмәгән ирләр христианча никахлашсыннар",—диелгән. Әлеге указның гомере кыска була. Мәкруһлар ныклы каршылык күрсәтәләр. Указ 1861 елда гамәлдән чыгарыла. Шул вакыттан соң патша исеменә мәкруһлар тарафыннан, ислам динен тотуга, аны өйрәнүгә рөхсәт сорап, үтенечләр килә. Әлеге хәрәкәт Зөя өязендә башланып, тиз арада бөтен Казан губернасына һәм башка губерналарга тарала. Бу үтенечләр "законга каршы килә" дигән җаваплар мәкруһларны тынычландыра алмый. Мөселманнар җаваплар патшадан түгел, чиновниклардан килә дип исәплиләр. Вәзгыять кискенләшә бара.

1867 елның 28 гыйнварында мәкруһларны үз диннәренә, мөселманлыкка кайтуга "котыртучы" 47 мулланы Көнчыгыш Себердәге Турухан краена сөрү турында әмер бирелә.

Ләкин әле бу яңа гарасатның башы гына була. Себергә сөрү империянең эчке эшләр министрына йөкләнә. Император канцеляриясенең өченче бүлекчәсе күрсәтмәсе сөрелүчеләрнең барысын да берьюлы түгел, аларны төркемнәргә бүлеп, төрле вакытта җибәрүне оештыра. Беренчеләрнең тавышы басылгач, икенчеләрен куалар. Себергә сөрүне мәхкәмәләрдә хөкем кылмыйча гына гамәлгә ашыралар. Бер үк вакытта "котыртучылар"ны да төрмәгә ябалар.

Моның белән бергә, Казан архиепископына вәгазь белән өндәргә әмер бирелә. Ләкин аның осталыгы, сәләте җитмәү сәбәпле, моның бернинди дә нәтиҗәсе булмый. Архиерей руханиларга вәгазь белән мәкруһларның авылларына ешрак барырга фәрман бирә.

Татарлар христиан руханиларын кабул итмиләр, аларга капкаларын ачмыйлар, аларны өйләренә кертмиләр. Руханилар авылларга полиция ияртеп бара башлыйлар.

Ислам диненә кайтучылар һәм кайтырга теләүчеләр белән поплар арасында көрәш кискенләшә. Мәкруһлар арасында "котыртучылар"ны эзләүләр көчәя. Аларны күпләп табалар, ләкин башлыкларының эзенә тиз генә төшә алмыйлар. Алар, Мөхәммәд диненә күпләп кайтырга өндәүчеләр: Зөя өязе Янгилде авылында туып-үскән Мөхәммәтсабит бине Шәрәфетдин, шулай ук аның Зөя өязе Аккуҗа

авылыннан булган өч фикердәше һәм Салтыган авылы мулласы Таҗетдин Мөхәммәдьяров.

Хакимиятләр мәкруһларның мөселманча никахларын танымаганнар, хәтта балаларына аналарының исеме буенча "Фатыймин", "Гайшин" кебек фамилияләр такканнар. Күренекле татар шагыйре Хәсән Туфан, мәсәлән, инде XX гасыр башында, әнисенең исеме буенча, Гөлзизин фамилиясендә йөрергә мәҗбүр була.

Мәкруһларның хәлен төгәлрәк күз алдына китерү өчен 1905—1911 елларда нәшер ителгән "Казан мөхбире" газетасының 1906 ел 3 май санында дөнья күргән мәкаләгә игътибар итик. Әһәмиятен истә тотып, биредә аны тулысынча китерүне урынлы саныйм.

"Чистай өязендә Тубылгы атавы карьясенең (хәзерге Татарстан Республикасының Яңа Чишмә районындагы Тубылгы Тау авылы. Т.В.) мәкруһларына рәсмән (рәсми) мөселман булып дәфтәрләренә (ислам дәфтәрләренә язылу—рәсми рәвештә мөселман булып теркәлү) язылырга вакытлы рөхсәт бирелгәне мәгълүм булды. Бу авылның мөвәкъкать имамы Габделрәфыйк хәзрәт рәсми мөселман булулары хакында зур иҗтиһад (тырышлык) кылган. Чистай өязендәге мәкруһлар тарафыннан депутат булып Петербургка да барды. Бу мөселманнарның тарихи хәлләре бик мәгълүм булмаса да, Русия дәүләтенә табыг булганнан соң, миссионер җәфасына төшеп, ата-бабаларыннан калган дине исламны югалтмаска зур иҗтиһад вә гайрәт иткәннәре мәгълүмдер. Габделрәфыйк хәзрәтнең сүзләреннән һәм вәкилләренең соңгы 60, 70 ел эчендә мәхкәмәләргә биреп йөргән гаризаларыннан, ни кыяфәткә дине исламны саклаганнарын һәм аның хакында үзләренә нindәен җәфалар булганын тәмам аңладык. Күп җәза күреп булса да, һичбер вакытта дине исламнан аерылмаганлыкларын исбат кылырга гаҗәп дәрәҗәдә тырышканнар икән. Боларның дине ислам хакында кылган иҗтиһадларын вә күргән җәфаларын (картларга шөкрана, яшьләргә гыйбрәт өчен) бернича аңлатмак булдык.

Казан вилайәтендәге мөселманнарның ата-бабаларыннан калган хәбәре буенча, Болгар мәмләкәтендәге Тубылгы атавы исемендә бер шәһәр булганы мәгълүмдер. Хисаметдин әл Мәслими хәбәре буенча, бу шәһәрнең кырыенда Кичү суының Шушма елгасына койган җирендә Болгар мәшаихләреннән Хуҗа әхрар исемле кемсәнең кабере дә бар, имеш. Хәзерге Тубылгы атавы карьясе мәзкәр Болгар шәһәренең урынында мөселманнары да шул Тубылгы атавы кальгасында булган болгарларның нәселе булса кирәк. Бу карья зурлыкта хәзер дә бер кечерәк шәһәр чаклы бар (җан хисабы 1600 чамасында). Тубылгы атавы карьясының янында хәзер дә бер зур иске кала урыны бар, өч катлы ур казып әйләнгән.

Бу мөселманнарның рәсмән насари (христиан) саналып кәнисә (чиркәү) дәфтәрләренә кай заманда языла башлагандыр, мәгаен (тәгаен) әйтеп булмый, әмма 1829, 1830, 1831 елларда "отпавший" исемендә йөртелә башлаганнар. 1856 елда Чистай һәм Спас өязләрендә булган гайре мәкруһлар (мәкруһлар көчләп чукындырылып та яисә рәсми документларда чукындырылган дип теркәлгән, әмма үз диннәренә тугрылыклы калган мөселманнар, рус телендә "отпавшие" гыйбарәсе белән мәгълүм) берлән бергә җыелышып падишаһ исеменә татарча язып, ике прошение биргәннәр. Прошениеләре бу рәвештә язылган: "Падишаһның 1846 елда булган фәрманы буенча, кәнисәле булган урыс авылларына күчерә башладылар. Приход кәшишләребез (поплар) нәсари (христиан) динен өйрәттерү өчен; ләкин без дөреслектә чын мөселманбыз нәсари (христиан) динен кабул иткәнебез юк, кәнисәләргә (чиркәү) һичбер вакытта йөрмибез, яңа туган балаларыбызга һичбер вакытта рус исемнәре кушканыбыз юк, семейный списокларда һәм ревизия сказкаларында урыс исемнәре язылган булса да, ул кәшишләр үзләре теләгәнчә язып куйган исемнәр генә. Хәзер дә становой пристав, окружной начальник, волостной кәшишләр берлән авылларыбызга килеп, безне төрлечә җәзалый башладылар, үзебезне каравылга ябалар, хатыннарыбызны җибәреп, җәмәгатьләребезне тараталар, биргән кызларыбызны ирләреннән аерып, яшь балаларын ятим калдыралар, халыкны фәкыйрьлеккә төшерәләр",—дип язганнар. Бу прошениенең внутренний министр—эчке эшләр министры бу елларда *(27. XI. 1878—6. VIII. 1880—Л. С. Маковторган)* отпавшийларның эшләү урынында тәфтиш кылу өчен Казан губернаторына кайтарган. Язган хәбәре дөрес булса, аларны тиешсез җәбер вә җәзалардан сакласын дип әмер булган. Губернатор бу эшне бик илтифат берлән тикшереп, духовный консисториядән сораган:

1) Чистай вә Спас өязләренең кайсы авылларында татарлар әүвәлдә нәсари (христиан) динендә булып та, хәзер дә исламга күчкәннәр? Вә һәм шул авыллардагы отпавшийларның исемнәре язылган списокны сораган.

2) Кайвакытта бу татарлар нәсари динен кабул иткәннән соң ул динне ташламаска дип, шул вакытта аларның кулларыннан язу алынганмы?

3) Бу прошение бирүче татарларның әүвәл дә христиан булып, соңыннан исламга күчүләре дөресме?

4) 1829, 1830 елларда исламга күчкән татарларның балалары нәсарилыкның шартларын йөртү өчен кәнисәгә (чиркәүгә) кергәннәре бармы? Әгәр дә булса, аларга шул мөкатдәс эшләрне кылучы кәшиш (поп) кайсы приходныкы?

Губернаторның сөальләренә духовная консистория бу рәвештә җавап биргән: "Авылларның һәм татарларның исемлекләре язылган дәфтәрләр булмаганлыктан, куелган сөальләргә җавап бирә алмыйбыз",—дип. Шуннан соң губернатор мәкруһларның прошениеләрен министрга кире кайтарып бирә.

1863 нче елда Чистайга наследник килгән вакытта (Чистайга падишаһ варисы Александр III килү турында сүз бара.—Т. В.) Тубылгы атавы карьясенең мәкруһлары наследник хәзрәтләренә дә гариза биргәннәр. Язулары бу рәвештә булган: "Без һичбер вакытта да нәсари динендә булганыбыз юк. Бала вакыттан бирле дине исламда торабыз, безнең бабаларыбыздан кем вә кайвакытта отпавший дип санала башлагандыр, безгә мәгълүм түгел. Безнең бу эшләребез, һич өзелмәенчә, бик күптәннән бирле тартылып килә, без һич гаепсез җәзаланабыз, мондагы начальникларыбыз безне төрлечә кысалар, читкә хезмәткә барырга безгә язу (билет) бирмиләр. Шул сәбәпле, хәзинәгә тиешле булган налогларыбызны да түли алмыйбыз. Үз хаҗәтләребезгә хәреҗебез булмый чит авылларга иргә биргән кызларыбызны (никахларын законсыз санап) атасы җәмәгатенә язып киләләр, наследниктан үтенгәннәр: үзләрен начальство тарафыннан булган җәбер-җәзалардан коткарырга һәм читкә чыгып йөрү өчен гайре крестьяннар белән бәрабәр һәртөрле хаҗәт булган язуларны бирегә рөхсәт ителсә иде, дип. 1867 елда Тубылгы атавы карьясенең ике мулласын (Рәхмәтулла Ярмиев, Галим Самигуллов) шул карьядә имам булып торган өчен һәм шуның белән бергә нәсари гадәтләрен ташлатуга сәбәп булалар дип, дәхи становой белән исправник помощнигының әмеренә каршы торган өчен дип. Казанда уголовный палачның 15 декабрьдә ясалган решениесе буенча дүртәр елга каторожная работага. Шул 4 ел үткәннән соң һәрвакытта Сибирияде торырга җибәрелгәннәр. Становой белән исправник помощнигының әмеренә каршы торган дигәне шул, имеш, карт имамнары Рәхмәтулла хәзрәт мәсҗидне пичәтләргә менгән становойны баскычтан сугып төшергән, шуннан соң исправник помощнигы килеп аңардан мәсҗидне пичәтләргә ихтыяр бирмәгәннәр, соңыннан губернатор барыпмы, ничек булса да мәсҗит пичәтләнгән. Губернатор Казан төрмәсеннән икенче имамнары Галим хәзрәтне богаулы көенчә үзе белән бергә авылга алып кайтып, халыкны бик үгетләп киткән, имеш. (Бу рәвештә мулланы авылга алып килү халыкны куркыту өчен генә булгандыр). Шуннан соң (дөрес булса, ишетүебезчә), мәсҗиднең ишегендәге пичәтне бозмыенча, стенасын кисеп кереп гыйбадәт кылганнар, имеш. Ишек урынына киез каплап торганнар дип сөйләшкәнне ишеткән бар. Рәхмәтулла хәзрәт 45 ел имам булып торган, каторгага киткәнгә решение булганнан соң, Чистай төрмәсендә вафат булган. Икенче муллалары Галим хәзрәт 20 ел имам булып торган. Ул хәзер дә исән, имеш, мәгәр бик картайган диләр. Ясалган җәзаларын бетергәннән бирле Семипулат шәһәрендә тора икән. Бу кешене иленә кайтару турында Тубылгы атавы мәкруһлары мәхкәмәләргә күп мәртәбә гаризалар биреп йөргәннәр, ләкин бер дә илтифат булмаган. Һаман отказ килгән. Мәсәлән, 1879 елның апрель, 1880 елның февраль числоларында бу авылның доверенныйлары министр юстициядән биргән гаризаларын падишаһка ирештерүне сораганнар. Шул прошениеләре внутренний министрга бирелгәне мәгълүм булгач, 1881 нче елда дәхи гариза биреп, әүвәлге прошениеләренә җавап сораганнар. Ләкин 1882 елда министрдан отказ килгән. 1881 елда Уфа һәм Казан губерналарына ревизия өчен килгән сенатор Ковалевскийга да, үзләренең дини хаҗәтләрен сорап, гариза биргәннәр. Никадәр сорап йөрсәләр дә, бу заманга кадәр һичбер нәтиҗә чыгара алмаганнар, хәлләренә илтифат итүче булмаган, үткән елда мәкруһлар тарафыннан депутат булып Петербургка барган Габделрәфыйк хәзрәттән сорашып белдек: бу мөселманнарның никахлары законный саналмыенча, биргән кызлары һаман аталары җәмәгатендә санала икән. Гәрчә чит авылларга бирелгән булса да,

балалары үсеп җитеп зур җәмәгать атасы булган карт һаман хатынсыз (холостой) саналып, паспортларына да шулай языла, имеш. Балалары аналары тарафындагы бабасының җәмәгатенә язылып, фамилияләре дә хатыннар исеме белән йөртелә, имеш. Мәсәлән, Фатыйма углы булса "Фатыймин", Гайшә углы булса "Гайшин" дип йөртәләр икән".

## Урыслаштыру сәясәте

*Русскими не рождаются,*
*Русскими становятся*
*(Урыс булып тумыйлар,*
*Тугач урыс булалар)*

"Русское радио" (2003 ел)

Патша самодержавиесенең милли изү сәясәте тарихында татарлар аерым бер урын алып тора. Бу гыйбрәтле тарихның беренче сәхифәләре татар халкының бәйсезлеген җуюдан башлана.

Империядәге милли изү сәясәте халыкара хәлне, илнең эчке халәтен исәпкә алып үткәрелә. Бу изү Русиядәге халыкларның барысына да тигез төшми. Хәтта мөселман халыклары арасында да аның үз аермалыклары, үзенчәлекләре бик ачык күренеп тора. Татар гасырлар буена милли изүнең үзәгендә булды.

XIX гасырның икенче яртысында Россия хөкүмәте урыслаштыру сәясәтенә үзгәрешләр кертә. Татарның ул чактагы милли аң үсешенең бер чагылышы итеп керәшеннәрнең кире мөселманлыкка кайту хәрәкәтен атарга була. Моңа каршы урыс чиновниклары яңа керәш формалары эзләргә мәҗбүр булалар. Миссионер Н. И. Ильминский, Англиянең күп тапкырлар дөньякүләм сыналган колониаль изү тәҗрибәсен киң файдаланып, христиан динен җирле "инородец"ларга сеңдерү методикасын эшли. Ул тәкъдим иткән система нигезендә кириллица белән җирле халык телендә дини китаплар чыгару, мәктәпнең башлангыч сыйныфларында христиан дине нигезләрен татар телендә үзләштерү ята. Аның фикеренчә, урыс динен, тарихын, гореф-гадәтләрен генә таныган "инородец"лар, урысча әйбәт сөйләшмәсәләр дә, маңкортка әвереләләр, күңелләре белән урыслашалар. Шулай итеп, Ильминский мөселманнарны үз телләре, язулары аша юкка чыгарырга омтыла. Халыкның динне алыштыруы аныңча—урыслаштыруның беренче этабы, урысча белү—икенче һәм соңгы этабы булып санала башлый. Диннән мәхрүм итүдән соң урыслаштыруда икенче мөһим адым "инородец"ларның аңына урыс халкының бөеклеге, аның рухи яктан өстенлеге турындагы фикерне сеңдерү була.

1860 елларның икенче яртысында керәшен авыллары дип саналган авылларда күпләп конфессиональ мәктәпләр ачыла. Ул мәктәпләрдә мөселманнар һәм мөселманлыкка кайтканнарның балалары укырга тиеш була.

Җирле халыкларны мөселманнар йогынтысыннан саклау, мөселманлыкка чыгу куркынычын бетерү сылтавы белән Ильминский җитәкчелегендәге миссионерлар, православие дине әһелләре, губерна администрациясе, Казан уку-укыту округының попечителе күп тапкырлар югары властьларга диния нәзарәтен бетереп, аның эшләрен губерна идарәләренә тапшыру, мәчетләрне төзекләндермәү, муллаларның санын киметү, татар милли мәктәбен кысу, мөселманлыкка кайткан керәшеннәрне күпләп Себергә сөрү, мөселманнар сайлануга хокуклы булган волость идарәләренә православиедәгеләрне билгеләү, хәтта авыл старосталары итеп тә христиан дине вәкилләрен кую кебек тәкъдимнәр белән чыгалар.

Императрица Екатерина IIнең дин ирege турындагы указыннан соң ислам дине эшләренә тыкшынуга беркадәр чик куела. Патша хөкүмәте XIX гасырның икенче яртысында үз сәясәтен яңарта. 1866 елда Казанга килгән мәгариф министры граф А. Толстойга татарның үзенә бер дөнья булып, урыс йогынтысына бирелмичә көн күрүе бер дә ошамый. Мондый бәйсезлекнең нигездә татар милли мәктәбе белән мөселман руханилары эшчәнлеге ятканын яхшы аңлаган хөкүмәт үзенең урыслаштыру сәясәтен шушы ике "куркыныч" көчкә каршы оештыра. Исмәгыйль Гаспралы сүзләре белән әйткәндә, мөселман дөньясына, аның тормыш һәм фикер үсешенә йогынтысы теләсә нинди Европа университетларыныкына караганда чагыштыргысыз дәрәҗәдә көчлерәк булган татар мәктәбенә һөҗүм башлана. Урыс булмаган халыкларга аң-белем таратуның ахыр максаты ачыктан-ачык урыслаштыру һәм урыс халкына кушу дип игълан ителә.

XIX гасырның икенче яртысында мәгариф министрлыгы эшләгән программа "агарту" эшен ике юнәлештә: чукындырылган "инородец"лар һәм мөселманнар арасында алып баруны күздә тота. Мөселманнарны урыслаштыру фәкать урыс телен өйрәтү аркылы гына мөмкин дип ассызыклап әйтелә. Программага училищеларда татар балалары өчен әзерлек сыйныфлары булдыру, мәктәпләрдә мәҗбүри рәвештә урыс сыйныфлары ачтыру, 1860 елдан башлап яңа мәктәпләрне андый сыйныфлардан башка гамәлгә куймау, урыс теле укытучысын тоту чыгымнарны авыл мәхәлләсенә йөкләү кебек пунктлар кертелә. Чыгымнар 350 сумнан ким булмаска тиеш, дип әйтелә.

Карамзин, Соловьев, Ключевский кебек галимнәр урыс кенәзләренең 1552 елга кадәр үк Казанга утыз тапкырдан артык һөҗүм итүләрен язалар. Яу вакытында христианлаштыру урыслаштыру белән бергә алып барыла. Татарга каршы көчле коткы таратыла һәм бу дөнья күләмендә алып барыла. Без хәзер дә тормышта, әдәбиятта, сәнгать әсәрләрендә, аерым тарихчыларның хезмәтләрендә әледән-әле бу күренешкә тап булабыз. Мәсәлән, тарих фәннәре докторы В. Каргалов үзенең "На степной границе" дигән китабында *(Мәскәү, 1973)* болай дип яза: "Рус халкының һәм илебездә башка халыкларның агрессив татар ханлыгы белән көрәше берничә гасырга сузылган. 1552 елда Казанны алу белән Иделдәге юлбасарлар оясы—Казан ханлыгы бетерелде" (3 б.).

Миссионерлар һәм хакимиятләр тарафыннан татарларның үзләре арасында да коткы таратыла, моның өчен үзләре теләп христианлашкан керәшеннәр файдаланыла. Урыслаштыру юлы—бердәнбер котылгысыз юл—татар күңеленә янә шундый фикерне иңдерү максат ителә. Янәсе, "татарская лопата", "собака", "чаплашка", "гололобый", "желудь" кебек мыскыллау сүзләре урыслашкан татарга әйтелмәячәк, аның хокуклары урысныкы белән тигез булачак.

Әлбәттә, мәкруһлар яшәгән авыллар арасында урыслашкан булып кыланганнары да табыла. Ләкин китапка, мәдәнияткә ия татар халкын урыслаштыру мөмкин булмый. Зөя өязе татарлары арасында яманаты таралган миссионер Н. И. Ильминский да, хакимият чиновниклары да урыслаштыру сәясәтенең җитәрлек нәтиҗә бирмәвенә аптырап калалар, моның сәбәпләрен эзләргә керешәләр.

1863 елда Н. И. Ильминский университетны ташлап Казан православие руханилары академиясенә күчә һәм башы-аягы белән Рәсәй халкын христианлаштыру һәм урыслаштыру эшенә чума. Ул миссонерлар, чиркәү руханилары һәм хөкүмәт тарафыннан күрелгән чаралардан соң бер генә мәкруһ та урыска әйләнми кала алмаячак дип өметләнә. Бу төреле күсәкнең авыр башы Зөя өязе мәкруһларына төште дияргә дә була. Алар, рәхимсез эзәрлекләүләргә дучар ителсәләр дә, бирешмәделәр, милләтләрен сатмадылар.

Безнең бабаларыбыз милләтне саклауның төрле юлларын белгәннәр. Шуларның гасырлар буе сыналганы (бәлки, иң мөһимедер) хакимлек итүче кавем белән мөмкин кадәр азрак мөнәсәбәттә булу. Мәкруһлар, көчләп чукындырылган һәм мөселманлыкта булган татарларның урыслар белән дөньяви дуслыгы, алар белән алыш-биреш итү дөрес дип саналса да, аларның яшәү рәвешләре хәрәм саналган.

Бабаларыбыз халкыбызны үз тормышыбыз ассылыгыннан чыгармаска тырышканнар. Читләрдән килгән, татарныкы булмаган һәртөрле мәдәни, гыйльми, дини, гадәти күренешләргә сагаеп караганнар, аларның дингә каршы булу, урыслаштыруга юнәлдерелү ихтималы турында кисәтеп, моны балаларының күңелләренә сеңдерергә омтылганнар.

Заманында кыска акыллы миссионерларның, дин әһелләренең тиз арада христианлаштыруга, аннан соң урыслаштыруга ният ителгән чараларына, татарны милләт буларак юкка чыгаруга ашкынуларына алар, ышанычлы кирто итеп, үзләренең күкрәкләрен куйганнар.

Читтән ни генә китермәсеннәр, безнең бабаларыбыз "зәһәре белән агу" дип, китерелгәнне кире куйганнар, авызларына алмаганнар. Алар гасырлар дәвамында янап килгән урыслаштыру куркынычыннан, чын мәгънәсендә юкка чыгудан курыкканнар. Андый шикләнү-куркулар, борчылулар татар халкының бәгъренә сеңдерелгән, гореф-гадәтләренә кереп урнашкан, буыннан-буынга күчеп килгән, балалар күңелендә сакланган. XIX гасырда, мәсәлән, татар урыс чабатасын кимәгән, урмәгән, хатын-кызларыбыз арты бөрелгән сарык туннарын тектермәгәннәр. Озын чәчле, көрәк сакаллы татарны авылдашлары, үз туганнары һәм дуслары: "Поплыкка язылдыңмы?" дип шелтәләгәннәр. Сөннәт һәр мөселман иргә лазем булса да,

кайсыбер ир бала, авылга "бабачы" (сөннәт мулласы) килгән саен куркып качып сөннәтсез кала. Һәм ул авылдашлары каршында гел уңайсызлык тоеп яши. Авыл кешеләре аның исеменә "урыс" сүзен өстиләр, көләләр. Мондый егет кызлар янына да бара алмый, алар да көлә. Бу хәлне ул үзе дә фаҗига дип саный. Кимчелекне төзәтү нияте белән Зөя өязе Кошман авылына барып, "бабачыны" табып, яше 20дән узса да сөннәтле булып кайтучылар була. Аларга инде 3-4 көн урынына 2-3 атна ятарга туры килә. Ә "урыс" сүзе кушаматка әйләнеп берничә ел тагылып йөри, кайсыбер бәхетсезенә исә гомерлеккә дә ябышып кала. Шуңа күрә ир балалы ата-аналар үзләренең улларын вакытында сөннәтле итәргә тырышканнар. Моны миссионерлардан, чиркәү руханиларыннан, волость старшинасыннан яшереп кала белгәннәр...

"Тәрегә туры карасаң—чукындырылуың бар". Хәтеремдә әле, сугыш еллары. Яңгырсыз коры көннәр тора. Шуны сәбәп итеп, Колангы авылыннан зур гына бер төркем халык тәреләр, иконалар, өч балаклы дини байракларын күтәреп, чиркәү җырларын җырлап безнең Янгилде авылын әйләнделәр. Урысларның бу йолалары ел саен кабатлана иде. Каршы торырлык ирләр фронтта. Безнең әниләр кебек ялгыз калган татар хатыннарын санга сукмыйлар. Инешләрне, кизләүләрне чукындырып, өерләре белән тошке туплауга кайткан авыл көтүенә юнәлделәр. Бер кулына себерке, бер кулына тәре тоткан, попның каршысына озын чыбыркысын күтәреп күршебез, көтүче Камалетдин абый Җамалиев килеп басты. Чыбыркы сабы белән попка килгән юлын күрсәтте. Поп буйсынды, Колангы һәм Янгилде марҗаларын ияртеп авылына кайтып китте. Без, бала-чага, үзебезнең бурычыбызны үтәдек. Бер генә мәртәбә дә тәреләргә туры карамадык. Авыл татарлары исә Камалетдин абыйга рәхмәтле иде—бердәнбер туендыручы сыерларын чукындырудан котылдылар.

Колангыдан яңгыр теләп килгән урысларның теләкләре тормышка ашмады, яңгыр яумады. Өч көннән авыл малайлары боткасыз гына (боткага ярма юк) "яңгыр боткасы" ясадылар. Су сибештеләр, олыларга да эләкте, хәтта мулла бабайны да үз буасындагы су белән коендырып чыктылар. Булышты. Кичен күк күкрәп яшенле яңгыр явып китте.

Әчкечелекне, урыс милләте арасында киң таралган тискәре күренешне дә татарларны урыслаштыруда файдаланалар. Урысларның бихисап бәйрәмнәренең әчкечелек таратуга тәэсире шактый зур була. Мөселманлыкка кайтырга форсат кына көткән мәкруһлар әчү белән мавыгучыларны ныклы күзәтү астында тоталар, бу инде гадәткә кергән була. Алар урыслашудан шулкадәр дә куркалар ки, хәтта үзләренең эш-гамәлләрен, уйларын, сөйләгәннәрен, күргән төшләрен анализлаганда да урыслаштыруга каршы торуда таяныч булырлык мәгънәләр табарга тырышалар.

Мәкруһлар үзара сөйләшкәндә бер-берсенә бармак белән төртеп күрсәтмиләр. Зират өстендә каберләргә төртеп күрсәтү исә катгый рәвештә тыела. Чөнки андый вакытта кулның хәрәкәте чукындыру хәрәкәтен хәтерләтә.

Тамга һәр хуҗалыкта борын заманнан, ата-бабалардан мирас булып килгән. Ул—аларның имзалары, шәхси әйберләренә сугыла торган билге. Җир өлеше хуҗаларның да һәркайсы башына көрәк белән тамгасын сырлаган. Волость старшиналары, чукындырылган татарларның һәм мәкруһларның тамгаларын үзгәртеп, аларны турыпочмаклы, тәрене хәтерләткән геометрик фигуралар белән алыштырып карыйлар. Барып чыкмый, гауга куба. Һәр хуҗалык үз тамгасы белән кала. Хәтеремдә әле, безнең бабайлардан калган җир эшкәртү коралларында, кычыткан капчыкларында, киндер сугу станокларында—барысында да кош тәпие сурәте бар иде.

Урыс миссионерлары һәм хөкүмәт чиновникларына мәкруһларны урыслар яшәгән яки катнаш авылларга күчереп, катнаш никахлар аша урыслаштыруга да зур өмет баглаганнар. Элегрәк әнә татар морзалары, малларын, дәрәҗәләрен саклап калу ниятеннән, катнаш никахка кергәннәр. Нәтиҗәдә татарлыкларын да, мөселманлыкларын да җуйганнар. Мөселманнар, керәшен татарлары, мәкруһлар исә, хәтәрлеген аңлап, мондый юлга басмаганнар. Моны үземнең туып-үскән Янгилде авылын (Апас районы) мисалга китереп тә әйтә алам. Гасырлар буена бергә яшәп килгән урыс белән татар арасында катнаш никах кору очрагы булмаган, әчке тыю буыннан-буынга күчеп килгән. Мондый хәл безнең буын яшәгән дәвердә дә күзәтелмәде. Катнаш гаиләләр тирә-як авылларда да булмады кебек.

Зөя өязенә кергән, мәҗүсилек заманында чукындырылган берничә керәшен авылы халкыннан башка яңа чукындырылган татарлар, керәшеннәр дип йөртелсәләр дә, үзләрен мәкруһ дип санаганнар. Мәкруһларның бервакытта да күрше Мәлки,

Тәрбит, Янсура һ. б. авыллар халкы кебек "керәшен" булмаганы мәгълүм.

Әйтеп киткәнемчә, Зөя өязе авыллары мәкруһлары урыслаштыруга илтүче күренешләрне тиз арада юкка чыгару юлын эзләгәннәр. Мәсәлән, мәкруһлар йортларында тәрәзә әрәтәләренең өске өлеше ярымтүгәрәк итеп алына. Тәрәзә капкачының, кысасының һәм нәкышенең өсте дә шулай итеп эшләнә. Ягъни урамнан узып барган һәр кеше мәкруһ яшәгән йортны урысныкыннан җиңел аерган. Алай гына да түгел, авылларны да ерактан ук аерып була иде. Мәсәлән, җил тегермәннәренең канатлары. Урыс авылларында дүрт канатлы булса, мәкруһ авылларында—алты канатлы урыс авылларында тегермәнче тегермән канатларын җил юк чакта "дөресләп"—тәре формасына китереп турылап куя торган була. Ягъни авылның иң биек урынында торган җил тегермәне гигант тәре хезмәтен дә үтәгән. Алты канат исә ялгышып та тәре була алмый инде.

Тәре дигәннән, янә сугыш еллары искә төшә. Миңа алты-җиде яшь. Әбием Әмәйгел (1870—1949) янына балалыгы һәм үсмерлеге узган, бергә картайган Бибикамал исемле әби килә иде. Алар бергәләп дини китаплар укыйлар иде (ул китаплар бүгенге көндә дә гаилә архивында сакланалар).

Бибикамал әби капкадан килеп керсә, безнең әби каушап калыр иде. Ул моннан 50-60 ел элек суккан сөлгеләрен, диварларга элеп куелган тукымаларын җыештырырга керешә. Бибикамал әби туры өйгә керми, башта ишегалдын, аннан абзар-кураларны тикшерә. Өйгә пыр тузып кергән чаклары да була. Андый вакытта безнең әби: "Бибикамал тагын "крус"ка (тәрегә) охшаган нәрсә тапты бугай",—ди торган иде. Бервакыт, печәнлеккә менгәндә әни баскычны сөягән җиреннән алып, яткырып куярга оныткан икән. Бибикамал абыстай круска охшаган дип аны төртеп аударган. Сәнәк һәм көрәк аркылы-торкылы яткан икән—аларга да тибеп җибәргән. Күрше әби өйгә кергәч, безнең әбинең үзенә дә эләккәли иде. Бибикамал әбинең "Әмәйгел, мин сиңа 50 ел буе бу сөлгеләреңдә 99 "крус" табып була дип әйтеп киләм",—дип шелтәләвен хәтерлим. Әбием миңа һәм сеңлем Фәнзиләгә пычак белән кайчы бирде дә, кечкенә "крус"лардан җыелып ясалган чәчәкләрне сүттерде. Без ул эшне бер көндә башкарып чыктык.

Бибикамал әбинең миссиясе моның белән генә тәмамланмый. Ул авылның башка йортларына да кереп "крус" эзләп йөри. Авыл халкы Бибикамал абыстайның сүзен тыңлап, "крус"ка охшаган шикле әйберләрдән чистарынырга ашыга. Күрше авылларда да Бибикамал әби кебекләр бар иде.

Патша хөкүмәтенең мәкруһларны урыслаштыру сәясәтендә кулланган ысулларының берсе дә уңышлы булып чыкмый. Алда әйтелгәнчә, мәкруһларны мөселманнардан аерып алып ерак урыс йә булмаса урыс белән татар катнашып яшәгән авылларга күчерү кебек чаралар 1829, 1835, 1839 елларда гамәлгә ашырыла. Ләкин моның нәтиҗәсе бөтенләй башкача булып чыга. Күчеп килгән мәкруһларның шактый еллар яшәп яткан керәшен татарларына тәэсире көчлерәк булуы ачыклана. Урыслашу урынына татар теле ике дин, ике милләт вәкилләре яшәгән авылның "дәүләт теле" булып әверелә. Шулай итеп, авылларда хакимияткә буйсынмаган, ләкин урыслар белән уңай мөгамәлә саклаган мәкруһлар пәйда була. Алар ришвәт ярдәмендә өяз, волость, хәтта кайбер губерна канцеляриясе чиновникларын да үз кулларына алалар.

Рәсәйдә Явыз Иван заманыннан бирле ислам дине кысрыкланды. Шуңа карамастан, татарлар арасында иманга тугрылык көчәйде генә. Коръән бастыручы басмаханәләр булмаган чорда да Коръән ишләп күчерелде, таралды. XIX гасыр уртасында Коръән Кәримсез гаилә булмаган диярга мөмкин. Күңелләре иман белән сугарылган мәкруһларның өйләрендә дә, рәсми хакимият чиновниклары тарафыннан чукындырылган дип саналган татарларның өйләрендә дә Коръән сакланды.

Миссионерлар, чиркәү руханилары, өяз жандарм бүлекчәләренең тентү юлы белән мәкруһларны Коръәннән арындырырга маташулары да нәтиҗәсез тәгәлләнә. Мәкруһларның үз арасындагы контрольлек исә көчле була. Әгәр берәр йортта Коръән юк икән, анда яшәүчеләрне үзләре үк керәшеннәр рәтенә кертәләр.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# БАЛАЛАРГА ШАТЛЫК ӨЛӘШҮЧЕ

*Олуг шагыйребезнең юбилее уңаеннан тәкъдим ителә торган бу мәкалә Нил Юзиев тарафыннан 1986 елда язылган.*

Киң катлам укучылар Шәүкәт Галиевне күңелне кузгата һәм уйландыра торган дәртле, хисле шигырьләре, җырлары белән дә, тормыштагы кимчелекләрне, кешеләрдәге йомшаклыкларны үткен күзе белән күреп алган көлкеле мәзәкләре, хикмәтле сүзләре белән дә, нәниләр өчен язган күпсанлы әсәрләре белән дә яхшы беләләр. Бер әдип иҗатында үзенчәлекле хасиятләре белән әдәбиятның өч өлкәсе: лирика, юмор-сатира, балалар поэзиясе ачылып китә, һәм шуны да әйтергә кирәк, шагыйрьнең һәр өлкәдәге иҗаты әдәбият өчен бик кирәкле. Алай да, күп гасырларны иңләгән татар әдәбиятының тарихи үсеш яктылыгында караганда, Ш. Галиевнең балалар әдәбиятындагы эшчәнлеге башкалары белән чагыштырганда күп әһәмиятлерәк. Җәмгыятьнең киләчәге, шул ук вакытта даими үсештә, хәрәкәттәге бүгенгебез дә балалар күңеленә бәйле шагыйрьгә үзенең талантын гадәттән тыш җаваплылык белән эшкә җигәргә куша. «Бүгенге балалар XXI гасырның хуҗалары булыр... Үзебезне алыштырасы буынга алмашка киләсе гасырның күңел нигезләрен төзүчеләр дә—балалар язучылары»,—дип әдип балалар өчен иҗат итүне язучының гаять тә әһәмиятле иҗтимагый бурычы итеп саный. Ш. Галиев 60—70 елларда ук балалар поэзиясенең актив иҗат итүче, әйдәп баручы шагыйре буларак танылды. Бүгенге көнгәчә ул тугрылык, даимилек, тырышлык һәм нәтиҗәлелек белән шушы өлкәдә эшләвен дәвам итә.

Ш. Галиев—балаларның яраткан һәм популяр шагыйрьләреннән. Моны күп тираж белән басылган китапларының тиз арада сатылып бетүе дә, китапханәләрдә әсәрләренең күп укылуы да, балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә концертларда еш яңгыравы да раслый. Шагыйрь фантазиясендә туган Шәвәли, Камырша, Котбетдиннәр хәзер балаларның бик тә якын үз геройларына әверелде. Бу уңайдан «Советская Россия» газетасының шаян героебызга карата биргән бәясе дә бик гыйбрәтле, ул үзенең баш мәкаләсендә, Татарстанда Шәвәли Италиядәге Чипполино, Швециядәге Малыш һәм Карлсон кебек үк популяр, дип язды. Үзенең «Киләчәккә барырлык иҗат» дигән мәкаләсендә олы шагыйребез Хәсән Туфан да: «Шәүкәт мәктәбеннән безнең киләчәгебез булган балалар тапкырлыкка, дөньяны танырга өйрәнеп чыгалар. Зурларның Хуҗа Насретдиннары, Шомбайлары булса, балаларның да Шәвәлиләре бар инде»,—диде.

Шәвәли һәм Котбетдиннәр хәзер татарча гына түгел, башка телләрдә дә иркен сөйләшәләр, үзләренең гыйбрәтле кыланышлары белән төрле милләт балаларын үзләренә караталар, үзләренә ияртәләр. Ш. Галиевнең шигырьләре рус теле аша күп милләтле совет укучыларына барып ирешә. Шагыйрьнең балалар өчен иҗат иткән әсәрләренең абруйлы бүләкләр алуы да аның иҗатының популярлыгы, заман рухына ятышлыгы, халкыбызның культура тормышында әһәмиятле әдәби-эстетик күренеш булуы турында сөйли. «Шәвәли», «Кызык», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән» исемле җыентыклары өчен ул 1972 елны балалар язучыларыннан беренче буларак Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Совет балалар әдәбиятын үстерүдәге казанышлары өчен ул Аркадий Гайдар Билгесе белән һәм Ханс Кристиан Андерсен исемендәге халыкара Почетлы Диплом белән бүләкләнде, исеме Х. К- Андерсенның почетлы исемлегенә кертелде. Дипломда Ш. Галиевнең Татарстан китап нәшриятында русча басылып чыккан «Физзарядка ясый куян» исемле китабы балалар әдәбиятының «Халыкара әһәмияте булган күренекле үрнәге» дип бәяләнә. Шул

рәвешчә Ш. Галиев шигырьләре, татар балалар поэзиясенең үсеш дәрәҗәсен, ул ирешкән казанышларны билгеләп, олы мәйданда—халыклар әдәбияты аренасында да лаеклы яңгыраш тапты.

Һәр талантлы әдип үз чорының балалар дөньясын шул дәвер таләбенчә һәм үзенчә чагылдыра. Ш. Галиев шигырьләренә дә заман тойгысының көчле булуы хас. «Урамда күрәсең—олылар житәкләгән бала һәрвакыт артка таба тартылып бара. Адымга өлгерә алмаганга түгел, текәлеп карыйсы әйберләр күп булганга! Без бит өстән-өстән генә карап йөгерәбез... Балалар белән сөйләшү өчен алга барып, шактый нәрсәләр күреп куярга кирәк»,—дип бик дөрес нәтиҗә ясый шагыйрь. Ш. Галиев шигырьләреннән күренеп тора: нәни бала белән дөнья гизәргә чыккан шагыйрь абыйлары шактый тәҗрибәле, күзәтүчән, үткен күзле икән. Ул балалар дөньясын да, аны камаган тирә-юньне дә яхшы белә, аның нәниләр белән сөйләшер сүзе күп. Ул үзе дә, геройлары да тормышка өстән-өстән генә карап йөгермиләр, ә һәр нәрсәгә текәлеп карарга тырышалар. Шуңа да беренче карашка гади генә булып күренгән күренешләр, ни-нәрсәләр мәгънәле, серле яклары белән ачылып китәләр.

Заманчалык шигырь орбитасына эләккән тормыш күренешләренең тышкы билгеләрендә дә—нәниләрнең бүлмәне космос, сандыкны ракета итеп, үзләренең космонавт булып уйнауларында да, чех дуслары белән хат алышуларында да, шәһәрдәге зур төзелешләрне күзәтеп, аларны рәсемгә төшерүләрендә дә, тилгәннең чын бәбкә урынына пластмасса бәбкә эләктерүендә дә күренә.

Заман тойгысы Ш. Галиев шигырьләрендә тирән булып уелган, шигырьләренең нечкә күзәнәкләренә кадәр үтеп кергән. Чөнки шагыйрь аны көнкүрешнең тышкы билгеләрендә генә күрми. Ул—шагыйрьнең фикерләвендә, аның балаларга мөнәсәбәтендә, балаларның психологиясендә.

Балаларга гомер-гомердән кызыксынучан булу хас. Хәзерге чорда, информация көчле ташкын булып ишәйгән бер заманда, нәниләрнең шушы хасиятләре балалар әдәбиятында да дәвергә хас рәвештә тирәнрәк ачыла бара. Ш. Галиевнең нәни геройлары да—үтә кызыксынучан һәм күзәтүчән балалар. Күпне белергә омтылучан, тикшерүчән, уйланучан балалар. Бүгенге көн балалары. Хәзерге нәниләрнең шушы хасиятләрен тирән тою шигырь структурасының үзенчәлекле корылышында да сиземләнә. Шигырь үзе аңарда еш кына баланың хакыйкатьне, тормыш серен ачу процессын гәүдәләндерә. Бала уйлый, нинди дә булса сорауга җавап эзли. Кайсы шигырьдә ул җавапны табып та өлгерә, ә еш кына сер шигырьнең артында кала. Шигырь үзе баланы уйлату өчен этәргеч көчкә әверелә.

Ш. Галиев нәнине дөнья белән таныштыруны аның үзен камаган тирәлектән башлый. Олы дөньяга чыгу өй эченнән үк: әти-әниләреннән, әби-бабаларыннан ук башлана. Гыйбрәтле хәл-әхвәлләр, кызыклы биографияләр, героик тарих эзләре баланы камаган тирәлектә үк тулып ята икән ләбаса! Әбисен солдат итеп күз алдына китерүе нәнигә сәер, әмма әбисе чыннан да Бөек Ватан сугышында очучы солдат булып катнашкан, батырлыклары өчен орденнар белән дә бүләкләнгән икән.

Шигырь саен нәни бала табигатьнең ниндидер бер сыйфаты, дөньяның ниндидер бер кызыклы сере белән таныша бара. Шагыйрь табигатьне, тормышны аңларга гына түгел, аның матурлыгын, төрлелеген күрергә, шул төрлелегендә яратырга да өйрәтә. Менә томанлы көнне ул ни рәвешле образлы итеп күз алдына бастыра:

*Үзәннәргә, тугайларга*
*Тулган сөт кебек томан,*
*Чүмеч белән чиләкләргә*
*Тутырып булыр сыман...*

Ш. Галиев поэзиясендә белем бирү тәрбия максатларыннан аерылмый. Шагыйрь милләтнең әхлак принципларын нәни «гражданнар»ында тәрбияләүгә зур әһәмият бирә. Әхлак мәсьәләләренең күп шигырьләрендә күтәрелүе дә шул турыда сөйли. «Әдәбиятның бурычы,—ди шагыйрь,—кешеләрне яхшырту. Мона никадәр иртәрәк алынсаң, шулкадәр нәтиҗәле. Нигә кешенең кимчелекләре үзе белән бергә үскәнен көтәргә? Соңыннан дәвалыйсы урынга башта профилактика булсын. Менә

ни өчен мин балаларга атап язам». Шуңа да балада унай сыйфатлар тәрбияләү мәсьәләсе шагыйрь күтәрү белән бергә, балаларның үзләренә генә кагылышлы әхлак проблемаларына да игътибарын көчәйтә бара. Нәни Шәвәли дә соңгы елларда үсә һәм житдиләнә төшкән. Хәзер инде аның дөньясы көпә-көндез фонарь кабызып, бүлмәләр буенча чаба-чаба, төн эзләп йөрү белән генә чикләнми: ул диңгез буенда да була, Әстерхан якларында карбызларның ничек үсүләре белән таныша, «Себерне жылытучы» нефтьчеләрне дә күрә. Баланың уе да уенда гына түгел: ул да дөньяның хәвефле хәле турында уйлана, борчыла («Бомбалар үрчи,—әллә шашына,—ничәшәр тонна кеше башына»).

Табигать турындагы шигырьләрендә дә яңалык бар. Әгәр дә элегрәк нигездә табигатьнең серләрен ачу, аны танып-белү, өйрәнү игътибар үзәгендә торса, хәзер инде автор мондый карашны ачкан шигырьләр белән генә чикләнми. Шагыйрь табигатькә сак һәм сизгер мөнәсәбәт тәрбияли торган шигырьләр дә иҗат итә. «Нефть таптык», «Тургайлар министрына хат»—әнә шундыйлардан. Яр читеннән агып яткан нефтьне күргәч бала иң әүвәле «нефть таптым!» дип шатлана. Әмма бу олыларның саксызлыгы аркасында елгага аккан нефть булып чыга...

Ә инде самолеттан басуларга «дару» сиптерелгәч, кырда тургайлар юкка чыга. Шуңа борчылып бала «тургайлар министрына хат» яза:

*Абый!*
*Быел бездә тургайлар юк,*
*Мин аларны һаман көтәм,*
*Килмәсләрме инде бүтән?*

Ш. Галиев баланы табигатьнең аерым хасиятләре белән таныштырып кына калмый, бүгенге җәмгыятьнең кешелекне борчыган олы һәм тирән каршылыкларына, катлаулы күренешләренә алып керә, шулар турында уйланырга этәрә, кечкенәдән үк табигатьне саклаучы, аны яратучы кешелекле кеше тәрбияләргә омтыла.

А. М. Горький үз вакытында әдипләр алдына нәниләр өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итеп язу бурычын куйган иде. Бу бурычның әле һаман да әһәмиятен югалтканы юк. Ш. Галиев балалар психологиясен дә, балалар әдәбиятының үзенчәлекләрен дә тирән аңлап иҗат итә. Ул нәниләргә житди нәрсәләр турында кызыклы һәм мавыктыргыч итеп, балалар теле белән сөйли белә. Бу өлкәдә ул, бер яктан, татар әдәбиятының үз традицияләренә—Г. Тукай. Ә. Фәйзи, Б. Рәхмәт өлгеләренә таянса, аларны үстерсә, икенче яктан, күп милләтле совет әдәбияты тәҗрибәсен искә алып иҗат итә. Зурлар поэзиясендәге шигъри тәҗрибәсе дә (балалар өчен шигырьләр иҗат итә башлаганда аның лирика һәм юмор-сатира өлкәсендә бай тәҗрибәсе бар иде), халык авыз иҗатын, телен яхшы белүе дә аңа ярдәмгә килә. Шушы бай традицияләр синтезы ^шагыйрьгә балалар әдәбиятында тиз ачылып китәргә һәм иҗатының төп пафосы булу дәрәҗәсенә күтәрелә. Моның үтемле чарасы итеп ул юмор-сатираны саный. Көлкеле әсәрләрнең аның иҗатында зур урын алуы менә шуңа бәйле. Аның мондый шигырьләреннән дә яхшылык, ярату, жылылык ташып тора. Тәнкыйть орбитасына кемнәр генә эләкми: көч саклыйм дип эшләмичә яткан, нәтиҗәдә сабан туенда җиңелгән Тимерша да, мактанчык Ирек тә, тыштан яхшы булып күренгән, ә үзе астыртын гына киресен эшләгән Тәүфыйк та, бер ел буе әбисенә хат язмаган Кәли дә бар.

Ш. Галиев бик белеп кенә, өйрәтүдә чама тойгысын югалтмыйча гына нәнигә аның тирәлегендәге күренешләрнең «төсләр»ен, холыкларын, кеше характерындагы яхшы-начар якларны аерырга өйрәтә. Шагыйрь дөрес әйтә:

*Шигырьләр бит, балалар,*
*Витамин кебек алар:*
*Күңелләрне үстерә,*
*Йөрәкләргә көч бирә.*
*Булса кайчак әчкелтем,*

*Монысын белә ич һәркем—*
*Хак сүз булмый төчкелтем!*

«Хак сүз»не балаларга нинди күләмдәрәк һәм ни рәвешлерәк үтемле итеп житкерүне шагыйрь житди мәсьәлә итеп саный. Матбугатта 80 елларда басылган шигырьләреннән шагыйрьнең үзенә тагы да зуррак таләпләр куюы, балалар шигъриятенең тапталмаган сукмакларын, яңа юлларын тагын да тырышыбрак эзләве күренә.

Шагыйрьнең эзләнүләре һәм үсеше ниндирәк юнәлештә бара соң?

«Ленин бабай икмәк булә» шигырендә ул нәни бала белән житди темага олы сөйләшү алып бара, нәнине кыю рәвештә ижтимагый-политик өлкәгә алып керә. Төп эзләнү юлын һәм үсеш тенденциясен балаларны бүгенге чынбарлыкка, аның катлаулы дөньясына кыюрак алып керү, бүгенге олы тормыш, аның төрле яклары белән тирәнрәк таныштыру, житдирәк әхлак мәсьәләләрен күтәрү дип билгеләргә мөмкин булыр иде. Шушы яңа югарылыкның иң характерлы мисалы—«Әни, дим, әчмә инде!» шигыре. Сабыйның ачы җан авазы булып яңгыраган бу шигырь игътибарны бүгенге тормышның катлаулы якларына юнәлтә. Бу шигырь балаларны гына түгел, олыларны да тетрәндерә, сискәндерә, уйландыра. Артык зур булмаган бу әсәр балалар әдәбиятының бүгенге тормыштагы зур мәсьәләләрне күтәрә алуы, шул өлкәдәге олы мөмкинлекләре турында сөйли. «Көзгеләр көлеп тора», «Ярышу», «Ике төрле карандаш» шигырьләрендә дә бала күзе аша олылар дөньясындагы кимчелекле күренешләр кыю тәнкыйть ителә.

Ш. Галиев, балалар дөньясына да, олылар тормышына да бердәй дәрәжәдә караган әнә шундый житди әхлакый мәсьәләләрне тиз танылырга жирлек булды, шигъри ачышларының, табышларының бу өлкәдә аеруча бай булуына сәбәпче булды.

Балалар поэзиясендә Ш. Галиев шигырь формасы һәм жанр өлкәсендә үзен лирикага һәм юмор-сатирага караганда күп тапкырлар иркенрәк итеп тоя. Монда аның шигыре бала табигате кебек тере, хәрәкәтчән, йөгерек, тиктормас—ул эчтәлеккә хас рәвештә гел үзгәрә, янарып тора. Шуңа да шагыйрьнең жанр һәм шигырь формасы өлкәсендәге табышлары һәм ачышлары биредә аеруча нык күзгә ташлана, «һәр шигырьнең үз тыны, үз дөньясы булырга тиеш. Шагыйрь менә шуны дөрес тоеп, әсәрендә камиллеккә ирешә алса гына, шигыре дә үзенчәлекле булыр»,—дип яза шагыйрь һәм һәр шигырьне тулы канлы, җанлы спектакльгә тинли.

Автор үзенең «витаминлы» фикерләрен ялангач рәвештә көчләп такмый, сабый күңеленә төрле кызыклы хәлләр, гажәп күренешләр, күңелле вакыйгалар аша сеңдерә. Дөнья балага кызыклы, серле булып тоела. Ләкин шагыйрь шигырь эчендәге күп төрле уеннар, мәзәкләр белән генә чикләнми, бу уенга шигырьнең үзен дә, шигырьдәге сүзләрне дә куша. Сүзләрне дә уйната, үз ихтыярынча биетә. Шагыйрь нәни укучысын үз тирәсендәге дөньяны танып-белергә, андагы яхшы һәм начарны аера белергә генә түгел, сөйләшә белергә дә—туган телнең байлыгын, матурлыгын күрергә дә, музыкасын, шигъри нәфислеген тоярга да өйрәтә.

Сүзне шагыйрьнең үз сүзләре белән тәмамлыйсы килә: «Балалар өчен язуымның, ниндидер вакыйгалар, гажәп хәлләр, мәзәк хәлләр сөйләвемнең максаты акыл өйрәтү, әзер өлгеләр биреп кую түгел, йөгерек, тапкыр фикер йөртергә күнектерү, туган телнең тәмен сеңдереп кую. Иң мөһиме шул—шәхеснең мөстәкыйльлеге. Калганын ул үзе эшләр, хакыйкатенә, хаклыгына таянып үзе ирешер!».

Без дә моңа ышанабыз.

**Нил ЮЗИЕВ,**
*филология фәннәре докторы,*
*Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

## БЕЗНЕ БЕЛӘЛӘРМЕ?

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫНДА ЧЫККАН
«БАЛАЧАК ӘДИПЛӘРЕ» ТОМЛЫКЛАРЫ ТУРЫНДА

Әдәбият һәм мәгърифәт файдасына кылынган бик тә җитди һәм үтә савaплы гамәл турында, ягъни "Мәгариф" нәшрияты чыгарган "Балачак әдипләре" дигән дүрт томлы китап хакында язарга утыргач, инде унбиш ел элек вафат булган күренекле шагыйребез Мәхмүт Хөсәеннең бер сүзе искә төшеп елмайтты...

Хәтердә: кайсыдыр редакция бүлмәсендә өч-дүрт язучы сөйләшеп утырабыз. Шунда беребез, монаеп китеп, мондыйрак фәлсәфә куерта башлады:

—Менә язабыз инде без... Укучы күңеленә хуш килердәй, гыйбрәт вә фәлсәфә өстәрдәй әсәрләр иҗат итәргә тырышабыз... Ләкин безнең иҗатны, кемлегебезне укучыларыбыз белә микән соң? Бигрәк тә үсеп килүче яшь буын, мәктәп балалары белә микән, дип әйтүем инде...

Шул вакыт көр тавышлы, шагыйрьлегә өстенә йөзләрчә сәхнәләрдән чыгышлар да ясап каешланган Мәхмүт агаебыз кыланчык тавыш белән капыл гына:

—Безне беләләр!!!—дип куйды. Әлбәттә инде, рәхәтләнеп көлдек. Ә теге монсу сорау, кем әйтмешли, һавада эленеп калды:

—Безне чыннан да беләләр микән?...

Бу җәһәттән биш-алты сәхнәдә җырлап кул чаптырган, бер генә мәртәбә булса да телевизор экранынннан да күренгән замана кызлары һәм егетләре бәхетле, ичмасам: алар инде үзләрен шундук сәнгать йолдызына, моңарчы тиңе күрелмәгән җырчыга саный башлыйлар!.. Ләкин гомере буе халыкны туган телгә, әдәбиятка гашыйк итү, шул ук халыкка акыллы һәм файдалы фикерләр өстәү нияте белән дистәләрчә китаплар да язган, Ходай биргән миссиясен тирән аңлаган әдипне арзанлы шөһрәт кармагына эләктерә алмыйсың. Чөнки, нинди генә жанрда язмасын, ул—фикер иясе, халкының акыл чүлмәге. "Менә мин инде ул иң шәп шагыйрь, (хикәяче, романчы, драматург!..)"дияр идең, өстән—Тукай, як-яктан Фатих Әмирханнар, Галимҗан Ибраһимовлар, Һади Такташлар, Камаллар, Кәрим Тинчуриннар, Нәкый Исәнбәтләр, Кави Нәҗмиләр, Фатих Хөснипәр, Фатих Кәримнәр, Әмирхан Еникиләр, Гамил Афзаллар... кумәкләшеп көләр һәм шул гөнаһлы шапырынуың аркасында булган сәләтең дә корыр кебек. Ләкин, яшерен-батырын түгел, һәр язучының үз халкы алдында кадерле һәм танылган буласы килә. Һичьюгы, үзенең укучылары алдында билгеле булуына, "без бу язучыны беләбез" дидертерлек әсәрләр иҗат иткәненә инанасы килә. Иң зур өмет һәм хыял—мәктәп юлына кергән сабыйлар күңеленә "кармак салу", аларның зиһененә кереп калырлык, язучының үзенә дә, әдәбиятка да мәхәббәт уятырлык гыйбрәтле кыйссалар иҗат итүдер. Хәтта, бала күңеленә берничә кәлимә тамызып, шуларны гомере буе онытa алмаслык итеп сеңдерә алу да зур бәхет! Шуңа ирешә алдыңмы, бу бала инде гомере буе матбугаттан, меңнәрчә китаплар арасыннан синең исемеңне эзләячәк!

И, ул бала җанының нечкәлеге, җорлыгы, садәлеге! Бүгенгедәй күз алдында, өч-дүрт малай тезелешеп Ык буеннан—балыктан кайтып барабыз. Тамак җилләгән, кайта-кайта хәл киткән, тез буыннары йомшаган, һәркайсыбыз әлсерәп беткән... Үләнгә авып ял итәсе килә. Шулчак Хәниф дигән дустыбызның: "Гата, сазга бата-бата, куып йөрде бака..." дип әйтүе була, тәннәребезгә рәхәт дулкын йөгерә. Кызык! Күтәрелеп көләбез. Ни өчен дисәң, үзебез дә Абдулла Алишның шул Гатасы кебек, суга, сазга бата-бата, эләкмәс балык "куып" йөргәнбез бит. Шундук икенче малай шигырь укый башлый: "Хәйдәрнең аты булган, колагы

каты булган, сызгырсаң ишетмәгән, сыптырсаң килешмәгән... рәттән тугыз мәртәбә тибә икән тәртәгә". Аңлашылгандыр, монысы инде Фатих Кәримгә кереп китте. Өченчебез шул ук шагыйрь сурәтләгән гармунчы Аюның, ачуы килгәч, җиннәрен сызганырга уйлавы, тик көлмәгә булмавы хакында фәлсәфә куертмакчы: "Йәле, малайлар, шул Аюны күз алдыгызга китерегез... Җиннәрен сызганырга бик тели, ә көлмәгә юк! " Ярсыган Аюны кат-кат күргәндәй булып, тагын дәррәү көләбез... Ямаулы киндер ыштанның балаклары сызганылган ялантәпиле, күңел тулы шигырьле балачагым искә төшкән саен, күземнән шатлык яшьләре тамып тору һаман да бәхет минем өчен...

Әйе, әдәбиятка мәхәббәт ул адәм баласына ана сөте һәм туган тел белән бергә керсә генә гомерлек була. "Әдәбият" сүзенең "әдәп" төшенчәсеннән яралган булуын да истә тотсак, үз милләтенең әдәбиятын укып һәм белеп үскән кешеләр генә гомер юлыннан барганда афәтле сукмакларга кереп саташмый, ачыну һәм үкенү җәфаларына тарымый. Чөнки әдәбият—халыкның күп гасырлар буе җыйган акылы да, яшәү тәҗрибәсе дә ул.

Менә шушы бик тә җитди, үтә зарури миссияне бөтен тирәнлеге белән аңлап, Татарстанның "Мәгариф" нәшрияты соңгы елларда "Балачак әдипләре" дигән дүрттомлык бастырды. Шул китапларның кайсысындыр кулга алып укый башлауга ук нәшриятның изге максаты өлкәннәргә генә түгел, мәктәп балаларына да аңлашыла: яшь буынны үзе үскән замандагы күренекле әдипләрнең тормыш һәм иҗат юллары белән кинрәк таныштыру. Ягъни, рәсмирәк тел белән санап үтсәк, теге яки бу язучы кайда һәм нинди гаиләдә туган, нинди бәхетләр яки кайгылар, сөенеч вә көенечләр күрә-күрә, тәүге мәртәбә кулына каләм алып, беренче әсәрләрен язарга ниятләгән, кайчан һәм нинди китаплар бастырып чыгарган, аның иҗатына замандашлары нинди бәяләр биргәннәр... Исеме чорыбызның һәр татарына мәгълүм Гамил Афзал әйтмешли, һәм башкалар, һәм башкалар инде—язучылар турында белмәгәнең калмый да сыман...


*2002–08 елларда чыккан басмалар.*

Беразшаяртып та үтсәк, язучылар берлеге үзе бер колхоз ул. Әйтик, һәр колхозда тәмледән-тәмлене ашап кына, затлы киемнәр, елтыр туфлиләр киеп кенә тарантасларда, кошовка йә машиналарда җилдереп үсәчәк "персидәтел", хисапчы, завсклад малайлары яки кызлары туа. Шул ук колхозларда ямаулы ыштан, чабата киеп, арба-чана тартып теркелдәүче ачлы-туклы балалар да гомер-бакый күп булды. Төрле-төрле булсалар да, һәр баланың сәләтле булып үсәсе, киләчәктә "күрекле һәм бүрекле", ягъни чын кеше булып яшисе килә. Бу җәһәттән караганда, әдипләрнең дә шактые—зур түрә, язучы, галим, укытучы кебек затлы, белемле ата-анадан, ә күбесе көнлек ризыгын һәм өй түбәсенә ябар саламын да зур тырышлыклар, чиләнүләр белән тапкан җир сөрүче, терлек караучы һәм гади эшчеләрдән туган. Кемнәрдән генә тумасыннар, тора-бара, яхшыдан-яхшы әсәрләр тудыра-тудыра, танылганнар, әдәбият сөючеләрнең игътибарын яулауга ирешкәннәр һәм, ниһаять, "Язучылар берлеге" дигән "колхозга" кереп тупланганнар. Әйткәнемчә, һәркайсының зур хыялы—асыл әсәрләр тудырып, әдәбият мәйданында күренекле булу. Ләкин безнең, ягъни язучыларның, тагын да зуррак уртак хыялыбыз бар. Һәркайсыбыз:

—Бездән соң да әдәбиятыбызга сәләтле, хәтта үзебездән дә сәләтлерәк язучылар

буыны килсен иде, халкыбыз туган телгә, милләттәшләренә ярдәмчел гавам булып яшәсен иде!...—дигән өмет белән яшибез. Менә бу "Балачак әдипләре" (төп авторы, туплаучысы Рәис Даутов) дигән исемдә чыгып барган китапларны да нәкъ менә шул максат белән чыгарганнардыр, мәгърифәт дөньясына (иң әвәле—мәктәпләргә!) таратканнардыр дип аңлау ялгыш булмас кебек. Ни өчен дисәң, язучылар бер-берсенең кемлеген, иҗатын болай да яхшы беләләр...

Һәр китаптан теге яки бу язучыга ун бит чамасы "кишәрлек" бирелгән. Аңа:

1. Язучының биографиясе,
2. Аның иң әһәмиятле китапларыннан торган исемлек,
3. Библиографик белешмә, ягъни бу әдипнең иҗаты, тормышы турында матбугат басмаларының кайсында һәм кайчан нинди язмалар, мәкаләләр басылуы турында мәгълүматлар,
4. Әдип хакында төрле шәхесләрнең кыскача бәяләмәләре,
5. Язучының әдәбиятка ничек килә башлаганлыгы турындагы үз язмасы,
6. Биографиясенең кыскартылган урысча варианты сыйган.

Шик тә юк, аларның һәркайсы адәм баласында кызыксыну уятачак, язучылар кавеменең хәл-әхвәле белән шактый тулы таныштырачак дигән өмет тудыра. Ләкин шундук ошбу томнарның "проектчысы"—аның милләт, мәгърифәт өчен кирәклегенә беренче булып иман китергән шәхеснең—танылган тәнкыйтьче, тирән мәгънәле шагыйрь һәм "Мәгариф" нәшриятының баш хуҗасы Мөдәррис әфәнде Вәлиевнең дә (әдәби тәхәллүсе-псевдонимы—Салих Маннапов) бу томлыкларга карата үз бәясе, билгеләмәсе искә төшә. Беренче томның ахырдагы язмасында ук болай ди нәшрият башлыгы: "... без укучыны кызыксындыруы ихтимал булган бөтен сорауга да җавап бирү максатын куймадык. Киресенчә, берничә биттә фактик мәгълүмат, гомуми күзаллау алганнан соң, сездә яңа сораулар тусын, күренекле каләм иясенең иҗаты һәм шәхесе белән якыннанрак, тирәнтенрәк танышу теләге көчәйсен дип тырыштык". Ашаган белми, тураган белә, дигәндәй, монысы инде аеруча лаек, гадел бәя һәм ул хәтта балачак хатирәләрен дә яңартып елмайта. Без бәләкәй чакларда ата-аналарыбыз еш кына чистадан-чистарак киемнәрен кия башлыйлар, өйне тагын да тәртиплерәк хәлгә китерәләр, учакка ут төртәләр, самавыр куялар. "Фәлән абзыең (түтәең) кунакка килә, тәртипле бул!" дип кисәтергә дә онытмыйлар. Без инде, әлбәттә, тәртипле булырга тырышабыз. Ләкин теге кунак тупсаны атлауга ук, без—җепшек борыннар, дөньябызны онытып, күзләребезне тозландырып, авызларыбызны күтәреп ишек катына килеп басабыз да... нindirәк күчтәнәч чыгарыр микән бу әткәй белән әнкәебез бик мактаган кеше, дип, тегенең капчыгына текәләбез... Вәлиев-Маннапов хәер-фатиха биргән менә бу китапларда да безне (120дән артык әдипне) мактаганнар, бу абый-апаларыгыз бик шәп язучылар, дигәннәр. Димәк, әдәбиятка игътибарлы, укучыларын да яраткан, алар арасыннан да язучылар чыгу ихтималына өметләнгән мөгаллимнәр дә шулай сөйләргә тиештер... Ә укучы бала теге яки бу язучының "күчтәнәчләре", ягъни китаплары белән кызыксына: аларны кайдан табып була? Әлбәттә инде, сүз дә юк, хөкүмәт каршында да мәртәбә яулаган, бүләк-премияләр иясе булган, алтын тышлы күптомлыклар чыгару әмәлен дә тапкан, йә булмаса депутат яки җәмәгать эшлеклесе кәнәфиендә дә озак утырып, йогынтылы кеше булып танылган язучыларның, шулай ук бөек әдип булуы беркемдә дә шик калдырмый торган классикларның китапларын һәр мәктәп китапханәсеннән табып буладыр ул хәзерге цивилизацияле заманада... Ләкин бу дүрттомлык таныштырган әдипләрнең ничәсе генә бар икән дәреслекләрдә? Шуңа күрә әдәбиятка гашыйк балалар күңелләренә хуш килгән язучыларның "күчтәнәчләрен" үзләре эзләп табарга тиеш булырлар.

Шунысы да еш искә төшә: дәреслекләргә кергән язучыларның бик сирәкләрен ярата идек без мәктәп елларында. Ләкин яратмаганнарның да әсәрләрен укырга, хәтта ятларга мәҗбүр идек. Җавап биреп, "икеле"дән котылу, бер сыйныфтан алдагы сыйныфка күчми калмау өчен генә... Андый язучыларны мәктәп

капкасыннан чыгуга ук оныта идек тә, үзебезнең күнелгә хуш килгәннәренен китапларын табу өчен Минзәләнен бөтен китапханәләрен актарып йөри идек. "Балачак әдипләре" бу җәһәттән дә күп балаларга юл күрсәткеч булып хезмәт итәрдер әле!

Бу томнарны еллар буе актаргалап, укыштырып яши торгач, (шул ук Мөдәррис әфәнде әйтмешли, башыннан ахырына хәтле бер утыруда укып чыга торган күптомлык түгел бу!) бер нәтиҗә ясадым үземчә: мөгаен, бу китапларнын иң яратып укыла торган өлешләре әдипләрнен үзләре турында язганнарыдыр. Мәсәлән, балалар һәм өлкәннәр өчен дә гыйбрәтле, кытыклаучы әсәрләре белән кадерлегә әверелгән Шәүкәт Галиевнын шагыйрьлеге... "Сак-сок" бәетен тынлаудан башланган икән. Җәелмичә-кинәймичә бары тик шул турыда язган Шәүкәт абзабыз. Ләкин укучысынын җелегенә төшәрлек итеп ышандырган. Мәгълүм инде, бәет әнкәләре каргышын алган балаларнын кавыша алмыйча тилмереп йөрүләре турында...

*Аклы күлмәкне туя кимәдем...*
*Газиз әнкәмне туя күрмәдем...*

"Үксүем сизелмәсен дип юрган читен тешлим. Ник ул малайлар әнисенә карышты икән? .. Ник шулай каргады икән әниләре?"

Шәүкәт агайнын нәрсәдән елавын анлагач: "Мин дә беренче мәртәбә шул бәетне тынлаганда еладым бит!.." дип ихлас күнелдән әйтер идем дә ана, ләкин кеше бакчасына керергә маташуым булып тоелыр. Мин дә Тукай иҗатыннан авыз иткәнче шул бәетне тынлап җылаган идем бит, югыйсә! Ләкин сон инде... Үзем турында язганда мин тәүге мәртәбә Тукай шигыренә сокланып елавымны язганмын...

Башка язучылар гаеп итмәстер бу "ачышымны", бәлкем: талантлары Ходайдан бирелгән күп каләм ияләре елак була. Кеше кайгысын йөрәкләре, бәгырьләре аша кичереп тә елыйлар, ятимлекләр кичереп үскәннәре дә тетрәнеп елаганнар, үзләрен дә сокландырган фикер яки сюжет уйлап тапкан чакларында да күнелләре нечкәреп, күзләре юешләнеп китүчән. Чөнки хиссез, монсыз, кайгысыз адәм язучы була алмый ул. Син, язарга утыргач, каләменне канына булмаса да, күз яшенә мангаларга да әзер булырга тиешсен!

Татар драматургиясенен кыясына инде күптән менеп утырган Туфан бабагызнын да күнеле бик нечкә икән. Нәрсә язган дисез уч төбедәй җыйнак кына язмасында? Анын язу өстәленә сезнен кебек ( мәктәп балаларына карап әйтүем) оныгы "Бабай, мин сине яратам!" дип язылган кәгазь язып салган икән. Мөкиббән киткән картлач! Мангай күзен белән генә укысан, пүчтәкнен дә пүчтәге инде... Ләкин күзенә мантыйклы күнелен дә кушып укый белгән кешегә күп нәрсә анлашылыр. Картлык белән яшьлекнен дуслыгына, үзара ихтирамына, мәхәббәтенә ишарә ясый мәшһүр драматург. Бәлки анын әдәби талантын да нәкъ менә шул "яратам" дигән сүз үстергәндер. Беренче хикәячекләрен, шигырьләрен, скетчларын укыганнардыр да редакторлар: "Без мондый әйберләрне укырга яратабыз" дигәннәрдер. Үсенеп китеп, җитди драмаларга тотынгандыр. Таләпчән, кырыс режиссерлар да, ачылып китеп: "Маладис, Туфан, мондый пьесаларны яратып кабул итәбез. Тагын яз!" дигәннәрдер.

Һәр язучыга хас булган тагын бер серне ачыйм әле. Һәр язучы шыпырт кына үзенен әдәбиятта тоткан урынын билгеләргә тырыша: "Кайсы каләмдәшләрдән түбәнрәк яки югарырак микән мин? Укучыларым нинди бәя бирәләр икән? " дигән кебегрәк... Күбесе үз-үзенә төгәл җавап бирә алмый. Чөнки әдәбият спорт түгел. Әдәби дәрәҗәне очколар, баллар, шкалалар, призлар вә һәм дә кубоклар белән үлчәү мөмкин түгел. Ләкин, сөбханалла, кайбер кыю каләм ияләре үлчи белүләре белән чын мәгънәсендә сокландырып та куялар! Мәсәлән, танылган язучыларыбызнын берсе—Айдар Хәлим сүз башыбызнын шүрәлесе булган "Балачак әдипләре"ндә ап-ачык итеп болай яза:

"Мин үзем турында татарның киләчәге булган һәм, һичшиксез, Тукай йолдызлыгыннан булган зур шагыйремен дип уйлыйм. Мин бүген татарның иң күп укыла торган шагыйре, прозаигы, публицисты һәм ихтирам ителә торган җәмәгать эшлеклесе... Минемчә, монда арттыру юк. Болай уйлаучылар, минем белүемчә, татар бар җирдә бихисап. Минем үземне болай итеп тануымнан миңа күңелләме соң? Юк. Күңелсез, ай-һай моңсу миңа! Миңа иптәшкә үзем кебек тагын да бер-ике, өч-дүрт язучы кирәк булыр иде! Бирче, Аллаһ!"

Якын дустым һәм каләмдәшем язмасыннан шушы өзекне күчереп алуга ук... һичьюгы бер атна чамасы татар теле һәм әдәбияты мөгаллиме буласым килеп китте. Чөнки бу кыю да, тәвәккәл дә сүзләр укытучы өчен көтелмәгән табыш, минемчә! Шуларны файдаланып, мәктәбемнең төрле сыйныфларында ирекле дәресләр үткәрер идем. Ягъни: алып керер идем дәрескә берничә татар шагыйренең (Айдар Хәлимнекеләрне дә тыгып, әлбәттә) икешәр-өчәр шигырен һәм:

—Укучыларым! Бүгенге дәресне мин сезнең шигырьләргә карата зәвыкләрегезне барлап карау өчен багышларга булдым. Хәзер мин сезгә, авторларының кемлеген әйтмичәрәк торып, берничә шигырь укыйм. Ә сез шул шигырьләрдән күңелегезгә аеруча хуш килгәннәрен сайлагыз, аннары миңа әйтерсез. Шуннан соң гына теге яки бу шигырьнең авторларын белербез,—дип сүз башлар идем. Ачыклап кына калмас идем балаларның үтә сизгер рухларын яулаган авторларны, бәлки шушындый дәресләрнең гыйбрәтле һәм файдалы үрнәкләре хакында, төгәл мәгълүматларны да теркәп, Татарстан матбугатында тәҗрибә дә уртаклашыр идем. Кем белә, бәлки мондыйрак рухтагы язмаларның кайберләрен кулыгыздагы олуг журналыбыз да үз битләрендә бастырып чыгарыр иде. Һәр мәктәптә шундый иҗади дәресләр үткәрү гадәткә керсә, бәлки әле Айдар Хәлимнең Аллаһтан ялварып сораган ике-өч, хәтта өч-дүрт тиңдәше дә табылып куяр иде. Бер үзе генә Тукай йолдызлыгында булу, аңлап үткәнегезчә, күңелсез дә, моңсу да бит аңа... Шулай булгач, ошбу дүрттомлык әзерләнгән елларда вафат Гамил Афзал, Мөдәррис Әгъләм, Роберт Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Илдар Юзеев, Нурихан Фәттах, Наис Гамбәр кебек язучы һәм шагыйрьләрнең гүр тынычлыгын бозмыйча гына, исән каләм ияләре арасыннан ул теләгән өч-дүрт кенә кандидатны тәкъдим итеп карыйк әле аңа иптәшкә. Әле бая гына телгә алынган Туфан Миңнуллин лаек була алмас микән шуларның берсенә? Ул бит әле драматург кына түгел, бәлки тирән мәгънәле шигырьләре белән "азу ярган" шагыйрьләрнең дә борынына чиертеп сискәндерердәй каләмче. Милләт өстәленә, көндәлек матбугат битләренә салып, чын да, гыйбрәтле дә хикәятләр сибеп торуын әйт тагын! Бөтен матбугат та, әдәбият һәм сәнгать тә шуның җилкәсендә тора сыман бит. Инде ике дистә елга якын Югары Совет мөнбәреннән дә, радио һәм телевидение чаралары аша да кайный-кайный Татарстан мөстәкыйльлеген куәтләп чыгышлар ясап торучы бу депутатны җәмәгать эшлеклесе дип танымый булмыйдыр, ә? Минемчә, менә дигән иш булырлык ул Айдарга! Бар ул бездә Равил Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Лена Шагыйрьҗан, Марсель Галиев, Мансур Вәли-Барҗылы, Газинур Морат, Разил Вәлиев, Мөхәммәт Мирза, Нәҗибә Сафина кебек милләт күңелен дистәләрчә еллар буе яулап килүче, иҗатлары белән сокландыручы затлар!.. Соңгы елларда мин тагын бер шагыйрьнең үсүен сөенеп күзәтәм. Яшен бик яшь ул—миңа онык булырдай гына зат... Әмма, сөбханалла, балалар өчен язучы шагыйрьләр арасында иң сәләтлесе һәм иң кирәклесе шул Ленар Шәех түгел микән хәзер?! Менә кемнең шигырьләрен салырга кирәк мәктәп балаларының алдына! Валлаһи, дип әйтәм, шуннан үрнәк һәм рух алып кына да бүгенге мәктәп укучыларыннан дистәләп шагыйрь үсеп чыгачак алдагы ун ел эчендә. Хәтта минем талантлы мәсләктәшем һәм кадерле дустым Айдар да яратыр аны, йолдызлыкта япаялгыз моңаеп җемелдәгән чакларында үзенә иш итеп, дәвамчы итеп кунакка да чакыргалар. Шөкер, бу егетебезне дә кертkәннәр 120 сайланмыш язучылар арасына һәм бик гадел эшләгәннәр—аның турында да мул гына белешмә бар "Балачак әдипләре"нең соңгы дүртенче томында. Әйе, сүз уңаенда ачыклык

кертеп үтү мәгъкульдер, соңгысы икән шул инде... Чөнки бу әдәбият белән мәгърифәтне бергә үргән, һәр икесенә зур таяныч булып әверелгән китапларның дүртенчесендә аларның редакторы Люция Гыйззәтуллинаның тәенләмәсе бар. “Бусы, шаять, ефәк пута белән бәйләп куючысы булыр”, ди ул. Сәбәбен дә үпкә калдырмаслык итеп аңлата, “Мәгариф” нәшриятының төп юлы, миссиясе дәреслекләр һәм фәнни-педагогик хезмәтләр генә бастыру икәнлеген, ә инде боларының мөмкин булмаганны булдыру галәмәте икәнлеген әйтә. Шунысы да бар икән әле: кайбер язучылар үзләре турында мәгълүматларны бик “ялындырып”, озакка сузып тапшырганнар... Ә безнен, ягъни язучыларның, бу каләресенә дә зур рәхмәттән гайре сүзебез юк.

Әйе, Ленар Шәех кебек каләм ияләре—әдәбиятның киләчәк таянычлары, тоткалары булырлар, ә безнең буынга инде иҗатны түгәрәкләр вакыт житеп бара, дип дәвам итмәкче идем дә сүземне, Равил Фәйзуллин жинемнән тартып туктаткандай булды. Миннән әлләни яшь булмаса да, “Үзем турында үзем” дигән өлешенә болай язып куйган икән ул: “Иҗатны балалар язучысы булып башлаган идем һәм байтак еллар дәвам да иттем... хәзер дә балалар шагыйре булырга хыялланып яшим. Чөнки балалар язучысы булу сабыйлыкка, сафлыкка кайту дигән сүз. Ә кемнең болганчык, шактый ук пычранган сулык-күлдәвекләрне күргәннән соң чиста-пакъ чишмәгә йөз куясы килмәс икән!” Бу юлларны өстән-өстән генә укып чыккач, көлмәкче дә идем башта, карале, бу картлачның хыяллары мулдан икән әле, кабат яшәрмәкче икән, дип... Ләкин игътибар белән кабат күз йөрткәч, моңсу да булып китте... Шулай шул, безгә, нәфис әдәбиятка чумасы, балаларыбызга да садә рухтагы әсәрләрне күбрәк иҗат итәсе урында мөстәкыйль яшәү омтылышыбызга шашынып ташланган шакшы шовинистлар, күнел кайтаргыч космополитлар, татар халкын үз Татарстаныннан сифилислы тарафларга куарга кыжраган дерьмократ-фашистлар һәм тагын әллә нинди жирәнгеч империячел әтрәк-әләмнәр белән матбугат битләрендә, шулай ук радиолардан, телевизор экраннарыннан һәм дистә меңнәрчә милләттәшләребез жыелган зур мәйданнарда аяусыз көрәшергә туры килде. Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Мәхмүт Әхмәтжанов, Миргазиян Юныс, Зәки Зәйнуллин, Әмир Мәхмүдов, Рәфикъ Юныс, Равил Фәхретдинов, Нәжибә Сафина, Вахит Имамов, Рабит Батулла кебек талантлы да, тәвәккәл дә гаярьләребез каләмнәрен дәһшәтле коралга әвереллдерделәр, халыкның аңын ачы хакыйкатькә юнәлдерделәр. Үземнең дә күп китапларым милли азатлык темасына язылган публицистик әсәрләрдән тора... Әлбәттә инде, Равил Фәйзуллин да әллә нинди “штанистлар” әзерләгән пычрак күлдәвекләрне әйләнеп үтә алмады: аның әле татарның телен, бәйсезлеген яклап Югары Совет мөнбәреннән өзгәләнеп, ялкынланып ясаган чыгышлары хәзер дә колак төбендә яңгырап тора сыман. Нишлисең бит, пычраклар белән сугышканда үзең дә пычранмый кала алмыйсың... Әнә шул вакыйгаларны күздә тота икән бит Равил каләмдәшем! Ләкин тәмам чистарынып бетү насыйп булыр микән безләргә?.. Мөмкинлек туар микән? Провокацион сугышлар, татар халкының азмы-күпме ачылган күзен капларга, “азатлык!” дип кычкырасы авызларын томаларга маташулы сәясәт һаман дәвам итә ләбаса!.. Балаларның саф чишмәдәй мөлаем күзләренә, гөнаһсыз рухларына лаек әсәрләрне күбрәк язасы иде дә, “Балачак әдипләре” китабына керүләребезне тулырак акларга иде. Гомерләре буе кадерле балаларыбыз, исемнәребезне дә әйтеп:

—Без бала чактан ук әнә шундый-шундый язучыларны укып үстек, шуңа күрә туган телебезгә дә, милләтебезгә дә мәхәббәтле булып яшибез!—дип сөйләрлек булсыннар иде. Ныграк белер иде безне халык...

**Фәнзаман БАТТАЛ**

# ЛАТЫЙФИ РОМАННАРЫ

Роман—һәр әдәбиятның таҗы, аның үсешен билгеләүче төп монументаль жанр. Күренекле татар прозаиклары арасында романнар язып чын-чынлап танылган, тарихка кереп калган, укучыларның йөрәген яулап алган, тәнкыйтьчеләрне шаккатырган әдипләр бар. Флүс Латыйфиның иҗатын әнә шул төркемгә кертеп карау дөрес булыр: аның һәрбер романы игътибарга лаек һәм әле дә тирәнтен өйрәнүне сорап тора. Мәсәлән, язучының "Хыянәт" исемле тарихи романы әдәби тәнкыйтьтә дә, укучылар арасында да танылу тапты һәм күп яктан өйрәнелде, ләкин калган әсәрләренә, аерым алганда, "Ишелеп төшкән бәхет" һәм "Бәйсез этләрне атарга" романнарына әле дә җитәрлек игътибар бирелмәгән.

Ф. Латыйфиның иң яхшы әсәрләреннән саналган "Ишелеп төшкән бәхет" романы 90-нчы еллар азагында, милли хәрәкәтнең көчле күтәрелеш чорында языла һәм беренче тапкыр 1999 елда "Казан утлары" журналында басылып чыга (1999 ел, № 5, 6). Икенче тапкыр әсәр, аерым китап булып, кирилл һәм латин графикасында 2001 елда дөнья күрә.

Әсәргә беренче җитди бәяне Вахит Юныс бирә (Бәхет һәм тәхет // "Мәдәни җомга", 2000 ел, 4 авг.) Автор әсәрдәге ике очрашуга зур игътибар бирә, өлкән һәм яшь буыннарның бәрелешен үзәккә ала: берәүләр, безнең илдә гаделлеккә омтылып, бәхетне үз хезмәте белән табарга тырышсалар да, һаман бәхетсез калалар, ә башкалары, вөҗданга төкереп, түрәлеккә омтылсалар, якын түрәләргә таянсалар, ал да гөл яшиләр. Автор фикеренчә, романның иң зур кыйммәте—укучыда милитаризмга каршы нәфрәт хисе уяту, чөнки СССР империясендә "вакыт та, көч тә, акча да корал ясарга һәм сугышларга китә, ә юньле тормыш корырга калмый".

Мәкалә авторы, үзенең куанычын яшереп тормыйча, укучыларны тирән уйландырырлык әсәр язган өчен, язучыга рәхмәт сүзләрен кызганмый.

Ф. Сафин исә, әсәрнең бүгенге көн романнарына куелган таләпләргә нигезләнеп язылганын искәртеп, андагы бәхет эзләү мотивының фәлсәфи яссылыкта тасвирлануын билгели: "Әйе, язучының татар халкын бик бәхетле итеп күрәсе килә, аны төрле тормышчан, әмма әдәби кануннар җирлегендә туган ситуацияләргә куеп карый." (Хыянәтсез иҗат. Иҗат портретына штрихлар // "Казан утлары", 2001 ел, № 6)

Д. Заһидуллина үзенең күләмле мәкаләсендә, "Хыянәт" романы белән беррәттән, "Ишелеп төшкән бәхет" әсәренә дә анализ ясый. Соңгысында автор милли тормыш картинасының хәзерге чынбарлыкта тасвирлануын һәм бу миллилек әсәрнең төп сюжет сызыгында ук күренүен билгеләп үтә. Галимә романны милли реализм үрнәге буларак тикшерә, шуна күрә беренче чиратта татарларга каршы алып барылган геноцид сәясәтенә, хакимият һәм шәхес каршылыгына, образларның миллилегенә игътибар итә.

Әсәрдәге төп фикерне Д. Заһидуллина фәлсәфи катлам белән бәйләп аңлата: "Һәр кеше киләчәктәгеләр алдында җаваплы, үткән буыннар, аталар хатасы-ялгышы бүгенгеләргә бәхетсезлек булып «ишелеп төшә», бүгенгеләр ялгышы киләчәктә кайтаваз булып яңгыраячак." (Милли реализм юлыннан // "Казан утлары", 2003 ел, № 6)

Ф. Латыйфиның тагын бер мәшһүр һәм күп яктан уникаль әсәре—"Бәйсез этләрне атарга" роман-нәсере беренче тапкыр 2000нче ел ахырында "Казан утлары" сәхифәләрендә дөнья күрә (2000 ел, № 12). Соңрак бу әсәр, "Ишелеп төшкән бәхет" романы кебек, язучының сайланма әсәрләр җыентыгына да кертелә, ике графикада аерым китап буларак та басыла.

Әдипнең башка әсәрләре кебек, әлеге иҗат җимеше дә укучылар һәм тәнкыйтьчеләрнең игътибарыннан читтә калмый. Аерым алганда, Ф. Сафин үзенең мәкаләсендә "Бәйсез этләрне атарга" әсәренең иң беренче чиратта Мәһдиевчә җор теленә, нечкә лиризмына, халыкчан фәлсәфәсенә игътибар итә, зур булмаган әсәрдә дә "чорның бөтен катлаулылыгын, каршылыгын, гади кешеләрнең күңел байлыгын, түрә кыяфәтле бәндәләрнең җайсызлыгын аннарга үтеп керерлек итеп" тасвирлый алганына зур бәя бирә.

Әлеге әсәр А. Гыйләҗевны да битараф калдырмый. Күренекле әдип үзенең әсәрне әлегә иң тирән анализлаган мәкаләсендә татар теленең чисталыгы һәм язмышы өчен көенә, классик язучылары югала барган татар әдәбиятының киләчәге өчен борчыла. Ләкин Ф. Латыйфиның әсәрләре һәм, аерым алганда, "Бәйсез этләрне атарга" романы анда бик уңай тәэсир калдыра һәм яшь татар әдипләренә карата өмет уята. Сугыштан соңгы авыр еллар темасына күп кенә әсәрләр язылган булса да, Ф. Латыйфи, А. Гыйләҗев фикеренчә, мәсьәләне татар балалары турында, татар авылы тормышы мисалларында хәл итүе белән татар әдәбиятына яңалык кертә алган.

Әдип төп герой Харисның, аңлы бала булганга, һәрчак нәрсәдер эзләнүен, бәхетсез һәм кимсетелгән нәселнең бер нәни генә вәкиле буларак сурәтләнүен искәртә. Әсәрдә тасвирланган мәктәп күренешләренә, укытучы образларына Аяз ага аеруча зур игътибар бирә: "Совет мәктәбе кануннары сизгер һәм тапкыр малайны изеп, таптап, аның хаклыкны аңлау дәрәҗәсен, сәләтен имгәтеп, аны коммунистик кысаларга көчләп тыгарга омтылалар." Шулай ук Ф. Латыйфиның гаилә, балалар тәрбиясе мәсьәләсендә саран штрихлар белән бик күп мәгънәләрне әйтә алуы да автор игътибарыннан читтә калмый.

Романдагы төп конфликтка тукталып, автор авылның тере җанлы малайларына милиционерның—совет власте канаты астында пешеп чыккан кара көчнең—каршы куелуын күрсәтә, әсәрнең милиционер белән Харис мөнәсәбәтләренә багышланган сәхифәләре зур тәэсир көченә ия дип саный.

Аяз ага фикеренчә, "Бәйсез этләрне атарга" кебек чын милли рухлы әсәрләр безгә бик кирәк, чөнки ул татар кызлары һәм егетләрен "акны карадан аерып, әби-бабаларыбыз мең еллар буена салган якты сукмаклардан тайпылмаска" өйрәтә. (Өметләр уята торган әсәр // "Казан утлары", 2001 ел, № 12.)

Д. Заһидуллина үзенең мәкаләсендә "Бәйсез этләрне атарга" әсәренең төрле әзерлектәге укучыга атап язылганын, берничә әдәби катламны берләштергән үзенчәлекле, татар әдәбияты өчен яна күренеш икәнен билгели.

Мәкалә авторы әсәрдә шул чорның ачлы-туклы көн итүче халык һәм гел башка тормыш шартларында яшәүче җитәкчеләргә аерып бирелгәнен ачыклый. Әсәрнең исеменә чыгарылган «Бәйсез этләрне атарга!» дигән гыйбарәгә игътибар итеп, галимә аны фәлсәфи-символик катлам аша болай аңлата: "Харис, авыл малайлары—бәйсез, хөр булып дөньяга килгәннәр, ләкин җәмгыятьтәге кануннар шул бәйсезлек белән көрәшә, хөр фикерлеләрне юк итә." (Милли реализм юлыннан //"Казан утлары", 2003 ел, № 6).

Шулай итеп, Ф. Латыйфиның "Ишелеп төшкән бәхет" һәм "Бәйсез этләрне атарга" романнары татар матбугатында билгеле бер резонанс тудырганнар, аларга карата төрле фикерләр әйтелгән. Ләкин тәнкыйтьчеләр бу әсәрләрне күбрәк идея-эстетик яки гомуми планда гына тикшергәннәр, ә авторның иҗатын җитди анализлаган монографик хезмәтләр әлегә язылмаган. Шуңа күрә без алга таба әлеге ике романның образлар системасын тикшерү, әсәрләрнең үзәгенә куелган милләт язмышы проблемаларын ачыклау аша аларга тулырак әдәби анализ ясарга омтылырбыз.

Билгеле булганча, роман үзәгенә һәрвакыт катлаулы, каршылыклы характерга ия булган герой куела, җәмгыятьне күрсәтүче башка геройлар исә аңа оппозициядә урнаштырыла. Шулай итеп, романда персонажларның тотрыклы иерархиясе күзәтелә.

"Ишелеп төшкән бәхет" әсәрендә дә әдәби образларны берничә төркемгә бүлеп була.

Төп образлар әсәрнең сюжет, вакыйгалар катламын үз тирәсенә жыя, автор концепциясен тулы һәм төгәл белдерүгә хезмәт итә. Романдагы иң әһәмиятле герой—Сирин Сабиров. Ул әсәрдә тулы характер буларак ачылган һәм Ф. Латыйфиның башка әсәрләрендәге кайбер төп геройларга да охшаган (мәсәлән, "Ак-карага тимәскә" әсәрендәге Рәис Хаковка).

Д. Заһидуллина фикеренчә, "Сирин—теләсә нинди шартларда, заманда милли каһарман була алырлык егет." Ул әсәрдә заман герое итеп сурәтләнә: хакыйкатьне бар нәрсәдән өстен куя, заман һәм жәмгыять таләпләренә яраклаша белми һәм моны теләми дә, үз асылына тугры кала. Шул ук вакытта Сирин үз чорында тормыштагы урынын таба алмый, башкалар тарафыннан якланмый һәм үз көчләрен милләт файдасына кулланудан мәхрүм була. Шуңа күрә аның югалуы яки чит илгә китүе табигый нәтижә булып яңгырый һәм укучы күнелендә, бер яктан, канәгатьсезлек, икенче яктан, милләтнең хәленә ачыну хисләре уята.

Моннан ары, Сирин образы аша романда бәхет эзләү һәм инде ирешкән бәхетнең юкка чыгарылуы күрсәтелә. Гомумән, бәхетле булырга теләү һәм ана төрле юллар белән омтылу, чын тормыштагы кебек, барлык геройларга да хас. Ләкин аерма аңа ирешү юлының төрле булуында гына. Мәсәлән, Сирин Асия белән бергә булырга омтылган кебек, Дамирның да кызны үзенеке итәсе килә. Әмма икесе дә моңа төрле юллар белән бара: Сирин кызны чын мәхәббәт хисе белән тартса, Дамир караңгы һәм астыртын юллар сайлый (көндәшен армиягә жибәртү, кызны куркыту һ. б.)

Әмиржан Акчурин исә үзенең бәхетен туган иленә кире кайтуда күрә һәм моның өчен бөтен юлларны сынап карый. Хафиз Сабиров исә дүрт ел буе сугыш газапларын, вәхшәтен үз жилкәсендә күтәреп, туган жиренә кайту юлындагы бер киртәне алып ташлый: аманәт хатны юк итә һәм вәгъдәсен үтәми, мөһажирләр язмышын жиңеләйтерлек изге гамәлне башкарудан курка.

Шунысы кызык: киләсе нәсел вәкиле Сирин дә Акчуриннардан ераклашу һәм читтә калуны сайлый. Ләкин бу баш тарту гел башка сәбәпләргә бәйле була: "Асиягә аның күләгәсе белән дә, хәтта сүздә дә хыянәт итәсе килми иде. Аның кеше язмышларына катнашырга хакы юк. Юк! Аны ул хокуктан, ул кодрәттән тайга урманнарында мәхрүм иттеләр..." Бу гамәл Сиринне үзенең кимчелеген аңлаган һәм башкалар язмышын бозырга теләмәгән аскет, ялгызлыкта гына газап чигүне өстен күргән герой буларак та ача. Шулай итеп төп герой бәхетенең жимерелүе бөтен милләт язмышының ватылуы буларак төгәлләшә.

Роман тирән мәгънәгә ия булган һәм житди вазыйфа үтәгән ярдәмче һәм эпизодик образларга да бай. Билгеле булганча, алар төп геройларны һәрьяклап ачу һәм әсәрнең идеясен төгәлрәк житкерү максаты белән кертелә.

Мәсәлән, Хәдичә апа мисалында шанлы, ләкин онытылып баручы татар халкы казанышлары гәүдәләндерелә. Кайчандыр төрле илләргә гастрольләргә йөреп, тулы заллар жыеп, үзенә каратып торган мәшһүр биюче хәзер гади квартирада студентларга бүлмә биреп, "гомер буе идән юып, яисә урам себереп акча тапкан хатыннар хәлендә яши." Бу күренеш бер яктан кеше кыйммәтенең ничек тиз югалтылганын күрсәтсә, икенче яктан бу затларның кече күнеллекләренә мәдхия булып яңгырый.

Рифгать, Ильяс кебек образларның язмышлары тоталитар изү астына эләккән татар яшьләренең жыелма портретын тудыруга хезмәт итә. Сириннең авылдашы Рифгатьнең үз-үзенә кул салуы исә бу фажиганы тагы да тирәнрәк, тәэсирлерәк итә һәм укучыны тетрәндерә. Аннан аермалы буларак, исеме гел бозылып әйтелгән Камәретдинов Ильяс үзенең калган гомерен файдалы үткәрә, дусты Сириннең кызын Дамир бәйләнүләреннән яклый. Ә Сирин, язмышы бозылганын аңлый торып, күнелсезлеккә бирешми, университетны тәмамлый һәм аспирантурага керә, математика белгече булырга жыена.

Аларга каршы торган военком (Дамирның агасы), армиягә өндәгән капитан, татарларны мыскыл итәргә яраткан лейтенант Майорчук, ант биргәндә нотык сөйләгән полковник образлары исә системаның әмерен берсүзсез үтәүче тугры хезмәтчеләре рәвешендә сурәтләнә.

Мәрхәмәтле латыш табибы Янис образы әсәргә берничә фикер алып керә. Ин

элек бу персонаж аша мәрхәмәтле татар халкынын чит милләттәге ятим балаларны да авыр сугыш елларында тырышып тәрбияләүләре күрсәтелә. Шулай ук башка хәрби офицерлардан шәфкатьлелеге һәм анлаучанлыгы белән аерылып торган латыш Янис гади солдатларга якынрак. Үз көнелендә ташыган серне дә бу табиб якташы кебек тоелган Сирингә генә сөйли һәм егетнен күзләрен ача. Анын "Әгәр инде сон булмаса!" дигән куркыныч сүзләре Сиринне гомер буе әзәрлекләп йөри.

Әсәрдәге башка персонажлар да авторнын билгеле бер максатына буйсындырылалар. Әйтик, татар фронтовикларын Г. Исхакыйны кулга алу өчен Кытайга җибәрү, анын портретын атып төшерү күренешләренә тирән мәгънә салына; Чита өлкәсе прокурорынын Әмирҗан хатына җавабы ул чорда да тоталитар системанын әле нык һәм чыдам булганын, аны җимерү бик авыр икәнен искәртә.

Романдагы образларны берничә принцип буенча төркемләргә була:

1) Яшьләренә нисбәтле: өлкән һәм яшь буын.

Биредә өлкән буын милли характер үзенчәлекләрен саклаучы катлам буларак гәүдәләнә. Хәдичә апа, Оркыя ханым образлары аеруча җылы һәм чын милли җанлы итеп тасвирланганнар. Аларнын сөйләшүләре дә татарнын элеккеге димче хатыннары телен хәтерләтә: "Һич кенә дә мактанмыйча әйтәм, бу егет алтын баганадыр. Синен дә зәбәрҗәтен бар икән... Киләчәктә, бәлки, кулыбызга зәбәрҗәт кашлы алтын йөзек кию хакында уйлашсак та комаучаламас иде, димәкче идем..."; "—И әйтәсен бармы, Хәдичәкәем... Бөтен хыялыбыз Галияне үз кавемебез белән кавыштыру иде..."

Шулай ук Оркыя ханым образында бик озак "халык дошманы"нын хатыны булып яшәргә, бер илдән икенче илгә төрле авырлыклардан качып йөрергә мәҗбүр калган татар хатын-кызы гәүдәләндерелә. Ләкин туган туфракны сагыну хисе аны картлыгында да ташламый һәм ватанга кайтунын төрле юлларын эзләтә. Мона бәйле рәвештә хаксызга рәнҗетелгән һәм күп еллар үткәч тә аклану тапмаган, чит илләрдә яшәргә мәҗбүр ителгән барлык мөһаҗирләрнен халәте күрсәтелә. Аеруча Әмирҗан Акчуриннын кулга алынуы һәм нахак гаепкә сигез ел лагерьларда газап чигүе тоталитар системанын асылын ачып бирә, репрессияләрдә харап ителгән меңләгән "халык дошманнары"нын язмышы белән тәнгәлләштерелә.

Сириннен атасы Хафиз Сабиров образы аша язучы әсәрнен төп сюжет сызыкларыннан берсен алып бара һәм укучыны автор фикеренә китерә. Бу персонаж күбрәк татар милләтенен буйсынып яшәүгә бәйле аяныч халәтен һәм тоталитар системанын аерым кешеләрне изүенен никадәр көчле икәнен ачып сала.

Яшь буын исә романда бөтенләй башка төрле сурәтләнә. Алар арасына армиягә алынырга тиеш булмаса да, гаскәр хезмәтенен бөтен газапларын үз җилкәсендә татыган һәм якты киләчәген корбан иткән Сирин, Ильяс, Рифгать; сокландыргыч, күз явын алырлык итеп сурәтләнгән Асия; Америкада үсеп тә, чын татар җанлы итеп тәрбияләнгән Илдар һәм Галия Акчуриннар; үз теләгәненә ирешү өчен бөтенесен юлыннан алып атырга әзер булган Дамир һ. б. керә.

Аларны берәр нәрсә берләштерәме сон? Безнеңчә, алар барысы да яшь булулары белән бер-берсенә охшаш. Аларны аерып торучы төп билге—милләткә мөнәсәбәт. Бары Илдар авызыннан гына без татар милләтенен язмышына бәйле фикерләр ишетәбез. Башка яшьләрнен мөнәсәбәте исә аларнын эш-гамәлләрендә һәм язмышларында чагыла.

2) Яшәү урынына карап: Россиядә һәм Америкада яшәүче татарлар (мөһаҗирләр).

Әсәрдәге образларны кин географик планда бирү язучыга төрле җирдә яшәүче татарларнын хәлен, тормышын чагыштырырга мөмкинлек бирә. Шулай ук автор "Мөһаҗирләр ни өчен чит илләргә киткәннәр? Алар анда ничек яшиләр, бәхетлеме?" һ. б. шундый сорауларга җавап та эзли.

Америка татарлары ин элек Казаннын татар рухы кимегәненә ачынган Оркыя ханым, чит илләрдә яхшы белем алып, югары технологияләр белгеченә әверелгән Илдар һәм туган ягына кайтыр өчен акланырга бар көче белән омтылган Әмирҗан (Акчуриннар нәселе); шулай ук татарларнын бердәмлеген алгы планга куйган Рөстәм ага һәм "Американын төрле штатларына сибелгән татар хатын-кызлар таифәсенен

җаны" булган Гайшә ханым (Агишевлар) аша безнең күз алдыбызга килеп баса.

Җирле татарларның төп вазыйфасы—милләтебезгә каршы алып барылган геноцид сәясәтен ачып салу, аңа бирешмәүгә әзерләү. Яшь егетләрнең язмышы гаскәрдә радиация алу аркасында җимерелсә, Асия, үз мәхәббәтен югалткач, Сирин белән Дамир арасындагы кискен каршы юлны сайлый: "Сирин белән аерылуны гаять тә авыр кичергән кыз бик озак кияүгә чыкмаган. Соңра аның тыныч, сабыр гына холыклы бер урыс егете белән кушылып, ярым татар, ярым урыс телле балалар үстереп ятуы турында ишетелде." Бу юлларда авторның катнаш никахларга мөнәсәбәте дә ачык бирелә, урыслаштыру сәясәтенең нигезе дә ачыла.

Әсәрдә автор-хикәяләүче образы да бик әһәмиятле вазыйфа башкара. Ул милләтпәрвәр, милләт кайгысы белән яши һәм аның киләчәге турында уйлана торган итеп сурәтләнә. Хикәяләүче һәрвакыт төп геройга "ияреп йөри", үз бәясен әйтеп бара. Бу аерым бүлекләр башында аеруча нык сизелә. Мәсәлән, "Адәм баласы җайлашмый, ияләшми торган нәрсә юктыр, ахрысы" ; "Солдатның туймый торган ике әйбере бар. Берсе—йокы, икенчесе—ашау" кебек җөмләләрдә хикәяләүче гаскәр хезмәтенең авыр шартларына үзенең мөнәсәбәтен белдерә.

Моннан ары, хикәяләүче образының ахырда укучыга мөрәҗәгать итүе һәм роман вакыйгаларына кереп китүе сурәтләнгән хәлләрнең тормышчанлыгын арттыра, аларның чыннан да булганына укучыны ышандыра, төп фәлсәфи фикерләрне җиткерергә булыша.

Шулай итеп, романдагы барлык образлар да төп герой тирәсендә җыелалар һәм үзәк конфликтка бик җинел керерлек итеп тасвирланалар. Шул ук вакытта персонажларның милли мәсьәләгә мөнәсәбәте беренче планга чыгарыла, шуңа күрә образлар чын татар рухлы һәм татар исеме астына яшеренүче кешеләргә бүленәләр. Моның аркылы автор фикере укучыга төгәл һәм тәэсирле итеп җиткерелә.

"Бәйсез этләрне атарга" әсәренең образлар системасы "Ишелеп төшкән бәхет" романыннан шактый аерыла. Беренчедән роман-нәсердәге персонажлар, дөресрәге, сюжетка актив рәвештә катнашканнар саны аз. Икенчедән, геройларның характер буларак ачылу дәрәҗәсе дә кимрәк, сурәтләнгән тормыш юлы да чикләп алынган. Моңа карамастан, роман-нәсердәге персонажлар җыелмасы төзек бер система хасил итәләр, һәм аларның барысы да аерым игътибарга лаеклы.

Әсәрдәге барлык персонажларны да иң элек ике төркемгә аерырга була: балалар һәм өлкәннәр. Балаларның барысы да диярлек уңай яктан гына сурәтләнсә, икенче төркемдәге персонажлар арасында тискәре геройларны да аерып алырга була (Миләүшә Әхмәтовна, явыз милиционер һ. б.)

Төп геройлар арасында характер буларак иң яхшы ачылганы—әле бишенче сыйныфны гына тәмамлаган Харис исемле малай. Әсәрдәге барлык хәлләр аның күзе аша, аның сүзләре, дөресрәге, аның аң агышы ярдәмендә сурәтләнә. Әсәрнең тәүге юлларыннан башлап, язучы берәм-берәм Харисның берсеннән-берсе гүзәл хыялларын ачып бара: зур шәһәрдә институт бетереп, авылга абруйлы кеше булып кайту һәм авылдашларын шаккатыру; Ләйлә белән бергә булу; көчек тәрбияләп үстерү; авыл эшләрен күпкә җиңеләйтерлек тачка ясау һ. б.

Болардан күренгәнчә, Харис үз яшьтәшләренә хас булган хыял-өметләр белән янып яши, аларның чынга ашачагына ихластан ышана. Әмма аны әйләндереп алган кырыс чынбарлык, чорның тоталитар системасы хәтта үсмер баланың хыялларына да үсеп китәргә, иркенлек алырга мөмкинлек бирми. Мәсәлән, әлеге дәүләткә хезмәт иткән милиционер ул ясаган тачканың иң әһәмиятле детален тартып ала һәм нахак гаеп белән бикләп тота, ә Харисның иң якын дустына әверелгән этен, үз куллары белән бәйләттереп, күзе алдында бер гаепсезгә атып үтерә.

Нигездә самими, эчкерсез күңелле бу малай белән буйсындыруга корылган режим һәм аңа буйсынып яшәгән тирәлек арасында каршылык барлыкка килә. Иң аянычлысы шул: бу конфликт Харисның үз-үзен аңлый башлаганнан алып, билгесезлеккә кадәр дәвам итәчәк, ягъни әлеге мәңгелек коллизия хәл ителмәслек ситуация рәвешен ала, һәм шуңа күрә әсәр кысаларында тәмамланмый кала.

Шундый катлаулы сынаулар аша узган кечкенә Харисның күңелен күтәреп җибәрерлек һәм бу авыр көрәшне дәвам итәргә рухландырырлык образ—Лилия

исемле сыйныфташы да әсәрдә бик әһәмиятле роль уйный. Автор Лилияне малайның күңелен аңлый алырлык һәм ярдәм итәрлек чын дус, ярдәмче һәм фикердәш буларак тасвирлый. Моннан ары, малай белән кыз арасындагы мәхәббәткә тартым җылы мөнәсәбәтләрнең тасвирлануы Харисның үзенең карашларына тугры калачагына, кырыс чорның тәэсиренә буйсынмаячагына ишарә итә. Соңгы фразага салынган оптимистик рух та моны ачык күрсәтә: "Ярый әле җир йөзендә Лилия бар!"

Әсәрдәге башка ярдәмче геройлар да Харис характерының асылына төшенергә һәм изүгә корылган системаны фаш итергә юл ачалар. Мәсәлән, Харисның якын дусты Гыйльфан образы—әсәрдә бик уңышлы эшләнгән персонажлардан берсе. Сакау телле булып, "р" авазын әйтмәс өчен сүз байлыгын әллә нинди сирәк гыйбарәләр белән баетырга мәҗбүр булган малайның "күңеле әйбәт", үзе хәтта "алдаша да белми". Гыйльфан образы аша ике дус малайның кызыклы һәм көлкеле, урыны белән тирән уйга салырлык һәм монсу да булган маҗаралары әсәргә ямь кертә. Әйтик, Миләүшә Әхмәтовнаны туган көне белән котлау, беренче һәм соңгы тапкыр сәхнәгә менеп җырлау, "Бата-калка абый"га барып кайту һ. б. бик күп вакыйгалар язучының юмор белән оста эш итүен, балалар тормышын һәм фикерләвен яхшы күзаллавын (Ф.Латыйфиның "Сәләт"не оештырып йөрүчеләрдән берсе булганын онытмыйк!) ачык күрсәтәләр.

Өлкәннәр төркеменнән тискәре образлар, язучының максатына бәйле рәвештә, тулырак һәм тәэсирлерәк бирелгәннәр. Язучы Харис укыган мәктәпкә, анда эшләгән укытучыларга аеруча зур игътибар бирә, чөнки балаларның, ягъни яңа нәселнең нинди тәрбия алуы милләтнең язмышында бик әһәмиятле роль уйный. Аерым алганда, үз миллилеген саткан, урыс мәдәниятенең олылыгын балаларга дәрес саен "тукып торган" рус теле укытучысы Миләүшә Әхмәтовна образы Харис тарафыннан кайта-кайта сурәтләнә. "Мин—бөек рус культурасы традицияләрендә тәрбияләнгән кеше. Миннән үрнәк алыгыз... Шул тәрбиянең кайбер элементларын тырнак очы хәтле генә булса да сезгә йоктырырга телим,"—кебек сүзләре әлеге укытучының кече милләтләрне чүпкә санаучы һәм юкка чыгаручы рус шовинизмының, сәясәтенең тугрылыклы хезмәтчесе икәнен күрсәтә. Һәр төрле ялган һәм мәҗбүриләүне нечкә тойган Харисның эчендә бу сүзләр "кирелеккә дә, кимсенүгә дә,... рәнҗүгә һәм үртәлүгә дә охшаш хис" уята, ләкин малай мондый кечкенә яшендә дә аларны кычкырып әйтергә ярамаганын бик яхшы аңлый.

Икенче яктан караганда, Харисның күңелендәге милләте өчен кайгырту хисенең уянуына мәктәптәге тарих укытучысының, үзе дә татар була торып, татар балаларын Мамайны һәм татар-монголларны тар-мар итү белән рухландыруы һәм өлкән абыйсының үзе белгәнчә генә "тавык күкәе хәтле шеш" чыгарырлык итеп маңгаена чиртүе сәбәпче була. Моннан соң гына Харис "Без кемнәр соң? Нигә без иң изге урын дип санап йөргән йортта—мәктәптә—безне үз авызыбыз белән үзебезне ук сүгәргә өйрәтәләр?...Үскәч бездән кем чыгар?" кебек сораулар турында уйлана башлый, тормышның "үскән саен катлаулана" баруын тоя, ягъни рухи яктан олыгая бара.

Әсәрдә әлеге шовинист укытучыларга каршы куярлык бер генә образ сурәтләнә—татар теле укытучысы Җәүһәрия Шакировна. Мәктәп программасындагы рус теле дәресендә балалар үзләренең "гадел, бәхетле, җиңүчән һәм рәхәт илдә" яшәүләрен аңласалар, татар әдәбиятында тоташ ачлык, хәерчелек, күз яше, сыктау булып, Харис эчендә тагын бер кат кимсенү хисе уятса да, балаларның иң көтеп алган дәресе—татар теле. Чөнки Җәүһәрия Шакировна "үзе кыланчык түгел, үзе гади, үзенең белмәгән нәрсәсе юк." Ул балаларны дөнья әдәбиятының җәүһәрләре белән таныштыра, аларның хыялларын үстерә. Әлеге деталь аша автор укучының игътибарын яңа татар мәдәниятенә юнәлтә, балаларга өйрәтерлек татар әдәбиятының классик үрнәкләре мәктәп бусагасыннан үтә алмаганына ишарә итә.

Барлык бу сәбәпләргә карамастан, рус һәм татар теле дәресләре, укытучылары арасындагы каршылыкта балалар өчен үз милләтенең теле өстен чыга. Моның аркылы тагын бер тапкыр авторның татар теле язмышына булган өметләренең җитди булганы сизелә.

Харисның әти-әнисе дә әсәрдә мөһим урында торалар. Морза нәселеннән,

мулла гаиләсеннән булган өчен генә авылдан-авылга күчеп йөрергә, тиеннәр өчен үз-үзләрен бетергәнче эшләргә, үз фикерләрен төн уртасында гына әйтергә мәҗбүр булган Хатыйп белән Хөррия образлары тоталитар системаның мәгънәсез һәм мәрхәмәтсез кануннарын ачып бирергә ярдәм итәләр. Аерым алганда, совет мәктәбен тәмамламаган кешене, үз эшен күпкә яхшырак белүенә карамастан, санга сукмау, иске татар мәдрәсәләренә кимсетеп карау, заемнар белән иң хәерче кешене дә кычкыртып талау, ат тизәген җыюны тыймаган җитәкчеләргә рәхмәт уку, "хәерче" авылдан шәһәргә качу һ. б. проблемалар әсәрдә Сәубановлар гаиләсе аша тасвирлана.

Әсәрдәге тискәре геройлар арасында иң колоритлы һәм куе буяулар белән сурәтләнгән персонаж—исеме дә әйтелмәгән, шуның аша зур гомумиләштерүгә ия булган милиционер. Әлеге образ аркылы язучы безнең каршыбызга ике төп проблеманы калкытып куя: 1) Тоталитар системаның тугрылыклы хезмәтчесе буларак, әлеге "милиционер абый" психологик басым ясау, булмаган гаепне таныту өчен төрмә газаплары белән интектерү кебек рәхимсез методларны кечкенә балаларга карата да куллланудан тайчынмый. Моның аша автор укучының күз алдына бер гаепсезгә меңләгән кешене юк иткән репрессия чорын китереп бастыра. 2) Үз балаларын коткарырга килгән әнисе аша әлеге явыз милиционерның үткәне, авыр сугыш елларында бу гаиләгә сыенып исән калган бала булганы ачыклана, яхшылыкка начарлык белән җавап бирү, изгелекне юкка санау мәсьәләсе күтәрелә. Бу сыйфаты белән дә әлеге ситуация репрессия корбаннарын, үзләре корган система тәгәрмәче астына эләккән күп җитәкчеләрне һәм татар коммунистларын хәтерләтә.

Әсәрнең конфликты, ягъни вакыйгаларны хәрәкәткә китерүче каршылык милли нигезгә корылган. Һәрбер романга хас булганча, төп конфликт шәхес һәм җәмгыять (тирәлек, хөкүмәт) арасында оеша. Моннан ары, "Ишелеп төшкән бәхет" романы, милли реализм үрнәге буларак, милләт проблемаларын үзәккә куя, шуңа күрә әсәрдәге икенче әһәмиятле конфликтны бу юнәлештә эзләргә кирәк.

В. Юныс фикеренчә, романдагы төп конфликт фәнни ачышларга омтылган, милли телен һәм мәдәниятен сакларга тырышкан чын татарлар белән үзенең түрәлеген һәм илдәге коллыкны саклаучы, милли хәзинәләрне таптаучы, татар исемен йөртүчеләр арасында урнаша.

Чынлап та, югарыда әйтелгәнчә, әсәрдәге образларны җиңел генә ике төркемгә аерып була. Шул ук вакытта романда Сирин белән тирәлек, хөкүмәт арасында каршылык булганы ачык сизелә. Аның сәбәбе билгеле: төп герой бу илдә тыныч һәм бәхетле яшәргә тели, ә система аны һәм аның кебек ирек сөючеләрне изәргә, буйсындырырга омтыла. Шунысы мөһим, Сирин—Дамир каршылыгы аша да гәүдәләнгән бу конфликтта торучыларның ике ягы да татар милләтеннән. Шуңа күрә чын (милләт мәнфәгатьләре белән янучы) һәм ялган (милләт исеме астында яшеренеп яшәүче) татарларны аерып карау кирәк.

Димәк, Дамир, аның агасы военком, хәрби идарәчеләр һ. б. тоталитар система яки аның варислары образына җыеп бирелә. Әсәрдә аларга каршы тора алырлык бер генә каһарман—Сирин, ләкин аңа да үз көчләрен эшкә җигәргә ирек бирмиләр, шуңа күрә ул югалырга, чит илгә китәргә мәҗбүр була.

Шулай итеп, романга хас булган типик конфликт (шәхес белән тирәлекнең каршылыгы) әлеге әсәрдә төп геройның җиңелүе, кешеләрне буйсындырып тотуга нигезләнгән системаның өстен чыгуы белән тәмамлана.

Моннан ары, Америкада үсеп, дөньякүләм зур белгеч булган Рөстәм Агишев һәм әтисенең ярдәме белән илнең явызлыгына күзе ачыла башлаган Илдар образы аша да авторның өмете зурдан икәне сизелә.

Персонажлар композициясенә килгәндә, әсәрдә бер-берсенә кискен каршы торган һәм игезәк дәрәҗәсендә якын геройлар да бар. Янәшә торган геройлар әсәрдәге чынбарлыкны ике дөньяга—чит ил һәм туган җиргә—бүлеп караганда шундук күзгә ташланалар. Бәхет эзләп тә туган җирендә тынычлык тапмаган Сирин Сабировка "йомырка кабыгын ватып чыккан", яхшы карьера ясаган Илдар Акчурин янәшә куела. Алар икесе дә төгәл фән белгечләре, чын татар рухлы, кыю характерлы шәхесләр, киемнәре белән дә заманча кыяфәтле. Ләкин аларны кискен аерып торган

бер сыйфат аларның мохитына бәйләп аңлатыла. "Сирин һәм Илдар язмышларының янәшәлеге фәлсәфи аңланылу мөмкинлегенә ия." Чит илдә уңышка ирешкән Илдар образы аша автор татар милләтенең язмышы башка юлдан китәргә мөмкин булганын искәртә һәм Америка татарлары мисалында моның идеаль моделен төзи.

Галия һәм Асия образларын да әсәрдә янәшә торучыларга кертергә була. Ләкин бу янәшәлек күбесенчә тышкы охшашлыкка, ерак туганлык мөнәсәбәтенә кайтып кала, чөнки Асиянең фаҗигале язмышы сурәтләгән сюжет сызыгы тәмамланган, кызның характеры ачык бирелгән. Ә Галия татар гаиләсенең канаты астында үскән, киләчәккә ачык, саф кыз буларак кына тасвирлана, характеры ачылып бетми. Ләкин әлеге ике гүзәл кыз образлары аша да ике дөньяның капма-каршы торуы ачык күрсәтелгән.

Оркыя Акчурина белән Хәдичә апа, югарыда әйтелгәнчә, өлкән буын вәкилләрен гәүдәләндерәләр һәм бер дәрәҗәдә үткәндә калган милли традицияләрне сагыну, хәтта юксыну кебек янгырыйлар. Шул ук вакытта алар яшәү шартлары һәм тормыш дәрәҗәсе белән, ягъни хәзерге хәлләре белән кискен аерылып торалар. Элекке вакытта мәшһүр биюче булган Хәдичә апаның хәзерге тормышы Америкадагы Оркыя ханымның бай һәм бар яктан житеш хәятенә каршы куела. Алдагы пар геройлар кебек, монда да Америка татарларының тормышы идеаль вариант булып сурәтләнә.

Шулай итеп, романның төп композицион алымы дип каршылыклар аша сурәтләү алымын атарга була. Язучы төрле катламдагы һәм төрле яшьтәге персонажларны бер-берсе белән очраштырып, үзара чагыштырып, безгә ике тормыш моделен тирәнрәк ачуга ирешә, милли мәсьәләне ныграк ачып җибәрә.

"Бәйсез этләрне атарга" романында сурәтләнгән дөнья композициясе шулай ук кызыклы алымнарга корылган. Алдагы әсәрдән аермалы буларак, монда сурәтләү һәм хикәяләү бер шәхес тарафыннан алып барыла, төп сюжет сызыгы да шуңа күрә берәү генә. Мондагы төп конфликт, югарыда әйтелгәнчә, төп герой Харис белән тирәлек арасында урнаша. Тоталитар системаның вәкилләре буларак Миләүшә Әхмәтовна, явыз милиционер һ. б. персонажлар күрсәтелә. Аларның сайлануы да очраклы түгел: белем бирергә тиеш булган укытучы да, җәмгыять вәкилләрен начарлыктан сакларга тиеш булган милиция хезмәткәре дә малайга каршы куела. Бу очракта һәр вакыт таянырлык дуслары, авыр хәлдән коткарырлык һәм хәленә керә алырлык әти-әнисе, хәтта хуҗасын бер караштан аңлаган эт тә зур әһәмияткә ия була башлый. Моның аркылы әсәрнең конфликты кискенләштерелә, проблемасы тирәнәя, авторның фикере тәгәлләшә.

Әсәрнең персонажлар композициясе, шулай итеп, Харис яклы һәм аңа каршы торган ике төркем рәвешендә бирелә. Бу бүленешнең нигезендә төп геройга булган мөнәсәбәт кенә түгел, ә әйләнә-тирәгә, хөкүмәткә караш, үз-үзең булып кала белү һ. б. критерийлар да ята.

Тоташ хикәяләүдән баш тарткан, тормышны күренешләргә таркатып сурәтләүгә корылган, төп сюжет өчен бик әһәмиятле булмаган вакыйга-хикәятләргә һәм хронологик күчешләргә бай булганга, "Бәйсез этләрне атарга" әсәрендә төп композицион принцип буларак монтаж, ягъни янәшә килүче образлар, өлешләр ярдәмендә яңа мәгънә ачу алымы кулланыла.

Ф. Латыйфи үзенең иҗаты белән татар романнарының яңа мөмкинлекләрен ачуга һәм аларны яңа алымнар белән баетуга зур өлеш керткән. "Ишелеп төшкән бәхет" һәм "Бәйсез этләрне атарга" романнары—идея-тематик, композицион һәм стилистик яктан бик оста язылган әсәрләр. Үзара чагыштыру алымы белән алар арасында сурәтләү чараларын һәм тел-сөйләм үзенчәлекләрен куллануда түбәндәге аермалы яклар табылды:

1) "Бәйсез этләрне атарга" романында образлар системасы җыйнаграк, персонажларның характер буларак ачылу дәрәҗәсе йомшаграк;

2) текст төзелеше ягыннан "Ишелеп төшкән бәхет" романы симметрик яктан яхшырак оешкан, хикәяләү ретроспектив хронотопка корылган;

3) "Ишелеп төшкән бәхет" романының сюжет сызыклары катлаулырак төзелгән,

вакыйгалар да төрле персонажлар аша тасвирлана. Икенче әсәрдә исә тирә-яктагы хәлләр Харис исеменнән генә сөйләнә, аның аң агышы рәвешендә бирелә, шуңа күрә башка геройларга бирелгән бәя дә кечкенә баланың субъектив мөнәсәбәте кебек тәкъдим ителә;

4) "Ишелеп төшкән бәхет" романында, төрле яктан аерылып торган образларны сурәтләү өчен, каршылыклар аша сурәтләү алымы кулланылса, "Бәйсез этләрне атарга" романы монтаж принцибына нигезләнә;

5) хронотопның бирелеше дә ике әсәрдә аерыла: "Ишелеп төшкән бәхет" романында вакыт һәм урын киң масштабта бирелә, ә роман-нәсердә, киресенчә, бер көн эчендә бер авылда барган вакыйгалар зур гомумиләштерү көченә ия;

6) "Бәйсез этләрне атарга" романында төп сурәтләү чарасы буларак көлүнең төрле формалары тәкъдим ителә, башка троплар да күбесенчә ирония һәм сарказмны көчәйтү өчен хезмәт итәләр.

Шул ук вакытта ике романны үзара берләштереп торган уртак якларның да күп булуы ачыкланды. Мәсәлән:

1) төп герой итеп роман өчен типик булган тирә-юньгә каршы торучы көрәшче образының сайлануы; моннан чыгып, төп конфликтның да ике әсәр өчен охшаш булуы; моннан ары, ике роман образлары арасында игезәкләр һәм үзара күчешкән моментлар да күзәтелә (Харис → Сириннең балачагы, Лилия → Асия, Гыйльфан → Рифгать яки Ильяс һ.б.);

2) тискәре образларны дәүләткә, системага хезмәт итүче кешеләр рәвешендә тасвирлау (военком, милиционер, укытучы һ. б.);

3) автор-хикәяләүченең зур рольгә ия булуы;

4) интертекстуальлек алымының иркен кулланылуы һ. б.

Татар милләтенең аянычлы хәле һәм киләчәге Ф. Латыйфиның һәр әсәрендә теге яки бу күләмдә чагылган иң әһәмиятле мәсьәләләрдән берсе булып тора. Ләкин мондый масштаблы проблемаларны күтәрү һәм аларны хәл итү юлларын күрсәтү өчен иң кулай жанр, әлбәттә, роман булып кала. Шуңа күрә язучының "Хыянәт", "Ишелеп төшкән бәхет", "Бәйсез этләрне атарга" романнары, милләтебез өчен һәрчак актуаль булган мәсьәләләрне калкытуы, милли рухны саф һәм сыгылмалы татар телендә бәян итүе өчен, милли реализм үрнәкләре буларак тикшерүне таләп итәләр.

Мәсәлән, "Ишелеп төшкән бәхет" романы татар нәселенә карата алып барылган, милләтнең тамырына балта чабырга омтылган геноцид сәясәтен фаш итә, бер татар егетенең язмышын сурәтләү аша тулаем милләткә кагылган фаҗигане ачып сала.

Милли мәсьәләләр ягыннан караганда, әсәрдә берничә тапкыр кабатланган Г. Исхакый образы аеруча зур игътибарга лаек. XX гасыр башында безнең илдә, аннан чит җирләрдә татар зыялыларының юлбашчысын, күренекле мәгърифәтче һәм язучыны майор Гыймаев татар солдатларына "карагруһ милләтчеләрнең атаманы", "совет властеның кара дошманы", "үтә хәйләкәр, мәкерле... шпион, корткыч" буларак таныта, аны кулга алган кешегә орден вәгъдә итә. Мондый танытудан соң Чәнчүннең татар мәдрәсәсендә Исхакый сурәтен атып төшергән рус солдатының гаебе дә зур булып күренми. Тоталитар системаның тагын татарны татарның үз кулы белән бетерергә теләгәненә төшенгән Хафиз да СМЕРШка каршы күтәрелеп бер сүз әйтә алмый, Акчуриннардан алган әманәт хатын да шундук юк итә. Әлеге вакыйгалар һәм, гомумән, Хафиз образы аша романда тарихны бозып күрсәтү аркылы илдә үткәрелгән татарларның үз горурлыгын һәм миллилеген оныттыру сәясәте дә ачык күрсәтелә.

Моннан ары, татар солдатларын бик тырышып Исхакыйга каршы куйган шул ук майор Гыймаев баш военком вазыйфасында да әлеге сәясәтнең дәвамчысы буларак сурәтләнә. Аның тырышлыгы белән татарның бик күп асыл егетләре, милләтнең киләчәге, ракета гаскәрләрендә көчле нурланыш алып, яшьли тормыштан киткән. Әлеге фикерне автор-хикәяләүче прологта, әсәрнең язылу максатын аңлатканда ачыктан-ачык әйтеп бирә: "Мин мөһаҗирлектәге каһарман милләттәшләребезгә һәм сугыш елларында туган, яшьлекләре бөреләнеп килгәндә ракета гаскәрләренең касәфәтен күргән, вакытсыз вафат булган йөзләрчә татар егетләренә һичьюгы сүздән

һәйкәл куюны максат иттем."

"Бәйсез этләрне атарга" роман-нәсере үз чиратында хөр шәхес белән тоталитар система арасындагы конфликтның инде балачактан ук башланганын, ләкин, барыбер, хыялларына тугры калган шәхесләрне сындыра алмаячагын күрсәтә.

Алдагы романдагы мотивлар бу әсәрдә дә дәвам иттерелә һәм үстерелә. Аерым алганда, татарлыгыннан качу өчен балаларны үз исемен урысчалатып әйттерергә тырышкан, урыс офицерына кияүгә чыгып, башка милләткә җан көчләре белән хезмәт иткән Миләүшә Әхмәтовна образы да, яхшылыкка начарлык белән җавап бирүче милиционер образы да урыс шовинизмының ярдәмчеләре рәвешендә сурәтләнәләр.

Харисның тарих дәресеннән хисләнеп кайтуы һәм мангаендагы шешне тотып уйлану вакыйгалары аша тарихны бозып күрсәтү проблемасы әлеге романда башка ягы белән ачылып китә, татар балаларының инде мәктәптә үк үз милләтенә каршы тәрбияләнә башлавы фаш ителә.

Шулай итеп, Ф. Латыйфиның һәрбер әсәре, аеруча әлеге ике романы, татар милләтенең язмышы турында борчылу һәм киләчәге өчен кайгырту хисләре белән сугарылган. Татарларга каршы алып барылган мәкерле сәясәтләрне фаш итеп, язучы укучыларны, аеруча яшьләрне аңлы булырга, бу хәйләләргә бирешмәскә, татар телен һәм мәдәниятен үстерү аша милләт рухын сакларга чакыра. Житлеккән егет яшендәге Сирин һәм балалыктан чыкмаган Харис образларын автор безгә билгеле бер дәрәҗәдә үрнәк буларак та итеп сурәтли, аларның фикер һәм язмышларыннан гыйбрәт алырга да тәкъдим итә.

Татар әдәбиятында роман жанрының тамырлары тирән, нәзари яктан да ул шактый өйрәнелгән. Ф. Латыйфи кебек сәләтле прозаикларыбызның иҗатын күздә тотып, татар романнарының киләчәге дә бик өметле дип фаразлый алабыз. Дөнья әдәбияты казанышларын иҗади файдаланып, шул ук вакытта милли традицияләрдән дә читләшмичә, татар романы бик зур биеклеккә күтәрелергә мөмкин. Ә роман жанрының үсеше, билгеле булганча, гомумән әдәбиятның үсешен билгели.

**Марат ШӘЕХОВ,**

*Казан дәүләт университеты аспиранты.*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Михаэль Фридерих

### КОЗГЫН КӨНЧЫГЫШКА ОЧА

#### яки гасырлар очрашканда бер татар шагыйре

"...Мондый кыскартуларга "Д" дип исемләнгән шагыйрьне нинди сәбәпләр этәргәнен ачыклау шактый кыен булса да,нәтиҗәсе ачык: татар версиясе вәзгыятьне төгәлрәк һәм ачыграк итеп тасвирлый,нокта куя. Оригиналның интонациясе һәм Чайлд тарафыннан күзәтелгән ниндидер циник яңгырашы татар вариантында, минемчә,Пушкинга караганда ныграк сакланган...

Шундый осталык һәм зәвык белән ике козгын турындагы шотланд халык җырын ана теленә тәрҗемә иткән "Д" кем соң ул?.."

***Немец галименең Дәрдемәнд турындагы бу зур мәкаләсен, тәрҗемә итеп, журналга Искәндәр Гыйләҗев китерде.***

# ШИГЪРИЯТЕБЕЗДӘ ИСТАМБУЛ ОБРАЗЫ

Соңгы еллар татар шигъриятенә Төркия, Истамбул образлары зур бер дулкын булып килеп керде. Бу хәл аңлашыла да. Яшәештә булган үзгәрешләр, янарыш нәтиҗәсендә халык үзенең үткәне, тарихы белән кызыксына башлады, чит илләр белән иркен аралашу мөмкинлекләре туды. Мондый үзгәрешләр турыдан-туры әдәбиятта да чагылыш тапты. Мәгълүм ки, Төркия—бердән-бер мөстәкыйль төрки дәүләт—татарлар өчен элек-электән төрле юнәлештә таяныч булган: ике арада сәүдә эшләре гөрләгән, халык Истамбул аша хаҗга йөргән. Укырга, белем тупларга килүчеләр белән бергә, Төркия татарның илдән китәргә мәҗбүр аерым зыялыларын—Г. Исхакый, Й. Акчура, С. Максуди һ. б. үз кочагына сыендырган.

Дөрес, Истамбул образы элеккерәк елларда да сәяхәтнамәләрдә, проза стилендә язылган әсәрләрдә чагылыш тапкан иде инде. Әмма бүгенге көн чагылышы алардан байтак дәрәҗәдә аерыла, чөнки Истамбул образы хәзер инде шигъриятtә реалистик һәм романтик аспектларда яктыртыла башлады. Шагыйрьләр өчен Истамбул хәзер аерым очракта символ яки тарих, хыял, өмет һәм мәхәббәт урыны булып тасвир ителә.

Истамбул образы Равил Фәйзуллин, Чулпан Зариф, Рифә Рахман, Марат Закир, Нур Әхмәдиев, Ркаил Зәйдулла, Рөстәм Сүлти кебек авторлар иҗатында киң яктыртылды. Ир-ат шагыйрьләрнең шигырьләре, нигездә, реалистик сурәтләрдә иҗат ителгән, аларда тирән уй, фәлсәфи фикер, гражданлык пафосы өстенлек итә. Бер шигырьдән икенчесенә вакыт, галәм, мәңгелек төшенчәләре үрелеп бара һәм шулар аша авторлар шәхес, милләт, төрки халыклар яшәешен күзаллыйлар. Шагыйрәләр иҗатында да, нигездә, шул ук темалар һәм юнәлеш булса да, алар инде үзенчәлеклерәк яңгыраш ала, романтик рух алгы планга чыга: лирикада мәхәббәт җырлары да, тормыш матурлыгы өчен көрәш авазлары да, кеше акылының бөеклеген мәңгеләштерү, Казан-Истамбул бәйләнешләрен чагылдыру да бар. Лирик геройлар язмыш сынауларын үтеп ныгый, ил һәм төрек-татар халыклары язмышлары борылышларына, кешенең рухи халәтенә игътибарлы. Мәсәлән, Ч. Зарифның "Истамбулда җәйнең соңгы мизгелләре" шигъри циклында бер-берсен тулыландырып өч этап ачык төсмерләнә: Төркия җирләренә омтылу, аның белән бәйле өмет-хыяллар; Төркиядәге яшәеш һәм туган җирне сагыну, җирсү, ниһаять, чит җирләрдә дә үзеңне табу, теләккә ирешү мотивлары. Димәк, шагыйрә иҗатына хис иркенлеге, символика, аллегория, вакыт һәм ара кебек категорияләр белән эш итү хас:

*Исәнме, Истамбул—солтаннар каласы!*
*Тагын мин әле бу—бер татар баласы...*

Автор җанны иркәләгән һәр дулкынны, татар-төрки халыкларының йөрәк тибешен сизә кебек. Ул янәшәлек һәм чагыштыру ярдәмендә халыклар язмышы турында сөйләргә омтыла. Казанның Явыз Иванга әсир төшүе, "һәр ташы алтынга тиң" Истамбулның исә баш бирми, килүчеләрне үзе әсир итүе гипербола ярдәмендә түбәндәгечә ачыла:

*Яуларга килгәннәр, сине бер күрүдә,*
*Әсиргә әйләнеп, даныңа күмелгән.*

Һәр ике халыкның кичкенә генә шатлыгы да автор өчен зур куаныч. Шулай булмаса, төрекләрнең изге йолаларына, мәгълүм шагыйрьләренең иҗатына булган мәхәббәт каян тусын! Төрки халыкларга хас иманга тугърылык, милли горурлык,

изге гореф-гадәтләр, кайгыртучанлык кешеләштерелгән, сынландырылган Истамбул образында аеруча төгәл, үзенчәлекле ассызыклана:

*Истамбул! ...Яңгырмы сибәли түбәгә?*
*Яңгырлар астында рөхсәт ит үбәргә*
*Синең чал йөзеңне, кукшегән кулыңны,*
*Кояшта каралган куркусыз улыңны...*

Кичерешләрнең сәбәбе—Истамбул шәһәренә булган мәхәббәт, бирегә авторның йөрәгенә бер яучы булып килүе:

*Яраннар тибрәлә, җил исә, җил исә,*
*Бу кадәр сөюнең сәбәбен бер белсәм!..*

Шигырьдә кулланылган образлар очраклылык билгесе генә түгел, әлбәттә. Алар хис-кичерешне тагын да төгәлрәк ассызыклау өчен махсус сайланган. Мәсәлән, татар халкының иң яраткан гөлләре—яраннар, шигърияттә җил образы аша гасырлар дәвамында иң әһәмиятле дә, иң интим хисләр дә житкерелде, күгәрченнәр исә, аеруча пар күгәрченнәр татарда—мәхәббәт символы. Биредә авторның туган жиргә, туган төбәккә изге төшенчә итеп каравы, аннан көч, илһам алып яшәве аерым ассызыклана. Истамбулда, аның яшәешендә һәм табигатендә дә шагыйрә туган ягы, Казан белән охшашлыклар күрә. Бәлки, нәкъ менә шуна бу ике ил дә аның өчен бик якын, кадерледер. Шигырьдәге образ дәрәҗәсенә күтәрелгән хис-кичерешләр—әдәби гомумиләштерүләр нәтиҗәсе. Автор биредә тарихи үткән, бүгенге, киләчәк турында сөйли. Гүзәллекнең мәңгелек булуына басым ясый:

*Җир тетрәп, хәрәбә хәленә килсә дә,*
*Мин янә дәшәрмен—*
*Истамбул, исәнме!..*

Шулай итеп, томан эчендә утырган Истамбул шәһәре образы матурлык төшенчәсе белән ассоциацияләнә, автор әйтергә теләгән зур нәтиҗәләргә китерә, яна мәгънәләр туа. Чөнки Чулпан Зариф һәр детальдән уңышлы файдаланып образ ясый ала, жиһанны сынландыра. Истамбул сүзенең еш кулланылуы, синоним, антоним сүзләр, риторик эндәш, гипербола—соклану хисен тагын да тирәнәйтә. Юлдан-юлга үсә барган мәгълүм хис иң биек ноктасына житкерелә, эмоциональ тәэсир итү көче арта, соңгы сүзләрдә идея тулысынча ачыла.

Истамбул белән бәйле тормыш фәлсәфәсе, психологик тыгызлык, фикер киеренкелеге Рифә Рахманның "Төркиядән хатлар, Төркиягә хатлар" циклына кергән шигырьләренә дә хас. Ул ике арадагы дуслыкны олылый, ашкынуын кешеләргә ирештерү хыялы белән яши. "Төрек йортында" шигырендә, мәсәлән, ике илне тоташтырырдай күпер эзли ул:

*Килдем туган илнең әрем исе белән, Истамбул.*
*Җилдә килде сезгә туган якның дымы.*

Шигырь иҗтимагый-тарихи эчтәлеккә ия, биредә милли-мәдәни карашлар, чор проблемалары да ачыла. Дөрес, хис-кичерешләр шәхси, лирик геройныкы гына кебек, әмма ул җәмгыятьтәге, ил тормышындагы хәлләрдән туган психологик халәт.

Рифә Рахман физик һәм рухи гармониянең идеалын Истамбулда таба. Әлеге карашлар сурәтле фикерләү рәвешенә үтеп кереп, поэзиягә җылылык, самимилек өсти:

*Һәр көн калам кулда, һәр көн—кәгазь.*
*Язмаган сүз инде аздыр аңа!*

*Әй нечкә бил, әй, Истамбул җиле!*
*Сәлам илт минем Казаныма.*

Ике авторда да мәхәббәт темасы киң планда алынган: алар Төркия җирләренә, төрле язмышлы кешеләргә, табигатькә гашыйк. Чулпан Зарифның тагын бер "Өч көн тоташ яңгыр ява" шигыре, мәсәлән, беренче карашка пейзаж лирикасына карый кебек. Чөнки биредә автор баштарак Истамбулга хас табигатьне, соңрак сурәт-күренешне бирә:

*Мөәзиннәр азан әйтә. Җомга бүген.*
*Манаралар, зиһен җыеп, битен юа...*

Әмма биредә әйтергә теләгән фикер күпкә тирәнрәк: җомга -мөселманнарның изге көне, манараларның бит юып чистарынуы, яңгырның мифологик ышануларга хас булганча өч көн, өч төн явуы—символик мәгънәгә ия. Димәк, табигатькә бәйләп автор язмыш турында уйлана, яшәештәге үзгәрешләрне яхшыга юрау өчен җирлек эзли. Мондый борчылу-тынгысызлануның сәбәбе "Бу Баязит мәчетендә", "Хисләр анда төссез", "Истамбулда җәйнең соңгы мизгелләре", "Мәрмәр диңгез буе—гөлләр" кебек шигырьләрдә ачыла төшә:

*Өстәлемдә бушлык белән тулы*
*Көмеш көллек.*
*Җиде көнгә бар да онытылды—*
*Татар, төрек...*

Яшәеш мәгънәсен мәхәббәттә күргән лирик герой сөйгәне өчен каршылыкларны, авырлыкларны да җиңәргә риза. Шигырьдә вакытлы сөю хисләре генә түгел, ул инде гомерлек хискә әверелгән кебек. Бу очракта да автор күп кенә символлар куллана: сөйгәненең исеме—"Коръән-кәрим, дастан битләрендә", бүләк итеп бирелгән бөти, кара-яшькелт кашлы—ислам, хаят төсендәге йөзек—болар барысы да хис тирәнлегең ачарга, аңа үзенчәлекле төсмер бирергә ярдәм итәләр.

*Чит шәһәрдә чиксез телдә сөйләр*
*Ирен—нечкә сызык—*

әлеге юллар төрки телләрнең чиксез санлы булуына, һәрберсе үз төркичәсендә сөйләшсә дә бер-берсен аңлый алу, мәхәббәттә аралаша алу шатлыгына ишарә.

*...Гөл таҗларын коям: сөйми, сөя...*
*Чарасызлык...*

Татар халкында ромашка чәчәгенең таҗлары белән багу гадәте бар. Төрек җирләрендә лирик герой роза чәчәге таҗлары белән бага. Лирик геройның халәте—табигать, чәчәкләр белән тиңләшә, фәлсәфи мәгънә туа. Шулай итеп, беренче юлдан ук автор төп идеягә юл ала, сурәтләү объектының эчке хасиятен беренче планга чыгара.

Табигатькә бәйләп, аерым шигырьләргә ассоциатив фикерләү хас: Ч. Зариф аларда бер-берсеннән ерак торган төшенчәләрне көтелмәгәнчә берләштерә. Ул гади бер күренеш-вакыйга турында сөйли кебек, әмма укучы башка житдиерәк, мөһимрәк әйберләрне күзалларга мәҗбүр:

*Хөрмәләр өлгерә, бананнар...*
*Илендә, өендә шул алар.*
*...Хөрмәләр өлгерә, бананнар...*
*Бу хәлне, бу гамне кем аңлар?..*

Биредә үткән вакыйга-күренешләр аша бүгенгене анларга, үкенмәскә, бәлки

кадерен белергә һәм киләчәкне күзалларга омтылыш та сизелә. Лирик геройның уйлары ачылып, сагыш хисе белән кушылып китә. Әмма табигать аның хәленнән, йөрәктәге тойгыларыннан хәбәрдәр түгел, бу хәл шуна күрә геройны тагын да борчый кебек.

Истамбул образында Рифә Рахман да нечкә эчке мәгънә таба. Ул беркадәр реаль дөньядан аерыла, һәм бу хәл романтик стиль, омтылыш белән аңлатыла. Чөнки шагыйрәне төрек җирләре белән бәйле серлелек үзенә тарта. Мисалга авторның "Йолкып ат", "Клеопатра", "Төнге Истамбул", "Торналы күк" шигырьләрен китерергә мөмкин. Биредә хисләр еш үзгәреп тора: исәрләнү, соклану, бәхет табарга омтылу һәм таба алмау фаҗигасе. Ягъни шагыйрә шигырьләрен хис һәм фикер каршылыклары, көтелмәгән лирик борылышлар нигезенә кора, контраст буяулар, чагыштыру алымы белән эш итә:

*Утырасы килми*
*Ап-ак урындыкка,*
*Өстемдәге күлмәк*
*Кара төстә булгач...*

Күренә ки, үзәктә төп ике төс—ак һәм кара—ике каршы көч арасында тартыш бара. Кара төс биредә өметсезлек, авыр күңел кичерешләре сыйфатында бирелсә, ак төс инде гомер-гомергә бәхет, сафлык һәм мәхәббәт символы. Р. Рахман кичерешләр киеренкелеген, шул рәвешле, төс-бизәкләргә күчерә. Лирик герой күңелендәге хис ташкыны, аның сәбәбе, зурлыгы исә алга таба төрле әдәби сурәтләрдә, шартлы алымнар, символик образларда бирелеп, түбәндәгечә ачыла бара:

*Төшми күңелләрем*
*Кара чәчле ярга...*

Мәгълүм шәһәр белән бәйле рәвештә бирелгән мәхәббәт лирикасы каршылыклы. Биредә автор интим хисләрне үзенчәлекле җырлый: герой шатлана, борчыла, газаплана, әмма үз-үзен югалтмый. Еш кына аерым деталь, образ ассоциациясе аша әхлакый кыйммәтләргә килә, унышлы гомумиләштерүләр ясый:

*Әмма китәм,*
*Җан асрарлык һавасы юк!*

Әлеге юлларда инде алдарак карап үтелгән кичерешләрнең сәбәбе ачыла. Төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә туган кискенлек героинянын психологик халәтен күзалларга ярдәм итә. Мондый шигырьләрдән, нигездә, сагыш бөркелеп торса да, аннан гел моң гына эзләү дөрес булмас, автор үз иҗатында фикер һәм хис бөтенлегенә омтыла.

Шул җирлектә автор туган илнең кадерен ассызыклый. Гасырлар буена сузылган туган җирне ярату, горурлану хисен дә үстерә, шәхси бәхет милли аһәң белән баетыла. Ягъни, шагыйрә татар шигъриятенең менә кадәр булган ачышларына таяна, кичерешләрен Истамбулга бәйле рәвештә, заманча яңгыратырга омтыла.

Ч. Зарифта исә хисләр аңа капма-каршы:

*Әй, Акдиңгез!*
*Язмышымда "таң вакыты" кебек син!*

Әлеге авторның гаиләсе һәм улы турындагы шигырьләре дә үзенчәлекле. Биредә ике арада булган дуслык мөнәсәбәтләрен дә, шатлык-куаныч хисләрен һәм тирән фәлсәфи уйларны да очратырга мөмкин:

*Терекөмеш төрек-татар бер улыл!*
*Хәзердән ук кыйтгаларга сыймый ул.*

*...Әтиеңнең туган җирен хәтерләткән*
*Кара зәйтүн кебек кара*
*Күзләрең.*

Гомумән, нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин, Истамбул белән бәйле әсәрләр новаторлык һәм традиция арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр һәм поэзиянең үсеш юллары турында уйлану өчен бай материал бирә. Чөнки авторлар татар шигыренә Көнчыгышның гүзәл поэтикасын, аның аша яңа образлар, кичерешләр, яңа аһәң, яңгыраш алып килә. Димәк, татар әдәбияты яңа рух, темаларга байый. Төрки халыкларга хас образлар—түгәрәк ай, чишмә, күгәрчен, образ дәрәҗәсенә күтәрелгән исемле мәчетләр, гөл-агач исемнәрен еш куллану исә уртак язмышка һәм әдәбиятка ишарә. Мондый шигырьләр тагын бер ягы—кайчандыр Рәсәй сәясәте белән бәйле рәвештә татарларда онытылуга дучар ителгән ислам диненә, аның тарихына, асылын аңлаткан легенда һәм риваятьләргә (дөрес, алар еш кына кечкенә бер деталь белән генә дә күрсәтелергә мөмкин!) игътибары белән аерылып тора.

Шулай итеп, бүгенге татар поэзиясе кеше күңеленең моңарчы ачылып бетмәгән кыйблаларын табу юнәлешендә Истамбул образын уңышлы файдалана. Ул бай палитралы, бай төсле. Димәк, бүгенге татар шигърияте яңарак тема һәм проблемаларга, ягъни үзенчәлекле поэзиягә бай дип нәтиҗә ясарга ныклы нигез бар.

**Ләйлә МИНҺАҖЕВА,**
*ТДГПУ доценты*

**P.S.** *Мәкаләдә нигездә Чулпан Зарифның "Матбугат йорты" нәшриятында 2003 елда басылган "Кояшка юл тота кәрваным" һәм Рифә Рахманның Татарстан китап нәшриятында 2002 елда басылган "Керфекле тәрәзәләр" китапларында дөнья күргән шигырьләре файдаланылды.*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

### ИСХАКЫЙ ТУКАЙ БЕЛӘН ОЧРАШКАНМЫ?

Татар халкының үткән гасыр башында яшәгән ике бөек улы Габдулла Тукай белән Гаяз Исхакый арасындагы үзара мөнәсәбәт нинди булган? Алар очрашканнармы?

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИНның** киләсе елда журналыбызда басылып чыгачак хезмәте әнә шушы темага багышланган. Язмада әлеге ике олуг шәхеснең язмышы яңа фактлар аша тагын да ачыклана төшә,шул чорның рухи-әдәби мохите күз алдына китерелә.

***Хезмәт мавыктыргыч итеп язылган, укучылар аның белән танышып бай мәгълүмат алачак.***



Гомәр
Бәширов

# КҮҢЕЛ ДӘФТӘРЕ

### Әдипнең кәгъбәсе

Татар халык язучысы Гомәр Бәширов озын гомерле булды. Патша самодержавиясе дәверендә туып-үсеп, совет хакимиятенең барлык җиңү, үсеш һәм җимерелү этапларын кичереп, картлык елларын демократия дигән битлек астында килгән кыргый капитализм чорында уздырды. Аның физик гомере генә түгел, иҗат гомере дә шактый озын булды. Беренче зур әсәре "Сиваш" 1937 елда чыккан булса, соңгы көннәренә кадәр иҗат итеп килгән "Гыйбрәт" романы, кызганычка каршы, әдипнең вафатыннан соң 2000 елда дөнья күрде. Димәк, XX гасырның катлаулы, авыр елларын барысын да диярлек башыннан кичергән әдип үзенең уй-фикерләрен, тормышны аңлау фәлсәфәсен, иң изге хисләрен шул әдәби әсәрләре аша халыкка житкергән дип уйларга мөмкин. Әмма ләкин совет хакимиятендә хөкем сөргән кануннар, әдәбият-сәнгать өлкәсендә иҗат кешесенең хөрлеген бастырып яткан "социалистик реализм" дигән богаулар әдипне ул мөмкинлектән мәхрүм иттеләр. Бу-аерым Гомәр Бәшировның гына түгел, бөтен совет чоры язучыларының фаҗигасе. Әмма, шул богауларга да карамастан, Г. Бәширов халкына булган мәхәббәтен, ихтирамын һәм милләтнең буыннан-буынга саклап килгән иң яхшы сыйфатлары белән соклану һәм горурлану хисләрен үзенең әсәрләрендә тиешле дәрәҗәдә күрсәтә алды. Ул әсәрләр татар әдәбиятында үзләренә бер лаеклы урын алып торалар һәм бүген дә укучылар аларны яратып кулга алалар.

Әмма әдип Гомәр Бәшировның әйтәсе иң газиз сүзләре, тирән мәгънәле фикерләре, изге хисләре әле бүген дә халкына тулысынча житкерелмәде. Язучының әдәби мирасында 1937 елдан башлап соңгы көннәренә, 1999 елның май аена кадәр язып килгән көндәлек дәфтәрләре саклана. Әдип аларны "Күңел дәфтәре" дип атаган. Бу исем очраклы түгел. Әдәби әсәрләрендә, мәкаләләрендә әйтеп бетерә алмаган яки әйтә алмаган уйларын, кичерешләрен "Күңел дәфтәре"ндә теркәп барган. Бу калын-калын 5 дәфтәрдә илебезнең иҗтимагый-сәяси, халыкның көндәлек тормышы, әдәбият һәм мәдәният өлкәсендә булып узган вакыйгалар чагылган. Язучының "Сиваш", "Намус", "Туган ягым-яшел бишек", "Җидегән чишмә", "Гыйбрәт" кебек танылган әсәрләренең язылу тарихы, иҗат дәверендәге кичерешләре, килеп чыккан киртәләрне һәм каршылыкларны жиңү-барысы да көндәлек битләрендә тәфсилләп язылганнар. Замандашлары-күренекле татар язучылары Шәриф Камал, Таҗи Гыйззәт, Хәсән Туфан, Сәйфи Кудаш, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Ибраһим Гази, композиторлар Сара Садыйкова, Нәжип Җиһанов һәм башка бик күп

мәдәният әһелләре турында истәлекләре аларны безгә олы талант ияләре итеп кенә түгел, бәлки бөтен шәхси үзенчәлекләре, каршылыклары белән тасвирлый. Язмаларның күп битләре әдипнең илебез язмышлары турында уйлануларына, иҗат кешесенең җәмгыятьтә тоткан урыны һәм бурычы, гомумән, адәм баласының бу дөньяда яшәү мәгънәсе кебек мәңгелек проблемаларга багышланган.

Әдип 62 ел буена язып килгән көндәлек битләрен без бер-ике кич утырып укып чыга алабыз. Димәк, безнең күз алдында язучының язмышы, уй-фикерләре, иҗтимагый хәлләргә карашы кинодагы шикелле хәрәкәттә, үзгәреш процессында ачыла. Искә төшерик, язучы әдәбиятка гражданнар сугышында акларга каршы аяусыз сугышлар аша мылтык тотып узган, марксизм-ленинизм тәгълиматенә чын күңелдән ышанган һәм таянган коммунист булып керә. Соңгы елларында исә ул тормышка ашмаган коммунизм идеалларыннан арынган, фәкать гомумкешелек гуманизм идеяләрен һәм, иң әһәмиятлесе, үзенең халкына мәхәббәтен саклап калган һәм шуларга таянып иҗат итә башлаган әдип булып гәүдәләнә. Ничек узган бу процесс?

1939 елның 23 декабрендә үк әдип М. Гафуриның гаҗәеп тирән мәгънәле дүрт юллык шигыренең беренче юлын көндәлегенә язып куя:

"Изге күңлем кагъбәсеннән көн дә бер таш җимерелә."

Әйе, менә шулай 60 ел буена көн артыннан көн чын күңелдән ышанып яшәгән идеалларның берсе артыннан икенчесе җимерелеп барганын кичерү җиңел булмагандыр. Ә нәрсә калган?

Ул турыда уйлаганда минем күз алдыма Мисырның әллә ничә мең еллар җимерелми торган һәм киләчәктә дә торачак пирамидалары килеп баса. Әгәр дөрес булса, кайбер археологлар язуынча, ул пирамидаларның кайберләре тыштан шома, матур һәм ялтыравыклы юка ташлар белән түшәлгән булган, имеш. Тик алар гасырлар узу белән коелганнар, эзләре дә калмаган, әмма пирамидалар нык таштан төзелгән килеш бүген дә бөтен дөньяны сокландырып торалар. Әдипнең кагъбәсен мин әнә шул Мисыр пирамидалары итеп күз алдыма китерәм. Әйе, коммунизм идеаллары шул ялтравыклы тышкы ташлар шикелле коелып беткән, әмма әдипнең кагъбәсенең нигезен, асылын тәшкил иткән туган иленә, халкына-милләтенә, туган теленә мәхәббәте беркайчан да җимерелмәгән һәм алар әдипкә илһам, иҗат көче биреп торганнар.

Әдипнең әнә шул мәңге үзгәрмәс кагъбәсе бөтен иҗатының нигезен тәшкил итә һәм татар әдәбиятының киләчәгендә дә саклап калыр.

**Зөфәр БӘШИРОВ,**
*кулъязманы басмага әзерләүче.*

# БЕРЕНЧЕ ДӘФТӘР[1]

## (1937)

***

"Сиваш"ның хәзер түбәсе күренә башлады. Башта гел томан гына иде. Ә хәзер шул томаннан матур бина калкып чыга. Ул ямьсез булмаска охшый. Калыккан саен ул мөкәммәлрәк, күркәмрәк булып күренә. Үз проекты буенча эшләнә торган зур бинаның агачлар арасыннан бөтен бер нәрсә булып килеп чыкканын түземсезлек белән көткән архитектор-инженерны мин аңлыйм. Ул да менә шулай көтәдер.

**6 март, 1937.**

[1] Журнал варианты. Истәлекләр кыскартып басыла.

***

## *Үземә*

*Якты йолдыз калка дигәндә дә офыктан*
*Күренмәсә тирән шатлык син көткән -*
*Пошынма син, башың имә борчудан,*
*Бара бир нык басып туры юлыңнан.*

*Юлыңа аркылы төшсә еланнар,*
*Телгәләсә күңлеңне рәнҗетелгән вөҗдан -*
*Сатылма барабанга, ялтырауга,*
*Торма калтырап җан өчен куркудан.*

(Һа, нинди шигырь язып ташладым!)

**Июнь, 1937**

***

1937 елның ахыргы сәгатьләре. Бу ел үлә, яңасы туа.

Нәрсә бирде миңа бу ел?

"Сиваш"ны бирә язды. Мин аны йөрәк каным белән яздым. Мин ана бөтен көчемне бирдем. Төннәр йокламадым. Күнелемнен саф чишмәсеннән агып чыкты ул. Анда тузан кадәр дә кер юк иде. Һәм ул начар да түгел, һәйбәт әйбер, чын күнелдән язылган, зур әйбер.

Бюрократлар әле аңа һаман да дөнья йөзен күрергә ирек бирмиләр. Ул бу елда чыга алмады. Нигә чыкмый, белмим. Бәлки шулай кирәктер?...

**31декабрь, 1937.**

***

Ну, Тукай, шатлан, туган!

Бу арада синең бәйрәмеңне иттек. Шәп булды бәйрәм, һәйбәт булды. Син үз гомереңдә исән вакытында да андый тантананы, андый хөрмәтне күрмәден. Ул вакытта ул мөмкин дә түгел иде, чөнки син ул җәмгыятьнең үз кешесе түгел, ә аларга чит-ят иден. Синең йөрәгең безнеке иде.

Кичә Академиядә[2] синең тантаналы кичәң булды. Театр "тутырук" иде. Балконнар, "күгәрчен ояларына" хәтле тулган иде. Син андыйны күрә алмадың, Тукай. Синең чын күнеленнән агылып чыккан моңлы һәм үткен, ялкынлы һәм өметсез шигырьләрең әйтелгән саен зал котырынып кул чапты. Бу бит синен моңнарың, ялкыннарың әле хәзер дә исән, әле хәзер дә халык йөрәгенә барып житә дигән сүз. Бу бит әле син хәзер дә яшисен дигән сүз!



*Гомәр Бәшировның туган көненә кунакка килгән дуслары. Янәшә—шагыйрь Хәсән Туфан. Икенче рәттә, сулдан: фольклорчы галим Хәмит Ярми, шагыйрь Шәйхи Маннур. З. Бәширов фотосы.*

Шатлан, Тукай, шатлан!

Син чын укучыларыңны, синен шигыреннен чын юнәлешен һәм кыйммәтен, синең талантыңның олылыгын аңлаучыларны хәзер генә, безнең совет чынбарлыгында гына таптың. Бу бик дөрес. Чөнки чын культураның бердәнбер халык варислары без генә, совет җәмгыяте генә, безнен ил генә.

[2] Татар академия театры,Галиәсгар Камал исемендә.

Ни дисәң дә, йомшак якларың аз булмаса да, син бөтен иҗатыңны алып караганда халыкның үз моңын, үз кайгысын, үз көчен, үз йөрәк сагышларын җырлагансың. Син аны тирәнтен аңлагансың. Син вакытына күрә зур күсәк күтәреп чыккансың. Һәм сугышкансың. Ялгыз бер шәхес өчен бу зур эш, Тукай! Шуның өчен дә без сине яратабыз.

Шундый караңгы чорда тормыш хуҗаларына каршы үткен кылыч айкап чыгуың һәм талантың өчен сиңа рәхмәт, Тукай. Тик инде синең техникаң бераз картайган икән, анысына син гаепле түгел. Безнең шагыйрьләр синең рифмаларыңа сыеп кала алмыйлар. Сүзнең философик тирәнлеге мәсьәләсендә дә синнән узып китәргә кирәк.

**16 апрель, 1938.**

***

Әдәбият өлкәсендә эшләүче, бигрәк тә язучы яки шагыйрь, әгәр ул инде шул исемне алырга лаек булган икән, ул саф кеше, вак-төяк, чүп-чар хисләрдән, кешене әшәкеләндерә торган хисләрдән һәм гадәтләрдән арынырга тиеш. Андыйлардан арынырга аның көче җитәргә тиеш. Ул башкалар өчен һәм үзен үзе тотуы һәм белеме белән үрнәк булырга тиеш. Шундый кеше булмаганда ул массаны тиешенчә тәрбияләрлек әсәр яза алмый. Әйтегез, пожалуйста, ничек итеп исерек эчүнең зарары, аеклыкның файдасы турында кешене ышандырырлык нәрсә яза алсын? Яки вакчыл, көнче кеше, үзен һәммә кешедән дә дәү итеп уйлап та бер ни дә белмәгән кеше ничек итеп бөек идеяләр турында яза белсен?

Бүген радиода Гөлсем Сөләйманова җырлаганны тыңладык. Халыкчанлык дигән нәрсә ул әдәбиятта булсын, музыкада булсын, башкада булсын, формада гына түгел. Форма ягыннан халыкчан кебек күренгән нәрсәләрнең күбесе псевдонародный булып чыга. Монда формадан тыш халыкка хас булган тойгыларны, аның психологиясен яхшы белергә, аны китаптан укып, ятлап кына түгел, ә үзең бөтен күңелең, йөрәгең белән шуны сизәргә, хис итәргә кирәк. Халыкны белмәгән кеше форма белән генә, теге яки бу өлкәдә форма ягыннан халык иҗатына ошату белән генә бер ни дә булдыра алмый.

Җырчы Гөлсем Сөләймәнованың тавышы татар халык көйләрен җырлауга, аның моңын, музыкасын бирүгә иң лаек тавыш. Аның уңышының беренче сәбәбе шул. Бу тавыш безгә, татарларга таныш тавыш.

**29 сентябрь 1938.**

***

*"Изге күңелем кәгъбәсеннән көн дә бер таш җимерелә".*

М. Гафури[3]

Мин пессимистмы? Юк, мин оптимист, ләкин мин моңлы кеше. Нигә болай булды икән?

Моны минем тормышымның кече яшемнән үк эзли башларга кирәк. Кечкенә вакытта апа белән лапаста (гадәттә арбадагы печән өстендә) йоклап ятканда егетләр урамнан гармун уйнап китсәләр, мин уяна торган идем. Бик моңлы була торган иде. Мин гармун тавышын югалганчы тыңлый торган идем...

Элекке авыл минем өчен хәзер үзенең матурлыгы, күңелле яклары: көлгә пешкән бәрәңгеләре, бөрлегәннәре, мунчада үбә торган кызлары, ак оеклары, кичке уеннары, карабодай коймаклары һ.б. белән бергә, элекке тормышның бөтен караңгы якларын күрү өчен бер авыр сурәт. Аның сагыныр, мавыгыр җире юк. Тик моның әнә шул кечкенә чакта канга сеңеп, күңелгә утырып калып хәзер кайчак күңелне кытыклап торган көлдә пешкән бәрәңгеләре, ат ашатулары, кичке томаннары, күке, сандугач, песнәк, карлыгачлары гына бар. Боларны мин күңелдән алып ташларга теләмим дә.

[3] "Изге күңелем кәгъбәсеннән..." шигыреннән өзек. Мәҗит Гафури әсәрләре. Таттосиздат.Казан. 1941.158 бит.

Алар минем каныма сеңгәннәр. Ә шәһәрне мин алай ук якын итеп аңлый алмыйм. Авылның мина һәрбер исе таныш. Мин Бөйдә суыннан иртәнге томан белән бергә нинди ис күтәрелүен дә, юкә агачының бөресенең тәме, исе нинди булуын да беләм, аларны менә хәзер дә хәтерлим. Башка яклары да шулай ук.

**23 декабрь, 1939.**

***

Бу арада авылларда йөреп кайттым әле. 17октябрьдә чыгып китеп 5 ноябрьдә кайттым. Авыллар, заводлар, районнар күрдек. Фольклор җыйдык. Мин үзем генә дә 30дан артык әкият җыеп алып кайттым. Тик бу әкиятләр арасында оригиналь сюжетларның юк диярлек аз булуы гына һәйбәт түгел. Әкиятләр арасыннан "Мендәле" мина ошады. Бу минем өчен яна сюжет. Үзе, һичшиксез, татар халык әкияте.

Без Ярми Хәмит һәм Шәйхи Маннур белән бергә йөрдек. Ярми—киң күңелле, юмарт кеше. Эшен яратып, тырышып эшли. Иптәшлеге дә бик һәйбәт. Тик бераз җил як кеше. Үз фикере белән түгел, иптәше фикере белән йөрүчән. Кайчакны, шул кеше фикере белән йөри торгач, үзе дә күңелсезлеккә калгалый.

Шәйхи Маннур үзе турында бик күп уйлый. Акылсыз кеше түгел, таланты да бар. Ләкин үзен бик югары тота, үзенең үзлегенә табына, үзен бик дәү кеше, бик кирәк кеше дип уйлый. Анынча Маннур булмаса, пожалуй, дөнья да булмаган булыр иде.

Шулай да, башы мин-минлек исеннән айный торганда, бик кешелекле, иптәшлекле чаклары да булгалый.

**23 ноябрь, 1940ел.**

***

Сугыш! Сугыш!

Күптән ук көтелгән сугыш башланды. Без, менә зур сугышлар башланыр, менә ул вакытта шулай булыр, болай булыр дип сөйләнә торган сугыш шушы бит инде ул!

Дошман без көткәннән дә көчлерәк, явызрак булып чыкты. Ул, безнең җиргә басып кереп, сабый балаларны, хатын-кызларны суя башлады. Ул иң гади, хәтта иң тәрбиясез кешеләрдә дә була торган кешелек сыйфатларыннан да мәхрүм икән! Фашистлар күсәк күтәреп кеше өенә үтерү өчен ташланган исерек горилла кебек кылана. Ул кабахәтләрне хәтта поплар да чит күрәләр.

Хәзер дөнья үзгәрде. Бөтен халыкның күзе көнбатышка текәлгән: фашистларның берәр канаты сынмыймы? Зуррак берәр үзгәреш юкмы?

Безнең иманыбыз камил: фашизмга кабер казучы без булырга тиешбез.

Ә хәзергә көрәш, кан, көрәш, көрәш!

**10 август, 1941.**

***

Бүген Смоленскның китүен әйттеләр.

Борынгы шәһәр, борынгы халык. Бик күптән бирле килгән традицияләр—һәммәсе дә җимерелә, утка тотыла, җир белән тигезләнә. Нинди әшәке әйбер бу сугыш. Кеше XX гасырга яшәп килгәннән соң да бер-берсен суймыйча дөньяда яшәргә өйрәнә алмады, шундый бер җәмгыять оештырып житкерә алмады. Нинди вәхшилек, нихәтле кан, нихәтле һәлакәт!

Фашистларның балаларны, карт-карчыкларны суюлары, кешеләрне тере килеш егермеләп, утызлап кабергә салып күмүләре йөрәккә тия, күңелне ярсыта. Кабәхәтләр! Чын мәгънәсе белән кыргый разбойниклар икән. Борынгы кыргыйлар да дошманнарына гаҗәп каты булганнар. Ләкин болар, бу XX йөз вәхшиләре хәзер муеннарыннан канга йөзәләр. Бары дошманнарының йөрәкләрен йолкып алып ашамаулары гына бар.

Шушы кабәхәтләргә XX йөздә, көпә-көндез Европа уртасында шул кадәр

юлбасарлык итәргә ирек бирү ничектер күнелгә сыймый. Тизрәк туктатырга иде. Тизрәк дошманның бугазына ябышасы, үч аласы иде!

**14 август, 1941.**

***

Байтак иптәшләр фронтка китте. Муса Җәлилдән хат юк. Алиш сугыш полосасында. Дәүли хат язмый. Мин сугыш башлангач ук китәрмен дип уйлаган идем, әле һаман да алмыйлар. Хәер, мин картрак шул инде, аннан соң яна техника белән танышлыгым да шуның хәтле генә.

Кирәк булгач алырлар әле. Бер атна яки бер ай гына сугышны теге йә бу якка хәл итмәс. Әле бик күп корбан бирәсе булыр.

Тик шунысы кызганыч, шул сволочь дошманнарның комсызлыгы аркасында нихәтле халыкка кырылырга туры килә.

**6 октябрь, 1941.**

***

Кичә ике ай да ун көн йөреп фронттан кайтып төштем. Әле бүген-иртәгә ял итәм. Сугышны күрдем, аның кешеләрен күрдем. Авыр яклары да күп булды, түздем. Түземлек дигәндә ул миндә аллага шөкер бит, җитәрлек.



*Язучы Миргазиян Юныс (сулда) һәм Мөхәммәт Мәһдиев (уңда) Гомәр Бәшировта кунакта. Аккош күле. 23. 05. 74 ел.*

Инде хәзер күргәннәрне оештырып язып чыгарга кирәк.

Поезда кайтканда төрле халыкларның сугышта ничек катнашулары турында сүз чыгып китте дә, бер украина егете болай диде: "Татарлар минемчә иң яхшы кешеләр. Әгәр татар белән дусланып китсәң ул сине гомер буе онытмый, нинди генә кыенлыкка төшсәң дә, үзен корбан итеп булса да ул сине коткара. Аннан соң, гаҗәп тәвәккәл халык ул. Мин сугышның башыннан бирле фронтта. Татарларны миңа сугышның иң хәтәр урыннарында очратырга туры килде. Алар куркусыз халык".

Ул моны миңа түгел, башкаларга сөйләде.

Үз халкың турында шундый куанычлы сүзләр ишетү бик күңелле.

Ярый, бүгенгә җитәр.

**31октябрь, 1942.**

***

Истәлекләрдән самовар һәм мунча[4] турында язып ташладым да, башкасына тотына алмадым. Башта ике нәрсә бутала: бәрәнге, утын. Чөнки боларның икесе дә миндә юк, ә аларсыз яшәү мөмкин түгел. Киләләр дә башка керәләр, киләләр дә керәләр.

Иртәгә бераз җайласам, тынычлап тотыныр идем.

**14 декабрь, 1942.**

***

Шәриф абзый үлде.

Бу зур фаҗигане гади сүзләр белән генә әйтеп бирүе бик кыен. Үз гаиләннен

4 "Мунча". Хикәя,- Совет әдәбияты, 1943, №5.

бер әгъзасы кебек якын бер кешене, бөтен тормышы, эшчәнлеге, тирән акылы һәм бай тормыш тәҗрибәсе белән һәркемдә ихтирам тудырган шундый бер кешенең болай тиз генә үлеп китүе шул кадәр көтелмәгән бер хәл булды, әле менә хәзер дә, аның авырый башлавын һәм үлүен үз күзең белән күреп, каберенә балчык ташлаган кешегә дә ничектер бу бер ялгышудыр, бу чын түгелдер, бу табигатьнең иттифакый бер ахмаклыгыдыр шикелле тоела, аның үлүенә күңелнең ышанасы килми.

Безнең әдәбиятыбызның хөрмәтле аксакаллары, үзенең каләме, халык рухын тирәннән белүе белән ихтирам казанган ветераннары берәмләп-берәмләп мәңгегә югала баралар. Шәриф Камал шул хөрмәтле аксакалларның берсе иде. Аның әле язасы әсәрләре дә бик күп, ул әле минемчә язарга теләгәннәренең бер өлешен дә язып өлгермәгән иде. Без аның яңа әсәрләрен, аның авыр һәм гыйбрәтле бай тормыш юлын чигеп күрсәткән мемуар әсәрләрен көтә идек. Кызганычка каршы, алар барсы да Шәриф абзыйның үзе белән бергә һәлак булды. Инде һич булмаса көндәлеген генә язып калдырган булса да ярар иде.

Шәриф абзыйны өеннән Союзга күтәреп алып барганда Шамов, Яфаров, Нәкый Исәнбәт, Таҗи Гиззәт, мин һәм башкалар бар иде.

Тукайның аягы очына күмелде.

**25 декабрь, 1942.**

***

Иртәгә дүшәмбе көн, минем ял көнем. Ибрай Газый белән Фатих Хөсни фронтка киттеләр, иртәгә Мирсәй белән Шамов китәләр. Ә мин кайчан китәрмен икән?

Прозябание дип шушындый хәлне әйтә торганнардыр инде. Өйдә ут юк. Хатын кайтып керден исә караңгы дип, утын чи, мич янмый дип ачуланып йөри. Малайлар алып кайткан ипине ашап бетереп, яңадан сорый башлыйлар.

Барыннан да әшәкерәге шул, язып булмый, эшләп булмый. Кадерле вакытлар әрәм китә. Никадәр язасы әйберләр бар! "Татар егете" ярты юлда, "Туган ил" дигән нәсер язылмый ята, юл сызмалары язылмый тора. Чөнки ут юк. Эштән арып-талып кайтасың да караңгыда кармаланып ашап-эчкәннән соң йокларга ятасың. Башка чара юк. Сукыр лампаның да бензины бетәм, бетәм дип кенә тора.

Ичмаса көннәр дә тизрәк озынаймый.

Фронтка китәргә иде. Анда да китеп булмый, монда эшлә диләр. Эшләр шундый...

**14 август, 1943.**

***

Бу чиновниклык эше минем язучылыгымны харап итә бугай ахырысы. Эштән әлсерәп, телең чыгарып кайтасың да кич буе гасабиләнеп кулга эш тә алып булмый. Әгәр тыныч холыклы, ваемсызрак кеше булса, ул инде төкереп тә карамаган булыр иде. Ләкин мин алай була алмадым.

Я фронтка китеп булмады, я монда бер ни дә эшләп булмый. Бөтен вакыт, яза торган иң яхшы чак шул чиле-пешле хәбәрләрне, җанга ике тиенлек азык бирми торган җыен ерунданы төзәтеп уза.

**7 октябрь, 1943.**

***

Тукай кичәсендә булдым. Быел яхшырак узды.

Ничек әле:

"Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен..."[5], бер шигыре бар иде.

Гомер узган саен Тукайның кыйммәте ныграк сизелә бара, ул безгә ел саен якыная, халыкның аңа мәхәббәте көчәя бара.

Яшәсен Тукай!

**15 апрель, 1944.**

[5] Г.Тукайның "Көзге җилләр" шигыренә эпиграф.

***

"Намус"ны язам. Кичә алтынчы бүлеген очлап куйдым да тәртелеп торам. Нидә хикмәт?

Башта уйланган образлар әсәрнең барышында, конкретлаша башлагач, башта уйланмаган бик күп өстәмә көч сорый башлыйлар. Мәсәлән, яза торгач, миңа Нәфисәне бөтенләй икенче характерлы кеше итеп бирергә кирәк булып чыкты...

**16 апрель, 1944.**

***

Әле генә Сталин приказын тыңладым. Безнең гаскәрләр Бухарестка керделәр. Немецлар кача.

Союзниклар Германия чигенә 140 километр гына калдылар. Без җиңәбез. Сүз бары тик сугышның кайчан бетүе турында гына барырга мөмкин. Өч ай, дүрт яки аннан да тизрәк. Һәрхәлдә 1945 ел сугыш елы булмас инде.

Кешелек тормышының тарихында моңа хәтле тиңдәше булмаган шушы котычкыч авырлыкны җиңеп чыгып, үзенең чыдамлыгы, ныклыгы, куәте белән бөтен дөньяны таң калдырган шушы илнең иң гади гражданины булу да чиксез зур куаныч тудыра, рухландыра, көчне арттыра.

Шушы бөек чорга лаеклы эш эшлисе килә.

**31август, 1944.**

***

Әгәр дә ижат эше ирекле булса, ягъни әгәр аңа теләсә кем тотына һәм гайрәте кайткач бүтән эшкә күчә ала торган булса, аның өстенә ул акчага кызыгып кына эшләнә торган булса, димәк ижат кешесенең эчке дәрте һәм омтылышы куәтле булмаса, берәү дә бу эшкә үз ирке белән тотынмас иде.

Ижатның азабын бер нинди материаль кыйммәт белән дә түләп бетерү мөмкин түгел. Материаль бәя ул бары ижат кешесенең яшәешен тәэмин итү өчен генә ярый һәм шуның өчен генә бирелә торган нәрсә. Хәер, ул шулай аңлана да. Ижат кешесен аның башка ягы кызыксындыра, ижатның рухани азабы, авыр эзләнүләре, ижат куанычы канатландыра.

**12 гыйнвар, 1945.**

***

Акком асты язу өчен тыныч урам. Ләкин монда гына ятсаң (һәм озак ятсаң) үзең дә сизмәстән, акырын-акырын дәрвишкә әверелергә мөмкин. Ул вакытта янмассың, пыскырсың. 50 ел пыскып яшәгәнче 10 ел янып яшәсәң, ул мең өлеш артык.

Акыл сатам. Син акыл сатма, менә шуны күрсәтеп бир! Язып күрсәт. Кешеләр синең әсәреңнән шундый уйга килсеннәр. Менә булырсың егет!

**22 гыйнвар, 1945.**

***

Минем бик зур бер кимчелегем бар: мин тормышны һәм безнең киләчәкне шактый тирән итеп аңлый беләм, мин тар фикерле дә, вак та, коры шалтыравык кына кеше дә түгел. Дөньяны киң аңлыйм (относительно, конечно). Ләкин бөтен бәла шунда, бу карашым минем бик таркау, тегендә-монда чәчелеп, сибелеп яталар. Кирәк чагында мин аларны һәммәсен тиз генә бер җепкә тезеп бөтен бер нәрсә итеп оештыра алмыйм, кайвакыт иң төп чылбырын, төп моментны тота алмый азапланам. Минем таркаулыгым харап итә. Әсәрләремнең сюжеты җыйнак һәм нык эшләнгән булмавы да әнә шуннан килә булса кирәк. Бу гаҗәп нәрсә, хәтта җөмләнең артык сузынкы булуы, катлаулыгы, күбесенчә хәбәр тирәсенә килеп җитәрәк сүлпәнләнә баруы да әнә шуннан килгән кебек тоела.

Болар менә нәрсәдәндер: системалы тәрбия алмаудан. Яшь чагында теләсә нәрсә укыган, тормыш хадисәләрен теләсә ничек, буталчык итеп аңланган, укыганнарга тәнкыйть күзлеге белән карарга күз җитмәгән. Шуннан инде башта буткa килеп

чыккан, хаос.

Хәзер аны юлга салырга бик күп көч кирәк.

**24 гыйнвар, 1945.**

***

М. Горькийның бик акыллы сүзләре арасында мондыйлары да исемдә калган. Кешене экономик, сәяси һәм башка төр коллыктан азат итү генә җитми, аның рухы, җаны азат булырга тиеш.

Гаҗәп тирән һәм акыллы сүз!

Кешене икътисадый коллыктан азат итү белән генә ул әле чын мәгънәсе белән азат, ирекле, хөр кеше дигән сүз түгел. Ул коллыкка шул кадәр күнеккән, кешегә буйсыну шул кадәр аның канына сеңгән, ул үзен хөр кеше итеп, үз башына, мөстәкыйль эш башкарырга хаклы, шуна көче җитә торган кеше дип аңлый алмый. Бу бигрәк тә крестьян психологиясенә хас нәрсә. Крестьян гомер-гомергә патшага һәм аллага буйсынып гомер уздырган, шуңа гасырлар буенча күнегеп, атасы-бабасы каны белән шуны үзләштереп килгән кеше. Нилектән кайвакыт аңлатып төшендереп булмый, ә көч белән төшендереп була? Ул шунын галәмәте. Ул акылга караганда, көчкә буйсынырга яратарак бирә. Ул көчкә буйсынганда үзенең коллык хисен дә аклый: "Булмый бит, кушалар. Эшләми кара әле син!"

Яки менә хатын-кызлар. Совет хатын-кызлары закон буенча ирләр белән бер төрле хокукта. Ә чынбарлыкта ничек? Чынбарлыкта да шулай хөрме? Һич түгел. Һич күпертмичә әйтәм, аларның 100 дән 90 ы әле дә кол. Рухани яктан алар ирләренең, үзләреннән көчлеләрнең коллары. Хәтта бик белемле, культуралы кыз да, усал, чая холыклы комсомолка да күп вакыт иргә чыкканнан соң үзенең хөрлек сыйфатларын акырынлап югалта барып, төрле искедән калган гореф-гадәтләр, җолалар, тәртипләр һәм семья эчендәге законга сыймый торган кагыйдәләр йогынтысы астында гади бер өй эче кошына, иренең сүзсез буйсынучан колына яки, алай дип әйтү хәзерге заманда колакка бик каты, шыксыз булып ишетелмәсен дисәк, аның йомышын үтәүчегә әверелә.

"Намус" турында, аның сюжетын үзгәртү турында яңа фикер туып тора. Ул алгарак карап барсын, озын гомерле булсын өчен шушы соңгы вариант кулаерак булыр шикелле.

**12 март, 1945.**

***

Безнекеләр Берлинда сугышалар. Менә кайчан икән ул җиңү көне! Шушы бер атна эчендә сугыш бетәр шикелле.

***

Бүген иптәшләргә бик күп хат яздым.

Фатих Кәримнең үлгән хәбәре килде. Менә бит сугыш нинди ул.

**30 апрель, 1945.**

***

Мин исән-сау, һаман язып ятам. «Кайчан бетерәсең?»-диләр. Һай, башта яза башлавымны әйтмәгән булсамчы! Кайчан бетерермен икән соң? Бәлки декабрьдә, бәлки февральдә.

Бер нәрсә мине тынычландыра, ул да булса үземнең иҗатыма зур таләп куюым. Кайвакытта өчәр вариант языла. Ләкин берсе дә ошамый, берсе дә мин теләгәнне әйтеп бирә алмый. Аларны аяусыз, миһербансыз сызып ыргытам. Хәтта дүртенчесе дә ошамаска мөмкин. Анысын да сызам. Күңелем тынычланганчы шулай. Ә күңелем канәгатьләнерлек сурәт туганнан соң аны шулай язуыма монарчы үкенгәнем юк әле. Шаять, монда да ялгышмам.

**23 сентябрь, 1945.**

***

Мин теге яктагы фикернең дөреслеген әллә ничәнче мәртәбә раслый торган дәлилләрне менә бүген тагын очраттым.

Минем бер авылдашым бар иде. Кем иде ул? Бик гади генә бер малай. Аның белән бергә каз бәбкәләре үтереп йөрдек, тәрәзәләр ваттык, карчыкларның нәләтен алдык. 35 елдан соң мин аны бүген яңадан очыраттым. Ни күрәм? Минем авылдашым үзенә күрә бер философ, имеш. Ул шундый нечкә күңелле, ул шундый тирән әйберләрне белә, тормышның шундый нечкә борылышларын тоеп тора, һәм барыннан да бигрәк, аларны шундый гади итеп, крестьянча беркатлы һәм мәзәк итеп әйтеп бирә белә, мин дөресен әйткәндә бик гаҗәпкә калдым.

Нәтиҗәсе шул: без кешеләрне белмибез икән. Аерым алганда мин үзем әле һаман да кешеләр турында бер катлы уйда икәнмен. Гади кешеләр дә һәм башкалары да мин белгәнгә караганда бик күп катлаулырак һәм серлерәк икән.

**12 май, 1946.**

***

Бүген рамазан гаете.

Мин гадәттә дини бәйрәмнәрен белмим, искәрми уздыра торган идем. Чөнки якын-тирәдә, күршеләрдә бүген бәйрәм икәнлеген күрсәтерлек әллә ни үзгәреш булмас иде.

Хәзер, сугыштан соң бөтенләй башкача.

Бердән, 30-40лардан узган, өй тирәсендә торучы хатын-кыз һәммәсе дә ураза тотты. Уразасызларга карата хәтта ниндидер җәмәгать фикере урнаштыру, тәнкыйтьләү кебек нәрсә дә сизелә иде.

Бүген иртән торсам Татарстан урамын тутырып халык зиратка бара[6] (Алар гаетне тәмамлап чыкканнар инде). Кемнәр генә юк анда! Борынгы җиләнен кигән карт-коры, алардан яшьрәкләр, элек намазга йөреп калган, аның аз-маз рәтен белүче кешеләр. Алардан башка тагын, гаеткә бармый калуны яхшысынмыйча, олыларга ияреп баручы яшьрәкләр. Ярым хәрби киемдә, башына чуар кәләпүш кигән сугыштан кайткан кешеләр. Болар аеруча күп. Шундый сүз йөри: болар "әгәр исән-сау калсам, көчем житкән кадәр намазны укыр идем, гаетләрне калдырмас идем"—дип нәзер әйткән кешеләр. Алар хәзер үзләренең исән калуларын әнә шуннан күрәләр, шуна күрә гает кебекләрне, җомга кебекләрне калдырмыйлар.

Болардан калганнары яшьләр. Мәгълум ки, яшьләрнең күбесе комсомол членнары. Димәк, гаеткә баручылар арасында комсомол членнары да күп. Аннан кала малай-шалай.

Җомгага йөрүчеләр дә күп. Хәтта хәзер хатыннар да мәчеткә йөри башлады. Муллаларны ашка алу, авыз ачтыру һ.б. шундыйлар яңадан башланып китте.

Урамга күз салсаң карчыгыннан вак-төяк бала-чагасына кадәр һәммәсе киенепясанып чыккан. Димәк, бәйрәмне тегеләй-болай гына түгел, чын күңелдән итәләр. Хәтта моның ни икәнен аңлаучы кешеләрнең дә хәзер дин мәсьәләсенә алай элекке кебек нәфрәтләнеп карамаулары, ничектер аңа теләктәшлек күрсәтү сыман бер нәрсә дә сизелә.

Миңа шактый зур белемле берәү шул мәсьәлә турында болай диде:

—Ни кылмак кирәк, дин кешенең күңел бушлыгын тутырып, поэтик бер нәрсә белән тулыландырып тора торган бер нәрсә бит ул. Дин булмаганда тирән интеллектуаль тормыш белән яшәмәгән кеше үзенең рухын буш саный, ниндидер бушлык сизә, аңа билгеле, күңелсез була.Нигә дә булса бер нәрсәгә иман китерергә кирәк ләбаса.

Сугыш дигән нәрсә халыкның тормышына зур үзгәреш кертте. Диннең көчәюе дә әнә шуннан.

Дин бетүгә таба барасы урынга шулай көчәеп килә, тирәнәя. Элек мин яшьрәк вакытта дин нәфрәт тудыра иде, хәзерге татар яшьләре аңа ниндидер бер хөрмәт саклыйлар.

**22 сентябрь, 1946.**

[6] Ул елларда Татар зиратының капкасы Яңа бистә ягында иде, шунлыктан халык зиратка Татарстан, М.Гафури урамнары буенча йөри иде.

***

Биш елдан бирле сагынып, түземсезләнеп, зарыгып көткән куанычлы көннәр килеп житте. “Намус”ны тәмам итеп, ниһаять тапшырдым[7]. Бу чорны уздыру миңа шулкадәр авыр булды һәм мин бу әсәремнен тәмам булуын шулкадәр тынгысызланып көттем, хәтта каты авырган вакытларда мин инде аны тәмамлый алмам, ни булса да булыр кебек тоела иде. Гомеремдә беренче мәртәбә бугай, мин күңлемдәген үзем хис иткәнчә, үзем канәгатьләнерлек итеп әйтеп бирә алдым шикелле. Язучы өчен бу бик зур куаныч. Бу үзеннең идеалына якынлашып килү дигән сүз.

Бик күп авырлыклар кичердем, бик күп кыенлыкларны җинеп чыктым. Әмма ничек итсәм иттем, язып бетердем!

Менә хәзер аны укыйлар. Әле берәүнең генә дә кире фикер әйткәне юк. Мин ышанам, андый фикер булмас та.

(Иң соңгы өлешен 24 ноябрьдә тапшырдым).

**30 ноябрь, 1947.**

***

Беркөннәрдә мине Язучылар союзына яшь язучылар белән очрашырга чакырдылар. Иҗат эшләрен, ничек материал туплавын турында тәҗрибә уртаклашу булыр диделәр. Нибары 15-20 яшь язучы булачагын әйттеләр.

Барып керсәм, астагы бүлмәләр тулган, коридорда әлләни кадәр халык. Һәммәсе дә яшьләр, кызлар. Берничә әдәбият укытучысы һ. б. бар. Союз бүлмәсенә сыеп булмады, Тукай залын ачарга туры килде. Бераздан зал бөтенләй тулган иде. Иллědән артык сорау бирделәр. Арада “татар совет прозасын янадан аякка бастыруыгыз өчен бик рәхмәт сезгә!”-дигән записскалар да бар иде.

Гомумән, бик күнелле үтте.

Мәскәүдән бик күңелле хатлар килә. Төрле өлкә һәм районнардан килгән хатларның саны 40тан артык.

Менә шундый хәл.

“Намус”ка Октябрьнын 30 еллыгы уңае белән оештырылган конкурста Iнче бүләк бирергә карар ителде.

Иптәшләр бу зур уңыш белән котлап кулымны кысалар.

Сәгыйт Исәнбай сөйли: “Бик күп хатлар килә. “Н” кайчан чыга дип сорыйлар. Мин районда булдым. Райком авылнын барлык активына “Намус”ны укырга кушкан. “Н” укымаган кеше—надан кеше. Басуда агитаторлар шуны укыйлар. Чөнки аның агитациясе дә, бүтәне дә—һәммәсе дә үзендә. Аны укыганнан соң агитировать итеп торасы да юк”.

Күптән түгел Дөбъязда укучылар конференциясендә булдым. Менә кичә генә Республика китепханәсенә укучылар белән очрашуга, шулай ук конференциягә чакырдылар. Көн саен дөнья кадәр хат килә.

Гомумән, мин бу эшемнән канәгать.

Әйе, ул әнчекләр тик өрә бирсеннәр!

Аннан миңа ни зарар? Алар мине туктата алалармыни?

**18 февраль, 1949.**

***

Әй Тукай, моңлы Тукай, дәртле Тукай, даһи Тукай!

Татар халкының бәлки бердәнбер якты йолдызы! Син күптән сүнден инде, ә синең нурың һаман да балкый әле. Бәлки син безнең халыкның дөньяда яшәгәнлеген раслап калдыручы бердәнбер даһиендыр әле. Без бетәрбез, без сүнәрбез, ә синең даһиең дөнья күгендә һаман балкыр, шундый-шундый бер халык булганлыгын, кайчандыр шундый бер хезмәтчел, шундый бер шагыйрь җанлы тырыш халык яшәгәнлеген исбат итеп һаман ялтырар, һаман балкып торыр! Безнең исемебезне, безнең иң якты хыялларабызны киләчәкнең якты көннәренә алып барыр!

[7] “Совет әдәбияты” журналына.

Тукай шигырьләрен тыныч кына тынлый алмыйм. Ул татарның Пушкины. Бөек Пушкин рус халкының даһи сыйфатларын биргән кебек, Тукай да үз халкының иң гүзәл сыйфатларын җырлап узган. Аның кебек халыкчан, аның кебек үзендә туган халкының иң үзенчәлекле, иң гүзәл сыйфатларын гәүдәләндерә алган бүтән шагыйрь яки язучыны мин белмим. Нинди бәхет Тукайның булуы, һәм нинди зур фаҗига аның шулай вакытсыз, шундый аяныч хәлдә һәлак булуы!

**15 апрель 1949 ел.**

***

Бүген минем ифрат дулкынланган көнем: минем "Намус"ны быел Сталин бүләгенә кандидат итеп күтәрделәр. Монда узды, Мәскәүдә Язучылар Союзы президиумында бер тавыштан узды. Аның өстенә мин белгән бөтен кешенең фикере шулай: ул, һичшиксез, бүләк алырга тиеш диләр.

Белмим, үз әйберең турында ул шулай, ул алырга тиеш дип әйтү тыйнаксызлык булыр иде. Әмма, күңел дигәнең гаҗәп җилбәзәк нәрсә бит!

Үзем өчен түгел, әгәр минем бу әсәрем азмы-күпме лаеклы әсәр дип табылса, татар совет әдәбиятының авторитетын һәм дәрәҗәсен күтәрү өчен, бүтән әйберләр калкып чыкканчы минем әсәрем ала торса, билгеле, минем өчен генә түгел, безнең бөтен социалистик культурабызның үсүе өчен моның әһәмияте чиксез зур. Без бөтен Совет культурасына, аның совет әдәбиятына азмы-күпме хезмәтебезне өсти алдык дип куаныр һәм тагын да куаныбрак эшләр идек.

Белмим, иртәге көн ни әйтер. Кем белә, бәлки минем бу әсәремә салган якты уйларым башка иптәшләргә дә барып җиткәндер.

**21 декабрь, 1949.**

***

Күңелем тынычлана алмый. Нидер житми, нидер уйлаганча түгел. Нәрсә җитми? Мина кайвакытларны бик авыр, бик! Як-ягыма әйләнеп карыйм да юксынып күптән түгел узган вакыйгаләрне, кешеләрне күз алдына китерәм. Кеше үзе картаеп килсә дә аның йөрәге картаймый икән. Я, бик ансат кебек бит инде: барына канәгать булып, тик кенә, тыныч кына яши бирергә! Юк, алай булмый! Күңел эзләнә, күңел тормышның иң ямьле, иң матур узганнарына кайтып тагын бер мәртәбә шул узганнар белән яшәп карыйсы килә. Ә ул мөмкин түгел инде. Әмма аның мөмкин түгеллеген белсәң дә өметне өзәсе килми. Нигә? Алда тормыш озын бит әле. Нигә тагын шулай булмаска мөмкин? Нигә тагын теге вакыттагы кебек үк, унсигез яшьлек малайсыман, бөтен дөньянны онытып тормышның сиңа багышлаган ямьле, гүзәл саташуы эчендә яшәмәскә? Минем аңа хакым юкмени? Бар кебек.

**10 ноябрь, 1950. Акком асты.**

***

Бу көннәрдә "Культура и жизнь" газетасында "Намус" турында гаҗәеп бер мәкалә басылып чыккан иде, менә кичә инде шундый ук мәкалә "Правда"да басылды. Бер китап турында шундый авторитетлы ике газетада бер-бер артлы шундый мәкаләләр басылып чыгуы ул бит бик сирәк була торган хәл. Искиткеч! Минем әле ничектер ышанып җитәсем дә килми. Без бит андый югары күтәрүгә гадәтләнмәгән, мин бит үземне һәрнәрсәнең иң башта иң кыен, иң авыр ягын күреп, шул ягын көтәргә гадәтләнгән кеше.

Беренче мәкалә басылганнан бирле телефон бертуктаусыз чынлап кына тора. Галимнәр шалтыраталар, язучылар, артистлар, яисә иң гади шәһәр кешеләре—әдәбият укучылар шалтыраталар. Һәммәсе тәбрик итәләр, куаналар, рухлануларын, тагын да дәртләнеп китүләрен әйтәләр.

**11 март, 1951.**

***

Карар чыкканнан соң ун көн узды инде, ә мин һаман да эзгә төшеп житә алмыйм әле.

Ул 17сендә башланды. Дөресрәге, минем өчен ул аннан бер ун-унбиш көн элек башланган иде инде. Әмма Москва үз авызы белән әйткәнче ышанасы килмәгән иде. Ниләр булмаска мөмкин?

Әйе, 17сендә башланды һәм ниһаять 18ндә кичен ТАССтан телефон белән әйттеләр: Кави һәм мин икенче дәрәжәгә эләккәнбез. Менә шул вакыттан китте инде: шылтырата башладылар. Төнге бергә кадәр берсеннән берсе ишетеп ярты шәһәр шалтыратты, иртә белән карарны укый башлауга, мин үз фамилиямне ишетеп кенә бетердем, тагын башланды.

Менә хәзер генә төшенә башладым: ул минем куанычым гына түгел, бәлки бөтен халык куанычы булып әверелде һәм барлык жыелыш һәм митингларда шулай яңгырады. Халык аны миңа һәм бүтәннәр хезмәтенә хөрмәт итеп кенә түгел, бәлки үзенең талантына хөрмәт итеп кабул итте. Моннан да зуррак нинди бәхет булуы мөмкин тагын?

Я, моннан соң безнең начар язарга хакыбыз бармыни инде.

**29 март, 1951.**

***

Соңгы 3-4 ай эчендә минем тормышымда гына түгел, бөтен татар совет әдәбияты һәм культурасы тормышында гаять зур куанычлы вакыйгалар булып узды. Мондый хәл еш кабатланмый. Бу безнең барыбызга да зур сабак, бу безнең язучыларыбызның соңгы 30 ел эчендәге әдәби ижатларына бер йомгак. Чөнки ике язучыга бөек юлбашчыбызның бүләген бирү ул Кави Нәжми яисә Гомәр Бәшировның гына хезмәте түгел, бәлки бөтен татар совет әдәбиятының, аның алдынгы язучыларының казанышы, ул безнең партиябезнең оста һәм зирәк житәкчелегенең нәтижәсе.



*Язучы Сәйфи Кудаш Гомәр Бәшировта кунакта. Аккош күле.*

"Намус" 1948елда ук басылып чыккан иде бит инде. Аннан соң байтак кына вакыт узды. Аны 49елдан башлап һәр елны диярлек Сталин премиясе алуга кандидат итеп куялар, әмма ни булса була—ул узмый иде. Беренче елны ул әле подстрочник хәлендә генә куелды, икенче елны (1950елда) Таткнигоиздатта китап булып чыкса да Москвада чыгып өлгермәде, чөнки нәшрияттагы кайбер бюрократлар аны тәмам әзерләнеп житкәннән соң алты ай буенча укымый яткырдылар.

Минем беренче китаптагы егетләрем, кызларым һәммәсе дә үсәләр, дәү кеше булалар бит инде.

Аларның һәммәсенең үз юлы, үз тормышы бар. Һәммәсен алдан күрә белергә кирәк.

**4июль, 1951 ел.**

***

Мин үземнең язучы икәнлегемне оныта башладыммы соң, нигә бу дәфтәргә болай сирәк язам икән?

Шау-шусыз, гади генә узган тормышта да әллә никадәр сокландргыч вакыйгаләр, кабатланмастай күңелле хәлләр, онытылмаслык истәлекләр була.

Февраль аенда республиканың көньягында, нефть районнарында йөреп кайттым (алар турында аерым дәфтәрдә). Нинди байлык, нинди соклангыч кешеләр, никадәр поэзия! Хәзер менә барысы да күз алдына килә дә дулкынланам. Ул турыда язмыйча кала алмам ахрысы, язармын, начар да язмам! Хәзергә үз көчемә ышанам.

Гомумән алганда, тормыш дигәнең ифрат катлаулы. Фән бик күп яңалыклар ачты, җирнең астында һәм өстендә, һавада һәм суда кеше күзе житмәгән, кеше акылы, фән карашы белән яктыртылмаган бер өлкә дә, бер генә караңгы урын да калмады кебек. Хәтта бездән миллион километрлар ераклыктагы йолдызларның нинди матдәләрдән торуларын, аларда моннан миллион еллар элек һәм хәзер температураның нинди булуын, моннан ун меңнәрчә еллар элек яшәгән хайваннарның ни белән туклануларын да беләбез.

Ләкин табигатьнең ачылмаган яклары шулкадәр күп әле, ихтимал, ул кеше дөньяда күпме яшәсә шуңа кадәр дәвам итәр.

**29 март, 1952.**

***

Үзеңне үзең җиңүдән дә авыр көрәш юк диләр. Ул фикер дөрес булса кирәк. Әмма икенче яктан бу көрәш иң мактаулылардан да. Мин ышанам, әгәр бала чагында ук дөрес тәрбия алган кеше яшь вакытында ук үзен-үзе тикшерергә, үз кимчелекләрен төзәтергә, үз максатына ирешү өчен күп кыенлыкларны җиңәргә сәләтле булса, ул кеше бик югары күтәреләчәк.

Мин моны геройларым аша күрсәтергә омтылып карыйм әле. Иң төп максат—үз үзеңне "мөкаммәлләштерергә" омтылу, максатың булу, шуңа бөтен көчеңне, талантыңны туплау! Кимчелек бар икән, ыңгырашма, үзеңне кирәкмәгәнгә аклап маташма, бәлки кимчелегеңне төзәт! Гаебеңне әйтү, аны тану, бәлки мең төрле авыруга түзүдән дә мең өлеш кыендыр. Әмма күзеңә яшь килсә дә ачысын әйт!..

Кимчелегеңне таный белү, аны төзәтергә әзер булу йомшаклык түгел, бәлки батырлык. Чөнки ул кешедән зур көч сорый, кеше кимчелеген төзәтү аша гына алга китә алачагын аңлап эш иткәнлектән бу киң карашлы кешегә хас сыйфат дияргә мөмкин. Ялгыш булуын белеп торуына карамастан үз фикерен яклаучы кеше, никадәр генә нык, никадәр генә көчле кебек күренмәсен, ул вак кеше, мещан характерлы кеше. Әгәр шуны (ягъни, ялгышын) аңлый торып, шулай да белмәгәнгә салыша икән, кимсетелгән кеше булып кылана икән, ул инде куркак кына түгел, бәлки икейөзле дә.

Кешене монаю, юксыну, кайгы-хәсрәт кебек шәхси тойгыларын тату хокукыннан азат итәргә маташу ул иләк белән су ташу кебек үк мәгънәсез нәрсә. Чөнки аңа карап кеше кайгы-хәсрәттән бер үзе, үз көче белән генә азат була алмый. Кеше җәмгыять белән бергә, коллектив эчендә генә бәхетле була ала.

**20 апрель, 1952.**

***

Язучы граверга охшый. Ул чи материалны ала да шуны граверларча барлык якларын, һәр кырын үзенең идеясына буйсындырып, җентекләп эшли. Аңа сүз, тел ярдәм итә. Язучының уен әйтеп бирә торган тел бик нык эшләнгән, чарланган булырга тиеш. Монда язучы кеше уй-фикеренең мөмкин кадәр ачык, образлы, чит сүзләрдән, уйны яисә образны томалап торырдай артык сүзләрдән арынган булуына ирешергә омтыла. Җөмләнең һәр сүзе образның теге яисә бу ягын ачып бирергә, аны мөмкин чаклы калку, күренерлек итеп бирергә ярдәм итсен. Әгәр җөмләнең берәр сүзе шул максатка хезмәт итми икән, димәк, ул артык, димәк, ул нинди генә матур сүз, нинди генә көчле сүз булмасын, бу урында кирәкми, авырайтып кына тора. Мәсәлән, газеталарда шундый җөмләләр очрый: "Халыкны коммунизм рухында тәрбияләү хәзерге көндә иң мөһим бурычларның берсе булып тора..." Бу соңгы ике сүз—артык, чөнки алар ни дә булса өстәмиләр, бары сүзне генә күбәйтәләр, фикерне сыеклыйлар.

**6 сентябрь, 1953.**

***

Тажи Гыйззәт 7 мартта үлде, 9нчы мартта татар зиратында Салих Сәйдәш белән янәшә күмдек. Үләсе көннең элекке көнне безнең иптәшләр баргач әйткәне:

-Үзебезнең (язучылар) дачасында торасым бик килә. Верандага чыгып утырыр идем, яшь каен яфракларының леперләүләрен тыңлар идем. Шул вакытка кадәр түзә алсам, аннан соң үлмәс идем...

Тажи абзыйны күмәргә җыенып йөргәндә 8нче мартта Халыйк Садри үлде. 6ларында анын югалткан иде, шуннан соң аңына килә алмады. Аны 10 мартта М.Гали белән янәшә күмдек.

Иван Петрович Заботин да озакка түзә алмады, 17нче мартта көчле кан килеп ул да үлеп китте. Ул иртәгә, 19 мартта рус зиратында күмеләчәк.

Эшләр менә шулай бик күңелсез әле, туганнар.

**18 март, 1955.**

***

Бер серемне язып әле: минем эшем шактый ук авыр. Язучылар Союзының рәисе буларак байтак кына эшләр башкарырга туры килә бит инде. Күбесенең квартирасы бик начар, аның өчен дә мин җаваплы. Яхшы әсәрләр язарга кирәк, анысын да "дәү абыйлар" иң элек миннән сорыйлар. "Нәрсәләр бирәсез, ничек, нигә фәлән нәрсәләр турында язмыйсыз?" Аны бит барысына да кычкырып сөйләп йөреп булмый. "Язалар, менә фәлән әсәр чыга, тегене язалар, менә озакламыйча бу әсәр чыга, тегесе куела, фәлән-тегән..."-дисең. Ләкин укучының соравына лаеклы әсәрләр ни генә дисәң дә күп чыкмый.

Шуннан баш ката, халык бик күп сорый, әмма без бик аз. Бөтен Татарстанга нибары илле язучы. Аның арасында әле инвалидлар бар, яхшы яза алмаучылар бар, картлар бар. Ничек итеп язучыларны йөзгә житкерергә икән? Шул йөздән берике генә яшь язучы чыксын икән? Шамовларны, Ибрай Газый, Мирсәй Әмирне алмаштырырлык кешеләр! Андыйлар юк әле, юк! Ышаныйк, андыйлар безгә килсен, күп булсын!

**10 апрель, 1955.**

***

Күңел, күңел! Кайларга очасың, нәрсәләр көтәсең? Кайвакыт уйлар, хисләр, әле генә аякка баскан чебешләрсыман, бер нәрсә белмәстән, берни уйламастан, тегендә, монда төртеләләр, кайдадыр барырга, нидер эшләргә телиләр. Ләкин алар әле үзләренең кайда барасыларын да, ни эшләргә теләүләрен дә белмиләр. Ярый ла аларны кирәк урынына юнәлтергә акылың житсә! Ә житмәсә?..

**9 июнь, 1955.**

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Ф. Фәтхуллин, Казакъстан

### МОХТАР АУЭЗОВ һәм МУСА ҖӘЛИЛ

"...1957 елгы иң шәп әдәби әсәрләргә Ленин премиясе бирү мәсьәләсе тикшерелгәндә, СССР Министрлар Советы каршындагы әдәбият һәм сәнгать комитеты утырышларының берсендә данлыклы казакъ язучысы Мохтар Ауэзов чыгыш ясады... Татар телен Семипалатинскида,Татар бистәсе халкы белән аралашып яшәгән чакта ук шәп белгән әдипнең Җәлил шигырьләрен татарча укыганлыгы сизелеп тора иде. Чыгышының ахырында ул болай диде: "Әгәр премия бер генә кешегә бирелә торган булса да,бу кеше Муса Җәлил булырга тиеш".

***Җәлил Ленин премиясен алганга инде ярты гасырдан артып китте. Әмма һаман бер сорау ачык кала бирә: ике бөек язучы бер-берсен белгән микән?.."***



Бертуган Ләбибә һәм Венера Ихсановалар. 1980 ел.



Фәнис Яруллин әнисе Бибигарифә һәм сеңлесе Һәнүзә белән. "Бәкер" санаториясендә. 1963 ел.



*Артистлар гаиләсе. Халык артистлары Исламия Мәхмүтова һәм Хәлил Мәхмүтов. 2000 ел.*



*Язмыш. Чит илдә япа-ялгыз гомер кичерүче 99 яшьлек мөһаҗир Ильяс Абдулла (1909 елны Казанда туган). Мюнхен. 2008 ел.*



*Язучы һәм тәрҗемәче Лирон Хәмидуллин гаиләсе белән. 1995 ел.*

## Канәфи Нәфыйковка 70 яшь

Канәфи Нәфыйков 1938 елның 15 ноябрендә Татарстанның Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылында туа. Эчкерсезлек, тырышлык, җитдилек һәм үҗәтлек кебек сыйфатлары да авыл тамырларыннан, нәсел-нәсәбеннән, туган җиренә мәхәббәтеннән килә. Ул, картиналарында туган җир образын сурәтләп, туган халкына бетмәс рәхмәтен дә белдерә шикелле.



Театр рәссамы, тарихи жанр остасы буларак та аның бик күп полотнолары татар рәсем сәнгатендә күренекле урын алып тора.

Казан сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң Ташкент институтында укый, белемен-осталыгын күтәрә. Шул елларда ул данлы рәссам Чыңгыз Әхмәров һәм аның иҗаты белән якыннан таныша. Урта гасырлар ислам Көнчыгышы сәнгатен ачу һәм Үзбәкстандагы элек-электән тарихка карата булган ихтирамлы мөнәсәбәт белән очрашу аның язмышында зур роль уйный.

Ата-бабаларның, гомумән, халык тормышын өйрәнү, риваятьләрдә дан җырланган батырлыкларны яд итү, иске китапларда язылган зирәклек алдында баш ию—аның алга таба бөтен гомереңең төп максатын, үзенчәлеген билгели. Атаклы оста, рәссам Бакый ага Урманче белән аралашу сәгатьләре исә Нәфыйков өчен, профессиональ мәктәп булудан тыш, чын мәгънәсендә тормыш мәктәбенә дә әверелә.

Борынгы Болгар темасын (татар тарихы дигән сүз!) К. Нәфыйков, кайта-кайта төрле вариантларда эшли. Мәңгелеккә күчкән шәһәр урамнарын һәм базарларын, аны кешеләре белән дә "терелтеп", ул чактагы корылмаларның камиллеген, мәһабәтлеген күз алдына китереп бастыра ул *("Болгарда бер урам", "Ак палата", "Кызыл палата")* һ. б.

Тарихи портретлар... Боларны тарихи дәреслеккә тәңгәл китерү өчен күпме китап һәм истәлекләр укырга кирәк тә, күпме эзләнүләр, фантазия кирәк. Менә шушы "киртәләр"не ерып чыга Нәфыйков һәм безнең бөек шагыйрьләребездән Кол Гали, Алтын Урда чоры шагыйре Сәиф Сараи, Казан ханлыгының фәлсәфи шагыйре Мөхәммәдьяр, Габделҗаббар Утыз Имәни, Габделҗаббар Кандалый портретларын аның һич икеләнүсез зур уңышы дип бәяләргә мөмкин.

Татарстан рәссамнарының күбесенә хас булганча, Канәфи Нәфыйков та Тукай темасына еш мөрәҗәгать итә. Аны, барыннан да бигрәк, Тукай даирәсендәге шәхесләр кызыксындыра: Сәгыйть Рәмиев, Хөсәен Ямашев, беренче татар актрисасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская.

Инде дә аның музыкантлар, рәссамнар һәм сәясәтчеләр хөрмәтенә иҗат ителгән портретларның кайберләрен санап китик: Кәрим Тинчурин, Салих Сәйдәшев, Бакый Урманче, Шамил Монасыйпов, Лариса Маслова, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Тәлгат Галиуллин, Зәки Зәйнуллин (1980—2000).

1973-79 елларда Канәфи Нәфыйков Казан сәнгать училищесында укыта.

Ул—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1999).

## Мансур Хәсәнов



Хәсәнов Мансур Хәсән улы 1930 елның 25 июнендә Зәй районының Бигеш авылында туган.

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм дәүләт эшлеклесе буларак, аның башкарган эшләре һәм вазифалалары бихисап. Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы (1992). Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1995). Озак еллар Казан дәүләт университетында укыта, профессор. 1961-71 елларда КПССның Татарстан өлкә комитетында мәдәният, фән һәм уку йортлары бүлекләре мөдире. 1984- 1992 елларда премьер-министр урынбасары, соңрак аның беренче урынбасары.

1992 елда, үзгәртеп корулар чорында, Татарстан Фәннәр академиясен оештыручы һәм аның президенты. Бер үк вакытта 1992 елдан академиянең Татар энциклопедиясе институты директоры.

Аның фәнни һәм әдәби хезмәтләре татар ренессансына, әдәбият белеме методологиясенә, әдәбият, мәдәният һәм иҗтимагый фикер үсеше тарихына багышланган. Шулай ук Ш. Мәрҗани, Г. Тукай, И. Гаспринский, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Камал, К. Тинчурин, С. Максудиның иҗади эшчәнлегенә багышланган мәкалә, китаплары да олы ихтирамга лаек.

## Рафаэль Мостафин



Язучы, тәнкыйтьче, журналист Рафаэль Әхмәт улы Мостафин 1931 елның 14 маенда Татарстанның Баулы шәһәрендә туган. Казан университетын тәмамлаганнан соң укытучы, комсомол райкомы секретаре, район газетасы хезмәткәре булып эшли, аспирантурада укый. Аны тәмамлагач, Мәскәүдә чыга торган "Литература и жизнь" газетасының махсус хәбәрчесе, соңрак Казан телестудиясендә әдәбият-сәнгать бүлегенең баш мөхәррире. Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре (1963-68), аннары өч ел чамасы "Казан утлары" журналының һәм 1991-97 елларда "Татарстан" журналының баш мөхәррире. Филология фәннәре кандидаты.

Р. Мостафин күп еллардан бирле каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең легендар тормышын һәм иҗатын өйрәнү буенча тарихи-гыйльми эзләнүләр алып бара, бу темага күп кенә китапларын нәшер итә ("Муса Җәлил эзләре буйлап", "Дингез көндәлеге" һ. б.). Ул—Кабан күленә бәйле легендаларны яңача яссылыкта яктырткан "Кабан күле серләре" дигән документаль повесть һәм президентыбыз Минтимер Шәймиев турындагы саллы китапның автордашы буларак та укучыларга яхшы таныш.

Герой-шагыйрь Муса Җәлил турындагы әдәби-гыйльми тикшеренүләре һәм ачышлары өчен Р. Мостафин 1976 елда Татарстан яшьләр оешмасының Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды. 1985 елда аңа Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде. Ул—Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (2006).

**Альфрет ӘБДРӘШИТОВ**

## Заһидулла Яруллинның тууына 120 ел

Халык музыканты, беренче татар пианисты Заһидулла Яруллин 1888 елның 12 октябрендә Мамадыш өязенең Кече Сөн авылында крестьян гаиләсендә туа. Әтисе Ярулла сабан туйларында көрәшергә, "Кәмәринкә" һәм "Чабата" көйләренә биергә яраткан. Ул шахтага күмер чабарга киткән җиреннән кире әйләнеп кайтмый. Әнисе Гөлзәлифә дә, чирләп, кинәттән үлеп китә. Әнә шулай итеп, Заһидулла атлы малай биш яшеннән тома ятим кала, төрле гаиләләрдә тәрбияләнә.

12 яшендә аны Чистайдагы Иманкол байга тамак ялына малайлыкка бирәләр. Бай рәхим-шәфкатьсез була, ярты елдан малайны өеннән куып чыгара. Бәхетенә, урамда каңгырап йөргән ач малайны Иосиф Шнейдер дигән кеше үзенә тәрбиягә ала. Музыка коралларын төзәтүче бу останы ул "Йосыф абый" дип йөртә башлый.

Чистайның үзеннән генә түгел, чит-ерак җирләрдән дә, төзәтергә дип, бу йортка хәтта пианино да китергәлиләр. Үсмер Заһидулла Йосыф абыйсыннан беренче дәресләр ала, нота әлифбасын үзләштерә, пианинода уйнарга өйрәнә. И. Шнейдер вафатыннан соң Заһидулла икенче тапкыр ятим кала. Остазыннан аңа төрле инструментлар салынган бер капчык мирас кала. Ул Сембер, Самара, Уфа, Оренбург шәһәрләрен гизеп, скрипкада уйнап, музыка уен кораллары төзәтеп тамак туйдыра.

1908 елны, ниһаять, Казан каласына аяк баса. Вакытлыча постоялый дворга урнаша. Беренче көннәрендә үк атаклы Печән базарын гизә. "Амур", "Сарай" номерлары, Кәримовлар матбагасы, хәрчәүнә, чәйханә, трактирлар да шушы тирәләргә тупланган. Истәлекчеләр сөйләвенчә, Заһидулла Яруллинның "Болгар" номерында шагыйрь Габдулла Тукай белән очрашып сөйләшүе дә еш булгалаган.

Гомумән, үзешчән композитор татарның шул замандагы зыялылары, әйтик, Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтов, Солтан Габәши һ. б. белән якыннан аралашып яшәгән. Ул Шәрекъ клубында уздырылган концертларда еш катнаша, "Сәйяр" труппасының ансамбле белән житәкчелек итә. Шулай ук "Буфф" һәм "Свет" исемле кинотеатрларда пианист-иллюстратор булып та эшли. Казанда яшәгән елларында ук күп кенә җырлар иҗат итә: "Җәмилә", "Мандолина", "Сөн буйлары", "Мин мәкәрҗәдә булдым" һ. б. Аңа ин дан китергән әсәрләренең берсе—"Тукай маршы", әлбәттә.

Печән базары урамында "Сабах" көтепханәсе хуҗасы, татар укытучылар мәктәбе инспекторы, гыйлем иясе Шиһаб Әхмәров яши. Аларның гаиләсендә жиде-сигез яшьлек малай да бар. Салих Сәйдәшев дигән бу бала Заһидулла Яруллиннан беренче дәресләр ала һәм соңра, билгеле булганча, татар профессиональ музыкасының якты йолдызына әверелә.

З. Яруллин—фаҗигаи язмышлы шәхес. Аның улы Фәрит Яруллин беренче татар балеты "Шүрәле"не яза һәм Ватан сугышына китеп бара. 1943 елда әтисенә "хәбәрсез югалды" дигән кара пичәтле кәгазь кисәге генә килә. Фәритнең каберен, күп эзләнүләр нәтиҗәсендә, 40 елдан соң гына табу һәм ачыклау мөмкин булды (Белоруссия, Витебск өлкәсе). Икенче улы Мирсәет тә әтисенең юлын дәвам итә.

Заһидулла Яруллин гомеренең соңгы елларын туган авылында үткәрә. Вафаты алдыннан, таякка таянып, бөтен авыл буйларын йөреп чыга. 1964 елның көзендә тыныч кына дөнья куя.

1990 еллар азагында Кече Сөндә Яруллиннарга багышланган музей ачылды.

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Кенәр һәм Яңа Кенәр авыллары

Халкыбызның килеп чыгышы мәсьәләләрен хәл иткәндә, гидронимия һәм топонимия мәгълүматлары зур әһәмияткә ия. Галимнәр уйлавынча, барлык төр географик берәмлек атамаларыннан елга-су атамалары борынгырак дип санала. Халыкның көндәлек тормышында һәрдаим кулланышта булган мондый атамалар гасырлар дәвамында җыйналган тарих серләрен үзләрендә саклаганнар. Аларның мәгънәсен җентекләп ачу тарихның серле сандыгына күз төшерергә мөмкинлек бирә. Шушы күзлектән караганда, Арча районында Ашыт суы ярына урнашкан Иске Кенәр һәм Ашытның уң кушылдыгы Мәмсә суы ярындагы Яңа Кенәр авылларының атамалары игътибарга лаек.

Яңа Кенәр авылы Иске Кенәрдән аерылып чыккан. Иске Кенәр авылы район үзәге Арчадан 40 чакрым ераклыкта урнашкан.

Казан ханлыгы чорында булган авылларны теркәп калдырган галим Е. Н. Чернышев мәгълүматларына караганда, Ашыт елгасы ярындагы Кенәр авылы Казан ханлыгы чорында ук була. Ул—хәзер Ашыт елгасы ярына урнашкан Иске Кенәр авылы. Тарихи чыганакларда бу авылның исеме XVI йөздә һәм XVII йөз башларында теркәлгән.

Д. А. Корсаков җыентыгында (XVIII йөз) авыл чишмә янына урнашкан дип күрсәтелә. Ул Шинер-Кинер (Шинер Кинел) авылы дип аталган һәм анда 190 йомышлы татар яшәгән. Шунда ук тагын яңа оешкан пүчинкә, Мәмсә суы янындагы пүчинкә дә күрсәтелгән. Андагы 73 йомышлы татар көн иткән. А. Артемьев китабында авыл Шинер-Кинель дип бирелгән. Андагы 49 хуҗалыкта 187 ир-ат һәм 172 хатын-кыз көн иткән, Мәмсә суы буена урнашкан Яңа Кенәр авылы Н. Н. Вечеслав җыентыгында теркәлгән. Бу авылдагы 180 хуҗалыкта 877 ир-ат һәм 881 хатын-кыз яшәве күрсәтелгән. Монда бүрәнәдән салынган волость идарәсе, ике агач мәчет, бер мәктәп, ике тимерче алачыгы, вак-төяк сата торган ике кибет, бер су тегермәне булган. Шинәр-Кенәр (Иске Кенәр) авылы да Н. Н. Вечеслав игътибарыннан төшеп калмаган. Авылдагы 55 хуҗалыкта 235 ир-ат һәм 233 хатын-кыз исәпләнгән. Авылда агач мәчет һәм вак-төяк сата торган бер кибет булган. И. А. Износков Кенәр авылларын түбәндәгечә сурәтли. Уржум сәүдә трактына урнашкан авыл—Иске Кенәр (Кинер Старый). Ул Шинер дип тә атала. Халкы йомышлы татарлар дип күрсәтелә. 1885 елда бу авылда 65 йорт булган, 264 ир-ат, 264 хатын-кыз яшәгән. XIX гасырдагы тарихи чыганаклар күрсәтүе буенча, Ашыт суының уң кушылдыгы Мәмсә ярындагы Яңа Кенәр авылы Иске Кенәрдән аерылып чыккан һәм икенче төрле Мәмсә дип тә йөртелгән. Чөнки элек ул Мәмсә волостеның үзәге булган. 1885 елда бу авылда 250 йорт булып, анда 970 ир-ат, 957 хатын-кыз яшәгән. Вак-төякләр сата торган ике кибет, ике тимерче алачыгы, җил һәм су тегермәннәре, ике мәдрәсә булган. 1898 елгы җыентыкта Шинер-Кенәр һәм Мәмсә (Яңа Кенәр) авылларында татарлар яши дип күрсәтелә. К. П. Берстель хезмәтендә Шинер-Кенәр (Иске Кенәр) авылында 477 татар, Мәмсә яры янындагы Яңа Кенәр авылында 1998 татар кешесе яшәгәнлеге әйтелә. Иске Кенәр, Иске Ашыт, Печмәнтау, Серде, Ташкичү, Мәмсә, Иске Тазлар (хәзер Ташчишмә) авыллары халкы май ае ахырында Ашыт җыены үткәргәннәр. Бу җыен икенче төрле Ашыт каршы яки Катык җыены дип тә аталган.

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Яңа Кенәр авылы оешу турында мондый риваять бар. Аны Татарстанның Әтнә районы Мәмсә авылында Әхмәтҗанов Мостафадан Марсель Әхмәтҗанов язып алган (ул «Риваятьләр һәм легендалар» томына урнаштырылган).

«Әүвәл заманда Күшәр якларыннан Исәнгол бабай, тугыз улы белән, буш җир эзләп, бу якларга килеп чыга. Алар, урман эчләрендә йөреп, хәзерге Иске Кенәр авылы урнашкан урындагы бер аланлыкка юлыгалар. Бу җирне ошатып, ышна ачып, иген игеп көн итә башлыйлар. Бераз заманнар яшәгәч, ишәяләр һәм җир кытлыгы сизелә башлый. Шул вакытта Исәнгол бабай улларын Яңа Кенәр ягына җибәрә: «Авыл корырга яраклы урын булырга тиеш, барып карап кайтыгыз»,—ди. Уллары барып, хәзерге Яңа Кенәр промкомбинаты тирәсенә килеп чыгалар, бер алан һәм бер күл күрәләр. Бу турыда Исәнгол бабайга хәбәр итәләр. Бабай: «Ул тирә ташлыкмы, абагалыкмы?»—дип сорый.

Тегеләр: «Юк»,—дигәч, «Арырак барып карагыз, ташлык, абагалы җир булырга тиеш»,—ди.

Уллары барып, Яңа Кенәрнең Мәмсә очындагы бер ташлы елгага килеп чыгалар һәм бу турыда Исәнгол бабайга хәбәр итәләр. Исәнгол бабай урынны яраклы табып, улын Яңа Кенәр урынына күчереп утырта. Яңа авылга нигез шулай салына.

«Иске Кенәрдән бер төркем кешеләр, XVII гасыр ахырларында бүленеп чыгып, хәзерге Мәмсә һәм Яңа Кенәр авылларына нигез салганнар»,—дип яза Марсель Әхмәтҗанов. Бу датаны сакланып калган нәсел шәҗәрәсенә һәм тарихи риваятькә нигезләнеп билгеләдек".

1917 ел вакыйгаларыннан соң зур байлар чит илләргә күчеп китәләр, авылда яңа тормыш башлана. Колхоз төзү, үз көче, үз тырышлыгы белән көн күрүчеләрне читякларга сибеп-тузгытулар Кенәр авылларын да читләтеп үтмәгән. Авыл байларының күбесе чит илләргә качалар. Аларның байлыклары, җирләре ярлыларга бирелгән.

Еллар узу белән авыл зурая бара. Кызыл Юл районы МТСы 1936 нчы елда Яңа Кенәр авылында төзелә башлый. МТС өчен Түбән Орыдан Сөләйманов дигән мулланың кара-каршы йортын, шул ук авылдан Садыйк байның 2 бүлмәле таш кладовоен, Иске Әҗемдәге Садыйк Фатыйхы дигән байның йортларын бирәләр.

Авылда беренче тракторларның күренүе халык өчен зур вакыйга була. Мөхәммәт Хисаметдин улы Хисамов менә нәрсәләр сөйли: «1936 елның март аенда 15 яңа көпчәкле трактор бирделәр. Без биш тракторчы аларны Кенәргә алып кайттык. Кар тирән иде, безгә карны көрәкләр белән чистартып бардылар. Без бу якларны яраттык һәм даими эшләү өчен Кызыл Юл МТСында калдык".

МТС бу вакытта 30 дан артык колхозга хезмәт күрсәтә. 1937 елдагы язгы чәчүгә тракторлар саны 48 данәгә җитә. Урып-җыюга 20 гә якын «Коммунар» комбайны алына.

1941 елда сугыш башлана. Барлык башмаклы тракторларны, машиналарны һәм хәтта атларны да сугышка алалар. МТСтан ирләрнең күбесе сугышка китә, тракторда хатын-кызларга эшләргә туры килә. 1942 елның март аеннан МТС директоры итеп Сөләйманов Тимерхан куела. Ул бу постта 1958 нче елга кадәр эшли.

Сугыш елларының авырлыгы хатын-кыз җилкәсенә төшә. Тракторларга ягулыкны һәм чәчүлек орлыкны Арчадан (аралары 40 чакрым) чаналарда тартып алып кайталар. Юлда ашау өчен бәрәңге пешереп алып чыгалар. Менә шундый авыр шартларда эшләүгә карамастан, басудагы икмәк җыеп алына һәм дәүләткә тапшырыла. Сугыш елындагы бер документ ул чорны бик ачык сурәтли. Аның эчтәлеге моннан гыйбарәт: «МТС директоры иптәш Сөләймановка. Әгәр дә ул шушы ике-өч көн эчендә барлык комбайннарны һәм катлаулы сугу машиналарын ашлык сугу эшендә эшләтә башламаса, аның эшеннән алыначагын, партиядән чыгарылачагын һәм судка биреләчәген кисәтеп куябыз».

Менә шушындый шартларда колхозчылар фронтны икмәк белән тәэмин итеп торалар, фашистлар Германиясен җиңүдә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

Кенәр мәктәбен әйләнә-тирәдә яхшы беләләр.

1925—1926 елларда авылда башлангыч мәктәп ачыла. Аның мөдире булып Гариф Салихов эшли. 1932 елда мәктәп бинасы зурайтыла, мәчетне мәктәп итеп җайлыйлар, яңа класслар ачыла. Шулай да класс бүлмәләре җитми, балаларны аерым йортларда укыталар. Бу чорларда мәктәптә дан казанган укытучылар Гарифуллин Мохтәр һәм Зәки Миргазиз эшли. 1936 елдан авыл мәктәбе урта мәктәп итеп үзгәртелә. Мәктәп өчен яңа бина салына. Мәктәпне салуда директоры Гайнуллин Лотфулла зур көч

куя. Мәктәпкә укырга күп кенә тирә-юнь авыллардан да киләләр. Заманасында анда 500 дән артык бала укый һәм класс бүлмәләре житмәү күзәтелгән. Балалар саны елдан-ел арткан. Хәзер вәзгыять икенче шул...

1960 елда Яңа Кенәр авылында ярдәмче интернат мәктәп ачыла. Элекке райком, райбашкарма комитеты ишек алдында һәм промкомбинат урынында кирпеч бина, хезмәт мастерское, ике катлы йокы корпуслары үсеп чыга. Мәктәпкә күрше районнардан 280 бала җыйналган. Аның директоры булып Россия Федерациясенең атказанган укытучысы Р.Х.Халитов эшли. Интернат мәктәбендә балаларны тәрбияләү өчен бөтен шартлар тудырылган. Алар белем алалар һәм төрле хезмәткә, һөнәргә өйрәнәләр.

1979 елның 1 сентябреннән интернат мәктәп махсус ярдәмче мәктәпкә әверелә. Бу мәктәп бүгенге көндә дә яшәвен дәвам итә. Балаларга авыл предприятиеләреннән зур ярдәм күрсәтелә. Урта мәктәп һәм ярдәмче мәктәп тыгыз элемтәдә эшлиләр һәм яшиләр.

1963 елда «Северный» совхозыннан «Яңа Кенәр» совхозы аерылып чыга. Аңа Яңа Кенәр һәм Яңа Ашыт авыллары җирләре керә. 1992 елга кадәр совхозда терлек симертү һәм аны дәүләткә тапшыру эше белән шөгыльләнәләр. 1992 елдан соң совхоз терлек симертү белән бергә савым сыерлар асрауга күчә. Ит һәм сөт җитештерү өчен фермада бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган. Район буенча совхоз алдынгылар рәтендә.

Совхоз киләчәктә зур планнар белән яши. Хәзер авыррак заманалар булуга карамастан, совхоз шактый зур төзелеш эшләре алып бара. Фермалар яңартыла, машина паркы арта, авыл төзекләндерелә, газ кертелә. Кырчылыкта елдан-ел зуррак уңышка ирешәләр.

1935 елдан Яңа Кенәр авылы Кызыл Юл районының үзәге була. Шул ук елны авылда МЮД (Международный юношеский день) промкомбинаты төзелә. Аның максаты—халык хуҗалыгы өчен куллану товарлары җитештерү була. Бу комбинат хәзерге мех әртиле урынына урнашкан була. Аның өске өлешендә юрган, телогрейка сыру цехы булган, аскы катында шәл бәйләгәннәр.

Шул вакытта Носыдагы «8 нче Март» әртиле, ә Шушмабаштагы инвалидлар әртиле МЮД әртиленә килеп кушылалар.

1959 елларда район Әтнә белән берләшкән вакытта промкомбинат әртиленә Әтнә ягыннан 5, Кенәр ягыннан 5 предприятие килеп кушыла. Аннан соң тора-бара Әтнә Арча белән берләшә. Промкомбинат Тукай промкомбинаты исемен ала.

Кирпеч сугу цехында эшләүчеләр җәй көне әртилдә юрган сыралар, бу эш беткәч мех эшкәртәләр.

1970 елда кирпеч сугу цехы бу комбинаттан аерылып чыга һәм Арча филиалы булып исәпләнә. Комбинатта кирпеч сугалар, агач эшкәртәләр, такта яралар, урман хәзерлиләр.

1970 елның февраль аенда Тукай промкомбинаты Карадуган комбинаты белән берләшә, ә мех берләшмәсе Балтач мех фабрикасына кушыла. 1997 елда бу комбинат ДОК акционер берләшмәсе итеп үзгәртелә. Хәзерге вакытта ул Түбән Кама шәһәре белән килешү нигезендә контейнерлар җитештерә, ә мех берләшмәсе 1986 елның гыйнварында Арча мех фабрикасына күчерелә.

Яңа Кенәр авылында яшелчә киптерү заводы төзү турындагы карар 1953 елның 15 апрелендә кабул ителә һәм завод 1954 елның ноябрендә сафка баса. Бүгенге көндә дә завод бәрәңге, суган, кишер, сарымсак киптерү белән шөгыльләнә.

1935 елда авылда балалар тудыру йорты салына. 1940 елны больница төзелә. Ул вакытта монда авырулар өчен урын аз була. Хәзерге вакытта ул 60 койка-урынга исәпләнгән. Шулай ук авылның елдан-ел зураюын исәпкә алып, ике катлы яңа шифаханә бинасы салуга керешкәннәр. Анда бөтен уңайлыклар да булыр дип көтелә.

Яңа Кенәр авылында зурлар китапханәсе 1935 елда эшли башлый. Аның беренче мөдире булып Мөхәммәтшин Фатыйх эшли. 1984 елда китапханәдә янгын чыккан һәм бик күп китаплар янган. Бүгенге көндә авылда өч китапханә эшли. Берсе урта мәктәптә, икенчесе—балалар китапханәсе, ә өченчесе—зурлар өчен.

Авылда балалар бакчасы һәм ясле эшли. Шулай ук авыл хуҗалыгы химиясе, авыл хуҗалыгы техникасы предприятиеләре зур үсеш алган. Авылның зур гына электр станциясе бар.

Кенәрдә балалар өчен балалар үзәге эшли. Монда алар төрле һөнәрләргә

өйрәнәләр. Бу бина ял итү урыны булып хезмәт итә.

Кенәрдә парикмахерская, сәгать төзәтү, кер юуу машиналарын, телевизор-магнитофон һ. б. көнкүреш кирәк-яракларын ремонтлау өчен аерым бина бар.

Авылның үзенең орлык тикшерү бүлекчәсе эшли. Кырга орлыкларны шушы бүлекчә аша тикшергәннән соң гына чыгаралар.

Авылда даруханә, тәртип саклау участогы, ашханә, мәдәният йорты, зур-зур кибетләр, базар, бензоколонка, ял паркы бар.

Элек авылда алма бакчасы дип йөртелгән бакча да булган. Анда карлыган, крыжовник, алма, чия агачлары үскән. Әмма суык елларда агачларга салкын тигән һәм бу бакча элекке әһәмиятен югалткан.

Авыл янында Беренче күл, Икенче күл, Өченче күл, Сөрде күле, Сәрби чишмәсе, Тау асты чишмәсе, Миңкә чишмәсе, Әхми сазлыгы, Гали буасы, Хәмит буасы һ. б. елга-сулыклар, сазлыклар бар. Урманнардан түбәндәге исемлеләрен атарга мөмкин: Байкал урманы, Оры урманы, Яңа Ашыт урманы, Шекә урманы һ.б. Урманнарда нарат, чыршы, шомырт, имән, юкә һ. б. агачлар үсә. Халык хәтерендә түбәндәге басу исемнәре дә сакланган: Әхми басуы, Котып басуы, Хәйрүш басуы һ. б.

Авыл халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән.

Авылның элек өч мәчете, мәдрәсәсе булган. Хәзер авылның мәчете эшли, теләгән кеше гыйбадәт кыла.

Авыл тарихына багышланган музей бар, анда экспонатлар шактый кызыклы.

Авылда өч зират. Аларны Иске зират, Ямаш зираты, Кирпеч яны зираты дип йөртәләр. Мәрхүмнәр күмелә торган зиратларны карап һәм тәрбияләп торалар.

Авылда өлкән буынга хөрмәт зур. Күрше-күлән аларны яккан мунчадан, пешкән ризыктан калдырмый. Колхоз идарәсе һәм җирле үзидарә советы да аларга ярдәм итеп тора.

Хәзер авылда 900 хуҗалык исәпләнә, халык саны 3000 гә якын.

Яна Кенәр авылында язучы Равил Вәли улы Вәлиев туган.

Кенәр исемле елга һәм авыл атамалары Мари, Удмурт, Чуаш җөмһүрияте җирләрендә, Түбән Новгород өлкәсендә һ.б. урыннарда очрый. Мари иле җөмһүриятендә Кече Кенәр, Көтек Кенәр, Удмуртиядә Вятка суының уң кушылдыгы Кенәр ярында Кенәр авылы, Түбән Новгород өлкәсендә шулай ук Кенәр (Кинәр) авылы бар. Чуашстанда да Кенәр исемле авыллар шактый. Мәсәлән, Чабаксар районында Анат-Кенәр, Козлов районында Кенәр һәм Күнәр (Еметкино) авыллары теркәлгән. Моргауш районында Шомиково авылы кешеләре үзләрен кенәрлеләр дип атыйлар. Авыл яныннан ага торган елга да Кенәр суы дип йөртелә. Мари-Посад районында рәсми рәвештә Аксар дип атала торган авыл кешеләре (Аксар шулай ук татар телендәге ак+сар сүзләреннән чыгып аңлатыла) үз авылларын Кенәр бистәсе (Кенәркасси) дип атыйлар. Козлов районында Криуша исемле авыл халык телендә Кенәр Тамагы (Кенәрварри) дип йөртелә. 1946 елда Чабаксар өязенең Кенәр волостенда жиде генә йорттан торган Кенәр авылы теркәлгән. Узган гасыр ахырында этнограф В. К. Магницкий Чабаксар, Космодемьянский өязләрендә—Идел кушылдыгы булган Кенәр суы ярында Югары Кенәр, Урта Кенәр һәм Түбән Кенәр авылларын күрсәтә. Идел буйлап югары күтәрелгәндә, Чабаксар шәһәреннән 25 чакрым ераклыкта Кенәр дип атала торган елга ярында, XVI—XIX йөз документлары күрсәткәнчә, тагын бер төркем авыллар бар. Әлеге Кенәр суының Иделгә кушылган тамагыннан ерак түгел генә Иделдә Кенәр дип аталган утрау булган. Бу утрауда 1230 елда Идел буендагы Болгар дәүләте белән урыс кенәзе Юрий арасында тынычлык килешүе төзелә.

«Кенәр» сүзенең этимологиясе белән кызыксынучы галимнәр, русча—кинер, татарча—кенәр, удмуртча—конер, чуашча—кенер рәвешле әйтелгән бу сүзнең мәгънәсен санап кителгән телләр материалына нигезләнеп ачып булмавын язалар. Мари галиме Федор Гордеев һәм татар галиме Гомәр ага Саттаров бу топонимның мәгънәсен мари телендәге «куан, әнгер» (куан—таш, энгер—елга) сүзләре белән бәйләп карыйлар.

Югарыда әйтелгән Кенәр исемле елга ярларының күбесендә һәм авыллар тирә-юнендә дә таш булмауны искә алып, Кенәр гидронимнарын һәм аларның ярына урнашкан шундый ук авыллар атамасын төрки телләрнең угыз төркеменә мөнәсәбәтле рәвештә, аерым алганда төрекмән телләрендә сакланган «яр, елга яры, кырые», «суның җир белән тоташкан урыны» мәгънәсен белдерә торган кенар сүзе

белән аңлатырга мөмкин. Күргәнебезчә, Кенәр авыллары су-елга буйларына утырган. Шунысы да мөһим, күп кенә тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Болгар, Алтын Урда дәүләтләре чорында халыклар угызлар белән үзара нык аралашып яшәгәннәр. Татар халкы барлыкка килү процессында угыз телле кабиләләр дә үзләреннән байтак кына өлеш керткәннәр. Димәк, төрекмән, төрек, угыз, гагауз һ.б. халыкларның төп нигезен тәшкил иткән угыз кабилә-кавемнәренең бер өлеше элекке болгар һәм Алтын Урда дәүләтләре жирлегендә һәм ана күрше, чиктәш булган жирләрдә дә төпләнгән. Кенәр атамасы шул вакытларның истәлеге булып топонимикада ныгып калган, дип уйларга мөмкин.

Кенәр атамасының килеп чыгуы турында Марсель Әхмәтжановның карашы нигезле һәм төпле булуы белән аерылып тора. Кенәр сүзенең этимологиясен ул икенче яктан килеп ача. «Иске татар телендә кенәр сүзе чик, яр" мәгънәсен белдерә,—дип яза ул.—Күренекле тюрколог Николай Баскаков хезмәтләреннән күренгәнчә, балкан төркиләренең хәзерге Дунай суы буендагы Болгар дәүләте жирендә яши торган төркемнәрендә юрук һәм коняр дип йөртелгән этноним сакланган. Телләре буенча алар угыз төркеменең угыз-болгар төркемчәсенә керәләр. Китерелгән мисалдан күренгәнчә, бу ике атама бер этнонимның синонимик төрдәшләре булып чыга. Ул кайчандыр мөстәкыйль кулланылган ике болгар-төрки ыру-кабиләләренең бергә кушылып китүеннән килеп чыккан. Бу кабиләләр кайчандыр Идел буйларында яшәгәннәр». Болгарларның «коняр» этнонимын Марсель Әхмәтжанов Кенәр топонимы белән бердәйләштереп карый. Киров өлкәсендәге Жөрек яисә Йөрек исемле авыл атамасын ул (рус транскрипциясендә Старый Ирюк) болгар-төрки «йөрек» этнонимы белән тәңгәлләштерә. Шул рәвешле «коняр» һәм «йөрек» этнонимнарының килеп чыгышы татар (төрки) теле материаллары нигезендә ачыла. Болгар-төркиләр Урта Идел буйларында үз этнонимнарын авыл атамалары сыйфатында истәлек итеп калдырганнар.

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## *Алхәбәр. “Казан утлары” — 2009*

Әгъдәс
Борһанов

### ТАНСЫК БӨЕКЛЕК

СӘФӘРМОРАТ НИЯЗОВНЫҢ “РУХНАМӘ”СЕ
ТУРЫНДА ПАРОДОКСАЛЬ УЙЛАР

"...Рухнамә"не бер профессорга,рус кешесенә биреп торган идем. Укып чыккач, танышым ачынып–көенеп болай диде: "Их,минем милләтемнең дә шундый китабы булса икән ул!" Теләк шәп,әлбәттә,әмма аны гамәлгә ашырыр кешесе юк шул. Аннан, русларның тарихы да, традицияләре дә үзгәрәк, башкачарак бит. Без татарларга исә,гомумән,бөтен төрки халыкларга,милли рухны тергезү җәһәтеннән,"Рухнамә" бик тә ярап куяр иде... Аңа ябырылулар,һәртөрле мыскыллаулар исә Русия дәүләт бюрократиясенә хас кара көнчелекнең бер чагылышы гына ул..."

# "НӘҺҖЕЛ-ФӘРАДИС" (1358) ТУРЫНДА

ЯЗЫЛУЫНА 650 ЕЛ

Зур күләмле, аерым кулъязмаларында 549 биткә җиткән "Нәһҗел-фәрадис" ("Оҗмахларның ачык юлы")—Урта гасыр, аеруча Алтын Урда чоры төрки-татар әдәбиятының күренекле ядкаре. Ул 759/1358 елда Сарай шәһәрендә тәгаълләнә. Аның авторы—Мәхмүд бине Гали бине Гомәр әс-Сараи әл-Болгари әл-Кәрдәри. Фәндә әдипнең Болгарда укымышлы, зыялы гаиләдә тууы, укуы, гомеренең төп өлешен Алтын Урда башкаласында уздыруы искәртелә. "Кәрдәр" атамасын ике төрле аңлату бар: а) Болгар төбәгендәге бистә яисә авыл исеме; б) Урта Азиядәге гыйлем үзәкләренең берсе. Мәхмүд Болгари 1360 елның 22 мартында Сарай шәһәрендә вафат була. Миңа 1990 елда Хельсинкидәге "Ислам җәмгыяте"ндә "Нәһҗел-фәрадис"нең ахыргы өлешләрен генә үз эченә алган, бик таушалган бер кулъязма белән танышырга туры килгән иде. Анда "мосаныйф"ның (язучының) Мөхәммәд пәйгамбәр яшендә "дарелфәнадин дарелбәкага рихләт кылуы" (вакытлы йорттан мәңгелек йортка күчеп китүе, ягъни үлүе) искәртелгән иде. Бу факт, әгәр дә ул хак булса, авторның якынча 1297 елда тууын күрсәтә.




Мәхмүд Болгари—үз дәверенең күренекле кешесе. Чыганакларда ул шәхесебез, остазыбыз, зирәк юл күрсәтүчебез дип олуг ихтирам хисләре белән телгә алына. Аның бай мирасыннан, кызганыч ки, хәзергә тик бер әсәре генә мәгълүм.

"Нәһҗел-фәрадис"—дини-әхлакый рухтагы чәчмә әсәр. Ул дүрт бабтан (бүлектән) гыйбарәт. Һәр баб үз эченә унар фасылга, ягъни бүлекчәгә аерылган. Барысы—40 фасыл. Китапның бу рәвешле төзелүен автор Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисенә бәйләп аңлата. Әгәр дә берәү,—диелә ул изге сүздә,—пәйгамбәрнең 40 хәдисен "ишетмәгәннәргә", "белмәгәннәргә" өйрәтсә, "Хак Тәгалә ул кешене галимнәр" төркеменә язар; кыямәт көн булса, андый зат "шәһидләр" (дин юлында һәлак булучылар) җөмләсеннән саналыр.

"Нәһҗел-фәрадис"тагы тәүге ике бабның үзәгеннән Мөхәммәд пәйгамбәрнең, аның якыннарының, гаиләсенең, беренче хәлифәләрнең (Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали), имамнарның (Әбү Хәнифә, Шафигый, Мәлик, Әхмәд Хәнбәл) тәрҗемәи хәлләре, эш-гамәлләре һәм бу затларга мөнәсәбәтле гыйбрәтле сюжетлар тәшкил итә. Соңгы ике бабның тематикасы—Аллага якынайтучы һәм аннан яраклаштыручы эш-гамәлләр турында. Баб һәм фасылларның тематикасына нисбәтән, китапка төрле зурлыктагы күпсанлы гыйбрәтле хикәят-кыйссалар кертелгән. Мәхмүд Болгари аларның сюжетларын Шәрык халыкларының мифологиясеннән һәм фольклорыннан, аеруча гарәп һәм өлешчә фарсы телле чыганаклардан ала. Болар арасында, "Коръән" һәм аның тәфсирләреннән тыш, мөселман дөньясының имам Газзали, имам Бәһави, имам Бохари, имам Сәмарканди, имам Тирмизи кебек мәшһүр затларның китаплары бар. Автор алынма материалларны үзенең иҗат максатларына туры китереп, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртә, эшкәртә.

Китап эчендәге һәр бабның, һәр фасылның гомуми корылышында да билгеле бер охшашлыклар күзәтелә. Автор, кагыйдә буларак, әүвәл Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисен китерә, аның эчтәлеген, төп мәгънәсен аңлата, төрле абруйлы кешеләргә

мөнәсәбәтле аерым фикерләрне, эпизод-күренешләрне бирә. Алга таба исә хәдис темасына туры килешле хикәятләр тәкъдим ителә. Ахырда әйтелгәннәргә йомгак ясала, нәтиҗәләр чыгарыла. Китапта хәдисләр, аятьләр, аерым галимнәрнең сүз-фикерләре еш кына әүвәл гарәпчә, аннан шәрех юлы белән иске татар телендә бирелә.

"Нәһҗел-фәрадис" үзенең төзелеше белән тартмалы композицион жанр дип йөртелгән төркемгә керә. Ягъни ул тоташ, бердәм сюжетлы әсәр түгел. Андагы кыйсса-хикәятләр, баблар һәм фасыллар чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия. Аларны, иң беренче чиратта, гомуми тематика һәм идея охшашлыгы берләштереп тора.

"Нәһҗел-фәрадис"—дини, әхлакый, фәлсәфи, иҗтимагый, тарихи башлангычларны берләштергән синкретик әсәр. Ана фикри байлык һәм мәгънәви тыгызлык хас. Китапта яшәеш, тормыш тәҗрибәсе җанлы сурәтләр, гыйбрәтле вакыйга-хәлләр аша гәүдәләнеш тапкан. Әсәрдә реалистик башлангыч, тормышчанлык өстенлек итә.

Мәхмүд Болгари аеруча инсанга, аның иман-ышанычына, үз-үзен тотышына, әхлакына зур игътибар бирә. Автор фикеренчә, кеше—үзенең табигате, яратылышы белән олуг зат. Шуна күрә аның әхлакый йөзе, эш-гамәлләре җисеменә лаек булырга тиеш. Мәхмүд Болгари сабырлык, тугрылык, гыйлемлелек, тыйнаклык, ата-ананы хөрмәт итү, Тәнрегә бирелгәнлек, тәүбә кылу, кичерә белү, хәләл көч белән гомер кичерү һәм башка шундый уңай сыйфатларны, эш-гамәлләрне төрлечә зурлый, аларның капма-каршыларын (тәкәбберлек, гайбәт сөйләү, комсызлык, икейөзлелек, үч тоту, ялган сөйләү, мәкерлелек, зина кылу һ.б.) кискен тәнкыйтьли. Мәхмүд Болгари карашынча, бөтен начарлыкның, гөнаһларның нигезе хәмер эчүдә. Китапта моңа туры килешле берничә хикәят тә китерелгән. Автор үз әсәрендә оҗмах ишекләре бары тик матур әхлакый сыйфатларга, инсани эш-гамәлләргә ия булган кешеләр өчен генә ачык, начарлык исә Алладан ераклаштыра, тәмугка якынайта дигән фикер уздыра. Шуңа күрә ул укучыларны үзе идеал, үрнәк күргән рухта тәрбияләргә омтыла. Әсәр үзенең эчтәлеге, корылышы һәм гомумән бөтен рухы белән тормыш дәреслеген, тәрбия китабын хәтерләтә. Һәм бу төр вазифасын инде ул менә күп гасырлар буенча дәвамлы үтәп тә килә. Халык аны тулы килеш тә, аерым өлешләрен дә укыган. Китапның күпсанлы кульязмаларда таралуы—шуның ачык бер мисалы. Нигездә, татар кешеләре тарафыннан, үзебезнең укучыларны күздә тотып язылган бу күчермәләр хәзерге вакытта Казанда, Санкт-Петербургта, Истанбулда, Парижда һәм башка шәһәрләрдә саклана. Шунысы мөһим: аерым кульязмаларның төзелү, таралу тарихы—үзе бер гыйбрәтле тарих.

"Нәһҗел-фәрадис"нең иң борынгы күчермәсе 1360 елның 26 мартында Сарай шәһәрендә тәгалләнә. Аны авторны якыннан белгән кеше башкара.

Мәгълүм ки, Алтын Урда белән Мисыр арасында тыгыз мөнәсәбәтләр урнаша. Әдип-галимнәр бер илдән икенчесенә йөреп тора. Китаплар алмашу да гадәти хәл санала. "Нәһҗел-фәрадис"нең 1360 елгы күчермәсе XIV гасырның икенче яртысында—XV йөз башларында Мисырга китерелә. Ул берара Әбү Сәгыйд Чакмак (1437-1445) угылы Мөхәммәд китапханәсендә саклана. Бераздан, мөгаен, мәмлүкләр хакимияте бетерелгәч, бу кульязма Төркиягә эләгә. Хәзерге вакытта ул Истанбулдагы "Яни Җәми" мәчете китапханәсендә саклана. (Бу уңай белән бер хакыйкатьне искә төшерү урынлы булыр: алты гасыр ярымлык мондый кульязмалар тарихыбызда бик сирәк. Эчтәлекләре нинди булуына да карамастан, алар гаять зур фәнни һәм мәдәни кыйммәткә ия. Кызганыч, без андый факт-күренешләрнең әһәмиятен аңлап, бәяләп житкерә алмыйбыз. Ә бит бу кульязма—гадәти генә ядкарь түгел, ә 500 битлек бөек "Нәһҗел-фәрадис" нең күчермәсе!).

Мәхмүд Болгари әсәренең Алтын Урда дәүләтендә 1390 елда төзелгән янә бер борынгы нөсхәсе булган. Озак гасырлар буе ул Кырым төбәгендә укылып килгән. Үкенечкә каршы, Ялта музеена Якуб Кәмал тапшырган бу кульязма Кырым татарларын репрессияләү вакытында юкка чыга. Археограф С.Вахиди фикеренчә, "Нәһҗел-фәрадис"нең Алтын Урда чорына мөнәсәбәтле барлыгы 6 нөсхәсе бар *("Яңа милли юл" журналы.—1936.—№4.—24 б.).* Калган билгеле күчермәләре исә соңгырак гасырларга карый.

Мәхмүд Болгари әсәре Ш.Мәржани, Г.Газиз, Г.Рәхим, А.Самойлович, Зәки Вәлиди, Б.Яфаров, Ш.Абилов, Ә.Нәжип, С.Чагатай, А.Карахан, А.Караманлыуглы, Ф.Нуриева һәм башка галимнәрнең игътибарын үзенә җәлеп иткән. Аның берничә басмасы да бар. Әсәрдәге ике дистәгә якын хикәят "Борынгы татар әдәбияты" китабында (1963) нәшер ителгән. Венгр галиме Янош Экманн 1956 елда Анкарада "Нәһҗел-фәрадис"нең Сарай (1360) нөсхәсендәге текстларын фотокүчермә рәвешендә бастырып чыгара. Алдагы ике томда ул әсәрнең латинча транскрипциясен, сүзлеген тикшерү-аңлатмалар белән нәшер итәргә уйлый. Әмма бу, ниндидер сәбәпләр аркасында, гамәлгә ашмый кала. Галим үзе 1971 елда вафат була. Я.Экманның 1956 елгы басмасына, архивындагы материалларга нигезләнеп, 1995 елда Анкарада "Нәһҗел-фәрадис"ның яңа басмасы дөнья күрде. Бу эшне Сәмих Тизҗан һәм Хәмзә Зөлфикар башкара. Анкара басмасында Сарай (1360) кулъязмасының фотокүчермәсе һәм латин хәрефләре белән транскрипциясе бирелгән. Кечерәк кенә кереш сүз дә бар. 2002 елда "Нәһҗел-фәрадис"ның тулы басмасы Казанда да дөнья күрде. Фәнүзә Нуриева тарафыннан әзерләнгән бу китап кереш мәкалә, аңлашылмаган сүз-гыйбарәләргә аңлатмалар белән дә тәэмин ителгән.

"Нәһҗел-фәрадис" халкыбызны рухи яктан тәрбияләүгә генә түгел, әдәбиятыбыз, аеруча проза үсешенә дә зур йогынты ясый. Андагы аерым сюжет-мотивлар, образ-сурәтләр Мөхәммәдьяр, Т.Ялчыгол, К.Насыйри һәм кайбер башка авторлар тарафыннан иҗади файдаланыла.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ**

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

Адлер
Тимергалин

### АЛЛА

ФӘЛСӘФИ УЙЛАНУЛАР

Табигать фәннәре буенча галимнәр, теге яки бу фәнне тирәнрәк белгән саен, динне, иманны кире кага торган дәлилләрне күбрәк таба дип уйлаучылар байтак. Чынлыкта исә фән үзеннән-үзе галимне беркайчан да алласызлыкка алып бармый. Чын галим,—биологмы, физикмы яки математикмы ул,—әйләнә-тирә дөньяның чиксезлегенә, дөньядагы тәртипнең искиткеч оешканлыгына, максатчанлыгына, анда мәгънәсез бер генә нәрсәнең дә булмавына торган саен ныграк ышана. Бу тәртипнең очраклы рәвештә генә урнаша алмавына кире каккысыз математик дәлил бар, аны ихтималлык теориясе бирә.

Галимнәрнең эзлекле, мантыйкый фикер сөреше ахыр чиктә аларны бөтенесен колачлый торган көчкә—Аллага ышанута китерә.

Герман галиме Динард, дөньякүләм танылган галимнәрнең бер төркеменнән фикерләрен сорашып, мондый нәтиҗәләргә килә: галимнәрнең 20се нинди дә булса дини карашны якламаган, 242 галим Аллага ышана башлаган, фәкать 20се генә дин белән кызыксынмауларын таныганнар. Шулай итеп, галим-голәмәнең 90 проценты—дингә ышанучылар һәм бик азы гына дәһри-атеист булган. Өстәвенә соңгылары дингә ышанучы хезмәттәшләренә карата берninди дә ихтирамсызлык күрсәтмәгәннәр...

Әхмәт
Рәшит

# ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

## Елап кына яшәп булмас бит...

Бу хатирәләрем күңелнең нечкәргән чагына туры килде. Бәлки ул хакта сөйләп тормаска да кирәк булгандыр. Хәзерге тук чырайлы, иң затлы киемнәр кигән, иң соңгы марка автомобильләрдә җилдерүче, укуын да "икеле"гә, "өчле"гә тартып-сузып укыган, бу болгавыр заманда исә, үзен бик эрегә санап, хакимият айгырына менеп атланган адәмнәр минем бу зарларымны тыңларлар дисеңме?! Драматург Туфан Миннуллин бер сөйләгән иде. Ул зур түрәнең исемен дә, билгән дәрәҗәле урынын да әйткән иде. Кем икәнен бу очракта конкретлаштырырга кирәкмәс—азмыни андыйлар. "Мин бер генә китап та укымадым диярлек, әмма менә, кеше булдым бит әле",—дип мактана икән ул түрә дә. Хәтерлисеңме, татар халкының гыйбрәтле бер әсәре бар—һәр дүрт юллык "Менә шундый заман килер" дип тәмамлана. Андый заман килде дә микәнни? Без фәрештәләргә санап йөргән укытучыларыбыз, матур киләчәк килер, дип ихлас күңелдән ышанып, көчен дә, вакытын да кызганмаган фидакарь җанлы остазларыбыз, кешеләр сәламәтлеге сагында көне-төне уяу торган табибларыбыз, дөньяны шаккатырырлык ачышлар ясаган галимнәребез, рационализаторлык тәкъдимнәре керткән, әллә нинди мәртәбәләргә дәгъва итмичә, үз эшен ыңгырашмый, тыйнак кына башкарган гап-гади инженерларыбыз инде бу илгә кирәкмидәмени?! Кайберләре, бөтенесенә кул селтәп, чит мәмләкәтләргә китеп баралар, чит-ят кавемнәргә тәрәккый итәргә булышалар. Ә наданнар... беркая да китми. Кемгә кирәге бар соң аларның?! Россия дигән бу бәхетсез илдән "акылы алтын" булган бөекләр, даһилар йөзәрләп, меңәрләп башка кыйтгаларга агылып торганда, шүрәледән дә надан ул, бер көнлек хәлифләргә нинди хаҗәт бар?! Язучылар да, рәссамнар да, композиторлар да, артистлар да китә—хет картаймыш көнемдә булса да кешечә яшәп калыйм дип китә, бу алла каргаган җиргә кабаттан кайтмаслык булып китә.

Ә мин бу җиргә гомерлеккә кендегем белән берекәнмен. Әйе, әйе... кендек каным шушында тамган. Газиз әнкәмнең кабере дә монда. Әтием сөякләре дә шушы җирдә, шушы туфрактадыр. Ничек кенә кыен булмасын, түзәргә калгач, түзәм инде. Мин берәр айга гына читкә китсәм дә, шушы туган туфрагымны, мен газаплар татып та сынмаган, сыгылмаган Татарстанымны, сөекле Казанымны сагынып кайтам. Нинди тылсымнары бардыр инде. Ностальгия дигән нәрсә күңелгә бервакытта да тынгы бирми икән ул. Юк, беркая да китмим мин... Китмәячәкмен...

Шул ук чит илләрдә сәяхәт кылып йөргәндә дә, мин төрлесен күрдем. Бәлки заман безнең буынны идеалистлар итеп тәрбияләгәндер. Ләкин... ләкин күңелне

---

*Дәвамы. Башы журналның 8–10 саннарында.*

рәнжетә торган нәрсәләр дә бихисап бит анда.

*Монда халык көн-төн акча саный.*
*Ике сүзнең берсе: мани[1]... мани...*
*Найт маркетта[2] чибәр абыстайлар*
*Каш сикертеп уза:*
*—Һелло, җаный*
*Монда бөтен заман ябырылган—*
*Бер уч җирдә күпме байлык ята!*
*Сингапурны кемнәр сагына икән?—*
*Күпләргә ул вакытлыча Ватан.*
*Монда фимиам[3] һәм дуриан[4] исе,*
*Һәрнәрсәгә монда китә исең;*
*Күз камаша монда һәр нәрсәдән—*
*Базар диме аны, нәрсә дисең?!*
*Тик маташма, дөнья, безнең белән—*
*Барыбер илгә урап кайтасы без.*
*Кызыктырма—безне алалмассың!—*
*Байтак безнең ныклык запасыбыз.*

Әйе, фани икәнлеген аңлыйм мин аның. Әйтик, үзебезнең авылга сирәк булса да кайткалыйм. Бөтен йортлар диярлек Казан байлары салган коттеджлардан бер дә ким түгел. Кемнәр яши дип уйлыйсың шуларда. Карт белән карчык. Сәлперәеп беткән, бер аягы белән инде кабер бусагасына баскан карт белән карчык. Балалары кайсы тарафлардадыр—зимагурлыкта. Яннарында булса—аек көне юк, ата-анасын, туксан бабаларын телгә алып пенсия акчаларын даулый. Йортлардан кот качкан. Күрше күршесе белән генә түгел, юньләп туганнары белән дә йөрешми. Быел менә дигән урта мәктәптә дүрт авылдан—Чәчкаптан, Тәүгелдедән, Әхмәттән, Кужактан нибары йөзләп бала укый. Ә без ике параллель класста гына да шулкадәр диярлек идек. Дәреслекләренә сокланып туялмассың—полиграфиянең соңгы казанышы. Кием-салым күзләр чагылырлык. Класслар якты, иркен. Теләсәң—компьютер кабыз, теләсәң—магнитофоннан тыңла. Әх, безнең заманда да булса икән ул андый хикмәтләр! “Бишле”гә генә түгел, “Алтылы”га укыр идек.

Ә без укыган мәктәп—Кече аръяктагы мәчетнең манарасын кисеп, мәгариф хаҗәтләренә яраклаштырылган иске агач бина иде. Әни үлеп, әтинең абыйсы Каюм абзыйның дүрт “күгәрчене” арасына сыенган мин (сеңелем укырга кермәгән иде әле) аның улы Кадим белән бер класста укый башладым. Икебезгә бер дәреслек (экономия!). Күп очракта ул миңа эләкми дә. Тик шунысы бар—Кадим иртән иртүк торып ятларга бирелгән шигырьне кычкырып укый башлый—бер кат укый, ике кат, өч... Мин йокы аралаш аны тыңлап ятам һәм... ул яттан өйрәнгәнче инде бөтенесен отып алган булам. Тактадан һәм фанердан әмәлләгән “дипломат”ларны (чыннан да хәзер модадагы “дипломат”лардан бер дә ким түгел иде ул!) инде кулга тоткач, абый безне туктатыр да, янына утыртып, үзе әле генә чыгарган шигырьне укый башлар һәм дәресләрне яхшы үзләштерергә киңәш биреп капка төбенә хәтле озатып калыр иде. Икенче класста мин начар укыдым. Сәбәпләре аңлашыладыр: күңелне битарафлык биләп алган, күгәрчен гөрләсә дә, күз яшьләрем атылып чыгарга торган, бөтен дөньяга рәнҗүле, ниндидер фаталь азак көткән бер сәер халәттә идем мин. Берәрсе килеп башымнан сыйпаса да, кызганып берәр сынык икмәк яки “садакам булсын” дип ничәдер тиен акча бирсә дә, шатланудан бигрәк, күңел тулып ташый, әле күптән түгел булган якты хатирәләр янара иде. Кендек әбием Хәдичә бигрәк тә якын итә (өстәвенә ул безгә, ерак булса да, кардәш тә иде бит әле)—очрашкан саен күлмәгенең әллә кай жиреннән конфет яки прәннек актарып чыгара һәм “бисмилла”сын кат-кат кабатлап учыма сала иде. Дөресен әйтим, мин кимсенеп үстем. Югыйсә әле кайчан гына малайларның атаманы, беркемгә баш

1 Мани (инглизчә) — акча дигән сүз.
2 Найт маркет — Сингапурда төнге базар.
3 Фимиам — гыйбадәтханәләрдән тарала торган хуш исле һәм әчкелтем төтен.
4 Дуриан — исе сарымсак сасысын хәтерләткән, ләкин үзе искиткеч тәмле җимеш.

бирмәс бер зат идем. Ятимлек хисе, яклаучысыз, терәксез калу—минем фаҗигамне һаман тирәнәйтә, авыл малайларыча "әтигә әйтәм", "әнигә әйтәм", "абыйга әйтәм" дип телләшүләрдән дә мәхрүм идем мин. Әле ул гынамы? Бердәнбер сенлемне дә чынлыкта фәкать мин үзем генә яклый ала идем. Инде алда бәян иткәнемчә, бар белгән догаларымны һәр төн саен укый-укый Ходайга ялварулар инде сирәгәйгәннән сирәгәя барды. Бу мәрхәмәтсез дөньяны, бу фаҗигане елап кына төзәтеп булмасына ниһаять, төшенә башладым. Абыйның олы малае Зөфәр абый:

*Өй артындагы бакчада*
*Чыпчык кунган миләшкә,*
*Әти дә юк, әни дә юк,*
*Кемгә барыйм киңәшкә,—*

дип үртәгәндә дә, ул кадәр өзгәләнми, мөмкин кадәр тыныч күңел белән кабул итә идем.

Мине бу төшенке, кимсенүле халәттән, мөгаен, китаплар коткаргандыр. Язмышы минеке кебек үк ачы булган бөек язучы Максим Горький: "Всем хорошим во мне я обязан книгам" дигәнмәле? Мин, бер минут буш вакытым булса да, китапка тотынам—аларның юкаракларын көнгә икене-өчне укып чыга идем. Менә мәктәп китапханәсендәгеләр дә бетте. Аптырагач, Гыйбад Алпаровның катлаулы грамматика кагыйдәләрен аңлаткан кирпеч калынлыгы китабы белән дә таныштым, хәтта ноталар белән чыккан җыентыклардагы текстларны ятлап бетердем, медицина һәм ветеринариягә караган брошюралар да читтә калмады.

Авыл китапханәсендә исә "малай-шалайга укырга ярамый" торганнары күбрәк булгангамы, һәркемне дә якын җибәрмиләр иде. Әмма миңа, искәрмә ясап, Лев Толстойның "Яңадан туу" романын укырга рөхсәт иттеләр. Кызыл почмактагы ике шкафка шыплап тутырылган әсәрләр белән танышып чыккач:

—Нәрсә бирик инде сиңа?—диделәр һәм Елена Ильинаның "Четвертая высота" дигән рус телендәге китабын суздылар.

Рус әдәбиятыннан "бишле"гә укып барсам да, ул телне белүем чамалы иде. Шулай да җиңеп чыктым мин аны. Аңлаешсыз сүзләр күбен күп иде инде дә, күңел биреп тырышкач, булдырып була икән ул. Шулай итеп русча китапларга да теш үтә башлады.

Озак вакыт күршедәге Нурулла абыйларга керергә кыймый йөрдем. Белеп торам: анарда китаплар күп. Үзе Тәтештә педагогик училище бетергән, Казан университетына керергә җыена. Әлегә әти эшләп киткән урында—авыл Советы сәркатибе. Гармунда уйный, кызык-кызык мәзәкләр сөйли—теләсә кайсы компаниянең җаны инде менә. Ә аларга керергә җөрьәт итмәвемнең җитди сәбәбе бар: аның әтисе Кәлимулла абзый бакчаларына кереп суган урлаганым өчен заманында бик каты итеп колагымны борган иде. Бәлки оныткандыр да инде—ләкин шикләндерә.

Шулай да керәсе иттем. Төшке ашка җыелганнар иде—миңа да өлеш чыкты. Аннан кыенсынып кына китаплар турында сорадым.

—Кара, кара, рәхәтләнеп кара. Үзем дә тәртипкә салмакчы идем инде, вакыт кына тими,—диде Нурулла абый һәм теләсә кайсы китапны алып укырга рөхсәт итте.

Бу гаилә кешеләре белән бик якын мөнәсәбәтләр урнашу, әлбәттә, минем алдагы язмышыма да йогынты ясамый калмагандыр. Нурулла абыйның абыйсы Ярулла абый да, энеләре Насыйбулла абый белән Даян абый да, сеңелләре Гайнур да мине гомер буе үз иттеләр. Хәтта Нурулла абый шуның өстенә булачак хатыны Рокия апага язган яшерен мәхәббәт хатларын ташуны да нәкъ менә миңа ышанып тапшырды. Ә мин аманәткә хыянәт итүчеләрдән түгел идем.

Бер китап җене кагылгач, аннан тиз генә котыла алмыйсың инде ул. Ирле-хатынлы укытучылар Абдулла абый белән Рәхилә апа, үзләре дә ятим үскәнгәме, минем җәрәхәтле күңелне бик әйбәт аңлыйлар һәм һәрвакыт ярдәм кулы сузарга гына торалар иде. Минем аларны гомердә онытасым юк. Мин һәрвакыт яхшылыкка яхшылык белән җавап бирергә, аларның өметләрен акларга, йөзләренә кызыллык китермәскә тырыштым.

Класстан класска күчкән саен укуым да яхшыра барды. Дүртенче классны инде мин Мактау кәгазе белән тәмамладым. Югыйсә ана "А" классыннан икенче берәү өметләнә иде. Бу хәл мине бер башка үстереп җибәрде. Мине, яшемне бер елга олыгайтып, 1949 елда беренчеләрдән булып комсомолга кабул иттеләр (нишләп мәктәптә моңарча комсомол оешмасы булмагандыр), мәктәпнең "Яшь көч" дигән стена газетасына редактор итеп куйдылар. Үзешчән сәнгать коллективы спектакльләрендә һәм концертларда мин башлап йөрүчеләрнең иң активы булып киттем.

Моның уңай яклары булган кебек, әлбәттә, икеләндерә торганнары да бар иде. Эш шунда: безнең Яңа Чәчкап ул вакытта үтә дини, заманында башка күрше авыллардан аермалы буларак, кадими мәдрәсә тоткан, балигъ булган һәр кеше фәкать түбәтәйдән йөргән (кәпәч кебек шайтан оялаган баш киеме киюдән Алла сакласын!), уразасын калдырмаган, гаетләргә даими барган, садака мәсьәләсендә саранлану дигән нәрсәне белмәгән шактый диндар бер авыл иде. Хәтта гомерендә ураза тотып карамаган, дини йолалар белән алыш-биреше шулкадәр генә булган абый да миңа:

—Нәрсә, инде комсомоллар башлыгы да булдыңмыни?! Бу кадәр атаңа ошарсың икән,—дип кенә әйтеп куйды.

Шигырьләрне мин, алда әйткәнемчә, ун яшемдә яза башлаган идем. Аларны кая җибәрергә кирәклеген дә, чын шагыйрь булу өчен нинди баскычлар үтәргә туры киләчәген дә әле белми идем мин. Ә язасы килә—көн саен ниндидер шигъри юллар туа. Кышкы ай яктысында карлар җемелди—күңелдә шигырь шытып чыга. Нинди дә булса революцион бәйрәм якынлаша—укытучылар колакка киртләмәсә дә, стена газетасы редакторы буларак, көн кадагына суга торган берәр нәрсә сырлап куям. Ә җәйләрен колхозның да, бригаданың да "Сугышчан сәхифә"ләре—минем карамакта: алдынгыларны мактыйм, ялкауларны камчылыйм. Бу эшкә мине I бригада башлыгы Шәрифҗан абый тартты бугай. Юаш, ипле, кешеләрнең хәленә керә белә торган адәм иде мәрхүм. Эти белән дә якын дуслар булган алар. Әйтүенә караганда, этине соңгы тапкыр ул бер салам өеме өстендә каты яраланган көе күргән.

—Күкрәге кан гына иде. Аягына басар хәлдә түгел иде. Без немецлардан качып җан-фәрманга үзебезнең якка сыпыртабыз. Атаң мескен арттан нәүмизләнеп карап калды,—дип сөйләгән иде бервакыт.

Ләкин барыбер Шәрифҗан абый үзе немецлар кулына эләккән. Әсир булып тоткынлыкта газап чиккән. Хатыны, низаг килеп чыккан чакларда гел генә: "Пелинный, пелинный", дип ачуын китерә иде аның. Шәрифҗан абый мескен, авызына су капкан кебек, шым була да (еллары бит, еллары нинди!) тыныч кына өйдән чыгып китү җаен карый иде.

Аның сүзе никадәр хак булгандыр—ул кадәресен белмим. Әмма мине кызгана, башак җыйган өчен колхоз малайларга, кызларга дип биргән икмәктән миңа зуррак өлеш чыгара иде ул.

Хәзер ничәмә-ничә ел үткәч хөкем йөртәселәр кыендыр инде: бәлки ул хаклыдыр да. Бәлки... Этинең икенче яшьлек дусты Нуретдин абый исә этинең соңгы көннәрен башкачарак сөйли иде миңа. Аның әйтүе буенча, алар әсирлектән эти белән бергә качканнар, ач көе ниндидер карурманнарда адашып йөргәннәр. Эти бик нык авырып киткән.

—Бөтен йоласын китереп үзем җирләдем,—дип сөйләгән иде. Ләкин, инде үз-үземне белештерә башлагач, университетта укыган чагымда ничек-ничек булганын сорап язган хатыма нишләптер җавап бирәсе итмәде. Абый да аңа нишләптер ышанып бетми:

—Бер сөйләгәндә бер төрле, икенчесендә икенче төрле...—дип шикләнә иде.

Ярар, Алла хөкем итсен—хәзер үткәннәрне кире кайтарып булмый инде. "Хәтер китабы"на исеме теркәлгән—шунысы да минем өчен олы куаныч. Анда: "Рәшитов Әхәт Рәшит улы, 1910, Яңа Чәчкап ав., Буа РХК моб., с-т" дип язылган. Мин Буаның район хәрби комиссариатына да, Подольскидагы архив идарәсенә дә хатлар юллап карадым. Ләкин "Хәтер китабы"ндагы шул сүзләргә өстәп бер генә мәгълүмат та ала алмадым.

Фоторәсеме дә юк ичмасам. Хәер, бар иде ул—паспортка дип төшкән хәтта ике фотосы бар иде анын. Әни авырып китеп, аны Буа шифаханәсенә салгач, бөтен документларны абыйның олы малае Зөфәр абый алган булып чыкты. Ятим калып, яна гаиләгә килеп кушылгач кына аларны күрергә насыйп итте. Ул гына да түгел, сонынннан әлеге фотолар хәтта минем карамакка күчте. Аннан... ничек юкка чыккандыр алар—һич кенә дә башыма китерә алмыйм. Берсен үземнен шигырьләрне теркәп бара торган дәфтәремә ябыштырган идем—ул дәфтәр дә юкка чыкты. Кемнеңдер чорма башында тузан җыеп ятадыр бәлки. Әнә ич бер шигырьләр дәфтәремне дустым Тәүфикълар өен сүткәндә табып алып китерделәр. Хәтта Тархан урта мәктәбендә мин чыгарган кульязма журналны да кайдандыр чүп-чар арасыннан табып үз кулыма тоттырдылар. Бәлки ул дәфтәр дә, югалган башка язмаларым да табылыр әле. Әнә Пушкиннарның, Лермонтовларның кульязмаларын йөзәр ел үткәч тә табалар бит...

Ул чорда язган шигырьләр йомшак, көпшәк булган, әлбәттә—аларны бүгенге таләпчән укучыга күрсәтергә дә оят. Ә менә әтинен фоторәсеме ябыштырылган дәфтәр?.. Ничекләр генә саклый алмадым соң мин аны?! Әниемнекен дә... Ул иптәш кызлары Фәрхисорур һәм Ханифә апалар белән кайчандыр төшкән булган "карточкага". Аныкы дигәне самовар суы аккач юкка чыккан. Мин анын ахирәт дусларыннан да сорап карадым. Норлатта яшәүче Фәрхисорур апа бер заман:

—Бар ул миндә, бар,—дип сөендергән иде дә, актара торгач, күпме эзләсәк тә табылмады. Икенче ахирәтенә, Таҗикстанның Пролетарский дигән бәләкәй каласында яшәүче Ханифә апага хат яздым. Хатым: "Район боевых действий. Нет возможности вручить адресату" дигән язу белән кире кайтты. Шулай итеп бөтен өметләр өзелде. Аптырагач дәүләт музеенда эшләүче Фердинанд Кадыйров дигән рәссамга мөрәҗәгать иттем. Анын белән мине:

—Булдырса, ул гына булдыра ала,—дип Татарстан китап нәшрияты рәссамы Рушан Шәмсетдинов таныштырган иде. Мин үзем әнигә охшаганмын, аннан анын сенлесе Мәсруржиһан апанын яшьли төшкән фотосы да бар—шулай итеп тәвәккәлләргә булдым. Фердинанд эшне озакка сузмады. Ул ясаган рәсем нигәдер нәкъ менә әнине хәтерләтә—күнел алдамый торгандыр инде. Сонрак ул рәсемне, эзләү тарихларын да бәян итеп, "Сөембикә" журналында бастырып чыгардым. Бәлки эзләнү юнәлешендә үзенә күрә бер этәргеч булыр. Өметемне өзмим әле—бәлки чын фоторәсеме дә табылып куяр.

Атан-ананны югалтудан да авыррак хәсрәт бар микән? Хәзер ата-аналарын төрлечә рәнҗетүче яки аларны картлар йортларына тапшырып, мәчет зурлыгы йортларында көн күрүче балалар бәхетле микән соң? Мин аларны анлый алмыйм. Малайзиядә булуым вакытында безне озатып йөрүче гидларга:

—Сездә картлар йортлары, балалар йортлары бармы?—дип сорагач, алар бик гаҗәпләнгәннәр иде. Алар башта андый йортларнын нинди нәрсә булуын сораштырдылар, аннан:

—Без бит мөселманнар... Ничек мөмкин?! Ул карт-карчыкларнын, ул балаларнын кеме дә булса бар бит—алар үз тәрбиясенә ала. Ә якын туганнары булмаса, бөтен авыл белән карыйбыз,—дип җавап бирде.

Малайзия—мөселман иле. Анда мин хак динебезнен никадәр кешелекле булуына инанып кайттым. Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам безнен буынга нинди гадел фәлсәфә калдырган бит!

Балалар йортларында тәрбияләнгән сабыйларнын язмышы турында күп тапкырлар уйланганым бар минем. Аларнын бик азы гына тормышта үз эзен, үз юлын таба. Күпләре мөстәкыйль рәвештә көн итә башлагач та, тайгак юлга кереп китә—гомерләре фаҗига белән тәмамлана.

Кайсыдыр елны Буанын балалар йортында тәрбияләнүче нәниләргә матур-матур рәсемнәр белән бизәлгән 200 китап бүләк иткән идем. Үземнен дә ятим үсүем, аларнын күнелләре ничек китек булуын анлавым турында сөйләдем—тын да алмый тынладылар. Очрашу тәмамлангач, минем яннан, куллары белән киемнәремә кагылып үтүләреннән мин аларнын никадәр назга, иркәләүгә сусаганнарын анладым. Тамаклары тук, өсләре бөтен югыйсә. Гаилә җылысы, ата-ана игътибары гына җитми.

Күбесенең әти-әниләре дә исән—ә алар монда чит, ятим, яклаучысыз. Аларны тудырган, әле дә адәми зат исеме йөртүче җан ияләре эчкечелеккә, наркоманиягә, фахишәлеккә бирелгәннәр, юлдан язганнар—ә биредә җан җимешләре кемнәрдәндер яклау һәм фәкать аңлау сорап чит-ят күзләргә мөлдерәп карыйлар. Әй заманалар, әй әхлаклар!

Ул чакта йөрәктән сытылып шигырь чыкты, ә мин аны бәйнә-бәйнә кәгазь битенә төшерергә тырыштым.

*Усал җилләр улый-улый*
*Күз салкынын сылый тәнгә;*
*Чу, ни күрәм—кара төндә*
*Шыңшый-шыңшый кем елый?*

*Елый каршымда бер малай.*
*Әйтте ул шунда ни барын,*
*Өйдән кыйнап чыгарганын*
*Әнисенең һәм тагын...*

*Һәм тагын... кайчак кичләрен*
*Бер дәү абый килгәнлеген,*
*Әнисенең аның белән*
*Калганлыгын сөйләде.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

*Тел дәрьясы*

Рәфикъ
Юныс

### БАБАЙЛАРГА РӘХМӘТ!

КИЛӘСЕ ЕЛДА ЧЫГАЧАК МӘКАЛӘДӘН ӨЗЕК

"...Соңгы өч-дүрт гасырда татарга, табигый ки, телен үстерү вә чарлауда руслар белән ярышу мөмкин булмады. Ләкин бабаларыбыз безгә шундый да бай хәзинә туплап калдырганнар ки, күп кенә сүзләребезне "күрше" телдәге ишләре белән чагыштырганда сөенеп-горурланып та куясың.

Иң әүвәл бу *моң, күңел, бәхилләшү, пакьлек, ымсыну, нәүмизләнү, рәнҗеш* кебек русчага тәрҗемәсе булмаган нечкә-назик сүзләр. Ким Шакиров атлы авторыбыз, җыр турындагы хатирәсен русчага авыштырырга кирәк булгач, аның "Сагыну"ны сагыну" дигән исемен тәрҗемә итә алмыйча изаланды. ("Тоска" сүзен кулланыр идең, *тоска сагыш* бит инде ул, «соскучиться»дан исем ясар идең, *скука* килеп чыга!) ...Сыңар *любовька* (руслар алар гүзәл кызны да, дуңгыз шпигын да *любят*) бездә дә нәкъ шул рәвешле кулланылган *яратудан* тыш тагын *мәхәббәт* тә, *сөю* дә, *гыйшык* тоту да бар әле.

Өч яшьлек оныгым белән Казансу буендагы бакчабызда кайнашабыз. Мин су буенда ашарга пешерәм, Камилә болдырда уенчыклары белән мәш килә. Аратирә ул *"Бабай, бөҗәк!"* дип оран сала. Һәм бабасы, атылып-бәрелеп чабып килә дә, аны теге "бөҗәк явыз"дан коткара... Әгәр дә, мәйтәм, онык русча кычкырган булса? *"Дедушка, насекомое!"* дип әйтеп бетергәнне күтәргә бөҗәкнең түземе җитәр иде микән?

"Насекомое" дигәннән, рус телендә мондый, приставка, тамыр, суффикслары—эчәк-бавырлары күренеп торган ясалмыш сүзләр шактый икән ул. Туганлык атамаларын гына алыйк: *свояк, свояченица, свойственница*... Боларның татарчасы күп матуррак түгелме?: *баҗа, балдыз, кодагый* яки *кодача*... Балдыз белән *җизни* (җизнәкәй)—русчасы *зять* (зятёк)—дуэтын русчага тәрҗемә итә алган хәлдә дә, җырлап булмастыр, мөгаен..."

## Тукай—мулдакә

Ташкентка бер баруымда үзбәк халык шагыйре Шөкерулла (Юсупов) әкә белән гәпләшеп утырырга туры килде. Ике кулга икешәр чәйнек яшел чәй тотып. Гади, ифрат кин күнелле, аек акыллы (татар-үзбәк мөнәсәбәтләренә карашын әйтүем), инсаннарны ихлас яратучы шагыйрь үзенең әнә шул гадилеге белән игътибарны җәлеп итәдер, бәлки. Күнелләрдә ана карата соклану хисләре уяна. Күркәм әңгәмәдәш...

Беренче сүзеннән үк аңлашылды: Тукайга гашыйк, аны безнең чорның иң олы шәхесе дип саный. Менә Шөкерулланың блокнотым битләренә эләгеп калган кайбер сүзләре:

—Татар—бөек милләт, галим халык. Бу халык җиһанга олуг Тукайны бирде. Үзем балачактан Габдулла Тукайны укып үстем. Инде әйтәмен: Тукай—бөек мулдакә (мулла әкә—мулла абый). Бездә, үзбәкләрдә, Габдулла Тукайише мулдакә юк. Тагын бер тапкыр юк. Мөгаллим-мулдакәләребез дә әле генә булды. Урыс мәктәбен тәмамлаучылар. Ә безне теге елларда хәреф танырга, китап укырга татар мөгаллимнәре өйрәтте, мәдәниятле итте. Тукайны да алар алып килде. Үзбәк халкы барысы өчен татар кардәшләремезгә мәңге рәхмәтле. Мин моны сезгә дөнья күргән карт үзбәк буларак житкерәм.

—Син, Усман юлдаш, Казанга кайткач, Габдулла Тукай һәйкәленә Шөкерулла булып башыңны и!

Халык шагыйренең гозере үтәлде.

## Юксыну

Йөз елга, мең елга бер генә туа торган шәхесләрне күреп калу бәхете һәркемгә дә тәтемидер. Ә абзагызга аз-маз булса да эләкте ул кадәресе. Дәвер тудырган атаклы композитор Салих Сәйдәшев белән кулга-кул бирешеп, бер табында утырган яшүсмер идем бит мин заманында.

...Бер хатирә. Бауман урамындагы Матбугат йорты белән рәттән генә чәчтараш салоны бар иде. Анда бик тә чибәр Хәтирә исемле татар апае (өлкән буын хәтерлидер үзен) эшләде. Чиратымны көтеп утырам шулай. Ишектән Салих абый Сәйдәшев килеп керде. Сикереп торып урын бирдем. Ул күрешергә кулын сузды.

—Син дә монда йөрисенме, бәгырь?

Минем өчен Хәтирә апай җаваплады:

—Госман—безнең клиент, Салих абый, сабыр егет, ул ашыкмый. Хәзер сез утырырсыз.

—Әлбәттә, әлбәттә,—дидем кабаланып.—Хәтирә апай инструментларын безнең заводта кайрата. Хамутов дигән карт остадан. Шуңа күрә монда йөрибез чәч алдырырга.

—Алай икән... Син, бәгырь, сәлам әйт анда Камайга, байтактан күргән юк үзен.

Инде Камай дигәне аңлатма сорый. Үзем заводта фрезерчы булып эшлим. Ә Габдрахман Камаев дигән әзмәвер гәүдәле Арча татары бездә балта остасы санала. Гоголь урамы, 9 нчы йортта яши. Шагыйрь Мөхәммәт Садри да шунда. Болар ике дус. Мин килгәч, өчәү булабыз, юк, дүртәү икән! Мөхәммәт абый "чәебезгә" һәрвакыт Салих Сәйдәшевне дәшеп ала. Шагыйрь белән композитор бер төптән үсеп чыккан кушимән шикелле аерылмас дуслар, сердәшләр, ижаттәшләр. Узган гасырның 52-53нче елларында еш очраша идек үзләре белән. 1954 елның зәмһәрир суыгында Салих абыйның соңгы юлга озату гаять авыр булды. Г. Камал театрындагы табуты янындан узу өчен тышта, декабрь салкынында ике-өч сәгать шаңкәеп көтәргә туры килде. Аяктагы резина аслы чүпрәк штиблет үзенекен эшләде—атна

буе авырып яттым. Бәлки, сәбәбе тирәнрәктер дә...

Хәтер-хатирә яңартырлык сәбәпләр тагын килеп чыкты. Берзаман үземне Саба районына эшкә җибәрделәр. Яшим. Ямансу. Чәч тә үсте. Байлар Сабасының селькор Закир урамындагы "Парикмахерская" дип язылган келәткә барып кердем. Каршымда, әлеге дә баягы, ай-кояштай балкып, кулында тарак-кайчысын уйнатып, Хәтирә апай басып тора. Композиторны соңгы юлга озаткан язда ук туган якларына кайтып урнашкан икән. Истәлекләребез аның белән дәвам итте. Сәйдәшне юксыну дөрләде күңелләрдә...

## Галимнең ихлас шаяртуы

Әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллинны «Эрмитаж» бакчасында очраттым. Ак костюм, ак чалбар, ак кепкадан. Соңгысын салып, эскәмиягә куйган. Ялтыратып кырган башын кояшта җылытып тора. Исәнлек-саулык сораштым.

—Алга китеш юк,—ди бу.—Табиблар «Ессентуки-5» суын эчәргә кушалар. Эчәм инде, тик әлләни файдасын күрмим. Озак яшисе калмагандыр миңа...

—Алай димәгез әле, Мөхәммәт ага! Терелерсез, табиблар әйткән бит... Үзегез хәтерләмисездер инде, Мөхәммәт ага, Шәриф Камал музеенда сезнең белән каты гына бәхәсләшкән идем бер чакны. Яшьлек юләрлеге димме? Рәнҗемәгез, зинһар?!

—Сәбәбе ни иде?

—Галим кеше белән сүз куертуыма хәзер дә оялып йөрим. Фатих Әмирханның параличлануы турында барды сүз. Сез бу хәлне «Бакыр бабай» бакчасында булган, дисез.

—Син иденмени ул малай?

—Каты бәхәсләштек шул. Казансуда коенгач, исән-имин кайта Фатих Әмирхан өенә. Кичтән дин мәсьәләсендә әтисе белән, минем күк, каты гына бәхәсләшеп китә болар. Шактый дәрәҗәдә урыс тәрбиясе алган башбирмәс Фатих шул чакта ике аягы белән каргана. Һәм иртән торышка аның аяклары йөрмәс була, «Миндә кайбер сәнәт-истәлекләр бар бу хакта»,—дип дәлилләдем сүзләремне.

—Гафу ит, энем, син әйткәнчә булуы да мөмкин,—диде атаклы галим тыныч кына.—Мин дә ул чакта фән кандидаты гына идем, хәзер доктор, профессор әнә! Фатих Әмирхан белән тегендә очрашкач, ачыклап бетерербез анысын.

Беләсе иде: ачыкладылар микән?..

## Ике Туишев, понимаешь!

Заманында дөньяны шаулаткан мәшһүр гармунчы Фәйзулла Туишев Чернышевский (элеккеге Пионер)—Бауман урамнары чатындагы йортның икенче катында яшәде. Аның белән очрашу турындагы истәлекләремне "Гармун телләре уникe» дигән повестемда да язып чыккан идем.

50 нче еллар уртасында, язучыларның Тукай клубы директоры Азат Әхмәдуллин дигән егет белән, сәхнә ветеранының юбилее уңаеннан, концерт өчен, аның портретын алып килергә бардык. Тегеләй иттек, болай кыландырдык—идәннән түшәмгәчә эшләнгән әкәмәт олы сурәтне бүлмәдән чыгара алмадык. Коридордагы эт читлекләре (эреле-ваклы 8 җанвар санадым ул чакта) комачаулады. Калын, гөрелдәвек тавыш белән артист үзенең хөкемен чыгарды:

—Маташмагыз, егетләр, концертка үзем генә барырмын, понимаешь!

Ярты гәүдәгә ясалган икенче бер портретын алып кайтырга туры килде. Концертта икәүләп катнаштылар. Ике Туишев, понимаешь!..

**Госман ГОМӘР**

*Котлыйбыз!*

## Хәбир Ибраһимга 50 яшь

Үзенең әдәби эшчәнлеген театр-сәнгать өлкәсенә хезмәт итү белән башлап җибәргән Хәбир Ибраһим—бүгенге көндә инде танылган драматург.



1958 елның 19 ноябрендә Апас районының Борнаш авылында туган егет 1976 елда әлеге авылның урта мәктәбен тәмамлап, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына укырга керә. 1980 елда аны тәмамлаганнан соң Апас мәдәният йортына эшкә кайта, методист булып эшли, район халык театрында уйный, үзе дә яшьләр театры оештыра. Театр дөньясы, сәхнә белән якыннан аралашу, кызыксыну, әлбәттә, аның киләчәктә драматург булып китүенә йогынты ясамый калмагандыр. Әдәби мөхиткә тагын да ныграк үтеп керү, иҗатын камилләштерә төшү нияте белән ул 1986 елда Казанга килә, профсоюзларның союзара үзешчән сәнгать йортында методист, соңрак Казан телевидениесендә, Татарстан китап нәшриятында бүлек редакторы вазифаларын башкара, төрле газета-журналларда корреспондент булып эшли. Телевидениедә эшләгән чорында аның пьесалары буенча төшерелгән күп кенә телеспектакльләр куела.

1993 елда Әлмәт татар дәүләт драма театры аның ялгыз авыру карчык фаҗигасен тасвирлаган "Артык гомер" (режиссеры З. Туишева), 1997 елда К. Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры "Бәхетле килен" (режиссеры З. Харис) комедиясен сәхнәләштерә. Шулай ук Түбән Кама, Минзәлә, Әстәрлетамак башкорт дәүләт театрында, Оренбург татар дәүләт драма театрларында да бик күп әсәрләре куела.

2002 елда Казан телевидениесе төшергән өч серияле "Ялгыз тәкәрлек" фильмын да тамашачылар яратып кабул итте.

Х. Ибраһим—"Татар пьесасы" (1988), "Яңа татар пьесасы" (ике мәртәбә) бәйгеләре лауреаты. Ул әдәбиятның башка жанрларында да иҗат итә. Шигырьләрен, проза, сатира, драма әсәрләрен туплаган өч китап авторы: "Аһән" (2001), "Йокыга талган гүзәл" (2002), "Газиз ярым" (2006). 1994 елдан Язучылар берлеге әгъзасы. Авторның иҗаты әдәби җәмәгатьчелек игътибарыннан да читтә калмый.

"Хәбир Ибраһим, безнең чордагы яшь шагыйрьләрнең байтагы сыман, яңгыравыклы һәм көчле тавышлы сүзләргә мөкиббән китми. Аның өчен иң мөһиме: эчкерсезлек, садәлек, хәтта гадилек. Әмма хисләрдә төгәллек, тирәнлек. Кешене, укучыны ышандыра, җәлеп итә алу. Әсәрләрдән бик тә кешелекле, нечкә җан сулышы бөркелә",—дип яза тәнкыйтьче Мансур Вәлиев аның "Аһәң" дип аталган шигырь китабына язылган кереш сүзендә.

Хәбир Ибраһим иҗатына тормышчанлык хас. Лирик һәм сатирик рухта язылган повесть-хикәяләрендә ул тормышның тискәре якларын да чагылдыра. Шигъриятендә исә без аның шагыйрь буларак яши торган дөньясы белән таныша алабыз.

*Төнгә чыксам,*
*Төннәр мине яклый,*
*Сердәшләрем алар, кунагым.*
*Үз-үземә бәхет даулый-даулый,*
*Каләм алам кулга.*
*Уйларым,*
*Талгын гына җирдән күтәрә дә*
*Алып китә мине еракка...*

Хәбир Ибраһимны юбилее белән котлап, каләме, уйлары, иҗаты аны тагын да югарырак биеклекләргә күтәрүен, исәнлек-саулык теләп калабыз.

Әлеге көнгә кадәр миңа билгеле булмаган татар язучысы Равил Вәли әфәнденең "Канатлы татар" романын "Казан утлары" журналының быелгы 2-4 саннарында укып, хәйран калдым. Балет биючесе, батыр татар егете Рудольф Нуриевның искитәрлек тарихын белдем бу роман аша. Укып бетергәч, ул романда язылган фактлар турында өйдәгеләремә, танышларыма сөйләдем. Шул хәтле йөрәккә тиде, дулкынландырды бу әсәр, укып бетергәч, бер-ике ай уйланып йөрдем.

Роман бик тә күңелгә ята торган тарихны ачыклаган. "Тимер пәрдә" чорында яшәп үскән буын бит инде безнең яшьтәге кешеләр. Без 60-70нче еллардагы яшьлегебез вакытында капиталистик илләрнең культурасын бер дә белми идек. Аларда да, шул ук Англиядә үзләренең Галина Улановалары булган икән! Ул да булса—Марго Фонтейн, миллионер хатыны. Һәм алар, безнең егет һәм Фонтейн, парлашып биегәннәр. Татарча һәм русча язылган китаплар яшьлектә күп укылды. Араларында балет эшлеклесе турында шулай игътибарны җәлеп итәрлек итеп язылган бер китап та очрамады. Романны укып беләбез, Рудольф Нуриев гади балет биючесе генә булмаган, ул уйлап табучы да. Күрегез, ничек җаен табып "Жизель" балетына үзенең яңалыкларын кертә: принц Альбертның образын яңача трактовкалау алымын уйлап таба, шуның белән классик әсәрне яңартып җибәрә. Бу юлларны язуым шуңа, роман укучыны информатик баетуга китерә. Безнең татар егете хәтта АКШ президенты Кеннеди кабинетында булган, аның эш өстәле артындагы урындыгына да утырып алган икән бит. Аның Париж аэропортында КГБ агентларыннан балеттагы алым белән очып китеп котылу вакыйгасы үзе ни тора! Һәм башка, безнең өчен яңа булган фактлар белән тулган бу әсәр. Әллә, мин әйтәм, Равил Вәли Рудольф Нуриевның биографы булганмы, артыннан йөреп, булган маҗараларын дәфтәренә теркәп барганмы. Шундый киң һәм тирән итеп язылган бу әсәр. Андый эшне башкару—диссертация язу авырлыгында һәм җаваплылыгында. Үз алдына шундый авыр бурычны куеп, җиңеп чыга алуы өчен авторга зур рәхмәт әйтәсе килә.

Яшь буынга, балет сөючеләргә бик кирәкле әсәр бу. Әле мин, олы яшьтәге кеше, "Канатлы татар" романы "Казан утлары" журналында басылачагын белгәч, журналның яңа саны килдеме әле дип, киоскларга барып сораштырып йөрдем. Президент Шәймиевның "Без булдырабыз!" дигән сүзе бар. Шул уңайдан "Казан утлары" журналында басылып чыккан "Канатлы татар" романы авторына әйтәсе килә: булдыра торган егет икәнсез, Равил әфәнде! Рудольф Нуриевның юбилеена, туган көненә өлгертеп чыгаргансыз бу романыгызны. Зур рәхмәт! Шәп тел белән югары кимәлдәге әдәби әсәр итеп язылган ул. Күңелле укыла. Хәзер автор алдында яңа бурыч тора: романны рус, инглиз, француз телләренә тәрҗемә иттереп чыгару.

**Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ,**
*пенсионер, эшем буенча—нефть чыгару белгече. Казан.*

---

## *Алхәбәр. "Казан утлары" — 2009*

*Юмор һәм сатира*

- **Аманулла.** Джентельмен. Хикәя.
- **Фәнзаман Баттал.** Өч хикәя.
- **Камил Кәримов.** Эстрада монологлары.
- **Алмаз Хәмзин.** Сәхнә хикәяләре.
- **Ринат Абзалов.** Палиндромнар. Шаярулар.
- **Ринат Мәннан.** Үртәмешләр.

## Ә. ЕНИКИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУНЫ КАРШЫЛАП

**Әмирхан агабыз күрән тышлы гомуми дәфтәрләренең берсенә “Фактлар дәфтәре” дип язып куйган. Шуннан берничә “факт”ны бирә торыйк әле.**

* * *

Мөбинә ханым әйтә:
Галимҗан (Ибраһимов), Фатих (Сәйфи-Казанлы), Сәгыйт (Сүнчәләй) Усманов байның кызлары артыннан йөриләр иде, ди. (Бу революциягә чаклы Уфада “Галия” мәдрәсәсендә укыган яки укыткан вакытлары булса кирәк.) Арада иң чибәре Сәгыйт иде, ди. Галимҗан да хатын-кызга ошый иде, чөнки аның кашы белән күзләре матур иде, ди.

* * *

Бер заман Салих Баттал фоторәсемгә төшерү белән мавыгып китте. Урамда яки матбугат йортында очраган дусларын фотоаппараты белән төшерә дә ала бу... Мәсәлән, Кольцода Нәкый абзыйны, Әхмәт Фәйзине һәм мине очратып, шунда өчебезне бергә төшереп алган иде. Ләкин ул Фәйзинең ялгыз үзен генә дә төшергән булган. Әмма фото бик тонык килеп чыккан. Әхмәт мәрхүм фотоның артына түбәндәге ике юлны язып куйган иде:
*Салих Баттал фотосы сезнең фото ишеме,*
*Әхмәт Фәйзи урынында ике борын тишеге.*

* * *

Салих Сәйдәш Мәскәүдә үлде. Казанга самолет белән алып кайттылар. Шушы унай белән Әхмәт Фәйзи миңа түбәндәгеләрне сөйләгән иде:
—Салих гәүдәсен табут белән аэропортка китергәч, аны бары багаж рәвешендә генә кабул итәргә булдылар. Зур үлчәүгә салып үлчәделәр һәм квитанция язып бирделәр. Мин шул квитанция белән кассага барып, “багаж” бәясен түләдем. Шуннан соң гына табутны самолетка урнаштырдылар...—Мин Фәйзидән бу “багаж” өчен күпме түләгәнен сорарга онытканмын. Әмма Салих Сәйдәшнең татар халкы өчен “күпме торганын” аэродромда эшләүчеләр белделәр микән?



Татарстан Язучыларының X съездында (1984) сайланган идарә әгъзалары.



Оренбургтагы "Хөсәения" мәдрәсәсе. 1902 елгы фото.



Шагыйрь Марк Зарецкий.
1970 ел.



*Ике бөек шәхес: сынчы Бакый Урманче (1921–93) һәм композитор Рөстәм Яхин (1987–93). 1981 елда төшерелгән фото.*



*Шагыйрь Булат Сөләйманов (1938-91). 1981 нче елгы фото.*



*Мөдәррис Әгъләмовнең соңгы фоторәсемнәреннән берсе. Басып торалар (сулдан уңга): Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Илфак Ибраһимов, Разил Вәлиев. 2006 ел. (М. Әгъләмовнең юбилей кичәсендә төшерелгән фото.)*

*Тормыш язган хикәяләр*

Радик
Фәизов

## КЫЗГАН БОДАЙ ИСЕ

“...Инсан бабайларга лотерея уенында җиңел машина чыккан иде. Әмма Инсан бабай аны өйләренә алып кайтмады.

– Иптәш Сталинның үзенә бүләк итәм мин ул машинаны. Аякларын талдырып җәяү йөрмәсен,машинага гына утырып йөрсен!—дигән ул бу хәлдән бик аптыраган кешеләргә.

Инсан бабай—басу каравылчысы. Аз гына шикле әйбер күрде исә,аның чепи күзләре дәү булып ачыла,борын аслары ялтырап китә,ул нечкә,ниндидер рәнҗүле тавышы белән кычкыра башлый...

Без әниләр янына менеп җиткәч,алар беразга уракларын куеп,эшләрен туктатып торалар. Басуда икенче хәрәкәт башлана. Әниләр безне юл читенә,сакка бастырып куялар. Үзләре үлән арасыннан, яшергән урыннан зур таба тартып алалар да, шул таба өстенә тук башакларны уалар. Аннары коры камылдан учак тергезеп җибәрәләр,бодайлы табаны ут өстенә куялар. Бу гамәлләр бар да тиз-тиз,ялт та йолт кына эшләнә. Алла сакласын,Инсан бабай килеп җитә күрмәсен!

Менә берзаман басулар өстенә искитмәле тәмле,авыздан сулар китерә торган, шулкадәрле хуш кызган бодай исе тарала...

Кайчак,әле бу ис беткәнче үк, Инсан бабай да килеп җитә. Ул эшнең нидә икәнен сизенә,күрәсең,асты юеш борынын күтәреп иснәнә,таягы белән камыл араларын капмалый,табаны эзли инде. Ләкин безнең әниләр ул мәрхәмәтле ризык савытын бу җәдәгән карт табарлык итеп кенә яшерәме соң?..”

---

*Ак җилкән*

## ЕФӘК ЯЛЛЫ ЕЛГЫР ДУСТЫМ

Быел **Рәйсә ЮСУПОВА** Тэтчер атлы хикмәтле маһмайның гаҗәеп маҗараларын бәян иткән иде (NN1-6). Киләсе елда ул сез “җилкәнчеләребезне” тагын бер соклангыч җан иясе белән таныштырмакчы.

Киләсе елда дип... Бу татлы сыйдан сез хәзер үк авыз итә тора аласыз ич.

“...Гаҗәп, мин гомерем буе бер төш күрәм: кулларымны канат итеп җәям дә, һавага күтәрелеп оча башлыйм. “Агроном-полевод” дипломы белән Чирәм жиргә—казакъ даласына эшкә килгән тәүге көнемдәге чын очышым төшләремдә дәвам итәр дип кем уйлаган!..

Ә ул чакта... Әйе, ул чакта мине сырып алган бер төркем ир-ат, бер-берсен бүлә-бүлә: “Менә сиңа – 60-70 чакрымга сузылган басуларны инләп йөриячәк агрономга—атның иң-иң шәбе!” дия-дия, мине кадерле дустыма әйләнәчәк бахбайга атландырдылар да, “һоп!” дип сөрән салдылар. Арткы аякларында ике-өч сикереш ясап алган яшь-яшь сылу айгыр кинәт кенә алга ыргылды... Ул мәлне мин Бульдо исемле ошбу бахбайның бер яшьлек тай булуын да, өйрәтергә тәүге тапкыр апчыгуларын да, ир-егетләрнең үзләре атланып карарга җөрьәт итмәгән атта агроном кызыйны сынарга теләп шукланууларын да—юк, белми идем әле...”

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2009 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу бара. «Казан утлары»ның индексы **73210**, Татарстанда ярты елга язылу бәясе физик затлар өчен **204**, юридик затлар өчен **234 сум.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

**Ф.СП-1**

Почта России

**АБОНЕМЕНТ** на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

*"Казан утлары"*

(наименование издания) количество комплектов:

на 20 09 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда

(почтовый индекс) (адрес)

Кому

(фамилия, имя, отчество)

---

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

*"Казан утлары"*

(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ____руб.____коп. | количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ____руб.____коп. | |

на 20 09 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда

(почтовый индекс) (адрес)

Кому

(фамилия, имя, отчество)

## НӘНИЛӘР СӨЕНӘЧӘК!

Казанның Петербург урамында «Әкият» Татар дәүләт курчак театрының яңа бинасына нигез ташы салынды. Бу тантанада Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев катнашты. Бәйрәм кунаклары арасында ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Казан шәһәре мэры Илсур Метшин, ТР мәгариф һәм фән министры Наил Вәлиев һәм башкалар да бар иде. Минтимер Шәймиев «Әкият» курчак театрын 15 ел җитәкләгән Роза Җаббаровага, 30 елдан артык гомерен балаларның күңелен күрүгә багышлаган баш режиссер Илдус Зиннуровка, яңа бинаның баш архитекторы Светлана Мәвлеевага, театр актерларына үз һөнәрләрен фанатларча яратулары өчен рәхмәт сүзләрен ирештерде. 1943 елда нигез салынган «Әкият» Татар дәүләт курчак театры илдәге театрларның беренчеләреннән санала. Аның 75 еллык хезмәт дәверендә сәхнәгә 300дән артык спектакль куелган. Яңа бинага килгәндә, ул 100 һәм 250 урынга исәпләнгән кече һәм зур заллардан, 150 шәр урынлык ике кинозалдан, балалар кафесыннан, әкиятләр бүлмәсеннән, кышкы бакчадан. Яңа ел бәйрәмнәре залыннан гыйбарәт булачак. Гомуми мәйданы 17 меннән артык квадрат метрны тәшкил итәчәк.

## "МӨСЕЛМАННАР"—ЛАУРЕАТ

"Россия" телеканалының "Мөселманнар" программасы "Берләшү" ("Единение") Бөтенроссия фильм һәм программалар бәйгесендә лауреат дип танылган. Бәйге экстремистлыкны, ксенофобия, раса һәм диннәр арасында каршылыкларны бетерүгә багышлап уздырыла.

Әлеге чара, федераль матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының финанс ярдәме белән өченче тапкыр уздырыла. Фильмнар һәм программалар җәмгыятьне бер йодрыкка туплау идеяләрен халыкка җиткерүнең нәтиҗәлелеге, материалның сыйфаты, проблеманы максималь колачлау күзлегеннән чыгып бәяләнгән.

Конкурс финалына Россиянең ун төбәге телекомпанияләре фильмнары һәм программалары кергән. Җиңүчеләрне бүләкләү Мәскәүдә булды. Анда "Мөселманнар" программасы коллективына алтын сын һәм диплом тапшырылды.

"Мөселманнар" "Россия" телеканалында атнага бер тапкыр эфирга чыга. Аңа моннан алты ел элек нигез салынган иде. Программаны кинога төшерү төркеме илнең 39 төбәгендә эшли.

## ЯКТАШЫБЫЗ БҮЛӘГЕ

Минзәләдә Балалар иҗат йорты ачылды. Аны ачу тантанасында ТР Премьер-министры Рөстәм Миннеханов, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Мәгариф һәм фән министры Наил Вәлиев һәм "Русский стандарт" холдинг компаниясе президенты Рөстәм Тарико катнашты. Әлеге социаль объект нәкъ менә Рөстәм Тариконың иганәчелек ярдәме белән төзелде.

Хөкүмәт җитәкчесе Минзәләдә туып-үскән Рөстәм Тарикога рәхмәт белдерде һәм аны Татарстанның мөһим стратегик партнеры дип атады, үзара хезмәттәшлекнең киләчәктә дә дәвам итәчәгенә өметләнүен әйтте. "Русский стандарт" холдингы җитәкчесе үз компаниясенең хәйриячелек эшчәнлеге, нигездә, мәгариф системасына юнәлтелгән булуын искәртте һәм Татарстан белән киләчәктә дә хезмәттәшлек итәргә вәгъдә бирде.

## ХЕЗМӘТЛЕЛӘРГӘ ХӨРМӘТ БАР

Татарстан Республикасының РФдәге тулы вәкаләтле вәкиле Назыйф Мириханов ТР Президенты Минтимер Шәймиев йөкләмәсе буенча илнең Дәүләт академия зур театры җитәкчеләренә—театрның генераль директоры Таһир Иксановка һәм аның урынбасары Олег Мисковецка «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медален тапшырды. Бүләкне тапшырганда тулы Вәкаләтле вәкил театр җитәкчелегенең Татарстанга карата аеруча ярдәмчел булуын ассызыклады. «Аерым алганда әлеге гамәл тулысынча FISU бәяләү комиссиясенең Россиягә визиты вакытында күренде. Комиссия «Универсиада-2013»не Казанда үткәрү мөмкинлеген тикшерергә килгән иде. Бәяләү комиссиясенең Татарстанга юлы Мәскәү аша узды һәм аларны башкалада, шул исәптән Зур театрда да яхшы кабул иттеләр. Шулай итеп, Казан кандидатлыктан Универсиада башкаласына әверелде һәм монда театрның казанышы зур», дип белдерде Н. Мириханов.

## ЮГАРЫ БҮЛӘК—БЕЗДӘ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры 12-19 сентябрьдә Брест

шәһәрендә узган «Белая вежа» XIII Халыкара фестивальдә Гран-при яулады. Моннан тыш Искәндәр Хәйруллин ин яхшы ир-ат роле өчен приз алды.

Фестивальдә 16 илдән 26 театр катнашты. Камаллылар тамашачы хозурына Осетин драматургы Георгий Хугаевнын «Кара чикмән» спектаклен тәкъдим иткән иде.

### УЛ ҮЗЕНЧӘ БӨЕК ИДЕ...

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык шагыйре, 40тан артык шигъри җыентык һәм куплаган пьеса китаплары авторы Илдар Юзеевнең 75 еллыгы уңаеннан искә алу кичәсе булып узды. Кичәдә язучылар, шагыйрьләр, сәнгать әһелләре чыгыш ясады. "Галәт, холкы, лирик сурәте белән кыр казын хәтерләтсә дә, халкы, милләттәшләре канатсыз калган вакытларда бөркет кебек очып килеп, ярдәм итә торган кеше иде Илдар ага, чөнки лирик жанлы шагыйрьнең кодрәте чикләнмәгән,—диде Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов.—Илдар Юзеев олуг шагыйрь иде һәм сугыштан соң милли шигъриятта моңсу лириканы торгызды, Тукай, Такташтан соң тоталитар идеология аягы астына салып тапталган шигъриятка яна сулыш өрде, кеше күнеле, кеше хисләре турында язды. Илдар Юзеевнен икенче иҗат каныты—драматургия. Ул сәхнә белән бәйле әдәби жанрда да олуг шагыйрь булып кала алды.» Гомумән, Юзеевләр династиясе татар мәдәниятендә зур урын тота. Мәгълүм булганча, шагыйрьнең бертуганы Нил Юзиев шигъриятебезне фәнни яктан өйрәнгән күренекле галим (Г. Тукай премиясе лауреаты иде), улы Салават татарнын бөек шәхесләре турында документаль фильмнар төшерүе белән әтисе тоткан кыйблага, милләтебезгә тугрылык саклый.

Кичәдә шагыйрьнең иҗатташлары М. Яруллин, Ш. Галиев, М. Имашев һ. б. истәлекләр белән уртаклашты.

И. Шакиров, З. Сөнгатуллина, З. Сәхәбиева, А. Фәйзрахманов, Н. Нигъмәтуллин, Р. Низамов, Ф. Каһиров, Р. Асаев, А. Хәйри, Л. Муллагалиева һ. б. җырчылар шагыйрьнең шигырьләренә язылган җырларны башкарды. Ә артистлар Н. Ихсанова, А. Арсланов, Р. Шәрәфи, З. Зариф, Х. Җәләй аның шигырьләрен укып ирештерде һәм пьесалары буенча куелган спектакльләрдән күренешләр уйнап күрсәтте.

Кичәне Татарстанның халык шагыйре Р. Миңнуллин алып барды.

### БЕЗНЕҢ ДӘ ЯКТАШ

Даһи язучы Лев Толстойның тууына 180 ел тулды. Дөнья җәмәгатьчелеге аны зурлап билгеләп үтте.

ТР Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева котлавында әйтелгәнчә, Россия өчен әлеге дата дәүләткүләм зур әһәмияткә ия. Толстойлар нәселе Казан белән дә тыгыз бәйләнгән. Булачак даһи язучы өчен Казан—үсмерчак һәм яшьлек шәһәре, аның рухи һәм гражданлык позициясе формалашкан кала. Язучының иҗади мирасы—башкалабызның горурланырлык казанышы. Толстой шәхесенең үзенчәлеге шунда ки, ул төрле милләт һәм дин кешеләре өчен тартылу үзәге булып тора. Лев Толстойның беренче тәрҗемәчесе күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри булуы да аерым әһәмияткә ия.

Бүгенге көндә Казанда 1841-45 елларда Толстой яшәгән мемориаль йорт торгызыла. ЮНЕСКО тарафыннан Лев Толстой елы дип игълан ителгән 2010 елда анда даһи язучының музее ачылачак.

### ДУСЛЫК ҖЕПЛӘРЕ ӨЗЕЛМӘСЕН

Һәр ел саен Дагыстан Республикасының Махачкала шәһәрендә Рәсүл Гамзатовның туган көнендә, ягъни 8 сентябрьдә, "Ак торналар" дип аталган әдәби бәйрәм уза. Быел әлеге чара шагыйрьнең 85 еллыгына багышланды. Бирегә Россия Федерациясенең күп кенә республикаларыннан һәм өлкәләреннән язучылар килгән иде. Россиянең язучылар делегациясен Россия Язучылар берлеге рәистәше Станислав Куняев һәм берлек идарәсенең беренче секретаре Геннадий Иванов житәкләде. Әлеге төркемдә шулай ук Татарстанның халык шагыйре, Россия Федерациясенең дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харис та бар иде.

### МӘШҺҮР ҖЫРЧЫ ВАРИСЛАРЫ

Хәйдәр Бигичев исемендәге конкурста Казан музыка училищесы, Әлмәт музыка колледжы, Казан дәүләт консерваториясе, Уфа сәнгать училищесы, Уфа дәүләт мәдәният академиясе, Чуваш дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты студентлары катнашты. Гала-концертта беренче бүләк Казан музыка училищесы укучысы Г. Шәйхулловага һәм Уфа сәнгать училищесыннан С. Макаевка, икенче бүләк Казан дәүләт консерваториясенең чыгарылыш курсы студенты Э. Сәлаховага һәм Уфа дәүләт сәнгать академиясеннән Р. Сәйфетдиновка тапшырылды.

### СЕЗОН АЧЫЛДЫ

Татарстан дәүләт кыллы квартеты да яна сезонын ачып җибәрде. Коллектив репертуарында төрле илнең күренекле классиклары белән беррәттән, татар композиторлары әсәрләренә зур игътибар бирелә. Моннан тыш Зур концерт залы директоры, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мансур Шиһапов инициативасы белән хәзер квартет ай саен бер татарча концерт куя. Ягъни классик музыка белән таныштыру өстенә алар яшь буын арасында татар

композиторлары әсәрләрен популярлаштыру кебек изге эшне дә алып барачак.

Коллектив яна сезонда «Композитор Мирсәет Яруллин» (5 ноябрь), «Сәйдәшстан» (2 декабрь), «Татарстан музыкасы мәдәниятенә нигез салучылар» (25 февраль), «Габдулла Тукайга багышлау» (24 апрель) һ. б. концерт программаларын тәкъдим итәчәк.

### ЯҢА УРЫНБАСАР

Мәдәният министры урынбасары вазифасына Гөлшат Нигъмәтуллина билгеләнде. Элек ул социаль-мәдәни эшләр һәм муниципаль мәдәният учреждениеләре белән хезмәттәшлек бүлеге башлыгы вазифасын башкарган. Яңа урынбасар 1968 елда Казанда туган. Казан дәүләт консерваториясен («Музыковедение» белгечлеге буенча) һәм Казан дәүләт финанс-икътисад университетын тәмамлаган. Башта укыту эше белән шөгыльләнгән, аннары «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясендә эшләгән. Мәдәният министрлыгында 1993 елдан хезмәт итә.

### БЫЕЛГЫ ЛАУРЕАТЛАР

Әлмәттә «Татнефть» ААЖ булдырган Сажидә Сөләйманова исемендәге бүләккә быел Сарманнан Дамир Гарифуллинның «Язганнарны укып, уйлар тукып», «Герантау итәгендә» дигән китаплары, Балтачтан Гарифҗан Мөхәммәтшинның «Робагыйлар бакчасы», Казаннан Асия Юнысованың «Сагынырсың әле», «Алмагач песие» дигән китаплары лаек дип табылды.

Казаннан Марат Закиров «Кояшлы төн», Фирүзә Жамалетдинова «Догалы корт», Рифә Рахман «Айлы күлдәвекләр» дигән китаплары өчен кызыксындыру бүләгенә ия булды.

Моннан тыш ун студент Сөләйманова стипендиатлары булдылар.

### АФӘРИН!

"Мисс Милләт—2008" халыкара бәйгесендә 11 яшьлек Татарстан кызы беренче вице-мисс титулына лаек булган. Бразилиянең Куритиба шәһәрендә узган әлеге чарада катнашучылар үзләре һәм туган илләре хакында сөйләп, жюри әгъзаларына милли киемнәрне тәкъдим итәргә тиеш булган. Инде үзебездә үк шактый осталыкларын күрсәтеп, "Татарстанның кечкенә принцессалары" бәйгесендә җиңгән Лия Латыйпова бу юлы да сынатмаган. Аның башкаруындагы җыр исә талантлар бәйгесендә генә түгел, гала-концертта да яңгыраган.

### ОНЫТЫЛМАС ШӘХЕСЛӘР

Г. Тукайның әдәби музеенда язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе Борһан Шәрәфнең тууына 125 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә узды. Кичәдә бертуган Шәрәфләр тормышы турында «Фаҗига» китабын язган галим, тарих фәннәре докторы, профессор Рәмзи Вәлиев һәм Шәрәфләрнең туганнары катнашты. Музейда Шәрәфләр тормышын һәм иҗатын чагылдырган күргәзмә дә оештырылган иде.

### ИСКӘ АЛУ

25 октябрьдә күренекле язучы Нурихан Фәттахның тууына 80 ел тулды. Әлеге уңайдан ТР Милли китапханәсендә аның китапларын үз эченә алган «Хезмәт һәм талант бердәмлеге» дип исемләнгән күргәзмә ачылды.

Күргәзмәгә куелган китаплар арасында Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур», «Сызгыра торган уклар» романнары, «Шәҗәрә», «Язык богов и фараонов» дигән тарихи-лингвистик тикшеренүләре, балалар өчен язылган китаплары да бар.

### НАҖАР НӘҖМИНЕ ОЛЫЛАУ

Башкортстанның Дүртөйле районында халык шагыйре Наҗар Нәҗми истәлегенә багышлап күп кенә чаралар үткәрелде. Мәктәпләрдә, китапханәләрдә Наҗар Нәҗми укулары узды, күргәзмәләр ачылды. Шагыйрьне искә алу кичәләрендә катнашу өчен Татарстаннан шагыйрьләр Роберт Миңнуллин белән Рәдиф Гаташ барды. Район үзәгендәге Н. Нәҗми һәйкәленә чәчәкләр салганнан соң, шагыйрьнең туган авылы Миңештәгә юл тоттылар. Анда Наҗар Нәҗминең йорт-музеенда булдылар һәм аның кабере янында һәйкәл-комплекс ачылды .

### ҖЫРЫМДА ЮАТЫРМЫН

М. Сәлимҗанов исемендәге Актерлар йортында шагыйрь Фәннур Сафинның тууына 60 ел тулу уңаеннан «Җырымда юатырмын» дип исемләнгән искә алу кичәсе узды. Кичәдә шигырьләре, поэмалары һәм шагыйрь сүзләренә язылган җырлар да яңгырады.

Фәннур Сафин Казан телестудиясендә редактор, «Татарстан яшьләре» газетасы, «Ялкын», «Казан утлары» журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшләгән.

Шагыйрь иҗатында мәхәббәт, ватандарлык, яшәү мәгънәсе, үзенең һәм халкының язмышы турында уйланулары чагылыш таба. Ул—«Кеше юлга чыкса», «Сез кемнәр?», «Тынлык», «Күкчәчәк», «Чәчәк гомере», «Яңгыр малае» җыентыклары һәм күпсанлы җырлар авторы да.

Кичәне язучы, "Казан утлары" журналының бүлек мөхәррире Камил Кәримов алып барды.

### ЯҢА ПРЕМЬЕРА

Татар дәүләт «Әкият» курчак театрында Г. Тукайның «Су анасы» әкияте нигезендә

3. Хөснияр язган пьесаны баш режиссер Илдус Зиннуров сәхнәләштерде. Аның музыкасын Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луиза Батыр-Болгари язган, рәссамы—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Валентина Губская. Төп рольне Татарстанның халык артисты Рәмзия Фәйзуллина башкарды.

## ҮЗ ИЛЕНДӘ САНДУГАЧ

Мамадыш шәһәренең мактаулы гражданнары исемлеге тулылана бара. Күптән түгел ул исемгә районның хөрмәтле кешесе—киң күңеллелеге, картаймас рухлы, җор телле булуы белән якташларын сокландырып яшәүче, заманында җитәкче урыннарда эшләгән, 9 шигырь китабы чыгарган (В. Галиев—Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы), туган авылы Иске Комазанда үз акчасына мәчет салдырган, авыл имамына хезмәт хакы түләп торган Вахит Мөхәммәтвәли улы Галиев лаек булды. 9 бала тәрбияләп үстергән, 26 онык сөю бәхетен татыган Вахит агага Мамадышның мактаулы гражданины исемен Гаилә елында бирү дә зур мәгънәгә ия. Шунысын да белдерик: ул—мәшһүр җырчы Миңгол Галиевнең бертуган абыйсы.

## ТУГАН ТӨБӘКТӘ ЯҢА МӘКТӘП

Ульянов өлкәсе Яңа Малыклы районы Иске Төгәлбуга авылында яңа мәктәп бинасы өлгертелде. Ул өлкә губернаторы Сергей Морозов ярдәме белән төзелде. 1 сентябрьдә шул бинаны ачу тантанасына авылга губернатор үзе һәм өлкәнең берничә министры килгән иде. Губернатор үз чыгышында берничә зур татар авылын берләштергән Яңа Малыклы районы халкының эшчән-уңган булуын, азык-төлек җитештерүдә өлкә күләмендә иң алда баруын билгеләп үтте. Мәктәпне ачу тантанасында шул авылда туган язучылардан Лирон Хәмидуллин да катнашты. Митингтан соң алар өлкән сыйныф укучылары белән очраштылар. Язучылар мәктәп китапханәсенә һәм татар теле укытучыларына үз китапларын бүләк иттеләр. Л. Хәмидуллин бу кайтуында туган авылы мәктәбенә үз китапханәсеннән дә шактый өлеш чыгарды: әдип вә галимнәребезнең, шул исәптән тарихчы улы Булат Хәмидуллинның китапларын, Казанда нәшер ителүче кайбер журнал төпләмәләрен тапшырды.

## ИҖАУДА ШАГЫЙРЬ БӘЙРӘМЕ

Ижауда Татарстан һәм Удмуртия язучылар берлекләре әгъзасы Ринат Батталовка 60 яшь, иҗат эшчәнлегенә 30 ел тулуга багышланган "Иҗатым—гомер юлым" дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә уткәрелде. Шагыйрь бәйрәмендә Татарстанның Республика прокуроры Кафил Әмиров, язучы-публицист Шаһинур Мостафин, Удмуртия Язучылар берлегеннән Василий Глушков һ. б. катнашты. Юбилей уңае белән Казан нәшриятларында шагыйрьнең ике—"Гомер учагы" һәм "Кояш исе" исемле китаплары дөнья күрде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебез мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүдәге казанышлары, күп еллар дәвамындагы нәтиҗәле эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры **Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева**, Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, Дуслык ордены белән бүләкләнде.

***

Татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен язучы, "Сүз" нәшриятенең баш редакторы **Мостафин Шаһинур Сафа улы** (Шаһинур Әхмәтсафа) "Фидакарь хезмәт өчен" медале белән бүләкләнде.

***

Татар мәдәниятен, телен һәм милли традицияләрен торгызу, халыкка аң-белем тарату өлкәсендәге нәтиҗәле эшчәнлеге өчен, Екатеринбургтагы М. Гафури исемендәге татар һәм башкорт мәдәнияте региональ җәмгыяте рәисе **Сөфхәт Лотфулла улы Надыйровка** Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

***

2008 елның сентябрь ахырында шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Муллагалиев Сафуан Галәветдин улы** 81 яшендә вафат булды.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татар мәдәнияте зур югалту кичерә. Шушы елның 7 октябрендә күренекле шагыйрь, 1982 елдан Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Харрас Әюп** 63 нче яшендә кинәт вафат булды.

Шагыйрь Харрас Әюп (Харрас Гыйльмегали улы Әюпов) 1946 елның 21 августында Татарстанның Мөслим районы Түреш авылында колхозчы гаиләсендә туган. Түрештә башлангыч белем алып, 1964 елда Күбәк урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Х. Әюп үзенең хезмәт юлын 1969 елда Мөслимдә район газетасында әдәби хезмәткәр буларак башлап җибәрә, соңрак редакциянең авыл хуҗалыгы бүлеген җитәкли. Казанга күчеп килгәч, 1972 елның апреленнән алып 1983 елның декабренә кадәр "Татарстан яшьләре" газетасы редакциясендә эшли. 1983 елдан башлап хезмәтен Татарстан китап нәшриятында дәвам иттерә: башта матур әдәбият редакциясендә редактор була, 1992 елның сентябреннән—шул редакциянең мөдире, ә 1994 елдан—нәшриятның баш мөхәррире. Мәктәптә үк шигырьләр яза башлаган Харрас университетта укыган елларда әдәби иҗат белән ныклап шөгыльләнергә карар итә. "Әллүки" әдәби берләшмәсенә йөреп, тәҗрибә туплый, танылган язучылар белән аралаша. Шигырьләре республика газета-журналларында, "Идел" альманахында, яшь авторларның күмәк җыентыкларында дөнья күрә. Х. Әюп иҗаты 60 нчы елларда татар шигъриятенә килеп кергән яңарышның бер чагылышы буларак бәяләнә. Аның "Ышаныч" дип исемләнгән беренче китабы 1980 елда басылып чыга. Аннан соң бер-бер артлы дөнья күргән "Кояшлы яңгыр" (1983), "Каен балкышы" (1985), "Таң суы" (1987), "Төнге кояшлар" (1989), "Сабыр савытлары" (1992), "Җәяүле буран" (1996), "Көй эзләү" (2001), "Йөз яктысы" (2005) китаплары Х. Әюпне шигърият сөючеләргә сүз тәмен белгән, халык рухын яхшы тойган җитди каләм иясе итеп танытты. Ул үзенең шигырь-поэмаларында халкыбызның уй-кичерешләрен, заманның гыйбрәтле һәм әһәмиятле үзгәрешләрен, үзенең дөньяга карашын чын сәнгать ядкарьләре югарылыгында, күңелләрне кузгатырлык итеп әйтә белә иде.

Харрас Әюпов озак еллар «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы булып торды.

Талантлы шагыйрь Харрас Әюпнең якты истәлеге халык күңелендә мәңге сакланыр.

**З. Р. Вәлиева, И. Р. Метшин, Р. И. Вәлиев, Р. Р. Хәбипов, И. М. Ибраһимов, Д. С. Шакиров, Р. Г. Фәйзуллин.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* **Борынгы төркиләр. Хан анты.** К. Нәфиков *картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Заһид Фәйзи**.

# Яңа китаплар




**Мударрис Валиев.** Визитная карточка. Литературные статьи, эссе-размышления. Казан: Милли китап, “Мәгариф” нәшр., 2008.—144 б. Тиражы—1000 данә.


Әдип Мөдәррис Вәлиевнең бу хезмәте Китапның, гомумән Әдәбиятның тарихи яшәвебездәге урыны, бүгенгесе һәм киләчәктәге язмышы турында уйланулардан гыйбарәт. Матур әдәби телдә ихлас бәян ителгән, тирән гомумиләштерүләргә ия бу китап мәдәни тарихыбыз белән кызыксынучылар өчен кыйммәтле чыганак. “Визитная карточка”—“Мәгариф” нәшриятының “Милли китап” сериясендә чыга торган затлы басмаларның берсе санала ала.




**Илсөяр Иксанова.** Кырык кыл. Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008—239 б. Тиражы—2000 данә.

Бу китапка шагыйрә Илсөяр Иксанованың төрле елларда иҗат ителгән иң яхшы шигырьләре тупланган. Моңа кадәр дөнья күргән “Ышанасы килә”, “Кышкы канәферләр”, “Син—язган язмышым” китапларының сүзтезмәсеннән тыш, җыентыкта соңгы елларда язылган яңа шигырьләр дә урын алган.

Китапның “Кырык кыл” дип аталуы да аерым мәгънәгә ия. Җан кыллары тартылудан туган шигырьләр авторның кырык еллык гомеренә үзенә күрә бер йомгак та. Китапның мөхәррире—Харрас Әюпов. Рәссамы—Алсу Тимергалина.



Заһид Фәйзи

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)